ISSN 0206–4189
Индекс 73210

12+

# Казан утлары

8.2015





«Республиканың иң яңа тарихы катлаулы шартларда башланды. Татарстанның дәүләт суверенлыгы турындагы Декларация, Татарстан Республикасы Президенты вазифасын кертү, Татарстан Республикасы гомумреспублика референдумы нәтиҗәләре буенча кабул ителгән Конституция аерым роль уйнады».

**Рөстәм МИҢНЕХАНОВ,**
*Татарстан Республикасы Президенты*
*вазифаларын вакытлыча башкаручы*

*(Барлык чакырылышлар Татарстан Республикасы депутатларының һәм җәмәгатьчелегенең Татарстанда парламентаризмны торгызуның 25 еллыгына багышланган Дәүләт Советы сессиясендә ясаган чыгышыннан. 30 май, 2015 ел.)*

КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЯҢА ДӘҮЛӘТЧЕЛЕГЕНӘ — 25 ЕЛ**

Газинур МОРАТ. Кош хокукы кирәк кешегә. *Шигырь.* ....3
«Республикабыз язмышы өчен үзебез җаваплы — мөстәкыйльлек менә шул инде ул». *(ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИН белән Илфак ИБРАҺИМОВ әңгәмәсе).* ....4
Индус ТАҺИРОВ. Автономиядән мөстәкыйльлеккә таба. ....10

**ТУФАН МИҢНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА — 80 ЕЛ**

Минтимер ШӘЙМИЕВ. Туфан белән горурлану, иҗатына соклану көчәя бара. ....15

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рамил ХАННАНОВ. Ничә Туфан бәхәсләшә аларда... ....16
Туфан МИҢНУЛЛИН. Хат башы — яз каршы. *Баян.* ....65
Ул бит безнең күңел туфаны. *(Ш.Галиев, М.Әгъләмов, Г.Рәхим, Р.Миңнуллин, А.Юнысова, Ф.Тарханова, Л.Лерон, Р.Рахман, Л.Шәех, Ф.Гыйләҗев шигырьләре).* ....87
Туфан МИҢНУЛЛИН. Робагыйлар. *(М.Галиевнең кереш сүзе белән).* ....95

*100нче бит:* Туфан МИҢНУЛЛИН. Татарның әхлакый кодексы. ....100

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Туфан МИҢНУЛЛИН. Бетсен ирләр, яшәсен хатыннар! *Ике пәрдәле комедия.* ....17
Туфан МИҢНУЛЛИН. Го-о-о-ол! *Сатирик комедия.* ....40
Туфан МИҢНУЛЛИН. Әбрәкәй. *Комедия.* ....47

**ИСТӘЛЕКЛӘР**

Павел ЛОХАНОВ, Фәрит БИКЧӘНТӘЕВ, Ренат ӘЮПОВ, Фаил ИБРАҺИМОВ, Рөстәм ГАЛИЕВ, Олег ХАНОВ, Ләйләгөл МИНАЕВА мәкаләләре. ....101
Әхтәм ЗАРИПОВ. Яшьнәп яшәгән яшьтәшем ядкаре. ....141
Өмет хатлары. *(Т.Миңнуллинның мәхбүсләр белән язышкан хатлары).* ....160
Фәйрүзә МӨСЛИМОВА. Энә түгел, китап! ....167
Рашат НИЗАМИ. Туфан дәвам итә... ....179
Әлфия МИҢНУЛЛИНА-ЮНЫСОВА. Туфан кызы язмалары. ....181

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Разил ВӘЛИЕВ. Туфрактан яралган Туфан. *(Туфан Миңнуллинның гамәл дәфтәреннән кайбер сәхифәләр).* ....114
Илфак ИБРАҺИМОВ. Мин белгән Туфан. ....120
Рәдиф СӘГЪДИ. Драматург-режиссёр. ....135
«Шәймиев чоры татар тарихына кереп калачак» *(Туфан МИҢНУЛЛИН белән Нурсөя ШӘЙДУЛЛИНА әңгәмәсе).* ....153

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА. «Төш»тәге серләр *(Т.Миңнуллинның «Төш» спектакленнән соң уйланулар).* ....169
Мөхәммәтгали АРСЛАНОВ. Туфан Миңнуллин драматургиясе. ....177

*Шаян сәхифә.* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ....185

«Казан утлары» архивыннан. ....98
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

татмедиа

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*
**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*
**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары — 222-09-83 (өст. 1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст. 1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст. 1268).*
**Факс** — (843) *222-09-83 (өст. 1612).*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 31.07.2015, график буенча 31.07.2015.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-2081. Тираж 4010.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2015 ел

Газинур
Морат



## Кош хокукы кирәк кешегә

Хакны әйтергә дә хокук кирәк,
Әйтим дисәң ярып турысын,
«Птичье право» дигән гыйбарәсе
Искә килеп төшә урысның.

Һава ярып, әнә кошлар оча,
Кош тоткандай яңа күзләрең.
Күкне иңләп очкан кошка баксаң,
Искә килеп төшә үз хәлең.

Үз хәлеңне күршеләрдән сора —
Ут-күршеләр яши күршеңдә...
Хакны әйтергә дә хокук кирәк,
Кош хокукы кирәк кешегә.

Ут-күршеләр әнә ут салганнар
Тарихыңа синең, телеңә.
Ничә гасыр тарих пыскып ята, —
Казынабыз бүген көлендә.

Хакны әйтергә дә хокук кирәк,
Хакны әйтүчеләр илдә бер.
Кошлар хокукына ия жаннар
Кеше хокукына иядер.

Ирек яуларга да хокук кирәк,
Сорап алып булмый ирекне.
Кошлар хокукына ия халык —
Бәйсез халык — димәк, иректе!

Һава ярып, әнә кошлар оча,
Син очасың бары төшеңдә.
Кеше булырга да хокук кирәк,
Кош хокукы кирәк кешегә.

# «РЕСПУБЛИКАБЫЗ ЯЗМЫШЫ ӨЧЕН ҮЗЕБЕЗ ҖАВАПЛЫ — МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК МЕНӘ ШУЛ ИНДЕ УЛ»



*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе **Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин** белән «Казан утлары» журналының баш мөхәррире **Илфак Ибраһимов** әңгәмәсе.*

**— Татар халкы тарихындагы иң кызыклы, әһәмиятле һәм күренекле вакыйгалар үзебезнең дәүләтчелегебезне торгызу белән бәйле. Егерменче гасыр азагында күзәтелгән катлаулы сәяси һәм иҗтимагый вазгыятьтә бу ачык чагылды. Сез үзегез дә 90нчы елларда булган вакыйгаларның шаһиты, аларның эчендә кайнаган сәясәтче, дәүләт эшлеклесе. Дәүләтчелегебезне торгызу юнәлешендә бу елларда ирешелгән төп нәтиҗәләрне билгеләп үтсәгез иде...**

— 1990 елларда безнең җәмгыятьнең сәяси активлыгы нинди дәрәҗәгә җитүен хәтерлисездер. Ә Татарстанны дәүләт буларак төзүгә карата нинди генә карашлар юк иде?! Республиканың шул елны сайланган 12нче чакырылыш Югары Советын гына карагыз! Ана кискен ярышта, көрәштә сайланган депутатлар килде. Алар бар нәрсәне дә тамырдан үзгәртергә әзер иделәр һәм үзгәрешләрне кичекмәстән уздыру теләге белән яндылар. Сәяси кризис үтә кискен иде: бер яктан — тулы мөстәкыйльлек, хәтта Россиядән аерылып чыгуны таләп итүче радикаль татар фиркаләре вәкилләре, икенче яктан — элеккеге совет-партия хакимияте мирасыннан бер селтәнүдә арынырга өндәгән «Народовластие» төркеме депутатлары.

Мондый шартларда, вакыты-вакыты белән, республиканың киләчәге кыл өстендә калган чаклар да булгалады. Югары Совет утырышлары радио һәм телевидениедә турыдан-туры тапшырыла иделәр. Республика шул утырышлардагы бәхәсләр, дискуссияләр белән яшәде. Барлык депутатларны да халык таный иде. Яклыйммы яисә инкарь итәме, килешәме яисә каршы киләме, әмма депутат үзенең нинди генә фикерен белдермәсен — бу республика өчен мөһим вакыйгаларда катнашу иде. Ул еллардагы Югары Совет кайнап торган казанны хәтерләтте. Микрофонга 10-12 кеше чиратка тезелә иде. Ләкин бу тәҗрибәнең республикага киләчәктә файдасы тиде. «Татарстан» һәм «Народовластие» төркемнәре якынча тигез булганлыктан, компромисска килми торып карар кабул итү мөмкин түгел иде. Әмма безнең барыбыз өчен дә бер генә нәрсә уртак иде — республикада һәм тулаем илебездә демократик, хокукый дәүләт төзи башлау теләге.

Хәл шулкадәр катлаулы иде ки, хәтта татар депутатларының бер өлеше Милли Мәҗлес дип аталган милли парламент оештырды. Аның башында Тәлгать Абдуллин торды. «Күләгә» хөкүмәте дә бар иде. Әлбәттә, әлеге оешмаларның хокукын беркем дә юридик яктан танымады, ләкин аларның фикердәшләре шактый күп булды. Аларга Россия төбәкләрендә яшәүче татарлар да теләктәшлек белдерде.

Катлаулы мәсьәләне хәл итү өчен, без төрле төркемнәргә керүче депутатларны

жыйдык. Бер якта — «Народовластие» вәкиле Иван Грачёв, каршыда — Милли Мәҗлестән Тәлгать Абдуллин һәм Фәүзия Бәйрәмова, шулай ук Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев һәм мин. Ә депутатлар таралышкач, без Шәймиев белән бергә фикер алыша идек. Шулай итеп, сәяси процесс тукталып тормады. Без Минтимер Шәрипович белән бер йортта яши идек. Кичке уннарда ул миңа эндәшә: җәяү кайтыйк, ди, ял итүебез булыр. Ә кайтышлый тагын баш ватабыз: нишләргә? Ничек дөресрәк булыр? Чөнки һәр як та үзенчә хаклы бит. Милли җанлы татар депутатларының «тел онытылып бара, милли мәктәпләр бетте, мәдәниятнең милли үзенчәлекләре югала» дигән сүзләре, чынлап та, дөреслеккә туры килә иделәр бит. Ләкин шул ук вакытта моннан радикаль нәтиҗәләр ясау җәмгыятьне куркыныч упкынга этәргәнен дә күреп тордык — Россиядән аерылып чыгуны таләп итүчеләр аны «күрше дәүләт» дип атый башладылар. Руслар пошаманга төште: президент һәм парламент шундый кискен позициягә күчмәсме, янәсе... Ләкин республика президенты да, җәмгыятебез дә, парламент та фаҗигале хәлләргә алып бара торган капма-каршылык юлына төшмәде. Ә бит тыныч тормышка нигезләнгән потенциалы да, шулай ук җимергеч куәте дә гадәттән тыш зур иде безнең җәмгыятьнең.

Аннан соңгы чирек гасыр вакыт ачык күрсәтте: татар халкы, Татарстан халкы мөстәкыйльлеккә ирешүнең канкойгыч радикаль юлын түгел, ә сөйләшү-килешүләргә нигезләнгән цивилизацияле тыныч юлын сайлап, үзенең сәяси өлгергәнлеген раслады. Татарстанның мөстәкыйльлеге турындагы мәгълүм Декларация кабул ителгәннән соң, республикабыз, татар халкы үз дәүләтчелеген кору һәм ныгыту өчен зур мөмкинлекләргә ирешге.

Аның беренчесе һәм иң әһәмиятлесе — Татарстан Конституциясе. 1992 елда кабул ителгән Конституция өр-яңа шартларда үзебез корган дәүләтнең үзебез язган Төп законы булды. Хәтерегездәдер, совет чорында РСФСРга кергән барлык республикаларның конституцияләре, игезәкләр кебек, бер-берсенә охшаш иде. Аларда республикаларның атамалары гына төрле. Ә безнең төп закон Татарстанның демократик дәүләт булуын дөньяга танытты — бу татар халкының берничә гасырлык хыялы иде.

Әлбәттә, соңгы 25 елда Татарстан дәүләтчелеген торгызу юнәлешендә ирешелгәннәр турында сөйләгәндә, бу вазгыятьнең фәкать формаль ягы белән генә чикләнергә ярамый. Әйе, Конституциябез бар, Декларация һәм референдум нәтиҗәләре бар, Россия Федерациясе белән үзара вәкаләтләрне бүлешү турында шартнамә бар, флаг, герб, гимн кебек дәүләт символлары бар. Ләкин дәүләтчелекнең асылын реаль мөмкинлекләр, эш-гамәлләр, социаль-икътисади казанышлар, мәдәниятнең, мәгарифнең, сәнгатьнең янарыш кичерүе дә тәшкил итә әле. Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстанның чит илләрдәге һәм Россия төбәкләрендәге вәкиллекләре, 2013 елгы Универсиада, әле генә уңышлы үткәрелгән Су спорты буенча дөнья чемпионаты, күпсанлы халыкара сәнгать фестивальләре, куәтле нефть химиясе, машина һәм авиатөзелеш сәнәгате — болар барысы да дәүләтчелекнең мөмкинлекләрен һәм дәрәҗәсен күрсәтә.

**— Татар иле дигәндә, без дәүләт буларак Татарстан Республикасын да, бөтен дөньяга сибелеп яшәүче берничә миллион милләттәшебезне дә күзаллыйбыз. Асылда Татарстан дәүләт эчендәге дәүләт булып тора. Шуңа күрә мондый шартларда безнең мөстәкыйльлегебезне үз кануннарыбыз гына түгел, ә Россия Конституциясе, аның кануннары да гарантияләргә тиеш. Ә чынбарлыкта ничек? Татарстанның мөстәкыйльлеге тарихка вакытлы гына күренеш булып кереп калмасмы?**

— Дөрес игътибар иттегез: дәүләт эчендәге дәүләт. Федератив дәүләт унитар дәүләттән шундый төзелеше белән аерыла да инде. Моннан егерме биш ел элек Югары Советта иң күп куертылган сорауларның да берсе республиканың хокукый субъектлылыгы турында булды — Татарстан Россия Федерациясенә керәме, юкмы? Без ачыктан-ачык игълан иттек: беркая да китәргә җыенмыйбыз. Республиканың икътисади, мәдәни, интеллектуаль, аграр һәм кадрлар куәтен исәптә тотып, көн тәртибенә Советлар Союзы составында союздаш республика статусы таләбе генә куелды.

Мөстәкыйльлек вакытлыча күренеш түгелме дигәннән, шуны әйтәсем килә: икътисади потенциалы ныгыган саен, Татарстанның сәяси абруе да үсә бара. Республикабызның дәүләт статусы Мәскәүдәге кайбер сәяси клоуннарның Россия субъектларының

барысын да бер төрле губерниягә әйләндерү турындагы демагогияләрен нигезсез итә. Нык үсеш алган һәм даими тотрыклы системага салынган, инновацияләргә нигезләнгән, бөтен федерациягә үрнәк булган сәнәгый, фәнни, мәдәни инфраструктурасы булган Татарстанны дөньяда яхшы беләләр, Россия Федерациясе составындагы республика буларак таныйлар. Аның дәүләт органнары белән исәпләшәләр.

Без — үзенә нинди законнар кирәклеген үзе билгели торган федератив субъект. Россиянең уртак хокукый кырына керүне без баркайчан да тулысынча кабатлау яки тәңгәлләштерү буларак кабул итмәдек. Федерация субъектларының барысында да бертөрле законнар була алмый.

Бүгенге катлаулы икътисади кризис һәм кискен халыкара сәяси шартларда федераль үзәкне шактый күп вәкаләтләрдән азат итәргә була. Ул чакта үз хаталарың өчен Мәскәүне тәнкыйтьли алмыйсың инде. Минемчә, бүген Россиядә мондый системага (Европада аны субсидиарлык принцибы дип атыйлар — хакимият барлык дәрәҗәдә бөтен көченә һәм нәтиҗәле эшли) күчү мөмкинлеге бар. Ләкин, кызганычка каршы, бу процесс озаккарак сузылды.

**— Сентябрь аенда үтәчәк сайлаулардан соң республика җитәкчесенең атамасы үзгәрә. Бу — Татарстанда Президентлык институты бөтенләй бетә дигән сүзме?**

— Сентябрьдә без Татарстан Президентын сайлаячакбыз. Ә президентлык институтының да, республиканың иң югары дәүләт җитәкчесе атамасының да язмышы турында федераль үзәк белән сөйләшүләрнең тәмамланганы юк. Әлеге сөйләшүләрдә безнең позиция Россия Конституциясенә, Татарстан Конституциясенә, Россия белән Татарстан дәүләт хакимият органнары арасындагы Килешүгә нигезләнә. Шуңа күрә Татарстанның җитәкчесе башкача аталачак икән дип кистереп әйтергә ашыкмагыз!

**— Татарстан — Шартнамә нигезендә федераль үзәк белән вәкаләтләрне реаль бүлешкән бердәнбер республика. Бу вәкаләтләрнең язмышы киләчәктә ничек булыр икән?**

— Россия Федерациясе дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары арасында вәкаләтләрне үзара бүлешү турында 1994 елда кабул ителгән һәм 2007 елда яңартылган Шартнамә Россия тарихында яңа сәяси чорның башлануын аңлата, дияр идем, чөнки мондый хәлнең әлегә кадәр булганы юк иде. Бу тарихи документ реаль федератив дәүләтнең ничек төзелергә тиешлеген ачык күрсәтте.

Шартнамәдә сүз Татарстанга вәкаләтләр тапшыру турында түгел, ә аларны үзара бүлешү һәм бер-беренә тапшыру турында бара. Ул буйсыну-буйсындыруга янсә вертикаль принципка түгел, ә симметриялелек принцибына нигезләнгән. Кызганыч, документның бу гадәттән тыш мөһим ягына бүген игътибар итүче юк диярлек.

Шартнамә республика һәм федераль үзәк мәнфәгатьләрен килештерүче, Татарстанның милли-тарихи үзенчәлекләрен исәпкә алучы универсаль коралга әйләнде. Ул Татарстанда яшәүче барлык халыкларның һәм милләтләрнең үсеше һәм рухи яңарышының хокукый нигезе булып тора.

Татарстанның милли-дәүләтчелек төзелешен реформалавы, социаль-икътисади үзгәрешләр буенча мөстәкыйль курста торуы башта кискен тәнкыйтькә дучар ителде. Соңрак исә без кулланган яңалыклар федераль үзәк тарафыннан кабул ителде һәм башка субъектлар арасында алдынгы тәҗрибә буларак таратылды. Халыкны адреслы социаль яклау белән дә, исерткеч эчемлекләр җитештерүгә дәүләт монополиясе урнаштыру белән дә, тузган торакны бетерү программасы белән дә, җинаятьчелеккә каршы көрәш белән дә шулай булды.

Шартнамә 2007 елда яңартылды һәм федераль закон белән расланды. Элек кайбер федераль министрлыклар, безнең таләпләргә карамастан, төрле сылтаулар табып, Шартнамә таләпләрен үтәми кала алалар иде. Ә Федераль закон барысы өчен дә мәҗбүри: Татарстан өчен дә, федераль министрлыклар өчен дә. Шулай итеп, җаваплылык ике якка да төшә.

**— Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов кайчандыр: «Акчасы кайсы телдә сугылса, кайсы телдә пичәтләнсә — дәүләт теле, дәүләт үзе шул була», — дип язган иде. Мөстәкыйльлек турында өндәмәләр алгы планга куелган вакытларда Татарстанның**



*Халкыбыз — таянычыбыз. Казан, Ирек мәйданы. 1991 ел.*

**үз акча бирәмлеген булдыру турында тәкъдимнәр ишетелгәли иде. Сезнеңчә ничек, бу таләп хәзер актуаль була аламы?**

— Яшермим, ул вакытларда да мин мондый фикерләргә каршы булдым. Дәүләтчелекне бары тик милли-региональ акча берәмлеге кебек формаль күрсәткеч белән генә аңлату һич дөрес түгел, минемчә. Федератив дәүләт шартларында төбәкләрнең үз акча берәмлеге дигән нәрсәне бөтенләй күз алдына китереп булмый. Бердәм сәүдә-икътисад, бердәм хокукый кыр... һәм кайсыдыр субъектның үз акча берәмлеге — бу бернинди логикага да сыймый, моның бернинди хаҗәте дә юк. Аннары, карагыз әле, бөтен дөньяда глобальләшү процессы бара, Европа илләренең абсолют күпчелеге уртак валютага күчте, ләкин берсе дә финанс ясәсә сәяси мөстәкыйльлеген югалтмады — барысы да милли дәүләтләр буларак үсүләрен дәвам итәләр. Ахыр чиктә, камилләшкән товар әйләнеше өчен валютаның, дәүләт облигацияләренең, компанияләр акцияләренең, банк вексельләренең һәм башка кыйммәтле кәгазьләрнең нинди телдә язылган булуы мөһим түгел.

**— Татарстан — Россиянең иң куәтле донорларының берсе. Бу үзебез эшләп тапканны күпләп бүлешү, үзебезгә тигән өлешне чикләү түгелме?**

— Чынлап та, Татарсан гадәттән тыш икътисади куәткә ия. Бездә елына 1,5 трлн. сумлык товар җитештерелә һәм хезмәт күрсәтелә. Республиканың 2015 елгы бюджетының керем өлеше 174 млрд сум тәшкил итә. Федераль бюджетка ел саен кертүкән өлешебез бик зур. Әлбәттә, без яхшы аңлыйбыз: Россия белән Татарстан арасындагы Шартнамә нигезендә федераль үзәккә тапшырылган вәкаләтләрне үтәү өчен республика үз керемнәренең шактый зур өлешен Мәскәүгә биреп барырга тиеш. Әмма шунысы бар: вәкаләтләрне финанс белән ныгыту — бер хал, ә менә федераль үзәкнең әлеге вәкаләтләрне нәтиҗәле үтәве — икенче нәрсә. Бу юнәлештә эшлисе бар әле, федераль үзәк белән республика арасындагы финанс-бюджет мөнәсәбәтләрен камилләштерү таләп ителә.

**— Татарстан елына йөзәр миллион тонна нефть чыгарып ятканда, шәһәрләребез төссез, авылларыбыз юлсыз, газсыз иде... Шөкер, газлы булдык. Әмма бик күп мәсьәлә әлегәчә хәл ителеп бетмәгән: эш һәм торак белән тәэмин итү, юллар салу, эшкуарлыкка шартлар тудыру һәм аларга дәүләт ярдәме күрсәтү, экологик хокукларны тәэмин итү һ.б.**

— Алай димәгез! Татарстан беренче чиратта нәкъ менә нефть ярдәмендә бүгенге

казанышларга ия булды бит — моны танымау мөмкин түгел. Кайбер мәсьәләләр, чынлап та, әлегә хәл ителеп бетмәгән, ләкин тулаем алганда, Татарстанда халыкның ихтыяжларын канәгатьләндерү өчен бик күп эш башкарыла. Шәхсән мин үзем кешеләрнең мәнфәгатьләрен телевизордан карап, радиодан ишетеп яисә газеталардан укып кына белмим. Республика җитәкчеләренең кайсысын гына алма — барыбыз да даими рәвештә районнарга, шәһәрләргә чыгып йөрибез, коллективлар белән очрашабыз, кешеләр белән аралашабыз, урыннардагы җитәкчеләр белән вазгыятьне анализлыйбыз. Мәсәлән, 2014 елны Татарстанның бишенче чакырылыш Дәүләт Советына сайлауларга әзерлек барган көннәрдә без халыктан берничә мең теләк-тәкъдим кабул иттек. Алар барысы да тикшерелде, өйрәнелде, күбесе үтәлде яки үтәлеп бара. Соңгы елларда Татарстанда йөзләгән Мәдәният йорты, клуб, фельдшерлык-акушерлык пункты, мәктәп, балалар бакчасы, тораклы полиция бүлеге бинасы, бихисап Спорт сарае һәм мәйданчыклары ачылды һәм ремонтланды. Һәрбер авылны район үзәге белән тоташтыручы юллар салу программасы уңышлы үтәлеп килә. Торак төзелеше буенча Татарстан бөтен илдә алдынгылардан санала. Аерым категориягә кергән кешеләрнең чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, кече мәйданлы яисә арендага бирелә торган фатирлар салу күләмен арттыру планлаштырыла. Шул ук вакытта социаль ипотека программасы буенча да ел саен йөзәрләгән гаилә фатир ала.

Эш белән тәэмин итү һәм эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләрен республика җитәкчелеге һәрвакыт игътибар үзәгендә тота. Әйе, илдәге финанс-икътисади кризис шартларында кайбер предприятиеләр эшләүчеләр санын киметергә мәҗбүр. Ләкин эшсезлек дәрәҗәсе алай ук кискен тормый әлегә. Киресенчә, күп кенә урыннарда кытлык күзәтелә. Аеруча эшче һөнәрләренә ихтыяҗ зур. Бөтен кешегә юрист яки икътисадчы булырга димәгән ләбаса!

Тагын шунысы бар: бездә эшкуарлык өчен шартлар тудырылган. Эшлә генә! Үзеңнең кече яисә урта бизнесыңны оештырыр өчен районнарда индустриаль парклар зур мөмкинлекләр тудыра, анда үз эшен башлап җибәргән эшкуарлар салымнарның күбесеннән азат ителә. Шулай ук авыл җирендә фермерлык, гаилә фермасы, шәхси ярдәмче хуҗалык кебек формада эшләүчеләргә дә дәүләт тарафыннан ярдәм итәргә тырышабыз.

**— Дәүләтчелегебезнең төп билгесе — ана теленең дәүләт теле булуында. Шунда ук аның белем һәм фән теле, әдәбият һәм сәнгать теле булуы өчен дә хокукый нигезләр кирәк. Берничә чакырылыш Дәүләт Советы депутаты булган Туфан ага Миңнуллин, башка милли зыялыларыбыз телебезне мәктәпләргә, милли мәгариф стандартларына бәйле дип тәкрарлап килделәр. Сезнең белән бу әңгәмәбез август аенда, укытучыларның традицион август киңәшмәсе үткән көннәрдә басылып чыгачак. Милли мәгарифне саклап калу, үстерү буенча алда нинди хокукый адымнар ясалыр?**

— Татарстанда тел сәясәте хакимиятнең барлык тармакларының — Президентның да, Министрлар Кабинетының да, Дәүләт Советының да — игътибар үзәгеннән төшкәне юк. «Татарстан халыкларының телләре турында»гы законны без 1992 елда ук кабул иттек. Ә 2004 елда республика парламенты әлеге закон нигезендә «Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм башка телләр турында» закон кабул итте. Республикада 2008 елда Дәүләтнең милли сәясәте концепциясе гамәлгә кертелде. Бу юнәлештә дәүләт программаларын үтәр өчен республика бюджетыннан ел саен бик зур күләмдә акча тотыла. Бер генә мисал китерәм. Күптән түгел, июль башында гына, республиканың ике телдә иң уңышлы эшләп килүче 50 балалар бакчасына берәр миллион сумлык һәм егермесенә бишәр йөз мең сумлык грантлар тапшырылды.

Дәүләт Советы, гомумән, татар теленең дәүләт теле буларак үсешен законнар белән тәэмин итү юнәлешендә күп эш башкара. Бу аңлашыла да, чөнки парламентта соңгы егерме биш ел эчендә милли әдәбият һәм сәнгатебезнең күренекле вәкилләре эшләде һәм эшләп килә: Сез телгә алган Туфан Миңнуллин, шулай ук Разил Вәлиев, Ренат Харис, Роберт Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим...

Әлбәттә, без татар халкының киләчәген милли мәгарифне үстерү, милли мәктәпләрне саклап калу белән бәйләп карыйбыз. Шуңа күрә федераль үзәкнең

милли үзенчәлекләрне юкка чыгаруга илтә торган инициативалары, гамәлләре бездә зур борчылу тудыра. Бердәм дәүләт имтиханнарын мәктәп укучыларының бары тик рус телендә генә тапшыруы белән дә, югары уку йортларында татарча белем алу мөмкинлеге булмау белән дә без килешә алмыйбыз. Хәл шуна барып житте ки, татар теле буенча фәнни диссертацияләрне хәзер русча яклаталар — эшмени бу?!

Минемчә, татар теле һәм әдәбияты буенча сыйфатлы укытучылар әзерләү дә гаять кискен проблема булып тора. Башкалабыз Казан университетларында татар педагогик кадрлары әзерләнми хәзер, андый факультетлар Чаллы белән Алабугада гына калды. Шуна күрә Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиевнын Милли педагогика институты зарурилыгы турындагы фикере белән мин тулысынча килешәм. Сыйфатлы һәм әзерлекле педагоглар булдырмый торып, мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытуны да яхшыртып булмаячак, татар теленен гомуми кулланылыш дәрәҗәсендә популярлыгы да үсмәячәк.

**— Сез рәсми чыгышларыгызда, очрашуларда еш кына Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Галимҗан Ибраһимов исемнәрен атыйсыз... Гаиләгез белән театрларда еш күренәсез. Парламент Рәисенең, гомумән, китап укырга, әдәбият яңалыклары белән танышып барырга вакыты каламы?**

— Әлбәттә, мин депутат язучыларнын иҗаты белән яхшырак таныш, чөнки алар миңа якынрак бит. Классик әдипләр турында әйтеп тә тормыйм, аларнын фикерләре, нинди генә чор булуга карамастан, һәрвакыт актуаль булып кала бит. Театр карап та, бүгенге язучыларнын әсәрләрен укып та мин иҗатчыларның нәкъ менә шул сыйфатына игътибар итәм. Очрактан файдаланып, шуны әйтер идем: «Казан утлары» журналы татар әдәбиятын пропагандалауга да, язучыларыбызны барлауга да, милли әдәбият әсәрләрен саклап калуга да бик зур өлеш кертә. Бу матур сүзләр минем фикер генә түгел. Ул — татар халкынын искиткеч зур хәзинәсе.

**— Зур рәхмәт, Фәрит Хәйруллович! Сездә тормыш тәҗрибәсе дә, һөнәри, акыл тәҗрибәсе дә муллан. Шуларны китап итеп язып, киң катлау укучылар белән уртаклашасыгыз килмиме?**

— Дөресен генә әйткәндә, нинди дәрәҗәдә тәҗрибәм бар икән — мин аны яшереп, кайчан да булса мемуарлар язармын дип җыеп ятмыйм. Язган китапларым, мәкаләләрем шактый. «Татарстан Республикасы: иң яңа тарих. Вакыйгалар. Комментарийлар. Бәяләр», «Әтием турында хатирә», «Мөхәммәтшин. Беренче чыганак» һәм башкаларның барысында да күпмедер күләмдә минем тормыш юлым, дөньяга карашым, тәҗрибәм чагылган. Ә киләчәк турында сөйләгәндә, кем белгән, бәлки хатирәләр язылыр.

**— Адәм баласы кем генә булмасын, аның язмышы туган халкы белән бәйләнгән. Һади Такташның «Җир уллары трагедиясе»ндәге Кабил: «Халкымның язмышында мәңгелек михнәт күрәм, кайдадыр очмак булам да, юл табалмый интегәм», — дип гаҗизләнә. Халкыбыз һәм республикабызның соңгы чирек гасырда ирешкәннәре үз юлыбызны табуны дәлилли кебек. Тагын 25 елдан Татарстанның киләчәген ничек күз алдына китерәсез?**

— Купшы сүзләр сөйләп тормыйм. Үз илемне, республикамны, халкымны яратучы һәм хөрмәт итүче кеше буларак, Татарстанның киләчәген ничек күз алдына китерә алам инде мин? Әлбәттә, гөрләп яши торган республика, тормыш дәрәҗәсе мул булган халык, дус һәм тату гомер кичерүче милләтләр. Боларның барысына да бүген нигез салына, ул нигез нык, ышанычлы булыр, өметләребез акланыр дип ышанам.

**— Әңгәмәгез, ихлас җавапларыгыз өчен зур рәхмәт!**

# АВТОНОМИЯДӘН МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕККӘ ТАБА



1920 елның 27 маенда В.И.Ленин һәм М.И.Калинин Татарстан Автономияле республикасын төзү турындагы декретны имзалыйлар. Әгәр дә шушы документ булмаса, 1990 елгы Суверенлык декларациясе дә булмас иде. Бу ике документ бергә энә белән җепне хәтерләтәләр. Алар бергәләп — Татарстанны илнең мөстәкыйль республикага әверелдерү чыганаклары.

Республика төзү Декреты төрле яктан әзерлекле җирлектә ята. Халкыбыз дәүләтчелеген аякка бастыру юлына тулы әзерлек белән килә. Аның тарихи хәтере 1552 елдан соңгы дәүләти бушлыкны тарихи җыр һәм бәетләрдә саклап килде. Сөембикә ханбикә образы легендалаштырылды. Кыскасы, татарның тарихи хәтереннән ватан төшенчәсе беркайчан да китмәде. Киресенчә, ул ватан-дәүләт хыялы белән байый торды. Бу хыялга тормышка ашу өчен уңай шартлар гына кирәк иде. Һәм ул шартлар барлыкка да килә. Аларны революция чоры тудыра.

Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән, дигән Тукаебыз. Шушы елларны татарның, Дәрдемәндчә әйтсәк, тарихи каны белән сугарылган изге сөте куера, аның өсте куе каймакка әверелә. Халкыбызның яшәү көче, ирекка омтылу куәте бермә-бер арта. Аның дәүләти омтылышын Тукай, Дәрдемәнд, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Шәехзадә Бабич, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов һәм башка әдипләребез, журналистларыбыз куәтләп торды. Нәкъ Мәҗит Гафури язганча:

*Бер адым алга басам да*
*Әйләнәм мин артыма.*
*Кайда басканнар икән дип*
*Күз салам мин халкыма.*

Аларның тырышлыгы аркасында беренче рус революциясе елларында татарның 20дән артык газета-журналы барлыкка килә. Күп меңләгән тираж белән китап бастырып, халык арасында тарату гадәти хәлгә әйләнә. Татарлар Россиянең иң укымышлы халкы булып җитлегәләр.

Кыскасы, Рәсәй күгендә татар йолдызы балкый башлый. 1911 елны «Вакыт» газетасында басылып чыккан бер хатта шушы күренеш болай сурәтләнә: «Үзенең китап теле һәм әдәбияты, үзенең тарихы, менә дигән үткәне булган халык беркайчан да юкка чыкмас... Менә безнең халык уяна, өстендәге кабер туфрагын кагып төшерә һәм озаклап яткан кабереннән чыга. Татарның киләчәге томанлы түгел, ул бик тә ышанычлы».

Шул ук елгы бер жандарм белешмәсендә: «Казан губернасында һәм кайчандыр куәтле булган тарихи татар патшалыгының үзәге Казанда алдынгы татар элементлары җыела», — диелгән. Шул елларны Петербург шәһәрендәге татар студентлары «Татар учагы» исемле оешма корып, анда татарлар өчен махсус республика булдыруны үзләренең бурычлары итеп билгелиләр.

1917 елның маенда Мәскәүдә Бөтенроссия мөселманнары съездында Габдулла Сөләймани исемле Нижгар мулласы Россияне штатлар рәвешендә үзгәртеп кору һәм анда татарлар өчен махсус штат булдыру идеясен күтәрә. Дөрес, бу бердәнбер тәкъдим булмый. Ләкин татар күнелендә нәкъ менә шушы тәкъдим тамыр җәя, башка тәкъдимнәрнең уңай яклары белән баетылып, 1917 елның көзендә ул тормышка да аша башлый.

Бу башлангыч Милләт мәҗлесе тарихына бәйле. Мәҗлескә сайлау үткәрү турындагы карар 1917 елның июлендә өч мөселман съездының уртак җыелышында кабул ителә. Һәм ана яшерен рәвештә тавыш бирү принцибы нигезендә гомум сайлаулар да үткәрелә.

Шул ук елның 20 ноябрендә Уфада Милли мәҗлес җыелып, күренекле шәхесебез Садри Максуди җитәкчелегендә эшен башлап та җибәрә. Ул 1918 елның 11 февраленә кадәр дәвам итә. Бу унайдан «Известия Всероссийского Мусульманского Военного Шуро» болай дип яза: «Хәзерге заманда һәр милләт үзенең эчке тормышын кору белән мәшгуль. Инде ниндидер съездлар, кәгазь резолюцияләр вакыты үтте — иске җимерекләкләр нигезендә Россия халыкларының яңа, якты киләчәкләрен төзергә кирәк. Милләт мәҗлесе нәкъ менә шул практик эш белән шөгыльләнә». Мәҗлестә Бөтенрусия Мөселман Хәрби шурасының рәисе, 22 яшьлек прапорщик Ильяс Алкин күтәреп чыккан татарчылык рухы хөкем сөрә. Безнең, ди ул чыгышында, тарихи хәтеребез көчле һәм без ана таянып, нинди генә юллар белән булмасын, Татарстанны барлыкка китерергә тиешбез.

Мәҗлес Урал-Идел Штатын төзүнең Коллегиясен сайлый. Аның составына И.Алкин, С.Янгалычев, Г.Шәрәф, Ф.Мөхәммәдьяров, Ф.Сәйфи, С.Атнагулов, Г.Гобәйдуллин, Н.Халфин кертелә. Җитәкчелек вазифалары Ильяс Алкинга йөкләнә. Ә аның рәистәше итеп күренекле галим Галимҗан Шәрәф сайлана. Монда тагын руслардан — 5, чуашлардан — 2 һәм чирмешләрдән 1 кеше кертү тиешле табыла. Коллегиянең Казанда эшләргә тиешлеге фаразлана.

Хәрби Шура 1918 елның 17-18 гыйнвар көннәрендә бу эшкә кичекмәстән тотынырга кирәклеге турында карар кабул итә. Карарда Штатның II Бөтенроссия мөселман хәрби съездында игълан ителергә тиешлеге күрсәтелә. Тиз арада тыл һәм фронттагы хәрби частьлардан съездга 200 делегат сайлана. Һәм 1918 елның 8 гыйнварында ул үзенең эшен башлап та җибәрә. Аны Ильяс Алкин ача. Йосыф Мозаффаров, кулына Галимҗан Шәрәф төзегән Штат картасын тотып, аның асылы турында доклад ясый.

Шул ук көнне съезд Совет властен яклап, III Бөтенроссия Советлар съездының карарларын тулысы белән танығанлыгын белдерә. Тик менә Казан Советы аларны да, Идел-Урал Штатын да танырга теләми. Аның К.Грасис һәм Я.Шейнкман кебек җитәкчеләре теш-тырнаклары белән Штат игълан итүне булдырмаска тырышалар. Һәм татар сулларына таянып, аларның кулы белән съезд җитәкчелеген кулга алалар. Һәм Штатны 28 февральдә игълан итү кичектерелә. Ә инде аннан соң бөтенләе белән юкка чыгарыла.

Бу вакыт Мулланур Вахитов Петроградта Бөтенроссия Мөселман Комиссариатын җитәкли. Аның урынбасары — Галимҗан Ибраһимов. Комиссариатта башка күренекле татарлар һәм башкортлар. Алар барысы да Совет хөкүмәте белән аңлашып эшләү тарафдарлары, ана ихластан ышанучылар. Аларның барысының да күңелләрен дәүләтчелегебезне торгызу максаты били. Алар, документларда күрсәтелгәнчә, Штат мәсьәләсендә аңлашу өчен Ленин янында да булалар. Нәтиҗәсе безгә билгесез, визитның уңышсыз тәгамәлләнгән булуы ихтимал. Чөнки бервакыт, бәлки, шуна риза булмавын белдереп, Мулланур Вахитов постыннан җибәрүне сорап гариза яза. Күрәсең, аны тынычландырганнардыр, чөнки урынында калырга күндерәләр. Менә шунда булса кирәк, Татар-Башкорт республикасы идеясе калкып чыга. Шуна тәнгәл рәвештә Үзәк Мөселман Комиссариаты Татар-Башкорт Комиссариаты итеп үзгәртелә.

1918 елның 11 мартында шушы Комиссариатның Баш коллегиясе республиканы тормышка ашыру өчен махсус фонд төзергә карар бирә. Һәм 1918 елның 22 мартында И.В.Сталин һәм Мулланур Вахитов тарафыннан имзаланган Татар-Башкорт республикасы турындагы Положение пәйда була. Тик ул да, күрәсең, тормышка ашыру өчен түгел, сәяси уен рәвешендә генә туган документтыр. Чөнки аны берәү дә гамәлгә ашырырга җыенмый. Мулланур Вахитов зур вәкаләтләр белән Казанга җибәрелә. Тик, ни кызганыч, аклар кулына эләгеп, анда һәлак була.

1919 елның 13 декабре көнне РКП(б) Политбюросы Милли Эшләр Халык Комиссариатының Татар-Башкорт республикасы турындагы положениесен юкка чыгара һәм республиканы төзү өчен агитация алып баруны тыя.

Шуннан соң бервакыт республиканы Казансыз һәм Уфасыз төзү идеясе туа. Монысы кайдан килеп чыккан да, кемгә кирәк булган ул? Моңа тулы анык җавап юк. Тик, ничек кенә булмасын, моңа инде барлык күренекле зыялылар бердәм рәвештә каршы чыгалар. Һәм шуның нәтиҗәсендә 1920 елның 27 маенда Татарстан автономияле республикасын төзү турындагы декрет барлыкка килә.

Республиканы оештыру өчен Сәхибгәрәй Сәетгалиев җитәкчелегендәге революцион комитет төзелә. Республиканың чикләрен билгеләү эше Галимҗан Шәрәф җитәкчелегендә башкарыла. Һич кенә дә җиңел эш булмый бу, чөнки ул төрле губерналарның татарлар күпчелекне тәшкил иткән өязләреннән барлыкка килергә тиеш була. Самара губернасының Бөгелмә, Сембер губернасының Буа, Уфа губернасының Минзәлә, Вятка губернасының Алабуга һәм Әгерҗе өязләре шушы республиканың төп җирлеген тәшкил итәләр.

Татарстанны төзү декретында искәрмә рәвешендә Уфа губернасының Бөре һәм Бәләбәй өязләренең республикага керү мәсьәләсе плебисцит, ягъни халык фикере нигезендә хәл ителергә тиеш, диелгән. Әмма берәү дә халык фикере белән кызыксынмый. Республиканы төзү өчен бар ителгән Ревком плебисцит үткәрү өчен зур әзерлек күргән булса да, бу тормышка ашмый кала. Күрәсең, монысы да уен гына булгандыр. Бу өязләр Татарстанга кертелмиләр, ә 1922 елда исә алар Башкортстанга бирелә.

Монда Солтангалиевнең битарафлыгын күрсәтеп китмичә булмый. Ул әлеге ике республиканың барыбер кушылачакларына шикләнми һәм шунлыктан плебисцит үткәрүнең әһәмияте юк дип саный.

1920 елның 26-27 сентябрендә республиканың Учредительный съезды үтә. Анда аның Үзәк Башкарма Комитеты төзелеп, рәисе итеп — Борһан Мансуров, Халык Комиссарлары Советының рәисе итеп Сәхибгәрәй Сәетгалиев сайланалар. Хөкүмәт составына сәламәтлек саклау халык комиссары булып Кәшшаф Мохтаров, Җир эшләре халык комиссары булып Юныс Вәлидов керәләр.

Моннан соңгы еллар республика өчен зур сынау була. 1921 елны республика халкы коточкыч ачлык кичерә. Шушы елларны Спасс өязендә ачтан — 48 мең, Зөя өязендә — 36 мең, Чистай өязендә 29 мең кеше үлә. 1920-1926 елларда республикада татарлар саны 300 мең кешегә кими. Күп урыннарда көн саен 5-6 кешене бер кабергә җирлиләр.

Ачлык фаҗигасен җиңүдә Помгол оешмасы белән бергә АКШның сәүдә министры Герберт Гувер җитәкчелегендәге АРА оешмасы зур эшләр башкаралар. Буа өязенең «Якты юл» авылы крестьяннары «безгә иң авыр вакытта Помгол һәм АРА ярдәмгә килделәр», дип әйтә торган булганнар. Чыннан да, әгәр авылда 120 баланы тукландырырлык ашханә ачылган, олыларга паёклар бирелә башлаган икән, ничек моның өчен рәхмәтле булмаска кирәк. Башка урыннарда да бу оешмаларның эшләре уңай бәяләнә.

Ачлыкка каршы көрәшне оештыруда мөфти хәзрәт Баруди зур тырышлык күрсәтә. Төркия һәм Азәрбайҗаннан шактый күп ярдәм алуга ирешә ул. Шушы изге юлда йөргәндә авырып китеп, Мәскәүнең Боткин хастаханәсендә вафат була. Җир эшләре халык комиссары Юныс Вәлиди дә Казанга берничә эшелон икмәк китертә.

Ә менә хөкүмәт башлыгы Сәетгалиев халкы турында кайгыртудан битәр республикага салынган продразвёрстканы арттырып үтәү белән мәшгуль була. 1921 елны республикага 10,5 млн. пот икмәк развёрсткасы билгеләнә. Моны Шамил Усманов республикага үлем карары чыгару дип бәяли. Развёрстка исә артыгы белән үтәлә.

Тиздән Сәетгалиев урынына хөкүмәт рәисе итеп Кәшшаф Мохтаров билгеләнә. Ул зур тормыш мәктәбен үткән, зирәк акыллы, тәҗрибәле кыю шәхес була. К.Мохтаров җаны-тәне белән Татарстанны тулы хокуклы чын республикага әверелдерү өчен көрәшә, хөкүмәт һәм партия органнарының вазифасын ачык итеп билгеләүне алга сөрә. Татар телен гамәлгә кертү эшен җайга сала. Республикада икетеллелек хөкем сөрә башлый.

Аның белән кулга-кул тотынышып эшләүчеләр арасында иң әүвәл җир эшләре халык комиссары Юныс Вәлиди исемен атау урынлы булыр. Аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә заманында су, юл буйларыннан куылып җирсез һәм сусыз калган

татар крестьяннары өчен Идел буйларында, башка уңайлы урыннарда «Кызыл Байрак», «Чыңгыз», «Мәгариф» кебек махсус посёлоклар барлыкка килә. Тик шул вакыттагы партия өлкә комитеты житәкчелегенә аның бу эшләре һич кенә дә ошамый. Вәлидине партия оешмасының эшендә катнашмауда, кадрларны дөрес сайламауда, чәчү кампаниясен өзүдә гаепилиләр. 1922 елның 18-19 апрелендә партия өлкә комитеты бюросында хәтта аның персональ эше дә карала. Аны катгый рәвештә Халык Комиссарлары Советы рәисе Кәшшаф Мохтаров яклап чыга. Ул Вәлидинең Комиссариат белән житәкчелегенең дөрес юнәлештә икәнлеген, аның максатчан эшчәнлеген ассызыклый һәм, чәчү кампаниясен өзү турында сүз дә булырга мөмкин түгел, ди.

Өлкә комитеты һәм хөкүмәт арасындагы каршылык партия Үзәк комитеты исеменә юнәлтелгән «39 төркеме» хатының барлыкка килүенә китерә. Татар кадрлары имзалаган шушы хатта Өлкә комитетның башбаштаклыклары, татар кадрларын кысуы бәйнә-бәйнә дәлилләнгән була. Тик Үзәк комитет жирле партия оешма житәкчеләрен яклый. Кәшшаф Мохтаров хөкүмәте отставкага жибәрелә.

Партия һәм Совет органнары арасындагы тартышлар шулкадәр дә кискенләшә ки, 1927 елны Шәһимәрдән Шәймәрдәнов житәкләгән хөкүмәт тулы составы белән ярдәм сорап Мәскәүгә, РКП (б) Үзәк комитетына килергә мәжбүр була. Тарихка бу факт наркомнар стачкасы дип кереп калган. Хөкүмәт Мәскәүдә ярдәм таба алмый. Киресенчә, республиканы кысрыклаулар арта гына төшә. Совет органнарының, гомумән, республиканың хокукы бертуктаусыз чикләнә тора.

Әгәр монарчы республиканың 6 комиссариаты бары жирле хөкүмәт органнарына гына буйсынып, ниндидер күләмдә автоном хокукларга ия булган булса, СССРның һәм РСФСРның 1936-1937 елларда кабул ителгән конституцияләре нигезендә алар турыдан-туры Мәскәүгә буйсындырылалар. Шулай итеп, автономия бары тик коры куыкка яки хокуксызлык синонимына әверелә. Гомумән, Россия республикаларының хокуклары гади административ берәмлекләрнен хокуклары белән тәңгәлләштерелә. Ә Никита Хрущёв заманында ул республикаларның жисемнәрен генә түгел, исемнәрен дә бетерү, аларны бөтенләе белән юк итү мәсьәләсе көн тәртибенә басты. Бу турыдагы карарда «пока республики сохраняются» дигән сүзләр бар.

Менә ни өчен дә Татарстаныбызны декретлы республикадан үзбилгеләнү хокукына нигезләнгән суверен республикага әвереләдерү кирәк була.

Илне үзгәртеп кору дулкынында Татарстан үз статусын союздаш республикаларныкы белән тигезләштереп, яңа шартнамә нигезендә үзгәртеп корылырга тиешле Союзга тулы хокуклы мәмләкәт буларак керүне дәгъвалый. Алай гына да түгел, хәтта бәйсез дәүләт булдыру таләпләре дә яңгырый башлый. Бу эшнең башында Марат Мөлеков житәкләгән Татар ижтимагый үзәге тора.

1990 елның 30 августында республикабызның Суверенлык декларациясе кабул ителә. Бу документта Татарстанның РСФСР субъекты икәнлеге язылмаган. Чөнки, әгәр дә күрсәтелгән булса, ул яңа Союзга турыдан-туры керү мөмкинлегеннән мәхрүм калган булыр иде. Документта Россия һәм башка республикалар белән шартнамә нигезендә махсус мөнәсәбәтләр урнаштырылырга тиешлеге ассызыкланган. Декларациянең әһәмияте — Россиянең бөтенлеген бозмастан мөстәкыйль дәүләт төзүгә юнәлтелгән бердәнбер уникаль документ булуында. Бу — монарчы беркайда да күрелмәгән уникаль документ. Аны тормышка ашыру өчен Россия житәкчелеге белән аңлашу кирәк иде. Һәм шушы максатка ирешү максатыннан, ике яктан ике делегация төзелде. 1991 елның 12 августында Мәскәүнең Ак йортында сөйләшүләр булып үтте. Россия делегациясенең житәкчесе — РСФСРның Дәүләт секретаре Геннадий Бурбулис, Татарстан делегациясенеке — республиканың вице-президенты Василий Лихачёв.

Делегацияләрнең 15 август көнне кабул ителгән уртак беркетмәсендә моннан соң Россия һәм Татарстан мөнәсәбәтләре ике яклы шартнамә нигезендә алып барылачак, дип язылган. Әгәр дә шул елның 19 августы көнне башланган ГКЧП фетнәсе яңа Союз шартнамәсенә кул кую юлын бикләмәгән булса, Татарстан аны мөстәкыйль рәвештә имзалаячак иде. Тик ни эшләмәк кирәк, СССР кояшка чыгарып куелган боздай эреп юкка чыкты. Әмма Татарстанның шартнамәле республика булырга тиешлеге үз көчендә калып, сөйләшүләр дәвам итте.

ТАССР Югары Советы «Бәйсезлек акты» – «Акт о независимости» кабул итте. Һәм шуның нигезендә 1992 елның 21 мартында республикада референдум үткәрелеп, Татарстанның суверен статусы халык фикере белән ныгытылды. Шушы статусны республика сайлаучыларының 61,39 проценты яклап чыкты. Бу исә Татарстан делегациясенә сөйләшүләр алып бару өчен көч өстәде.

Ниһаять, 1994 елның 15 феврале көнне Б.Н.Ельцин һәм М.Ш.Шәймиев Россия белән Татарстан арасында үзара вәкаләтләр бирешү турындагы шартнамәне имзаладылар. Шулай итеп, 1920 елның 27 май декреты нигезендә туган республика шартнамәле республикага әверелде. Моның әһәмияте шунда ки, әгәр декретлы республиканы шундый ук декрет белән юкка чыгарып булса, суверенлыгы шартнамә нигезендә танылган республиканың язмышын халык үзе генә хәл итәргә хаклы.

Безнең республикага ияреп, Россиянең кырыктан артык төбәге Үзәк белән шуңа охшаш шартнамәләр төзеде. Шулай итеп, шул елларны күпләр тарафыннан горур дип аталган Татарстан унитар Россияне федератив рельсларга бастыра алды. Дөрес, Россия төбәкләренең күбесе, шартнамә биргән вазифаларны тарта алмаслыкларын сизеп, аннан ваз кичтеләр. Татарстан исә шартнамә биргән мөмкинлекләрдән ныклап файдалана алды. Бу очракта республикабызны тулысы белән газлаштыру, тузган торак программасын тормышка ашыру, Казанның меңьеллыгын үткәрү, башкалабызда метро төзү һәм тагын бик күп гамәлләребез турында сүз алып барып булыр иде. Кама аша күпер салу үзе генә дә ни тора!

2007 елның июнендә яңа шартнамә барлыкка килде. Монысы Россия Федераль җыелышының ике палатасы аша үтеп, Президент В.В.Путин тарафыннан имзаланды. Шулай итеп, ул закон төсен алды.

Бүгенге көнне Татарстан — Россиянең бердәнбер шартнамәле республикасы. Ул махсус статуска ия.

Казанның меңьеллык бәйрәмен үткәрүдә БДБ илләренең җитәкчеләре һәм кайбер ерак чит ил вәкилләре дә катнашты. Алар республикабызның уңышларына зур бәя бирделәр. Шул көннәрне Казанда БДБ илләренең саммиты да булып үтте. Казанда узган Универсиада республикабызга өстәмә дан китерде.

Шушы үзгәрешләр Татарстан өчен киң мөмкинлекләр ачты. Республикабыз халыкара мәйданга чыкты, чит мәмләкәтләр белән күп төрле мөнәсәбәтләргә керде. Күп илләрдә аның вәкиллекләре барлыкка килде.

Шулай итеп, Декларация кабул итеп, аны референдум рәвешендә халык фикере белән ныгыту 1920 елның 27 маендагы декрет буенча барлыкка килгән республикага сыйфат үзгәреше кертте. Кабатлап әйтәм: моңарчы декрет белән барлыкка китерелгән республикабызга бүтән декрет белән юкка чыгарылу куркынычы янап торды. Инде әйткәнемчә, Хрущёв заманында аның язмышы кыл өстендә иде. Хәзер исә Татарстан халыкның үзбилгеләнү хокукы нигезендә үзгәртеп корылды. Никадәр янасалар да, хокукларын никадәр кыссалар да, аны инде декрет белән юк итеп булмый.

Ил карабын җитәкләгән, бәйсезлегебезнең юл башында торган Минтимер Шәймиев Президент вазифасын Рөстәм Миңнехановка тапшырды. Ул — тәҗрибәле, кыю фикерле, киң карашлы шәхесләребезнең берсе. Аңа көч-куәт, дәрт һәм дәрман биреп торыйк, кадерле милләттәшләрем. Бербөтен, бүленмәс һәм көчле халык булып яшик!

Татар халкы зур сынаулар үтеп, бәйсезлек баскычына басты. Авырлыклар күптин-күп. Бертуктаусыз дәвам иткән прокурор протестлары, законнарыбызга каршы чыга торган суд карарлары, гаделсез Дума законнары аша үтәргә туры килә республикабызга. Илебез өстендә бертуктаусыз хәтәр җилләр исә. Ләкин халкыбызның рухы нык, яшәү көче зур. Аның 1920 елның 27 маенда билгеләнгән, референдумда үз фикере белән ныгытылган дәүләтчелек юлын дәвам итәчәгенә тулы ышаныч бар.

**Индус ТАҺИРОВ,**
*академик*

# ТУФАН БЕЛӘН ГОРУРЛАНУ, ИҖАТЫНА СОКЛАНУ КӨЧӘЯ БАРА

Туфан — тормышның ямен дә, тәмен дә, мәгънәсен дә, идеалларын да үз туган җирендә, үз милләтенә хезмәттә тапкан затлы, зыялы шәхес, татар баласы. Көн артыннан көн үтә, еллар уза, Туфан хәзергәчә күз алдында, мыек астыннан елмаеп, дәррәү кабынып китә... Аның әсәрләрен, аның турында истәлекләрне телевизордан да, газета-журналларда да, интернетта да күрәм, хәтеремә аның кайчандыр әйткән сүзләре килә дә, фәлсәфи уйларга бирелəм. Дөрестән дә, иҗатында кайчак тарихка мөрәҗәгать итсә дә, гамендә һәрвакыт татарның бүгенге язмышы иде. Ул, Тукай шикелле, табигать матурлыгына мөкиббән, иҗади илһамын авылдан эзләде, очрашканда, авыл турында сөйләми калганы бик сирәк иде. Ул бит әдәби геройларын да тормыштан, үзебезнең арадан алып сәхнәгә менгерде, без тамашачыларга күрсәтеп бирде: сез менә шулай яшисез, ә бит башкача яшәргә дә мөмкин дип, бу дөньяны игелеклерәк, яхшырак итү юлларын тасвирлап бирде. Аның бу омтылышы бигрәк тә үзгәртеп кору елларында ачык чагылды.

Гомумән, минем фикеремчә, Туфан Миңнуллинның иҗаты киләчәк буыннар өчен үлемсез халык иҗатына тиң кадерле мирас булачак. Чөнки аның бөеклеге, фикер тирәнлеге, халкыбыз өчен әһәмияте көннән-көн ныграк ачыла, аның белән горурлану, иҗатына соклану көчәя бара.

Әйе, горурланабыз, Туфан Миңнуллин белән бер чорда яшәвебез, аны шәхсән белүебез белән бәхетлебез. Бу яңгыравык сүзләр түгел, күңел түреннән чыккан хисләр.

Язмыш дигәнең кызык нәрсә бит ул. Мин менә Туфан белән бер утырып сөйләшкәндә инандым. Язмыш безне, тизрәк очраштырырга теләгәндәй, гел янәшә йөрткән булып чыкты. Икебез дә авыл балалары, икебез дә бер үк чорда Казакъстанда чирәм җирләр күтәреп йөргәнбез: ул — Кустанай өлкәсендә хисапчы, мин — Павлодар өлкәсендә комбайнчы студент. 1960 еллар башында ул — Минзәлә театры артисты, мин — Минзәлә районара "Сельхозтехника" берләшмәсе башлыгы. Ниһаять, Казан һәм безне таныштырган, якынайткан Камал театры. Ул — шактый ныгып килүче драматург, мин — мелиорация һәм су хуҗалыгы министры, театр сөюче. Дөресен әйтергә кирәк, безне гомер буе янәшә тоткан көч, ул, һичшиксез, театрга, сәнгатькә, әдәбиятка мәхәббәт иде.

Дөрес, соңрак без Туфан белән зур сәяси мәйданга да бер чордарак аяк бастык. СССР халык депутатлары булып Мәскәүләрдә йөрдек. Татарстан Дәүләт Советы сессияләрендә ул — депутат, мин — аның шактый четерекле сорауларына җавап бирүче Президент. Шунысын әйтәсем килә: гаять катлаулы чорларда халык мәнфәгатьләрендә дөрес карарлар кабул итә алуыбызда Туфан Миңнуллинның да роле зур булды. Туфан үзен һәрчак лаеклы тота белде. Гомумән, без бер-беребезне тигез күреп, үзара ихтирам итеп аралаштык.

Туфан заманча дөньяви процессларны, глобальләшү үзенчәлекләрен яхшы аңлаган халдә бу проблемага ераккарак китеп карый белә иде. Җир шарында ни генә булмасын, кеше барыбер үзенең тамырларын эзләячәк дип саныды ул. Мин аның бу фикерен бүген, халкыбызның тарихи-мәдәни мирасын торгызу һәм саклау эшенә керешкәч, тагын да ныграк аңладым. Иманым камил, Туфан әсәрләрен укып, аның фикерләрен аңлап, васыятьләрен үтәп яшәсәк, тарихта эзебез югалмас.

**Минтимер ШӘЙМИЕВ,**
*Татарстан Республикасының Беренче Президенты*

# НИЧӘ ТУФАН БӘХӘСЛӘШӘ АЛАРДА...

Туфан ага Миннуллин белән мин үз гомеремдә нибары өч тапкыр очрашып, сөйләшеп, фикерләшеп калдым. Аның беренчесе университетта соңгы курста укыганда булды. Без – татар яшьләре – «Шәрык» клубына җыелган идек. Туфан ага белән очрашуга... Бирегә ул Нәҗибә апа һәм оныгы Данияр белән бергә килде. Чәй өстәле янында шактый гына кызыклы әңгәмә булды. Татарның олпат әдибеннән бераз шүрләтсә дә, ана бер-бер артлы сораулар яудырганыбыз исемдә. Туфан ага, безне сынап, үзе дә сорау арты сорауларын кызганмады. Замана яшьләрен, аеруча да фикерлеләрен ярата, аларны өйрәнә иде ул...

Икенче очрашу, инде мин укуны тәмамлап, университетта эшли башлагач булды. Татар драматургиясе һәм аның төрки әдәбиятлар контекстында формалашу үзенчәлекләрен кандидатлык диссертациясе кысаларына тупларга омтылып йөргән көннәремнең берсе иде. Уку йортыбызның «Мизгел» яшьләр театры Туфан аганың «Ай булмаса, йолдыз бар» әсәрен сәхнәләштерде. Режиссёр Марсель Җаббаров, күренекле драматургыбызны инде ничә тапкырлар чакырып та, аерым сәбәпләр чыгып, гел килә алмыйча калуына үзенә генә хас бер борчылу белән янып йөри, премьера көнне бик үзгәрә, уйга кала, инде ышанып бетмәсә дә, Туфан Миннуллинның да килүе мөмкин, дип безгә хәбәр салып куя. Һәм килә Туфан ага... Килү генә бер хәл, спектакльгә зур бәя бирә. Чыннан да, «Мизгел» сәнгатьнең бар таләпләрен күздә тотып иҗат итә, аны тамашачы ярата, төрле районнарга гастрольләр оештырыла, хәтта «Халык театры» исеменә лаек була!

Менә шулай әвәрә килеп йөргән вакытта (журналистлар белән теге яки бу рольне башкаручыны, режиссёрны, хәтта Туфан аганың үзен «кавыштырып» чабулаганда), әйдәман драматургыбыз белән минем арада кем булуым, ни белән шөгыльләнүем һ.б. хакында җәһәт сүз алышу булды. Мин, аның кесә телефоны номерын сорап алып, «Илһам» әдәби иҗат берләшмәсенә (бу вакытта аның җитәкчесе идем) чакырачагыбызны әйттем. Туфан ага сынаулы караш ташлады...

Берничә көннән теге номерны җыям. Туфан Миннуллинның көр тавышы минем үтенеп чакыруга (яшьләр арасында пьесалар язарга теләк-омтылыш, хәтта беренче тәҗрибәләр дә бар, тик тиешле юнәлеш бирердәй остаз юк!) уңай җавап кайтара. Тиешле вакытка килә, очрашабыз... Аудиториябез шыгрым тулы. Туфан ага шат: иҗат турында ачылып китеп сөйләшердәй егет-кызлар, яшь мөгаллимнәр бар, драматургия буенча диссертация әзерләнә...

Туфан ага белән өченче очрашуым шулай була. Әлбәттә, яшьләр өчен бихисап тәҗел фикерләр яңгырый, даими очрашып торырга килешенәбез, драматург берничә өметле яшь «пьесачыны» шефлыкка алырга вәгъдә бирә. Әмма... бу очрашуыбыз соңгысы булуын ул вакытта кем уйлаган?!

Еллар узган. Соңгы очрашуыбызда Туфан аганың иҗат турында әйткән бер, әмма берәгәйле фикере истә: «Матур әдәбият әсәре тудыру өчен, бер Туфан булып кына язу җитми, әсәрдә ничә персонаж булса, ничә образ катнашса, минем күңелдә дә шул хәтле Туфан була. Үз-үзең белән бәхәсләшеп, гадел хакыйкатькә җитәргә, укучы-тамашачыңа да шуны җиткерергә кирәк!»

Олуг әдиптән зур иҗат кала. Басылганнары һәм басылмаганнары, әйтелеп бетмәгән фикерләр... Туфан ага безне калдырып киткәч тә, шулай булды. Бу санда тәкъдим ителә торган бер бәян һәм өч пьеса (берсе төгәлләнмәгән) әле менә кадәр беркайда да дөнья күрмәгән. Без ул кульязмаларны редакцияләргә, үзгәреш кертергә, пьесаларның ул билгеләгән исемнәрен алмаштырырга җөрьәт итмәдек. Ул әсәрләр кайчандыр язылып онытылган, читкә куелган кульязмалар түгел, ә әдипнең тән һәм җан җылысын гомеренең иң соңгы мизгелләрендә үзенә сеңдереп калган язмалар — ничек бар, шулай калсын, дидек. Алар әдипнең иҗат лабораториясен дә хәтерләтәдер әле. Бер нәрсәдә шигебез юк: бу өр-яңа әсәрләр сезгә ошаячак, укучыларыбыз! Нәкъ Туфанча, яшәешебезнең төрледән-төрле актуаль мәсьәләләрен кыл үзәккә куеп, ничәмә-ничә Туфан бәхәсләшә аларда!

**Рамил ХАННАНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты*



Туфан Миңнуллин

# БЕТСЕН ИРЛӘР, ЯШӘСЕН ХАТЫННАР

ИКЕ ПӘРДӘЛЕ КОМЕДИЯ

**Катнашалар:**

В ә с и м ә, В ә с и м — ир белән хатын.
С ә л и м ә, Х ә т и м ә — авыл хатыннары.
Г а л и я б а н у — авыл карчыгы.
А й с ы л у — авыл кызы.
С и х е р ч е к а р ч ы к.
В а р в а р а — балалар бакчасында тәрбияче.
Х ө л л и я, Н а т а ш а, Ш а р л о т т а — «аллар».
« Б о м б а », « П о п к а », « М и с с П и п и с » — тәтәйләр.
Л ә л и я, М а ш а, Э л и з а б е т — кеше хокукын яклаучылар.
Г у з е л ь к а, Н а т а ш е н ь к а — балалар.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ.

*Жир шары өстендә урын-жире җәелгән караваt. Күктә ай һәм йолдызлар. Айга эленгән бауда Вәсим белән Вәсимәнең бергә кочаклашып төшкән рәсеме эленеп тора. Сәхнә өстендә тар гына экран. Анда сәхнәдә барган вакыйгаларга комментарий рәвешендә икеюллыклар язылып бара. Вакыйга башланыр алдыннан экранда:*

Куйдык та сыртны сыртка,
Пешердек тозсыз ботка,

*дип язылган. Караватның ике ягында сыртны сыртка куеп ир белән хатын — Вәсим белән Вәсимә утыра.*

В ә с и м *(авыз эченнән көйләп).*

Былтыр жуйган балдагымны
Быел таптым утлыктан.
Җырлыйсым килеп җырламыйм,
Җырлыйм хатын юклыктан.

*(Вәсимәгә таба борылып.)* Әйт инде берәр сүз.

В ә с и м ә. Җырла, җырла. Оятсыз. Янында хатыны утыра, хатын юк, ди.

В ә с и м. Дәшмисең бит, сөйләшмисең бит. Мин сине юк дип торам.

В ә с и м ә. Юктыр шул. Сөйрәлчекләр янында йөргәч, хатын юк булып күренәдер.

В ә с и м. Сөйрәлчек дип бүтән хатыннарны мыскыл итмә, Вәсимә. Алар да бит синең җенестәшләрең. Сөяркәләр диген.

В ә с и м ә. Үртәмә. Миңа сөяркә ни, сөйрәлчек ни. Мир үгезе.

В ә с и м. Алай түгел ул, Вәсимә. Сөяркә хатын кебек үк күңелгә якын була. Үзең кебекләрне мыскыл итмә.

В ә с и м ә. Минем кайчан сөйрәлгәнем бар?

В ә с и м. Алла диген, Вәсимә. Дөнья бу. Ярый ла синең менә дигән ирең бар.

В ә с и м ә. Синме ир?

В ә с и м. Кем соң?

В ә с и м ә. Әйтер идем инде...

В ә с и м. Син әйт, Вәсимә. Барысын да әйт, мин белеп торыйм. Ир түгел дисең инде? Син, Вәсимә, ни сөйләгәнеңне белеп сөйлә. Уйлабрак әйт. Үзең мир үгезе дисең, үзең ир түгел дисең. Сөяркәләрең дисең, үзең ир түгел дип әйтәсең. Ир булмаган ирнең сөяркәләре буламы?

В ә с и м ә. Көлмә миннән. Житеп килә торган кызларың бар. Оялмыйсың да, һаман сөйрәләсең.

В ә с и м. Әйдә болай сөйләшик, Вәсимә. Син минем кебек оятсыз белән торма, аерып жибәр. Үзеңә менә дигән ир тап.

В ә с и м ә. Бик кирәкләре бар. Барыгыз да бер иш. Кулымнан килсә, бөтенегезне кырып бетерер идем. Берегезне дә калдырмас идем җирнең йөзендә.

В ә с и м. Бөтенебезне дә димә инде. Арабызда әйбәтләребез дә бардыр... Мин дә ул кадәрле үк начар түгел инде.

В ә с и м ә. Сине беренче булып юкка чыгарыр идем.

*Эленеп торган карточканың алдын артка әйләндереп куя.*

В ә с и м. Карточкадан үч алма.

В ә с и м ә. Тормасын җан көйдереп.

В ә с и м. Рәхмәт, Вәсимәкәй. Ләкин булып чыкмый ниятең. Ирләрсез яши алмый хатын-кыз.

В ә с и м ә. Яшәмәде ди, котеп тор. Әнә Сабира апа әйтә, ирдән котылгач, рәхәтләнеп яшим, ди.

В ә с и м. Сандугачым...

В ә с и м ә. Әйтмә миңа сандугачым дип.

В ә с и м. Карлыгачым...

В ә с и м ә. Мыскыл итмә, диләр.

В ә с и м. Ярый алайса, сандугачым да димәм, карлыгачым да димәм, чыпчыгым диярмен. Менә нәрсә, чыпчыгым, синең рәхәтләнеп яшим дигән Сабира апаң беркөн миңа әйтә — бер генә кочакла әле, Вәсим, ди.

В ә с и м ә. Алдашма. Кирәгең бер тиен.

В ә с и м. Ярый инде алайса. Бер тиен тек бер тиен. Хәзерге тиенне җирдә ятса да иелеп алучы юк. Шулайдыр инде без дә. Ничек соң сине бәхетле итәргә, Вәсимәкәй? Син, әйдә, болай эшлә. Ходайдан сора, и Алла, бу дөньядан ир дигән хайваннарны юк ит, үзебез генә калып рәхәтләнеп яшик, диген.

В ә с и м ә. Авызың ерма, сорармын да шул.

В ә с и м. Юк, Вәсимәкәй. Алла андый этлекне эшләмәс. Ни әйтсәң дә, ул безне алдан яраткан. Аннан соң безнең кабыргадан — сезне. Син ин яхшысы — сихерче карчыклардан сора. Алар явыз. Алар сине тыңлар.

Мин бетәргә риза үзе. Әйдә, икәү бергә чагында ятып сөйләшик. Мин сине кочагыма алырмын, син шунда ирләр кирәкми, диярсен. *(Ята.)*

В ә с и л ә. Якын киләсе булма, орынасы булма. *(Вәсимгә аркасын куеп ята. Серле музыка астында серле утлар сәхнәдә хакимлек итә. Ай дерелди, йолдызлар сикерешә. Сәхнә яктырганда, Вәсимә ялгызы гына караватта ята. Вәсим яткан урынны капшап карый. Вәсим булмагач, торып эзләнә.)* Әй, кайда син? Вәсим! Вәсим, дим.

*Экранда язу:*
*Ирләр бетсен, үлсен, катсын,*
*Хатыннар чәчәк атсын.*

*Сихерче карчык пәйда була.*

С и х е р ч е   к а р ч ы к. Вәсим юк. Ирең юк.

В ә с и м ә. Ничек юк? Син кем?

С и х е р ч е   к а р ч ы к. Мин бөтен жир шарындагы сихерче карчыкларның президенты. Кичә сезнең ишегалдында безнең жыелышыбыз булды. Көн тәртибендә сезнең теләкне тикшерү иде. Озакка сузылган фикер алышулардан соң, сезнең теләкне канәгатьләндерергә булдык.

В ә с и м ә. Нинди теләк?

С и х е р ч е   к а р ч ы к. Кулымнан килсә, бөтен ирләрне дә кырып бетерер идем, дидегез. Дидегезме?

В ә с и м ә. Дигән идем.

С и х е р ч е   к а р ч ы к. Дисәгез, шул теләгегез үтәлде. Жир шарында һәм космоста бөтен ир заты юкка чыгарылды.

В ә с и м ә. Ничек?

С и х е р ч е   к а р ч ы к. Сихер көче белән. Рәхәтләнеп яшәгез, Вәсимә ханым.

В ә с и м ә. Туктагыз әле...

С и х е р ч е   к а р ч ы к. Туктарга ярамый безгә. Без һәрвакыт хәрәкәттә булырга тиеш. Сихерчеләр илендә сездәгечә түгел. Бездә барысы да уйланылган. Без сүзләребезне уйлап сөйлибез. Сүзебезне төгәл үтибез. Бездә кризис-мризис юк. Бездә барысы да модернизацияләнгән һәм структуризацияләнгән. Бездә сездәге шикелле бюрократизм юк. Хушыгыз. *(Югала.)*

*Вәсимә, сәхнәнең төрле ягына барып карана. Тынлый. Жир шарындагы хатын-кызларның шатлыктан көлгән тавышлары яңгырый. Күрше хатыны Хәтимә керә. Анын белән бергә экранда:*
*Тыныч ашаган ашым —*
*Юк янымда алкашым,*
*дигән язу языла.*

Х ә т и м ә. Вәсимә, минеке сезгә кермәдеме ул? Иртә таңнан чыгып югалды, заразы, дуңгыз прачункасы.

В ә с и м ә. Синеке түгел, үземнеке дә юкка чыккан әле.

Х ә т и м ә. Бергә киткәннәр микәнни? Алай дисәң, синеке минеке кебек дуңгыз урынына эчми дә инде. *(Һавада «Ур-ра!» дигән хатын-кыз тавышлары яңгырый.)* Син ишетәсенме, нәрсә кычкыралар анда?

В ә с и м ә. Сихерче карчыкның әйткәне дөрес булып чыкты, ахрысы.

Х ә т и м ә. Нинди сихерче?

В ә с и м ә. Иртән торсам, каршымда бер карчык тора. Бөтен ирләрне бетердем, ди, хатын-кызлар гына калды жир шарында, ди.

Х ә т и м ә. Кит әле! Нишләп икән?

В ә с и м ә. Кичә Вәсимгә ачуым чыккач, бөтен ирләрне бетерер идем жир шарындагы, дип теләк теләгән идем, шул теләгем үтәлде, ди.

Х ә т и м ә. Кит аннан!.. Чынмы икән?

В ә с и м ә. Юк бит, синеке дә, минеке дә юк.

Х ә т и м ә. Ходаем, шундый бәхетнең дә килер көне булыр микәнни? *(Каранып.)* Кара, чыннан да урамда ир заты күренми. Тукта, Санияләргә кереп чыгыйм әле, аның хәрәсәне нишләде икән. *(Чыгып чаба.)*

В ә с и м ә. Кара, көтмәгәндә килеп чыкты бит әле бу. Нишләргә икән? Кызык булып китте бит әле. *(Жырлый.)*

Мондый көнне күрер көн дә булыр икән,
Тормышыма бәхет ташып тулыр икән –
Ир дигән азгыннан котылдым,
Ялгыз башым — тыныч колагым дип кенә
Үз җаема, үз көемә иплəп кенә
Рәхәттә яшәргә тотындым.

Кайчан кайтып керер икән бу азгын дип,
Кайсы кошны тотты икән бу козгын дип,
Ут йотып ятмамын төннәрен;
Бәхетемне шатлыгыма төйнәп кенә,
Җырлап кына, көен көйгә көйләп кенә
Рәхәттә үтәрдер көннәрем.

Х ә т и м ә *(атылып кереп).* Валлаһи, дөрескә чыкты әйткәнең, Вәсимә, Саниянең дә ишәге юкка чыккан, Әминәнең дә сарыгы югалган. Сөенеп туялмый Әминә. Аерылам, аерылам дип яшәдем шул сарык белән, ди. Рәхмәт яусын Вәсимәгә, ди. Авыл тулы өйләнмәгән егетләр иде, урам этләре кебек өерелеп йөриләр иде, берсе дә күренми. Чыннан да, кая олактылар икән алар?

В ә с и м ә. Үле гәүдәләре дә күренмиме?

Х ә т и м ә. Ю-ук, күренмәве яхшы да әле аның. Күмеп мәшәкатьләнер идек. *(Көлешәләр.)*

*Сәлимә керә.*

*Экранда язу:*
*Мохтаж түгел ир-атка,*
*Сезнеке булган чакта.*

С ә л и м ә. Карале, кызлар, ирләр юкка чыккан, диләр, дөрес микән? Карагыз әле, законный ирләр генә бетте микән, законный булмаганнар калды микән?

Х ә т и м ә. Өметләнмә, Сәлимә, бетте килгән-киткән мужикларың.

С ә л и м ә. Ир бетсә дә, сөяркә бетми ул, җаным.

В ә с и м ә. Вәсимгә дә өметең сузма, югалды.

С ә л и м ә. Юкка шикләнәсең, Вәсимә, синекенең кунганы булмады.

Х ә т и м ә. Синдә кунмаган ир булды микән.

С ә л и м ә. Аллага шөкер, анысы. Тагын да кунарлар әле. Болай гына юри генә әйтәләрдер әле, бетмәгәндер ирләр. Ирләр бетсә, дөнья бетә ич.

*Шулвакыт «Тыңлагыз! Тыңлагыз!» дигән тавыш яңгырый.*

1 т а в ы ш. Тыңлагыз! Тыңлагыз! Казан сөйли. Мәскәү вакыты белән сигез сәгать кырык минут.

2 т а в ы ш. Говорит Москва. Московское время восемь часов тридцать минут.

С ә л и м ә. Карале боларны. Икесе ике төрле сөйли. Казан кырык минут ди, Мәскәү утыз, ди. Әллә Мәскәү безгә вакытны бераз арттырганмы?

Х ә т и м ә. Тукта, тырылдама, тыңлыйк.

1 т а в ы ш. Казан сөйли. Бүген иртәнге сәгать алтыда бөтен җир шарында ир женесеннән булган затлар юкка чыкты. Бары тик хатын-кыз женесеннән булган затлар гына калды.

2 т а в ы ш. Сегодня в шесть часов утра на всей территории земного шара ликвидирован мужской род. Остались только особы женского рода.

С ә л и м ә. Мәскәү әйткәч, дөрес булып чыкты алайса. Мәскәү белми сөйләмәс. Аның ялганы да дөрескә охшаган. Этлек ишетәсең килсә, Мәскәү радиосын тыңла. Ходаем, нишләрбез икән ирләрсез.

В ә с и м ә. Нишләрбез икән димә, нишләрмен икән диген.

С ә л и м ә. Аллага шөкер, мин ичмасам күрәсен күреп калдым. Бетсәләр дә, үкенечкә калмады. Үкенечкә калмады. Китим әле, берәрсе берәр җирдә посып калмады микән. *(Чыгып китә.)*

В ә с и м ә. Сөйрәлчек.

Х ә т и м ә. Шулар аркасында бозылды да инде дөньясы. Алар булмаса, син дә теләк теләмәгән булыр идең. Карале, күрше, кемнәр ул тегендә? Әллә бүген берәр бәйрәмме?

*Экранда язу:*
*Үзебез үзебезгә —*
*Кирәкми ирләр безгә.*

*Ал төстәге флаглар, лозунглар күтәргән бер төркем хатын-кызлар керә. Лозунгларда: «Бетсен ирләр, яшәсен хатыннар!», «Яшәсен хатын-кыз белән хатын-кыз мәхәббәте!», «Ал төс — затлы төс!» дигән язулар. Төркем Васимә каршына килеп житкәч, сафларга тезелеп жыр суза.*

Без котылдык безне басып торган,
Безне изгән ирләр затыннан.
Без әйткән сүз — безнең девизыбыз:
Бетсен ирләр, яшәсен хатыннар!
Безнең байрагыбыз ал төстә —
Ал төс балкып торсын һәр төштә.

*Жыр тәмамлангач, төркемдәгеләр Васимә алдына чәчәкләр сибәләр.*

Хөллия *(алга чыгып).* Хөрмәтле Васимә! Сез жир йөзеннән ирләр дип аталган котсыз, шыксыз, кыяфәтсез, шөкәтсез, килбәтсез, мәнсез, рәтсез, нурсыз, йогышсыз, көшпәтсез, мөрәвәтсез затларны кырып-себереп ташлап, бөек эш эшләдегез. Бу гамәлегез безне чиксез шатландырды, куандырды, сөендерде. Төрле төбәкләрдә яшәүче, төрле телләрдә сөйләшүче аллар исеменнән сезгә зур рәхмәт. *(Васимәне үбеп ала.)*

Наташа *(Хөллияне алыштырып алга чыга).* Дорогая наша подруга Васима! Уничтожив безобразный род человечества — мужчин, вы сделали огромное дело. От имени всех розовых вам огромное спасибо! *(Васимәне үбеп ала.)* А вы очень сладкая, Васима.

Васимә. Туктагыз әле, сез кемнәр?

Шарлотта. Мадам Васима... *(Хөллия белән Наташа әйткәннәрне французча кабатлый һәм Васимәне караватка егып салып үбә. Башкалар кул чабып котлап торалар.)*

Васимә *(Шарлотта кочагыннан котылып).* Нишлисен син? Сез кемнәр?

Хөллия. Әйткәнемчә, без — аллар. Әллә ишеткәнегез юкмы? Икенче төрле итеп әйткәндә, лесбиянкалар. Без — дөньяның рәхәтен ирләрдән башка гына татый белүчеләр. Без — нәфислек символлары. Ирләр дип аталган тупас жаннардан жир өстен арындыруыгыз өчен без сезгә роза чәчәкләре алып килдек. Ә болары ал төстәге мәк чәчәкләре. *(Жырга күчеп).*

Мәк чәчәге, мәк чәчәге,
Мәк чәчәге ал була;
Күзең сирпеп бер карасаң,
Йөрәгемә ял була.

Белегез, кадерле Васимәкәй, без мәк чәчәген чүп үләне белән бутаучылар түгел. *(Мәк чәчәге бәйләмен Васимәгә тапшыра. Хатыннар төрле телләрдә Васимәгә рәхмәт әйтәләр. «Огромное женское спасибо!». «Данке шон!», «Мерси!», «Сенкью веремеч» дигән авазлар янгырый).*

Хөллия *(Хәтимә янына килеп).* Ә сез кем буласыз?

Хәтимә. Мин Васимәнен күршесе — Хәтимә булам.

Хөллия. Сез дә чибәр хатын.

Наташа *(Хәтимә янына килеп).* Аппетитная, правда?

Хәтимә. Сез әллә кыз-тәкәләрме? Ирдәүкәләрме?

Хөллия. Анысы да түгел, монысы да түгел. Без — нәфислек фәрештәләре. Килегез әле бирегәрәк, кочаклагыз әле мине.

Хәтимә. Хатын-кыз кочакларга мине кем дип белден?

Хөллия. Ә син кочаклап кара. *(Хәтимәне кочаклый-үбә.)*

Хәтимә. Нишлисен, жибәр! *(Хөллиядән ычкынып, Наташа кочагына керә. Анардан ычкынып чыгып чаба. Аллар төркеме көлешә, кул чаба.)*

Хөллия *(Васимә каршына килеп).* Без китәбез, Васимәкәй. Без әле очрашырбыз. Безне эзләп табарга теләсәң, безнен адрес — бөтен жир шары.

Наташа. Наш адрес: весь земной шар.

Безнең байрагыбыз ал төстә,
Ал төс балкып торсын һәр төштә,

*дип жырлап чыгып китәләр.*

*Хәтимә керә.*

Хәтимә. Киттеләрме? Шулар бу, Вәсимә, шулар — кыз-тәкәләр. *(Көлеп).* Кочаклый, үбә... Кытыкны китерделәр. Начар түгел икән үзе.

Вәсимә. Ни сөйлисең син?

Хәтимә. Ни сөйлисең дип... Дөньяда булмаган эшме? Исерек ирнең өстенә атлануы түгел инде. Иркәләнәсе дә килә бит. Кил әле, кочаклыйм әле үзеңне, Вәсимәкәй.

Вәсимә. Якын киләсе булма.

Хәтимә. Курыкма, шаярам гына. Әй дөньялар, дөньялар. Кая таба бара бу дөньялар? Нишләтәсең, Вәсимә, ирләр исемен йөртеп, ир булмаганнар дөнья тулы. Алар бар дип алданып яшәгәнче... Аптыраганнан инде болар барысы да. Үгез теләп тә үгез булмаса, сыер өстенә сыер да атлана шул. *(Караватка чалкан ава да җыр суза.)*

Наз күрәлмыйча үтте гомерләр,
Чәчәк атмыйча сулдылар гөлләр.
Яфрак атмыйча корды каеннар,
Корган каеннар — безнең кайгылар.

Синең ичмасам, ирең азгын булса да, ир иде. Рәхәтен күрә идең.

Вәсимә. Каян беләсең?

Хәтимә. Үзең зарлана идең ләбаса. Йокларга ирек бирми дия идең. Бүтән хатыннар янына йөргәнгә тузына идең. Йөрерлек ирең булсын иде лә ул. Миңа да булмады, бүтәннәргә дә тәтемәде. *(Вәсимәне кысып кочаклый да чыгып китә.)*

*Экранда язу:*
*Ир-атлар да кешеләр,*
*Почти хатын-кыз ишеләр.*

*Портфельләр тоткан, ирләрчә киенгән күзлекле өч-дүрт хатын керә.*

Ләлия. Керергә рөхсәттер дип беләбез. Исәнмесез. Здравствуйте, бонжур, гутен таг. Гражданка Вәсимә Бариева биредә яшиме?

Вәсимә. Әйе.

Ләлия. Безгә аны күрергә мөмкинме?

Вәсимә. Мөмкин. Мин ул Вәсимә Бариева.

Ләлия. Бик яхшы. Без Халыкара кеше хокукын яклау оешмасыннан.

Маша. Мы правозащитники человеческих прав. Из всемирной организации правозащитников.

Элизабет. *(Маша әйткәнне инглизчә кабатлый. Тезелешеп басып, үз оешмаларының гимнын җырлыйлар).*

Һәр җирдә һәм күктә, һәр төштә
Бертигез хокукта кешеләр:
Ирләр һәм хатыннар барысы
Һәм безнең, һәм сезнең ишеләр.

На земле, на небе, повсюду
Равные права у людей.
Женщины, мужчины всех мастей
Все равны, нет рабов, нет судей.

*(Гимнны инглиз телендә җырлыйлар).*

Ләлия. Безнең оешмада ирләр дә бар иде, ләкин алар кинәт кенә юкка чыктылар. Ишетүебезчә, аларны юкка чыгаручы — сез.

Вәсимә. Мин түгел, сихерчеләр.

Ләлия. Ләкин сезнең үтенечегез буенча.

Вәсимә. Мин үтенмәдем, теләдем генә.

Ләлия. Димәк, сезнең теләкне искә алып, сихерчеләр җир өстендәге ирләрнең тамырын корытты?

Вәсимә. Тамырлары ук корымагандыр, юкка чыгулары хак бугай.

Ләлия. Сез, ханым, үзегезнең җинаятьче икәнлегегезне таныйсызмы?

Вәсимә. Ниткән җинаятьче?

Ләлия. Сез аңлыйсызмы, бер кешене үтерүчене гомерлеккә төрмәгә ябалар, ә сез миллиард кешенең башына җиткәнсез.

Вәсимә. Нәрсә сөйлисең син, ниткән кеше?

Ләлия. Сезнеңчә, ирләр кеше түгелмени?

Вәсимә. Минем кешедә эшем юк, үз ирем белән теләсә нишлим.

Телим икән үтерәм, телим икән яшәтәм.

Элизабет. Сезнен ирегез дә кеше бит.

Вәсимә. Ул сезнен өчен кешедер, минем өчен ир генә.

Маша. Вообще-то она права.

Вәсимә. Сез нәрсә, мадам Мария. Сез жинаятьчене якларга жыенасызмы?

Маша. Я в том смысле, что не все мужья мужчины.

Элизабет. Ах, бу Россия! Бөтен милләтләрнең дә хатыннары бертөсле. Европада, мадам Мария, бөтен ирләр дә кеше.

Маша. И вашу Европу я знаю. Кочаклап йокларлык ир юк.

Элизабет. Ләкин алар кешеләр. Сез безне гажәпләндерәсез, мадам Мария. Үзегез кеше хокукларын яклау үзәгенең әгъзасы, үзегез, кешелек дөньясын юкка чыгарган авыл хатынын яклыйсыз.

Вәсимә. Нәрсә һаман мина бәйләнәсез, мин иремне генә беләм, калганын сихерчедән сорагыз.

Элизабет. Юк, без сине хөкемгә тартабыз.

Ләлия. Кеше хокукларын яклаучы оешма исеменнән халыкара трибуналга мөрәжәгать итәчәкбез.

Вәсимә. Итмәгәегез. Минем иремдә берәүнең дә эше юк.

Элизабет. Әгәр дә сез үз ирегез кебек ирләрне генә бетерсәгез — бер хәл. Ләкин сез ир-атлар исеме йөртеп тә ирлек вазифаларын үти алмаганнарны да юкка чыгаргансыз.

Вәсимә. Аларында минем эшем юк. Сез нәрсә әле, хатын-кыз башыгыз белән алкашларны яклап йөрисез?

Ләлия. Алкогольнең монда катнашы юк.

Вәсимә. Ничек булмасын! Әнә Сания әйтә: эчә дә йоклый, эчә дә йоклый, ир рәхәтен күрми изаланам, ди. Нәрсәгә кирәк андый ир?

Маша. Браво! Браво! Дөрес! Нечего их кормить.

Элизабет. Мадам Мария, әгәр дә сез безгә каршы фикер йөртсәгез, без сезне халыкара оешмадан чыгарырга мәжбүр булабыз. Сез кеше хокукларын яклый белмисез.

Маша. Извините, кешеләрне яклыйм мин, ир була белмәгән ирләрне генә якламыйм.

Ләлия. Алар да кеше, анлагыз.

Маша. Булмагайлары. Мин — маржа, мина мине төнлә йоклатмыйча кочаклаучы мужик кирәк. *(Вәсимәгә.)* Синең ирен төнлә сине йоклата идеме?

Вәсимә. Мине генәме! Ярты районның ирсез хатыннарына житешә иде.

Маша. Һәм син шундый ирне юкка чыгардынмы, дура?

Вәсимә. Бүтәннәргә дә булмасын, мина да булмасын.

Элизабет. Сез кыргый халыклар, мадам Мария һәм мадам...

Вәсимә. Вәсимә.

Маша. Ә сез кем? Ир-ат белән йоклаган гомоларны яклап йөрисез.

Элизабет. Без кеше яклыйбыз. Кемнең кем белән йоклавында безнең эшебез юк. Кешенең теләсә кем белән йокларга хакы бар.

Вәсимә. Алтын икән акылыгыз. Йокламый торсыннар әле. Сөйрәлчекләр белән йокларга яраткач өйләнмәскә иде. Мин көчләп өйләндермәдем. Яратам, диде, артымнан ялынып йөрде. Синнән бүтәнгә карамыйм, диде.

Маша. Да, жаль мужика. Я бы его простила, пусть бегает. Хороший бык на всё стадо хватает.

Ләлия. Житте! Туктатыгыз эротиканы!

Элизабет. Бу эротика гына да түгел, бу — порнография. Кыскасы, мадам Вәсимәне халыкара трибунал хөкем итәчәк. Сез безнең белән китәсезме, мадам Мария? Әллә бу хатынның адвокаты булып каласызмы?

Маша. Юк, мин бу хатынны яклый алмыйм, шундый ирне юк иткәне өчен җәзанын иң катысын сораячакмын.

Вәсимә. Нинди була инде ул иң катысы? Асасызмы, атасызмы?

М а ш а . Юк, җинел генә котылырга уйлама, дорогая. Без сине мена бу хатыннар ише хатыннар белән гомер буе яшәргә мәҗбүр итәчәкбез.

Э л и з а б е т . Безгә һөҗүм итмәвегезне үтенәбез.

Л ә л и я . Китәбез, коллегалар. *(Вәсимәгә).* Ә сез халыкара трибуналда җавап тотарга әзерләнегез. *(Китәргә борылалар.)*

М а ш а *(китеп барган җиреннән туктап).* Әгәр дә мужигыгыз табылса, миңа хәбәр итәрсез. Дура ты, дура. Такого мужика потеряла. *(Частушка җырлый.)*

Помидоры, помидоры,
Помидоры — овощи:
Баба едет в карете,
Муж на скорой помощи.

Мой милёнок в армии –
Атлар эчерәм, дигән;
Пока гуляй — время шулай,
Кайткач кичерәм, дигән.

И-и-их! *(Чыгып китә.)*

*Экранда язу:*
*Алдын булса, арт кирәк –*
*Карчыкка да карт кирәк.*

*Галиябану керә.*

Г а л и я б а н у *(карана).* Монда берәр кеше бармы?

В ә с и м ә . Бар, Галиябану әбекәй, бар.

Г а л и я б а н у . Күзем күреп бетерми, кай тирәдә син?

В ә с и м ә . Менә ич. Каршында басып торам.

Г а л и я б а н у . Шулайдыр. Шулай икән шул.

В ә с и м ә . Уз, утыр, Галиябану әби.

Г а л и я б а н у . Узам, утырмыйм. Утырсам, тора алмыйм. Мин ята алам да басып тора алам. Кайда, кайда минеке? Тизрәк чыгар да кайтып китик.

В ә с и м ә . Нәрсә сорыйсын, Галиябану әбекәй?

Г а л и я б а н у . Нәрсә түгел, кем.

В ә с и м ә . Кемне сорыйсың?

Г а л и я б а н у . Кемне дип... Үземнекен сорыйм. Хәлилемне. Юкка чыкты. Янымда яткан килеш юкка чыкты. Арканы аркага куеп рәхәтләнеп җылынып ята идек. Нигә аркам туңа дисәм, Хәлилем юк. Кая киткән бу бер сүз дә әйтмичә дип урамга чыксам, әйтәләр — бөтен ирләрне дә Түбән оч Вәсимәсе җыештырып-төештереп абзарына ябып куйган, диләр. Ышанмадым ышануын, шулай да килдем менә. Дөресме шул, дөрес түгелме?

В ә с и м ә . Дөрес түгел, Галиябану әби. Үземнен дә Вәсимем югалды.

Г а л и я б а н у . Ни булды икән алайса? Җитмеш ел буе янымнан китмәгән иде. Дүрт елга сугышка гына барып кайтты да гел янымда булды. Кеше әйткәч тә шикләндем үзе. Япь-яшь хатын нишләсен туксан яшьлек картым белән, дим. Болай ул мутын мут та инде. Әле беркөн кибеткә барган идек, шунда Гайниҗамал итәгенә ышкылып-ышкылып үтә. Тегесе дә бит анын, нихәлләрдә, Хәлил абзый, җир җимертеп йөрисеңме, дигән булып чытлыклана.

В ә с и м ә . Ирләр барысы да бер. Туксан яшьтәгесе дә, унтугыз яшьтәгесе дә. Синеке дә шул, минеке дә шул.

Г а л и я б а н у . Синекен белмим, минеке, Аллага шөкер. Үзем сайлап алдым бит. Бер театр караган идем, шунда җырладылар. Берәү гармун тотып чыкты да җырлый. *(Җырлый.)*

Таң әтәчләре кычкыра —
Әллә таң ата микән:
Тәрәзә ачып карап калды,
Галиябану — сылуым-иркәм,
Әллә ярата микән?

Миңа атап җырлый дип торам. Галиябану дип җырлаучысы Хәлил исемле икән. Шунда мин үзәмә Хәлилне эзләргә керештем. Күршедә генә булган икән. Кая китте икән соң? Берәр җирдә егылып ятмаса ярый инде.

В ә с и м ә . Юк, Галиябану әби, Хәлилең егылып ятмый. Сихерче карчыклар алып китте аны.

Г а л и я б а н у . Кит әле, миннән

дә сихерчерәк карчык бар микәнни. Хәлилем дә мина сихерче дия иде, сихерләден дия иде. Дөрес сүз түгелдер. 90 яшьлек картны кем сихерләсен.

Вәсимә. Картына-яшенә карамаганнар, барысын да җыеп алганнар.

Галиябану. Шундый закон чыкканмыни?

Вәсимә. Законсыз гына җыеп алганнар.

Галиябану. Юк, юк, законсыз бирер хәлем юк. Ул минем законлы картым. Сугыш вакытында закон чыкты — биреп тордым.

Вәсимә. Юк икән юк инде, йөрмә аптырап туксан яшьлек карт өчен.

Галиябану. Нәрсәме дисен?

Вәсимә. Туксан яшьлек карт нәрсәмә кирәк инде дим.

Галиябану. И-и-и, кара моны. Хәлил бит ул. Минем Хәлилем бит. Уникe баламның атасы ич ул. Хәзер генә ул атасыз балалар туа. Без ирләрсез бала таба белми идек.

Вәсимә. Надан булгансыз, шуна ул. Хәзер баланы элеккечә тапмый башлаячаклар. Ирләрнен кирәге калмаячак.

Галиябану. Кит аннан!.. Шундый закон чыкканмы?

Вәсимә. Әлегә чыкмаган. Чыгачак...

Галиябану. Кит аннан!.. Булмас.

Вәсимә. Син колхозда эшләденме?

Галиябану. Эшләмәскә. Гомерем сыер астында фермада үтте.

Вәсимә. Ясалма орлыкландыруны беләсенме?

Галиябану. Белмәскә. Әстәгъфирулла, әллә кыз-хатыннарны да шулай итәчәкләрме?

Вәсимә. Итәчәкләр. Ирләр кирәк булмаячак.

Галиябану. Кит аннан! Без генә җүләр булып ирдән бала тапканбыз алайса?

Вәсимә. Шулай. Бар, җүләрләнеп йөрмә. Эзләмә картынны.

Галиябану. Сон, ангыра бәрән, Хәлилем мина бала табар өчен кирәкмени?! Арка җылытырга кирәк ул.

Вәсимә. Мичкә терәп ят аркаңны.

Галиябану. И Алла! Пич белән ирләр аркасы бер буламыни?! Ирләр аркасының җылысы шифалы аның.

*Экранда язу:*
*Ирләрсез бала булмый,*
*Аны бала да аңлый.*

*Сигез-тугыз яшьтәге кыз балалар төркеме керә. Аларны тәрбиячеләре Варвара ияртkән. Балалар, әлбәттә инде, җырлап керәләр.*

Безгә бирде әниләр
Бәхетле балачак:
Әтиләр булганда, без
Бәхетле булачак.

Нам подарили мамы
Наше будущее,
Папули подарят
Нам грядущее.

Варвара. Дети, становитесь в ряд. Гузелька, начинай.

Галиябану. Сөбханалла! Кем балалары бу?

Варвара. Бабуля, не мешай. Тебя нет в сценарии. Гузелька, начинай.

Гузелька.
Вәсимә апа, без сездән
Бик сорыйбыз үтенеп,
Зинһар өчен, син безгә
Кайтар әтине.

Галиябану. Сөбханалла!

Варвара. Бабуля, замолчи. Наташенька, продолжай.

Наташенька.
Мне нужна мама,
Мне нужен папа.
Да здравствует СНГ,
Пусть подохнет НАТО.

Галиябану. Сөбханалла!

Варвара. Бабуля, заткнись! Гуленька, давай.

Энекәш кирәк мина,
Бик бәләкәй булса да,

Колга хәтле булса да,
Башкортстанда туса да,
Татарстанда торса да.
Энекәш кирәк миңа.

Г а л и я б а н у . Машалла, машалла!

В а р в а р а . Бабуля, заткнись! Наташенька, давай.

Н а т а ш е н ь к а .
Братик мне нужен,
Я хочу братика.
Да здраствуй дружба,
Не нужна критика!

Г а л и я б а н у . Здорово!

В а р в а р а . Бабуля, подавись! Гузелька.

Г у з е л ь к а .
Безгә абый да кирәк,
Тормыш ямьсез абыйсыз.
Татарстан абыйлары
Хоккей яхшы уйныйлар.

В а р в а р а . Наташенька, не спи.

Н а т а ш е н ь к а .
Наши дяди молодцы,
Всем другим народам
Они старшие братья.
Да здравствует великая держава!

Г а л и я б а н у . Ләхәүлә вәлә куате.

В а р в а р а . Бабуля, убью. *(Васимәгә.)* Дорогая Васима апа, верните нашим девочкам любимых отцов, старших и младших братьев. Наши девочки цветочки счастливого светлого капиталистического будущего. Заодно верните мне моего любимого Маратика Мухаметсултанбековича.

*Экранда язу:*
*Телим икән, сатам,*
*Теләмәсәм, эткә атам.*

*Сәлимә керә. Ана «Бомба» ияргән.*

С ә л и м ә *(Васимәгә күрсәтеп).* Әнә ул — үзе.

« Б о м б а » *(артта калганнарга кычкыра).* Шалава!

*Бер төркем кәттә кызлар керәләр.*

« П о п к а » *(бәләкәй кызларга).* Что за пионеры? Вон отсюда!

*Кызлар чыр-чу килеп чыгып чабалар. Тәрбияче дә аларга иярә.*

« Б о м б а » *(Васимәгә күрсәтеп).* Әнә ул.

В ә с и м ә . Сезгә кем кирәк?

« Б о м б а » . Син Васимәме? Ирләрне юкка чыгарган хатынмы? Кулымнан килсә, бөтен ирләрне кырып бетерер идем диденме? Шулмы?

В ә с и м ә . Мин юкка чыгармадым. Сихерче карчык.

« Б о м б а » *(Галиябануга).* Синме ул сихерче карчык?

Г а л и я б а н у . Әстәгъфирулла, нишләп мин сихерче булыйм. Мин...

« П о п к а » . Молчать!

Г а л и я б а н у . Әстәгъфирулла... Нигә кычкырасың, кем булдың ул кадәрле?

« П о п к а » . Ты, колдунья, верни.

Г а л и я б а н у . Әстәгъфирулла... Нәрсә вирни? Кемне вирни?

В ә с и м ә . Бәйләнмәгез аңа, ул сихерче түгел. Аның гаебе юк.

« Б о м б а » . Алайса, ычкын моннан, җен карчыгы.

Г а л и я б а н у . Әстәгъфирулла... Кемнәр булды соң бу? *(Чыгып китә).*

« П о п к а » *(Васимәгә).* А ты, падла, верни наших клиентов.

В ә с и м ә . Туктагыз әле, сез кемнәр?

« Б о м б а » . Нәрсә, танымыйсыңмы?

В ә с и м ә . Каян таныйм, күрмәгәч.

« Б о м б а » . Әй, «Попка», таныт әле үзеңә.

« К о р о л е в н а » . Иди-ка сюда, кому говорят.

В ә с и м ә . Кеше өенә бәреп керергә ни хакыгыз бар? Чыгып китегез.

« М и с с  П и п и с » . Плиз! Плиз! *(«Попка» белән икәүләп Васимәне эләктереп алалар. Кулларын каерып тоталар.)*

« Б о м б а » . Кайтар хәзер үк ирләрне. Кайтар клиентларны.

« П о п к а » . Или плати, падла. Башляй.

«Бомба». Түлә.

Вәсимә. Нәрсә түлим?

«Мисс Пипис». Баксы. Бабло.

«Попка». Рубль, падла. Плати.

Вәсимә. Ни өчен?

«Бомба». Әле һаман да безне танымыйсынмыни? Казанны ишеткәнең бармы?

Вәсимә. Булмаска.

«Попка». Южную трассу знаешь?

«Мис Пипис». Монако... Монлартр... Куртизанки беләсеңә?

«Попка». Про досуг слышала?

«Бомба». Шалаваны беләсеңме?

Вәсимә. Каян белим ди. Сәлимә, син ияртеп кердең, кемнәр алар?

Сәлимә. Телевизор карыйсың бит, әллә танымыйсынмы?

Вәсимә. Каян таныйм?

Сәлимә. Болар үзләре.

Вәсимә. Кемнәр?

Сәлимә. Ангыра баш. *(Вәсимәнең колагына пышылдый.)* Шулар.

Вәсимә. Синең ишеләрме?

Сәлимә. Авызына сугып тешеңне сындырырмын. Кайчан минем акча алганым бар?

Вәсимә. Фуражлата аласың.

Сәлимә. Алырсың синең сараныңнан.

«Бомба». Аңладыңмы инде безнең кем икәнлекне? Аңладыңмы кем булып эшләгәнебезне?

Вәсимә. Сез эшлисезмени?

«Бомба». Кем әйтте эшләми дип?

Вәсимә. Шулай дип әйттеләр.

«Попка». Какой тёмный народ. Час — тысяча рублей, поняла?

«Мисс Пипис». Йөз баксы. Доллар. Илле евро.

Вәсимә. Каян килсен миңа андый акча?

«Бомба». Алайса клиентларны кайтар.

Вәсимә. Ничек кайтарыйм? Мин сихерче түгел. Үз иремне дә югалттым.

«Бомба». Сихерчене ничек чакырдың, хәзер дә шулай чакыр.

«Попка». Иначе мы тебя... Зови, падла. *(Вәсимәне тезләндерәләр.)*

Вәсимә. Мин аны чакырмадым, теләдем генә.

«Мисс Пипис». Хәзер дә телә.

Вәсимә. Әй, сихерчеләр! Мин ирләр кире кайтсыннар дигән теләк телим.

«Попка». Не так. Жылый-жылый телә. Иначе мы тебя...

Вәсимә. Әй, сихерчеләр! Мин жылый-жылый теләк телим. *(Ана кәттә кызлар да кушыла.)*

Кәттә кызлар. Әй, сихерчеләр! Кызганыгыз безләрне. Өстебез ялангач булса да, тамагыбызны ач итмәгез. Безне эшсез калдырмагыз. Без бит иң борынгы профессия кешеләре. Без ирләр булганда эшсез тормадык. Безгә ирләр кирәк. Акчалы ирләр кирәк. *(Җырга күчәләр.)*

Кәрлә буйлы булса да,
Тәртә буйлы булса да,
Бик матур булмаса да,
Чын батыр булмаса да,
Калын кесәсе булса,
Түләр акчасы булса,
Ир заты кирәк безгә.
Көчкә басып торса да,
Чалкан ятып торса да,
Үз өендә булса да,
Безгә килеп кунса да,
Калын кесәсе булса,
Түләр акчасы булса,
Ир заты кирәк безгә.
Хәленнән килмәсә дә,
Нишлисен белмәсә дә,
Яткач йоклап китсә дә,
Эчеп эче күпсә дә,
Калын кесәсе булса,
Түләр акчасы булса,
Ир заты кирәк безгә.

«Бомба». Күренмиме берәрсе?

«Попка». Нет.

«Мисс Пипис». Ноу.

«Бомба» *(Вәсимәгә)*. Харап иттең безне, кабахәт хатын.

«Попка». Мы сейчас уходим. Завтра опять придём. Если денег не будет — убьём.

«Бомба». Сыерың булса, сыерың сат...

«Мисс Пипис». Сарыгыңны, казыңны сат...

«Бомба». Өстәвенә, өеңне сат. Безнең минималь хезмәт хакыбызны әзерләп куй. *(Китәләр.)*

Вәсимә *(Сәлимәгә)*. Син алып килдеңме аларны?

Сәлимә. Менә кызык. Нишләп мин алып килим?

Вәсимә. Син дә бит шулар ишеннән.

Сәлимә. Мыскыл итмә, ярыймы. Ир табылмаганга әллә мин гаепleme?

Вәсимә. Эшлибез дигән булалар. Шундый эш буламы?

Сәлимә. Дөрес әйтәләр инде анысы. Эшне кем үзе теләп эшли? Акча кирәккә эшлиләр. Боларга да акча кирәк. Менә эшлиләр.

Вәсимә. Акча кирәк дип инде.

Сәлимә. Нәрсәгә исең китте? Кул эшли бит, аяк белән йөреп эшлисең бит. Башы эшли бит башлы кешеләрнең. Эшләп акча табалар. Нигә ул гына эшләмәскә тиеш ди. Бүтән нәрсәләр эшләгәнгә рәхәтләнеп ятмасын.

Вәсимә. Бар чыгып кит.

Сәлимә. Кумасаң да чыгам. Мин бәйләнмәгәнгә рәхмәт әйт. Күрше Каенлык авылыннан Кылый Баһау өй башыңны төзәтеп китәм дигән иде. Менә хәзер син төзәтеп бирерсең. Бер ирең аркасында млиард кешене бетердең. Ярамаган ир. Синең белән торганына рәхмәт.

Вәсимә. Миңа нәрсә булган, ә, миңа нәрсә булган? Сөйрәлчек.

Сәлимә. Нәрсә дидең, ә, нәрсә дидең?!

Вәсимә. Нәрсә ишеттең — шуны әйттем.

Сәлимә. Күрсәтермен мин сиңа сөйрәлчекне. *(Вәсимәгә килеп ябыша. Тарткалашалар.)*

*Хәтимә керә.*

Хәтимә. Нишлисез сез, тилеләр. *(Хатыннарны аера.)*

Сәлимә. Күрсәтермен сөйрәлчекне. Вәсимең генә кайтсын, тартам да алам үземә. Әлегә хәтле тими йөрдем. Күрсәтермен. *(Чыгып китә.)*

Хәтимә. Нәрсә бүлешә алмадыгыз?

Вәсимә Әллә ниләр сөйләнә.

Хәтимә. Син дә инде. Киңәшми, нитми... Алкаш булса да ярап тора иде әле. Айныган арада ни дә булса эшләп ала иде. Без җыелышып калып нишләрбез икән?

Вәсимә. Аптырама, әтиләр сугышка киткәч, әниләр җыелып калганнар әле, үлмәгәннәр.

Хәтимә. Бала-чагага тимәсәләр дә ярар иде. Саниянең дүрт малаеның дүртесе дә юк.

Вәсимә. Үскәч ир була инде алары да.

Хәтимә. Харап итеп ташламасаң ярый инде дөньяны.

*Экранда язу:*
*Күпме эремәгән бозлар кала,*
*Күпме сөелмәгән кызлар кала.*

*Елап Айсылу керә.*

Хәтимә. Ни булды, Айсылу?

Айсылу. Бүген килеп алып китәм дигән иде.

Хәтимә. Кем?

Айсылу. Хәбиб... Хәбибулла. Ничә ел килеп алганын көттем. Башта Зәмирә артыннан чапты, аннан Хәбирәгә тагылды, аннары Асия үзенә каратты. Мина чираты җиткән иде. Синнән әйбәтен очрата алмадым дигән иде. Бер генә атна йөреп калган идек. Кочаклаттырмаган да идем. Башта өйлән, аннары кочакларсың дигән идем. Бүген килеп алам дигән иде. Кыз килеш картаям бит инде болай булгач. Вәсимә апа, җаныкаем, кайтар әле Хәбибулламны. Ирләр кулы тимәгән тәнем салкыная барганда сөенгән идем. Кайтар Хәбибулланы, Вәсимә апа.

Хәтимә. Кайтара алмый Хәбибулланы Вәсимә апаң.

Айсылу. Ник?

Хәтимә. Үз ирен дә кайтара алмый әле.

Айсылу. Вәсим абый кайтмаса да, Вәсимә апа аның кочагында ятып калган. Минем бит ирләр кочагы күргәнем юк.

Хәтимә. Йоклап йөрмиләр аны. Төсен-кыяфәтен, буен-сынын бар.

Айсылу. Бар дип нишлим инде. Егетләр кочагына барып егыла алмыйм ич инде.

Хәтимә. Бүтәннәр егыла бит. Әнә Казан мәктәпләрендә кызлар юк инде, дип сөйлиләр. Авыз ачып йөрмиләр аны.

Айсылу. Ни сөйлисен син, Айсылу апа? Авыз ачып йөрмичә, итәк ачып йөри алмыйм ич инде. Әни дә насыйбы чыгар дип әйтеп тора. Насыйбы чыккан иде дә... Вәсимә апа, жаныкаем, бәхетсез итмә мине.

Вәсимә. Туктале, жылама. Үземнең дә акылым чуалган. Барысы да шул Вәсим аркасында...

Айсылу. Вәсим абый беркөнне урамда туктатып мина да әйтте.

Вәсимә. Нәрсә әйтте?

Айсылу. Оятсыз сүз әйтте. Кочаклап кына карыйм әле, диде.

Хәтимә. Кочаклап карыйм дигән сүз оятсыз сүз түгел инде анысы.

Айсылу. Мин бит кыз кеше.

Хәтимә. Кыз кеше булгач, жылап йөр инде хәзер.

Айсылу. Әни дә жылый. Безнең нәселне Ходай каргаган, ди. Әнинең апалары кыз килеш картайганнар. Ул вакытта ичмасам сугыш булган, егетләре сугышта үлгән. Хәзер бит сугыш юк. Хәзер без тыныч заманда яшибез.

Хәтимә. Хатыннар гына жыелып калса, ирләр кебек кенә сугышмаслар әле. Алла сакласын.

Айсылу. Вәсимә апа, жаныкаем...

Вәсимә. Бар әле, канымны кайнатма.

*Айсылу кергәндәгедән дә катырак кычкырып елап чыгып китә.*

Хәтимә. Кияүгә чыгып карамаган шул, мескен. Нигә чыкканына үкереп жылар иде.

Вәсимә. Бар әле син дә, эчемне пошырып йөрмә. Алкаш дигән булып мена дигән иренне.

Хәтимә. Кара, кара, нәрсә сөйләнгән була. Алма кебек Вәсимен харап итеп ташлады да...

Вәсимә. Кем харап итте?.. Каян беләсең харап булганын?

Хәтимә. Сихерчене әллә мин чакырттыммы? Вәсим кебек ирем булса, сихерчегә биреп жибәрмәс идем әле. *(Пырлап чыгып китә.)*

Вәсимә. Харап иткән, имеш... Итәрсен, бар. Йөридер әле сихерче кызлар белән буталып. *(Арты белән эленеп торган Вәсим фотосын әйләндереп куя.)*

*Экранда язу:*
*Азгын инде азгынга,*
*Тик ялгыштым аз гына.*

Вәсимә *(фотога карап сөйли)*. Барысы да синен аркала, азгын. Бер нәфесенне тыйсан, нәрсә була иде. Мена хәзер юкка чыктын. Кайларда йөрисең икән инде?! Харап итеп ташламасалар ярый инде. Сихерче кызлар минем кебек кенә итмәсләр. Артыгын әйтеп ташладым бугай шул үзем дә. Кем уйлаган сихерчеләр ишетеп алыр дип. Бүтән чакта күренмиләр, монда жыелышып килгәннәр. Тегеләр тагын акча сорап килсәләр, нишләрмен? Әйт, азгын, акча каян табыйм? Синең машинага дип жыйган акчанны биреп жибәрәм инде. Хәбәр салырлык жирдә булсаң, хәбәр сал. Үтереп үк ташламаганнардыр. Ачуымны китерсән дә, яратып чыктым бит үзенә. Яратмаслык та түгел идең, чукынчык. Мена хәзер карап торасын инде елмаеп, мин жүләрдән көлеп. Дөрес көләсең инде. Кирәкмәгәнне эшләп ташлыйбыз шул кайчакта. Кызларыбыз әти кайда дип сорасалар, ни әйтермен... *(Жырга күчә.)*

Тели белсәң генә теләк,
Тели белмәсәң — имгәк, шул.

Тели белмәсәң — имгәк.
Тели белмичә теләдем
Мин шул имгәктер, димәк, шул,
Мин шул имгәктер, димәк.

Хәзер инде тешләп булмый
Терсәк якын булса да, шул,
Терсәк якын булса да.
Яннарында ятып булмый,
Карточкада торса да, шул,
Карточкада торса да.

*Шулвакыт караватт астыннан хатын-кыз киеменә киенгән Вәсим чыга. Аны күреп, Вәсимә куркып артка чигенә.*

Вәсим. Курыкма, бу — мин — Вәсим.

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ.

*Беренче пәрдәдәге күренеш.*

*Экранда язу:*
*Бирәсем юк үлгәндә дә,*
*Гүрләргә кергәндә дә.*

Вәсим. Курыкма, Вәсимәкәй. Бу мин — Вәсимең.

Вәсимә. Син каян килеп чыктын?

Вәсим. Кешеләр каян чыга соң, Вәсимәкәй?

Вәсимә. Дуракланма, әйт, кайда идең?

Вәсим. Караватт астында идем.

Вәсимә. Дөньяда бөтен ирләр юкка чыкканда син ничек калдың? Ходаем, булсаң да булырсың икән. Бөтенесен дә ишетеп яттыңмы?

Вәсим. Ишетеп яттым, Вәсимәкәй. Бик кызык булды. Теге шәрә ботлы кызларның гына ботларыннан тотып карыйсы килде дә, түздем.

Вәсимә. Хәзер нишлибез инде?

Вәсим. Белмим, син нишләрсең икән? Минем нишлисем билгеле — җир шарының хатыннары миңа калды бит.

Вәсимә *(Вәсимне кочаклап алып).* Бирмим, берәүгә дә бирмим.

Вәсим. Ничек инде «бирмим». Алай булмый ул, Вәсимә.

Вәсимә. Берәүгә дә бирмим. Алып кына карасыннар. Муеннарын чәйнәп, борыннарын тешләп өзәрмен. Үземнеке генә син.

Вәсим. Бүтән хатыннар нишләр?

Вәсимә. Бүтәннәрдә эшем юк. Ходай сине миңа калдырган.

Вәсим. Ходайны катнаштырма, Вәсимә. Аның мәшәкате болай да җиткән. Син борчылма, кем янына барсам да, сиңа кайтып егылам мин.

Вәсимә. Бирмим, бирмим!..

*Хәтимә керә.*

Хәтимә *(бу күренешне күреп).* Бәтәч! Ни бу? Вәсим. Син ич бу.

Вәсим. Мин шул.

Хәтимә. Ничек?

Вәсимә. Бер-ике сәгатькә җибәрделәр. Вәсимән сагынган, диделәр.

Хәтимә. Кайда идең соң?

Вәсим. Каф тавы артына җыйдылар безне. Андагы халыкны күрсәң... Барысы да ир-атлар.

Хәтимә. Минеке күренмәдеме?

Вәсим. Бергә идек. Әйдә, кайтып килик, дигән идем, кайтмыйм, ди. Анда аракыны бушка эчерәләр. «Татспиртпром»нан иң затлы аракылар килеп тора.

Хәтимә. Тиенгән икән, алкаш.

Вәсим. Бик сагынса, бик юксынса, хат язып җибәрсен Хәтимә, диде.

Хәтимә. Шулай дидеме?

Вәсим. Кайчан минем ялганлаганымны күргәнең бар?

Хәтимә. Дөресен дә сөйләгәнең юк инде. Хат язып тормыйм, телдән генә әйт. Кайтып китсә дә ярый дип әйтте диген. Тик кайтканда аек булсын дип әйтте диген. Йә, ташла әле салып шул хатын-кыз кулмәген, туеп беткән аны күреп. Вәсимә, салдыр әле күлмәгенне. *(Вәсимә Вәсимнән үз күлмәген салдыргач).* Менә ичмасам, күзгә рәхәт. Сөенденме, Вәсимә?

Вәсимә. Сөенденме дип, ярый инде.

Хәтимә. Кайту, ни дисән дә, киту түгел инде. Кил әле, кочаклап карыйм әле үзенне. Ирләрне кочаклау ничек була икән.

Вәсим. Мин пионер кебек, һәрвакыт әзер, Хәтимә. Тик Вәсимәдән рөхсәт ал.

Вәсимә. Сина ярый. Тик кочагына кермә. Президентлар кочаклашкан кебек кенә кыланыгыз.

Хәтимә *(Вәсимне кочаклап).* Абзар башын да ябып бирерсең инде, Вәсим.

Вәсимә. Юк инде анысы. Беләм мин абзар башы ябам дип кунып чыккан ирләрне.

Вәсим.
Ай-ли, Гөлҗамал,
Көтәм әле мин һаман.
Бер генә төн кундыр әле,
Абзар башыңны ябам.

Вәсимә. Тукта, оятсыз.

Хәтимә. Тыйма, Вәсимә, ирләр тавышы ишетәсе килә.

*Сәлимә керә.*

Сәлимә. Әстәгъфирулла! Өстә Гарифулла! Бу нәмәрсә?

Вәсимә. Бар, бар, бар! Чыгып кит!

Сәлимә. Тукта, жаным-кисәгем. Ничек инде чыгып китим? Ирләр яныннан чыгып киткән Сәлиманә кайчан күргәнең бар?

Вәсимә. Якын киләсе булма Вәсимгә. Вәсим! Кер карават астына.

Сәлимә. Юк инде, жаным-кисәгем. Бөтенебезне ирләрдән мәхрүм итеп, үзенә яшереп калдырдыңмыни? Алай булмый ул, жаным-кисәгем. Элек иренә тими түздем. Бу юлы бүлешәсең инде. Кара син аны, яшереп калдырган да үзе генә рәхәтләнмәкче була. Вәсим!

Вәсим. Нәрсә, Сәлимә?

Сәлимә. Киттек безгә, «Тефаль» чәйнегем кайнап тора, мич башында көмешкәм сайрап утыра.

Вәсим. Мин... Мин нәрсә... Вәсимә белән сөйләш. Вәсимә бит командир.

Сәлимә. Хатын-кыздан куркыр көнгә калдыңмыни? И жаным-кисәгем! Кара син аның карап торуларын. Нәрсә, кызыгасыңмыни мина?

Хәтимә. Сәлимә, ымсындырма ир-атны, ымсынырга гына торалар.

Сәлимә. Торсыннар. Ирләр ымсынмаган хатын-кыз хатын-кызмыни?! Дөньяда ирләр булмасын дип сихерчегә заявление язган хатын-кыз да хатын-кыз түгел.

Вәсимә. Авызыңны үлчәп ач, сөйрәлчек.

Сәлимә. Юк, жаным-кисәгем, мин сөйрәлмим, минем арттан сөйрәләләр. Синең арттан сөйрәлүче юк. Мин әле бер генә иренең дә гайбәтен сатып йөргәнем юк. Син шушындый айгыр кебек иренне яманлап йөрисең.

Вәсимә. Чыгып китәсенме, юкмы?

Сәлимә. Бир иренне, китәм.

Вәсимә *(кәжә тоягы ясап).* Менә моны күрәсенме? Вәсим, нәрсә авызыңны ерып торасың? Әйт үзенә, чыгып китсен.

Вәсим. Хатыннар сөйләшкәндә кысылырга ярамый, Вәсимәкәй. Кысылып үлүенне көт тә тор.

Вәсимә. Хәтимә, ни карап торасың? Әйдә, типкәләп чыгарыйк шуны.

Хәтимә. Тибәргә аның да аягы бар шул, Вәсимә. Ярый, чыгыйм әле мин. Вәсим, син абзар башы турында онытма инде, ярыймы. *(Чыгып китә.)*

Вәсимә *(Сәлимәгә).* Бар, ычкын син дә.

Сәлимә. Ычкынды ди, көтеп тор. Биреп тор Вәсимне бер төнгә.

Вәсимә. Вәсим, ни сөйли ул? Нигә дәшмисең? *(Елый.)*

Сәлимә. Нәрсә, хәзер жылыйсыңмыни? Алдарак жыларга иде, жаным-кисәгем.

Вәсимә *(чыгырыннан чыгып)*. Кит! Үтерәм.

Сәлимә. Ярый, бу юлы китәм. Мине үтерерсең дә, тегеләр килсә, нишләрсең? *(Чыгып китә).*

Вәсимә. Вәт кәнтәй, вәт кәнтәй! *(Вәсимгә).* Ә син ияреп китәргә генә торасың?

Вәсим. Кирәкмәгәч китәсең инде ул.

Вәсимә. Ничек инде ул кирәкмәгәч?

Вәсим. Кирәк булсам, сихерчеләр чакырмас идең.

Вәсимә. Мин чакырмадым, чакырмадым. Әйттем генә. Әйттем генә мин. Уйламыйча гына әйттем.

Вәсим. Уйлап әйт дип ничә әйттем үзеңә. Йә, ярый, тынычлан. Кил яныма, утыр. *(Вәсимәне кочагына алып караватка утыра).* Менә шулай.

Вәсимә *(иркәләнеп)*. Хәтимәнең абзар башын япсаң да, Сәлимә янына барма, ярыймы?

Вәсим. Кистереп әйтә алмыйм, Вәсимәкәй, дөнья бу. Минем күзләрем дөрес түгел, Вәсимә. Менә бер күзем сиңа карап торганда, икенчесе читкә карый. Ә анда чибәр хатыннар.

Вәсимә. Мин дә ямьсез түгел бит инде.

Вәсим. Түгел, Вәсимә, түгел.

Вәсимә. Сәлимәдән чибәррәк бит.

Вәсим. Әлбит тә, әлбит тә. Шуңа күрә Сәлимәгә түгел, сиңа өйләндем. Ләкин, Ходайның хикмәте, дөньяда синнән дә чибәррәкләр очрый. Нишлисең, күнел уйнап китә бит шунда. Бозау да бит кояш күрсә сикеренә.

Вәсимә. Азгынлык ул, Вәсим.

Вәсим. Азгынлыктыр, сүзем юк. Кызык кына, әйеме? Үгез ничә сыер артыннан йөри, аны азгын димиләр. Безгә нигә ярамый? Нигә инде Ходай мине кеше итеп яраткан? Үгез итеп ятса, син дә жыламас идең, Сәлимә дә сүгенмәс иде, Хәтимәнең дә абзар башын ябасы булмас иде. Әйдә, без болай эшлик, Вәсимә. Чакыр син сихерчеләреңне...

Вәсимә. Нәрсә инде сез барыгыз да. Минем сихерчеләрем түгел алар.

Вәсим. Ярый, ярый. Чакыр сихерчеләрне. Әйт, алып китсеннәр мине. Дезертир булганым өчен жәзасын да бирсеннәр. Армиядән качып йөрүче егетләрне судка бирәләр бит. Мине дә утыртып куйсыннар.

Вәсимә. Беркая да жибәрмим. Минеке генә буласың дип кияүгә чыктым, минеке генә буласың.

Вәсим. Алайса, кара инде үзеңә, үзеңә кара.

Вәсимә. Өйдән беркая да чыкмыйсың. Әйт, чыкмыйм диеп.

Вәсим. Әйтә алмыйм өзеп, әйтә алмыйм.

Вәсимә.
Әйт, жаным, жанкисәгем,
Бердәнберем, бәгырем,
Башым миңгерәү булганга
Белмәгәнмен кадерең.

Вәсим.
Вәсимәкәй, жанкисәгем,
Бакчамдагы багалмам.
Өйдән бер дә чыкмамын дип
Өзеп кенә әйталмам.

Вәсимә.
Якты дөньядан киткәч тә,
Белермен мин кадерең.
Синең каберең янында
Булыр минем каберем.

Вәсим.
Вәсимәкәй, жанкисәгем,
Асыл кошым, күз нурым.
Кайларда гына йөрсәм дә,
Өйгә кайтып куныр мын.

Вәсимә. Әгәр дә син өйдән чыксан, алып китәчәкләр бит сихерчеләр.

Вәсим. Китсәләр китәләр инде. Мин бит президентлар кебек — халык кайда, мин шунда.

Вәсимә. Президентлар да юк бит инде. Президент хатын-кыз булса, калган булыр иде урынында. Нишләрбез инде, нишләрбез. *(Тәрәзәдән күреп).* Галиябану әби килә, кач тизрәк.

*Экранда язу:*
*Мәхәббәт картлыкка карамый,*
*Картлардан көләргә ярамый.*

Вәсим. Керсен. Ул карчыкка мин нигә кирәк?

*Галиябану керә.*

Галиябану *(Вәсимне күреп)*. .Дөрес әйткән икән Сәлимә. Нихәл, улым?

Вәсим. Исән-сау, Галиябану әби.

Галиябану. Кайттыңмы, кайтардыларммы?

Вәсим. Качтым, Галиябану әби.

Галиябану. Качып була торган жирмени? Безнеке нигә качмый?

Вәсим. Сагындыңмы әллә, Галиябану әби?

Галиябану. Сагынмаска. Хәлил бит ул.

Таң әтәчләре кычкыра,
Әллә таң ата микән?!
Төшләремә керсә чыкмый,
Хәлил бәгърем, жанкисәгем,
Һаман ярата микән?!
Урам аша чыккан чакта,
Бүрәнәгә абындым.
Сәгате — ел, минуты — ай,
Хәлил бәгърем, жанкисәгем,
Шулкадәрле сагындым.

Күрденме үзен, нәрсә ди?

Вәсим. Бер ун елсыз кайтып булмас, ди.

Галиябану. Әстәгъфирулла. Йоздә була бит инде ул чакта. Мин нишләрмен? Мин бит ялгыз торырга, ялгыз йокларга күнекмәгән. Күз алдымда ир-ат булып болганып йөргән кешене күрергә өйрәнгән.

Вәсим. Бер-ике сәгатькә үзем барып килермен, Галиябану әби. Күз алдында болганырмын.

Галиябану. Әстәгъфирулла...

Вәсим. Хәлил бабайның киемнәрен киеп торырмын. Ул дип уйларсың.

Галиябану. Кит, юньсез. Хәлилемнең бөкресен каян аласың? Аныкы кебек килешле бөкре беркемдә дә юк. Тагын да шул Каф тавы артына барыр булсаң, әйт Хәлилемә, кайтып житсен. Вәт юньсез, кешенен ирләре кайтып житте, ул юк.

Вәсим. Яратмыйдыр үзенне, Галиябану әби.

Галиябану. Әстәгъфирулла. Хәлилнең Галиябануны яратмаганын кемнән ишеткәнең бар? Күзебез күзләрдән китмәде. Килер иде гармунын култык астына кыстырып тәрәзә каршына. Мин аны тәрәзәдән тартып алыр идем. Сөйләшеп туймый идек. Таң әтәчләре кычкырганда гына кайтып китәр иде. Арабыздан чебен дә очып үтәрлек түгел иде. Исмәгыйль дигән бер бай малае гына арабызга кереп маташты. Алтатар дигән мылтыктан Хәлилгә атты да әле, юньсез. Ярый әле Хәлилемне бүлнистә коткарып калдылар. Ул чакта безнең авылда да бүлнис бар иде. Хәзер яптылар. Хәзер бөтен нәрсәне ябалар, итәкне генә ачалар.

Вәсимә. Галиябану әби, озынмы әле сүзең?

Галиябану. Тынлыйсың килмимени? Шулайдыр шул, ир кадерен беләсезмени ул хәзерге хатыннар?! Без өйләнешкәч...

Вәсимә. Йөз тапкыр тыңлаган бар инде.

Галиябану. Мен тапкыр тыңласагыз да таманга килә әле сезгә.

*Жыр авазы ишетелә. Жырлап халыкара хокук яклаучылар килә.*

*Экранда язу:*
*Тимәгез кешегә, тимәгез,*
*Ул фәлән, ул төгән, димәгез.*

*Халыкара хокук яклаучылар жыры:*

Без — хокук яклаучылар,
Кешедә шәхесне саклаучылар.
Гаепленең гаебе булса да,
Кешене какмаучылар.
Да здравствует человек!
Кешенең хокукы яшәсен!
Ист лебе геноссе айн менш!

Вәсимә. Киләләр, Вәсим, кач тизрәк. *(Вәсим карават астына кереп кача.)*

Ләлия. Күрдек, качуның кирәге юк. Һәм, гомумән, кеше качып яшәмәскә тиеш, кешене карават астында яшәтү — кеше хокукларын бозу.

Маша. Человек! Звучит гордо! *(Карават астына керергә маташа.)*

Вәсимә. Кая барасын?

Маша. Я освобождаю человека.

Вәсимә. Күрсәтермен освобождаюынны. *(Яртылаш карават астына кергән Машаны сөйрәп чыгара.)* Чык, Вәсим. *(Вәсим чыга.)*

Ләлия. Исәнмесез, Вәсим әфәнде.

Маша. Здравствуй, Васимчик.

Элизабет. Гутен таг, һерр Васим.

Вәсим. Мин гаепле түгел.

Ләлия. Без сезне гаепләргә җыенмыйбыз. Сезне рәнҗеттеләр. Сезне хатыныгыз карават астында яшәтә. Бу — кешегә карата гаделсезлек.

Маша. Мужика не надо держать под кроватью, его место под юбкой.

Вәсимә. Өйрәтмә.

Элизабет. Вас ист дас?

Ләлия. Әнә фрау Элизабет та әйтә, безнең халыкара оешмада сезгә бирәр ярдәм кирәкмиме, ди.

Вәсимә. Кирәкми, кирәкми.

Галиябану. Ярдәм миңа кирәк. Хәлилемне кайтарыгыз.

Маша. Кто вы такая?

Галиябану. Я Халила невеста. Потерялся мой жених.

Маша. Ура! Сама старуха, сама по-русски знает. Вот она права человека.

Галиябану. Кайтарыгыз Хәлилемне.

Элизабет. Вас ист дас?

Ләлия. Әби, без — югалганны кайтаручылар түгел, без — кайтканны югалтмаучылар. Без кеше хокукын яклаучылар.

Галиябану. Минем дә картым белән яшәргә хокукым бар.

Ләлия. Әби, безгә эшләргә комачаулама.

Маша. Не мешай, бабушка. Не стариков, молодых надо беречь. *(Вәсимнең кулыннан алып читкәрәк китә.)* Ты мне нравишься.

Вәсим. Ты тоже.

Маша. Может где встретимся?

Вәсим. Конечно.

Вәсимә *(Вәсим белән Маша янына килә).* Нишлисез монда?

Маша. Не мешайте, у нас индивидуальная беседа.

Вәсимә. Үз ирең белән беседуй.

Маша. А где мой муж? Что сделала с моим мужем? Значит так, Ләлия ханум и фрау Элизабет. Моё предложение: отобрать у этой женщины мужика и сохранить его в особой изоляции.

Ләлия. Әйе, әйе. *(Вәсимгә).* Без сезне алып китәбез һәм аерым бер резервациядә яшәтәбез.

Вәсим. Ни өчен? Минем гаебем юк бит.

Ләлия. Ир булсын, гаебен табабыз без аның. Сине хатының янында калдырырга ярамый, син — бердәнбер экземпляр. Без сине якларга һәм сакларга бурычлы.

Вәсимә. Мин аны үзем дә саклыйм.

Элизабет. Вас ист дас?

Ләлия. Ирен саклаган хатын аны карават астында яшәтми.

Вәсимә. Мин кертмәдем аны карават астына, үзе керде. Вәсим, нигә бер сүз дә дәшмисең, алып китәләр бит үзеңне.

Вәсим. Мин нәрсә... Безнең сүз йөрми бит хәзер, сезнең сүз дөрес. Нәрсә эшләтәләр, шуны эшлибез инде хәзер.

Вәсимә. Ишәк булма, Вәсим бәгырькәем, тынлама алар сүзен, китмим, диген. *(Елап Вәсимнең кочагына ташлана.)*

Маша. Ай-ай-ай... Нельзя! Теперь он под нашей опекой. *(Вәсимне Вәсимә кочагыннан азат итәргә тели. Тарткалашалар.)*

Вәсим. Уходи.

Маша. Сама уходи. Ләлия ханум, что смотрите, помогите освобождать

человека. Фрау Элизабет, арбайте, шнель!

Вәсимә. Галиябану әби, харап итәләр. Бир әле таягынны.

Галиябану. Нишләп сина бирим ди, үземнең дә кулларым бар минем. *(Таяк белән халыкара кеше хокукларын яклаучыларны дөмбәсли. Тегеләр чырылдап чыгып качалар.)*

Вәсимә. Рәхмәт, Галиябану әби. Вәт заразылар, тапканнар гатавый мужик.

Галиябану. Ир бирмәк — жан бирмәк. Мин дә китим инде. Бәлкем Хәлилем дә кайткандыр. Исмәгыйль очрап, алтатарыннан атып үтермәсә, кайтыр, Алла боерса.

*«Урам аша чыккан чакта», — дип жырлап чыгып китә.*

Вәсимә. Вәт заразы. Татар ирләре күрсә, күзләре акая. Болай да инде тартып алып бетерделәр.

Вәсим. Алар алмады, без үзебез алдык.

Вәсимә. Сина хатын-кыз итәге генә күрсәт инде, жиленнән исерәсен.

Вәсим. Сез тәмле булганга, безнең ни гаебебез бар? Имиегез белән ниегез булмаса, мин сезгә әйләнеп тә карамас идем.

Вәсимә. Әйдә, Вәсим, берәр жиргә китик. Эзләп табарлык булмасын.

Вәсим. Кая?

Вәсимә. Безнең авылга.

Вәсим. Авылыгыз юк ич инде.

Вәсимә. Бик яхшы. Ул инде картадан сызып ташланган. Чурт та эзләп табалмас.

*Жыр ишетелә.*

*Экранда язу:*
*Безгә кирәкми ирләр,*
*Без үзебез маһирләр.*

Вәсимә. Кач, Вәсим, тагын киләләр.

Вәсим. Кая качыйм, жир шарында безнең караваттан башка урын юк. *(Карават астына кача.)*

*Жырлап «аллар» керә:*
Алларын алга манам,
Ал булса гына алам;
Иркәм алларның да алы,
Шуның утында янам.

Ал таң ата, таң ата;
Аллар алны ярата;
Аллар алларыма ятып
Кайгыларым тарата.

Хөллия *(Вәсимәгә)*. Кайда ул?

Вәсимә. Кем?

Хөллия. Затсыз, котсыз, юньсез, мәнсез, шөкәтсез, йогышсыз, көшпәтсез, ятышсыз жан иясе.

Наташа. Где он?

Шарлотта. ...

Вәсимә. Нәрсә сөйлисездер, анламыйм.

Сәлимә. Кыланма инде, Вәсимә. Вәсимне эзлиләр алар. Кайда ул?

Вәсимә. Каян белим, чыгып киткәндер.

Сәлимә. Алдашма инде, Вәсимә. Чыгып китсә, мин күрми калмас идем. Үз өеннән чыгып киткән ир мина кагылмыйча үтми. (Карават астына карап). Әнә ул. *(Карават астына кермәкче була.)*

Вәсимә *(Сәлимәне сөйрәп чыгарып)*. Якын барасы булма. Чык, Вәсим.

Вәсим *(чыгып)*. Сөбханалла, нинди чибәр кызлар. *(Хөллия каршына килә.)*

Хөллия. Якын килмә, жирәнгеч жан иясе.

*Вәсим Наташага таба атлый.*

Наташа. Не подходи, тварь вонючий.

Шарлотта *(каршына килгән Вәсимгә)*. ...

Хөллия *(Вәсимгә)*. Жыеныгыз, кабахәт жан иясе.

Вәсим. Кая?

Наташа. Ты осуждён на смертную казнь.

Вәсим. За что?

Наташа. За то, что остался жив.

Хөллия. Гүзәл җир шарының ямен бозып йөрергә бездән рөхсәт юк. Бетсен ирләр, яшәсен хатыннар!

Наташа. Понял?

Шарлотта. ...

Вәсимә *(Сәлимәгә)*. Син алып килдеңме аларны?

Сәлимә. Килдем шул. Сиңа гына рәхәт яшәргә димәгән. Сиңа да булмасын, миңа да... *(Алларга)*. Сез, кызлар, аны миңа бирегез, мин аны үзем буып үтерәм. Үлде дигән справкасын үзем илтеп бирермен.

Вәсимә. Юк!!! Үзегез алып китеп теләсәгез нишләтегез, Сәлимәгә бирмим.

Сәлимә. Син закон чыгаручы түгел, Вәсимә. Законны хәзер болар чыгара. Алар Вәсимне миннән үтерттерергә телиләр. Шулай бит, кызлар? Вәсимне мин үтерергә тиешме?

Вәсимә. Вәсим! Син нигә бер сүз дә дәшмисең?

Вәсим. Миңа кайсыгыз үтерсәгез дә ярый.

Вәсимә. Их, Вәсим, Вәсим! *(Җырга күчеп)*.

Яратышкан идек бит без,
Сөешкән идек.
Син минеке, мин синеке,
Диешкән идек.
Тулган айны икәү бергә
Калкыткан идек;
Таң аттырып, җирнең йөзен
Балкыткан идек.
Сандугачларны уятып
Сайраткан идек.
Гашыйклар гына җырларлык
Көй тапкан идек.

И, Вәсим, Вәсим... Ничек син ятлар кочагында үләргә ризалык бирәсең? Мин сине кочаклап үтерә алмас идеммени? (Вәсимне кысып кочаклап) Бирмим, берегезгә дә бирмим, үзем кочаклап үтерәм.

Шарлотта. ...

Наташа. Дура.

Хөллия. Тиле.

Сәлимә. Аерып алыгыз инде, ни карап торасыз?

Хөллия. Мин әле сезгә карап торам. Үзегез шундый чибәр, ниндидер җирәнгеч җан иясенә ымсынасыз. Килегез әле, кочаклыйм үзегезне. *(Сәлимәне кочаклый.)*

Сәлимә. Кит, кытыгымны китерәсең.

*Хөллия кочагыннан ычкынып чыгып йөгерә.*

Хөллия *(Кочаклашып торган Вәсим белән Вәсимәгә күрсәтеп)*. Моны нишләтәбез?

Вәсимә. Ул үлде. *(Вәсимне кочагыннан чыгара, Вәсим егыла)*. Күрәсезме, ул үлде. Мин кочаклап буып үтердем.

Наташа. Ну и баба. Мне бы такую. Пойдем с нами, дорогая.

Вәсимә. Куда?

Наташа. В рай. В раю с нами будешь жить.

Вәсимә. Ярый. Мин бу азгынны күмим дә килермен.

Хөллия. Көтәбез.

*Җырлашып чыгып китәләр.*

Вәсимә. Рәхмәт, Вәсимем. «Үл!», дип әйттем колагыңа, үлдең. Бу егетлегеңне мәңге онытмам.

Вәсим. Шундый тәмле итеп кочакладың, ничек инде үлмисең.

Вәсимә. Рәхмәт, бәгырь кисәгем. Мин сине һәрвакыт шулай кочаклармын.

Вәсим. Мин дә шулай үлөрмен.

Вәсимә. Кочаклашып үләрбез без үлгәндә дә.

Вәсим. Кочаклашып көләрбез без көлгәндә дә.

Вәсимә. Кызыкмассың Сәлимәне күргәндә дә.

*Экранда язу:*
*Әтисез бала булса да,*
*Ирләрсез бала булмый.*

*Гузелька белән Наташенькаңы ияртеп Варвара керә.*

Варвара. Гузелька, начинай.

Гузелька.
Вәсим абый, без сине
Кайткан өчен котлыйбыз.
Безнең әтиләрне дә,
Кайтарырсыз дип уйлыйбыз.

Варвара. Наташенька.

Наташенька. Дядя Вася,
спасибо,
Что вернулись вы к нам.
Наших пап тоже верните,
Они очень нужны нам.

Вәсим *(кызлар каршына тезләнеп)*. Нинди чибәр кызлар. Әниләрегез бармы?

Варвара. Балаларга якын килмәгез, педофил ясап, судка бирербез. Гузелька, продолжай.

Гузелька.
Вәсим абый, без Сезгә
Гел рәхмәтләр укыйбыз.
Үсеп житкәч, мәктәптә
Отличнога укырбыз.

Вәсим. Һай, рәхмәт. *(Варварага күрсәтеп)*. Бу апагыз кем?

Гузелька. Ул безнең воспитательница.

Вәсим. Шулаймыни? Исеме ничек?

Гузелька. Варвара Васильевна.

Вәсим. Бигрәк матур икән.

Варвара. Гузелька, не отвлекайся. Наташенька, продолжай.

Наташенька.
Дядя Вася, вы — герой,
Сбежали от плена.
Ищет моего папу Марата
Моя мама Елена.

Вәсим. Вот спасибо, вот спасибо! *(Варвара янына килеп)*. Сәгать ничәдә килим?

Варвара. Как всегда.

Вәсим. Сагындым.

Варвара. Я тоже. Пойдём, Гузелька. Наташенька, пойдём.

*Чыгып китәләр.*

Вәсимә. Котәм, дидеме?

Вәсим. Кем?

Вәсимә. Әй, жаным, кем дигән була. Белмиләр ди. Антун авылына барып йөрергә иренеп, безнен авылга китерттерден бит.

Вәсим. Нәрсә инде син? Ул бит маржа, мин мөселман.

Вәсимә. Синме мөселман? Сине бит теге дөньяда хәтта тәмугка да кертмәячәкләр. Тәмуг капкасына асып куячаклар.

Вәсим. Алай димә, Вәсимәкәй. Минем берәүне дә көчләгәнем юк. Үзегез килеп ябышасыз да безне гаеплисез. Безне көчләгән өчен теге дөньяда сезгә аерым статья булачак. Безнең аяк астына егылгач, без абынып егылабыз инде ул.

Вәсимә. Барасыңмы шул маржа янына?

Вәсим. Мин бармасам, син барырсың.

Вәсимә. Нишлим мин аның белән?

Вәсим. Күрдең бит — аллар заманы да зәңгәрләр заманы.

Аклар булды яман,
Ә кызыллар таман.
Аллар белән зәңгәрләргә
Калып бара заман.

Вәсимә. Тьфү!

Вәсим. Иске коега төкермә, Вәсимәкәй. Мәкальне онытма.

Вәсимә. Сиңа түгел лә, заманына төкерәм.

*Экранда язу:*
*Елата да, көлдерә дә мәхәббәт,*
*Елавы да, көлүе дә рәхәт.*

*Тышта шау-шу. Үкереп елаган Айсылуны житәкләп, Хәтимә керә.*

Хәтимә. Әйдә, әйдә, кемнән оялясың? Менә — Вәсим, менә — Вәсимә. Бу кыз баланы жылавыннан туктатыгыз. Әйт, Вәсим, күрдеңме син акай Габдулла малае Хәбибулланы булган жирендә? Күрдем, диген, исән-сау, диген, гел Айсылуны уйлый, диген, озакламый кайтырга да мужыт, диген.

Вәсим. Юлга чыккандыр да инде. Ерак ара бит, Каф тавы артында.

Хәтимә *(Айсылуга).* Ишетәсенме, нәрсә ди Вәсим абыең, кайтырга чыккан, ди. Ничә көн кайтыр икән, Вәсим?

Вәсим. Йөгереп кайтса, иртәгә монда булачак.

Хәтимә *(Айсылуга).* Ишетәсеңме, иртәгә монда булачак, ди. Ишетсен колагын, ирләрне кирәгеннән артыгын яратырга ярамый.

Айсылу. Ул бит әле минем ирем түгел.

Хәтимә. Булыр, «Алла бирсә»не әйтсән.

Айсылу. Алла бирсә.

Хәтимә. Менә шулай. Гел җылап тормыйлар ул. Кияүгә чыккач та өлгерерсең. Әтисенә охшаса, җылатыр әле Хәбибуллаң.

Айсылу. Ул андый түгел.

Вәсим. Сөйләшеп утырдык Хәбиб белән. Айсылудан бүтән беркемгә дә карамаячакмын, ди. Айсылудан да чибәр беркем дә юк дөньяда, ди.

Хәтимә *(Айсылуга).* Ишетәсеңме, нәрсә ди Вәсим абыең?

Вәсим. Вәсим абый, диде Хәбиб, исән-сау кайтып җитеп, Айсылу синең янга мине сорашырга килсә, мине юксынып җыласа, кочагыңа алып юат, диде.

Вәсимә. Юатырмын менә мин сина! Кочаклап кына кара.

Вәсим. Кызык син, Вәсимә. Мин түгел бит, Хәбиб әйтте.

Вәсимә. Әйтмәде, әйтмәде. *(Айсылуга).* Йөрмә, җыен юк-барга ышанып. Хәбибне дә, чуртны да күрмәде ул. Караватт астында ятты. Син дә йөрмә, Хәтимә, кыз баланы алдап.

Хәтимә. Әй, Вәсимә, Вәсимә! Син Вәсимне яманлаганда, синең яклы булып йөри идем, болай булгач, Вәсим ягына күчәм.

Вәсимә. Күчәрсен дә. Ир күргәч, башыгыз әйләнде.

Хәтимә. Киттек, Айсылу. Үзем табып бирәм Хәбибулланы.

*Үкереп елаган Айсылуны җитәкләп чыгып китә.*

Вәсим. Син — надан хатын, Вәсимә. Кеше гашыйк булган, беләсеңме син шуны — гашыйк булган, гашыйк булган!

Вәсимә. Булса. Сиңа түгел бит, нәрсә кочакларга үреләсең.

Вәсим. Әй, Вәсимә, Вәсимә... Кеше җанын аңламыйсың син. Кешене юатырга кирәк, кешенең өметен өзәргә ярамый.

Вәсимә. Бик күпләрне өметләндердең, беләм.

Вәсим. Их, качасы калмаган карават астына. Халык белән бергә беткән булсам. Халыктан аерылырга ярамый шул, ярамый. Президентлар бит: «Мин халык белән», — дип юкка гына әйтми. Алар халык белән бергә булгач, тамаклары да тук, өсләре дә бөтен. Халык үзе ач булса да, авызыннан өзеп аларны ашата. Ничек син, Вәсимәкәй, шуны аңламыйсың?

Вәсимә. Президентлар Айсылу кочаклап йөрми, үз хатынын кочаклый.

*Экранда язу:*
*Безгә кирәкми секс,*
*Булсын безгә тик бакс.*

*Тантана иткән кыяфәт белән шаркыллап көлеп Сәлимә керә.*

Сәлимә. Киләләр! Киләләр, Вәсимә. Күрсәтәчәкләр алар сиңа. Үтүт Вәсимең, алып китәчәкләр. *(Кул изәп чакырып).* Һәй, һәй, һәй! Тизрәк килегез. Мона ул Вәсимә, менә ул Вәсим. *(Тәтәйләр төркеме кергәч).* Менә ул Вәсим, алыгыз.

«Попка». Вот как. Синмени инде ул Вәсим?

Вәсимә. Якын килмәгез. *(«Попка»га ябыша.)*

«Попка». Уберите её.

*Тәтәйләр Вәсимәне бөтереп алалар.*

Вәсимә. Караул, караул!..

«Попка». Заткните рот. *(Вәсимгә).* Вәсим, Вәсим... Ярыйсы экземпляр. Где другие? Бүтәннәр кайда?

Вәсим. Кем кирәк сезгә?

«Попка». Безгә кем кирәген әллә белмисеңме? Где остальные мужики?

Вәсим. Мин каян белим? Әнә хатыннан сорагыз.

«Попка». Какой хатын... Нам не нужна хатун, нам мужик нужен.

«Мисс Пипис». Плиз, плиз.

Сәлимә. Чишен, диләр, Вәсим. Тамагың туймый иде, хәзер туяр.

Вәсимә. Ходаем, нәрсә соң бу? Вәсим, ни карап торасың? Бир шуларга кирәкләрен.

Вәсим. Аларга акча кирәк, мин кирәкмим.

Вәсимә. Бир шуларга, бир. *(Түшеннән акча чыгарып).* Мә, бир. Сөт саткан акчама тыгылсыннар.

«Попка». Юк, түти, моның белән генә котыла алмассың. Ә без күбәү жир шарында. Кайтар мужикларны. *(Вәсимнен изүеннән алып).* Кайда бүтәннәр? Әйт, югыйсә печәбез.

«Бомба». Да, кастрировать будем.

Сәлимә. Кызлар, кызлар! Теләсәгез нәрсә эшләтегез, тик печмәгез генә.

«Попка». Әй, шалава! Тентегез өйләрен, безгә яраклыларын барысын да алыгыз.

*Тәтәйләр кайсы кая китеп актарыналар.*

Вәсимә. Сәлимә, бәгырькәем, зинһар, алып кит шуларны.

Сәлимә. Әһә, мин дә бәгырькәем булдыммы? Алып китәм, бер кичкә биреп тор Вәсимеңне.

Вәсимә. Юк, юк, теләсә нәрсәмне ал, Вәсимне бирмим. Бер кичкә дә, бер сәгатькә дә, бер минутка да бирмим. Бирмим, бирмим, бирмим!

*Вәсимне кочагына алып, караватка ава. Ут сүнә. Бөтен шау-шу тынып кала. Ут янганда, караватта Вәсимә ыңгыраша, бәргәләнә.*

Вәсим *(торып утырып).* Нишлисең син? Вәсимә, Вәсимә!

*Вәсимә уянып торып утыра. Ни булганын аңламыйча, Вәсимгә карап тора.*

Вәсимә. Ни булды ул?

Вәсим. Әллә куркыныч төш күрдеңме?

Вәсимә. Төш идемени ул?.. Синме соң бу, Вәсим?

Вәсим. Янында кем ятарга тиеш иде соң?

Вәсимә. Йә, Алла. Аллага шөкер, уяндым.

Вәсим. Нәрсә күрдең, миңа да сөйлә.

Вәсимә. Сөйләрлек түгел ул, Вәсим... Кил әле, бер кысып кочаклыйм әле үзеңне. Син бит минем бердәнберем. Син минем алтыным, син минем...

Вәсим. Ни булды? Ятканда сыртың куеп яткан идең. Азгын дип сүккән идең.

Вәсимә. Сүккән идем, яткан идем... Ачуланма, зинһар. Азгының азгын инде. Аннары шунысы да бар бит, Вәсим: хатыннар күзе төшмәслек ир дә ир түгел инде. Тик Сәлимәгә генә карама, ярыймы? И-и-и-и, минем Вәсимем! Вәсимем минем! Вәсимем бар бит минем! Ишетәсеңме, минем Вәсимем бар. Вәсимәнең Вәсиме бар!.. *(Экранда: «Бетсен ирләр, яшәсен хатыннар!» дигән язу чыккач),* Алыгыз, алыгыз ул лозунгыны. Кирәкми ул язу. «Яшәсен ирләр, яшәсен хатыннар!»

*Экранда: «Яшәсен ирләр, яшәсен хатыннар!» дигән язу чыга.*

*Пәрдә.*

Туфан
Миңнуллин

# ГО-О-О-ОЛ!

САТИРИК КОМЕДИЯ

**Катнашалар:**

Әти, Әни, Малай, Кыз, Шул, Теге — 1 нче баскыч кешеләре.

Бу, Ул — 2 нче баскыч кешеләре.

Беркем түгел, Беренче урынбасар (БУ), Икенче урынбасар (ИУ), Беренче бүлек мөдире (ББМ), Икенче бүлек мөдире (ИБМ) — 3 нче баскыч кешеләре.

Беренче министр, Икенче министр, Өченче министр, Дүртенче министр, Артист, Эшмәкәр — 4 нче баскыч кешеләре.

*Сәхнәдә баскычлы пирамида. Иң астагы баскычы — сәхнә идәне. Пәрдә ачылганда, боз сараенда хоккей уены баргандагы сызгырулар, улаулар, такытокылы музыка, «шайба-шайба», дип кычкырулар. Пәрдә ачылгач, ут пирамиданың беренче баскычын яктырта. Анда гади халык вәкиле ир, малае белән телевизордан хоккей карый. Читтәрәк кыз бала дәрес әзерләп утыра.*

Малай *(бар көченә кычкыра, сикереп).* Го-о-ол! Го-о-ол! *(Кыз килеп малайга тибә. Малай аңа кизәнә.)* Нишлисең, дура?

Кыз. Минем дәрес әзерлисем бар. Кычкырма.

Малай. Ә син нәрсә тибәсең? Дура!

Кыз. Син үзең дурак!

Малай. Дура!

Кыз. Дурак!

Ир. Әй, житте сезгә!

Малай. Ә нигә ул тибә?

Кыз. Ә ул нигә кычкыра? Мин дәрес әзерлим.

Ир *(малайга).* Утыр! *(Кызга).* Ә син әниең янына чык!

Кыз. Чыкмыйм.

*Дәрес әзерләргә утыра.*

Малай. Әти, әти, буллит!

Ир. Күрәм. Давай, давай!

Малай. Давай, давай! Го-о-ол! Го-ол-ол!

*Кыз елап кухняга кереп китә. Аннан әнисе белән чыгалар.*

Әни. Нишлисез инде сез?

Ир. Тукта әле, кычкырма.

Әни. Кычкырма, дип... *(Малайга).* Ә син нәрсә үкерәсең?

Малай. Кычкырма, диләр бит сина.

Әни. Нәрсә дидең? Мин сине... Күрсәтермен кычкырманы *(Малайнын якасыннан эләктереп).* Бар, әзерлә дәресеңне!

Әти. Тимә!

Әни. Тимәм менә! Кара син аны...

Әти. Тимә, диләр сина.

Әни. Син аны азындырасың.

Әти. Бар урынына. *(Малайга).* Ә син тик кенә утыр.

Кыз *(малайга)* Дурак. Әниләргә кычкырмыйлар.

Әти. Остарма. Барыгыз.

*Кыз тагын дәрес әзерләргә утыра. Әни кухняга чыгып китә.*

Малай. Әти, әти, кара, кара, нишли...

Әти *(телевизордагы хоккейчыга кычкыра).* Кая барасың, ишәк? Куып тот, куып тот, хайван. Молодец!

Малай. Судью на мыло. Әти, әти, дөрес сызгыртмады бит, әйеме?

Әти. Сатылган, сволочь.

*Малай ике бармагын авызына тыгып сызгыра. Кыз тагын елап әнисе янына кереп китә.*

Әни *(чыгып).* Туктыйсызмы сез, юкмы?

Әти. Әйттеләр бит сина.

Малай. Әти, әти, кертә, кертә.

*Әни барып телевизорны сүндерә.*

Әти. Нишлисең син, дура! Ну-ка кабыз!

Әни. Чыгарып ыргытам ул телевизорны. Рәтле әйбер күрсәтми.

Әти. Ыргытып кара. *(Телевизорны кабыза.)*

Малай. Беренче период беткән.

Әти. Сүндереп тор. *(Әнигә).* Ашарга бармы?

Әни. Әнә хоккеегыз ашатсын. Аталлы-уллы...

Әти. Йә, булды. Чыгар ашарга.

Әни. Ничек чыгарыйм, өлгермәгән әле.

Әти. Нишләп йөрисең соң анда?

Әни. Яна эштән кайттым. Хакки караганчы пешерә торырга иде.

Әти. Остарма.

Малай. Әти, әти, безнекеләр жинәчәк, әйеме?

Кыз. Безнекеләр дигән була. Безнекеләр юк та әле анда.

Малай. Әй, чүпрәк баш, син нәрсә беләсең.

Кыз. Белмәс сина. Безнең математика укытучысы сөйләп тора.

Әни. Укытасы урынга хакки сөйлиме? Барысы да женләнгәннәр. Әллә нәрсә диярсең. Боз өстендә резин кисәге куып йөреп.

Кыз. Аларга әле аена милиун сум түлиләр ди.

Малай. Әти, әти, күпме ала икән хоккеист?

Әти. До хрена.

Әни. Балалар алдында рәтле генә сөйләш.

Әти. Остарма. Ашарга өлгерт.

Әни. Кайный инде, нишләтим. Ни кызыгын табасыздыр шунын?

Кыз. Безнең Мария Сергеевна әйтә, хоккей, футбол — игра для слабоумных, ди.

Малай. Нәрсә белә ул химичка. Дура, әйеме, әти?

Әни. Әйтмә укытучын турында андый сүз.

Малай. Безнекеләр отса, өченче урынга чыга, әйеме, әти?

Әни. Күчми калырсың әле, шул булыр.

Малай. Хәзер күчми калсаң да күчерәләр, әйеме, эти?

Эти. Буламы инде ашарга? Икенче период башлана.

Әни. Әйтеп торалар лабаса.

Эти. Бер ашарга пешереп ашата алмыйсың.

Әни. Бер эшең юк, пешер дә аша. Эш юк дип кайтасың да шул хакиеңа, футболыңа ябышасың.

Эти. Мин гаеплемени эш булмаганга. Әнә Америкага әйт, кризис уйлап чыгармасыннар.

Әни. Хаки карап ятарга кризис түгел.

Эти. Нәрсә аңлыйсың син, чүпрәк баш.

Әни. Син күпме аңлыйсың инде, голдан башка рәтле сүз дә белмисең, көне-төне өйдә хакки карап ятып.

Эти. Акча бир, двориска барып карармын.

Әни. Шул гына житмәгән. Болай да инде квартир бәяләрен дә ел саен арттырып торалар. Хакки да футбол, хакки да футбол.

Кыз. Волейбол белән баскетбол бар әле, әни. Туплы хоккей бар.

Әни. Эшләргә юк диярсең.

Кыз. Мария Сергеевна әйтә, эти игры нужны, чтоб отвлечь внимание народа от проблем, ди.

Эти. Күп сөйләнсә, күрсәтерләр әле проблеманы. Кирәкмәгәнне тыңлама анда.

Кыз. Хоккей бик кирәк инде.

Эти. Остарма.

Малай. Нәрсә беләсең, чүпрәк баш, әйеме, эти?

Эти. Тик кенә утыр. Дәресеңне әзерлә.

Малай. Хоккей бит, эти.

Әни. Әнә күрше Хәмитне дә кыскартканнар иде, эш тапкан. Ә син — хакки.

Эти. Життеме инде сиңа. Хәмиткә чыгасың калган.

Әни. Хакки да футбол, театрга бармаганга биш былтыр.

Эти. Нәрсә калган анда. Көләсе килеп тормый әле монда.

Әни. Көлдерү генә түгел анда. Яшьләргә дә өйрәтәләр.

Эти. Өйрәтә. Өйрәтүчеләр кубәйде.

Әни. Ә хакки нәрсәгә өйрәтә?

Эти. Туктыйсыңмы син, юкмы? Аңла, чүпрәк баш, миңа ял итәргә кирәк.

Әни. Ял?! Нинди ял тагын?

Эти. Синең бытырдавыңны ишетеп арыйм мин.

Әни. Нәрсә, мин юкка бытырдыйммыни?

Эти. Ярый, булды, булды, икенче период башлана.

Малай. Давай, давай!

Эти. Давай, давай! Нәрсә карап торасың, ишәк?! Миллиун сум аласың.

Малай. Эти, судья тегеләрне яклый, әйеме?

Эти. Сатылган, барысы да сатылып беткән.

Малай. Жуликлар, әйеме, эти?

Кыз. Жуликларны төрмәгә утырталар.

Малай. Әй, син нәрсә беләсең.

Кыз. Белмәс, Мария Сергеевна әйтә, коррупция, ди.

Эти. Сөйләшмәгез.

Әни *(чыгып)*. Аш өлгерде, әйдәгез.

Малай. Монда чыгар.

Әни. Чыгарырмын мин сиңа. Тәмам азыңдың.

Эти. Сөйләшмәгез, диләр сезгә.

Әни. Аш өлгерде, диләр сиңа.

Эти. Күзең чыккан мәллә, чүпрәк баш. Күрмисеңмени, уйныйлар бит әле.

Әни. Аларның туктыйсылары юк.

Эти. Житте, диләр сиңа. Житте, диләр.

*Сикереп тора да Әнине эткәләп кухняга кертеп жибәрә.*

Кыз. Тимә әнигә!

*Эти кызны да кулыннан тотып кухняга озата.*

Эти *(урынына килеп утыра).* Ни булды анда?

Малай. Безнекеләргә керттеләр.

Эти. Ишәкләр.

Малай. Тәнәфес. Эти, ашыйбызмы?

Эти. Әйдә. (*Кухня ягына юнәләләр. Кухнядан Әни белән Кыз чыгып киләләр. Кыз елый.)* Кая барасыз? *(Әни дәшми генә ишеккә юнәлгәч).* Кая барасыз, дим?

Әни. Яшәгез үзегез генә хаккиегыз белән.

Эти. Тукта. *(Әни туктамагач).* Тукта, диләр. *(Әни белән Кызның каршыларына төшә.)* А ну-ка кухняга!

Кыз. Кычкырма әнигә.

Эти. Кычкырмам менә. *(Малайга).* Әй, малай, барыгыз әле кухняга апаң белән.

Кыз. Бармыйм.

Эти. Кемгә әйтәләр.

Кыз. Син тәрбиясез.

Эти. Ке-е-ем?! *(Кызны жилтерәтеп кухняга кертеп жибәрә. Малай да кереп киткәч, Әнигә).* Син нәрсә балаларны мина каршы котыртасын? Сугып жибәргәнне көтәсеңме?

Әни. Сук, әйдә, сук. Шул сугып үтерәсең генә калды инде.

Эти. Шул хоккей беткәнне дә көтмисен.

Әни. Синең ул хаккиеңның бетәсе юк.

Эти. Бетмәсә... Нишләргә кушасың мина?

Әни. Жүләрне генә кушып эшләтәләр. Аракы эчү дә хакки, аракы эчү дә футбол. Сина бүтәне кирәкми.

Эти. Сина нәрсә кирәк соң?

Әни. Минем кешечә яшисем килә.

Эти. Яшә. Сина кем мишәйт итә.

Әни. Син.

Эти. Мин? Нәрсә, мин мишәйт итә башладыммыни? Бүтәнне таптынмыни?

Әни. Туктале. Утыр әле. Утыр әле шунда. Нишләдең син, бәгырькәем? Мондый түгел иден бит син. Футбол уйнарга стадионга йөри иден. Кышларын мине ияртеп чаңгы шуарга алып китә иден. Сүз әйтә идемме? Күнелле иде. Хәзер шул телевизорга терәләсен дә каласын. Малайны шул телевизорга кадаклап куйдын.

Эти. Син карамыйсын чтоли телевизор?

Әни. Мин кирәген генә карыйм.

Эти. Мин дә үземә кирәген карыйм.

Әни. Сина шул хакки гына кирәкме? Шашасын бит инде. Йә, нәрсә бирә ул сина? Нәрсә бирә малаена? Үзебез укымыйча калдык. Болар да безнең сыман булсынмы?

Эти. Укыганнар да урам себерә.

Әни. Син дә себер. Эшнең ни ояты бар.

Эти. Юк инде, син миннән дворник ясама.

Әни. Ә болай кем соң син?

Эти. Булды, житте. Яшисем килми минем дөньягызда. Бөтен кызыгым шул.

Әни. Көне-төне хакки карауны яшәү дисеңме? Иртәгә ял. Авылыгызга кайтып килик. Әниеннең өен кар баскандыр. Күрәп килик.

Эти. Килсен монда, ятмасын авылым дип.

Әни. Нишләсен монда? Безнең ызгышканны карап ятсынмы?

Эти. Ызгышма, сина кем кушкан. Ике сәгать хоккей караганга түзмисен.

Әни. Ике сәгать кенә түгел, жаным. Синең уеңда, күнеленә шул. Кызынның исемен белмисен, дөньядагы хоккеист, футболчыларның фамилиясен беләсен.

Эти. Син инде бигрәк. Ничек инде кызымның исемен белмим?

Әни. Класс житәкчесе әйтә.

Эти. Нәрсә инде ул. Капылт сорады да.

Әни. Яшьләр бит әле без, жаным. Рәтле сүзен бетте. Элек «әнисе» дип эндәшә иден. Хәзер — чүпрәк баш.

Эти. Кысылма, ишетәсен килмәсә.

Әни. Мин кысылмый, кем кысылсын. Хатының бит мин синең.

Әти. Ярый, булды. Әйдә ашарга. Өченче период башлана.

Әни. Карама, түз.

Әти. Син нәрсә, ычкындың мәллә?

*Боз сарае. Тамашачылар утырган трибуна. Ут янәшә утырган Эшмәкәр белән Артистны яктырта. Хоккей баргандагы тавыш бераз тына, тәнәфес вакытын игълан итәләр.*

Эшмәкәр. Чыгып керәбезме?

Артист. Юк, буталып йөрисем килми.

Эшмәкәр. Сез, артистлар, сәхнә арты тараканнары. Сездә бит тамашачы да үзегез кебек. Йөргән булалар тын гына тәнәфес вакытында. Монда күнелле.

Артист. Салып алгач, күңелле була инде.

Эшмәкәр. Монда да салып йөрүчеләр күп түгел. Монда азарт. Монда кеше адреналин бушата. Сездә бит адреналин жыя. Монда кеше ял итә, Сездә арый. Чөнки уйлый. Уйлану ул кешене арыта. Хәтта комедияләрегездә дә Сез кешене уйлатасыз.

Артист. Уйламыйча да яшәп булмый бит.

Эшмәкәр. Уйлар өчен көн бар. Кичен кеше ял итәргә тиеш.

Артист. Син бу тамашаны ял итү дип уйлыйсынмы?

Эшмәкәр. Ял. Мин монда онытылып торам.

Артист. Ә мин менә онытылып тора алмыйм. Ничәмә мең кешенең егерме мужикның боз өстендә резина куып йөрүен күрәм.

Эшмәкәр. Бу — спорт.

Артист. Юк, спорт түгел. Бу безнең театрдагы кебек үк тамаша. Тик артистлары гына башка. Бездә кешене уйланырга өйрәтүче артистлар, монда кешене уйланудан биздерергә тырышалар.

Эшмәкәр. Кайсы яхшырак соң?

Артист. Белмим. Бездә безнең уенга кул чабалар, монда сызгыралар.

Эшмәкәр. Аның каравы, сездә хезмәт хакын тиенләп түлиләр, мондагы «артист»ларга миллионлап.

Артист. Ник алай икәнен беләсеңме соң?

Эшмәкәр. Әйтеп кара.

Артист. Без идеягә хезмәт итәбез. Без хәтта бушка да эшли алабыз. Шуңа күрә болар беркая да бара алмыйлар дип безгә түләмиләр. Ә боз артистларына түләмәсәң, китә дә бара. Уйларга теләмәүчеләргә без кирәк түгел, мондагы артистлар кирәгрәк. Шуңа күбрәк түлиләр. Акчага резина, футбол ... куучылар күбәйгән саен, кешелек дөньясы аңгыралана бара.

Эшмәкәр. Димәк, мин аңгыра?

Артист. Ангыра түгел, надан һәм ялкау сакаллы адәм баласы. Син спектакль караганда арыйсың, чөнки уйларга иренәсең.

Эшмәкәр. Ә нигә кирәк уйларга?

Артист. Кайвакыт мин дә шулай уйлыйм. Чыннан да, нигә уйларга? Ник тагын шунда дөньясы мәтәлеп китми. Нигә ул тел, милләт дип сөйләнүләр? Нинди телдә сөйләсәң дә, барыбер түгелмени? Сөйләшмәскә дә була хәтта. Шайба! Гол! дигән сүзне кычкырырлык телең булса җитмәгәнме? Ләкин бит хайванның да алай кычкырырлык теле бар.

Эшмәкәр. Сиңа шул тел кирәк тә милләт кирәк.

Артист. Сиңа да кирәк ул.

Эшмәкәр. Юк, миңа барыбер. Мин — бизнесмен. Акчаның теле дә, милләте дә юк.

Артист. Бар, дускай. Теле, милләте булган акча дөньяда кыйммәт йөри. Чөнки ул акча басучыларның үз телләре бар, милләте бар.

Эшмәкәр. Күңелсез синең белән.

Артист. Мин түгел, син үзең мине эзләп табасың.

Эшмәкәр *(паузадан соң)*. Шулай

шул. (Кесәсеннән эчемлек салынган жыйнак кына савыт чыгарып). Йотып куясыңмы?

Артист *(савыт авызыннан йотып куеп).* Театрга коньяк салынган савыт тотып килмиләр иде элек. Хоккей, футбол болельщиклары ул заразаны ияртеп килде. Театр ул аек акыллылар йөри торган урын шул.

Эшмәкәр. Син алай ук нитмә инде. Спорт кирәк булмаса, кешеләр уйлап чыгармас иде.

Артист. Әйтеп торам мин сина — бу спорт түгел. Бу — тамаша. Менә синең белән мин кәшәкә тотып шайба куып йөрсәк, ул спорт булыр иде. Бу спорт белән шөгыльләнергә иренчәк адәм балаларының тамашасы гына. Элек гладиаторлар сугышын карап кемнәрдер кәеф-сафа корганнар, хәтерлә.

Эшмәкәр. Кемнәр алар гладиаторлар?

Артист. Коллар. Шулар сугышып берсен-берсе үтергәннәр. Шуны карап кул чабып торганнар.

Эшмәкәр. Хәзерге хоккеистлар, футболистлар кол түгел, агай-эне. Алар — миллионерлар.

Артист. Хәзер дөнья үзгәрде инде. Хәзер трибунада акырып утыручылар — коллар.

Эшмәкәр. Мин дәме?

Артист. Син дә, бүтәннәр дә. Хәтта иң өстәге аерым кабиналарда утыручылар да.

Эшмәкәр. Син нәрсә инде?

Артист. Нәрсә инде дип... Артист кына шул...

Эшмәкәр. Да-а-а... Кызык синең белән.

Артист. Әле генә күнелсез дигән идең.

Эшмәкәр. Күңелсез дә, кызык та. Сиңа нәрсә, монда кызык түгел инде, әйеме? Безнекеләр отса да, оттырса да барыберме?

Артист. Кайда соң монда безнекеләр? Менә авылда малай чакта без уйный идек, күл каткач. Анда безнең урамныкылар һәм дә түбән очныкылар ярыша идек. Монда кайсы синеке? Монда синеке дә, минеке дә юк. Монда акча уены.

Эшмәкәр. Сөйләшеп булмый синең белән. Нәрсә, кайтып китәбезме, карап бетерәбезме?

Артист. Сине имезлектән аеру килешмәс инде.

Эшмәкәр. Кызыгын бетерден.

Артист. Икенче тапкыр мен сум түләп алып килмәссен.

Эшмәкәр. Акчадамыни эш...

Артист. Нәрсәдә соң?

Эшмәкәр. Йотып куясыңмы?

Артист. Китер. Безнекеләр отсын өчен йотып куйыйк.

Эшмәкәр. Көлмә инде. Буш вакытны ничек тә уздырырга кирәк бит, гел акча санарга димәгән. Ардыра. Сезгә рәхәт. Кул чапканга алданып куанасыз.

Артист. Нигә? Синең кул чапканга алдану рәхәт бит ул. Син бит кулыңны мине яратканга чабасың.

Эшмәкәр. Килештереп уйныйсың бит.

Артист. Беләсенме, мине мондый тамаша караудан бер яһүд егете биздерде, Мәскәүдә укыган чакта. Без татарлар, урыслар тулай торакның кызыл почмагына жыелабыз да хоккей карыйбыз, ах-ух киләбез, ур-ра кычкырабыз. Арада бер яһүд тә юк.

Эшмәкәр. Яһүд ул евреймы?

Артист. Әйе. Беркөнне яһүд егете Михаил миңа әйтә: «Син акыллы гына егет, нигә син анда вакыт уздырып утырасың, — ди. — Ул резина кисәге кайсы капкага керсә дә, барыбер түгелмени, — ди. — Берәр театрга барып спектакль кара, син бит артист буласы кеше», — ди. Тәки биздерде.

Эшмәкәр. Алайга китсә, театры да шул инде. Сез сөйләгән сүзне тыңладың ни, тыңламадың ни. Барыбер бернәрсә дә үзгәрми.

Артист. Кемгә ничек инде.

Эшмәкәр. Кемгә ничек шул. Дөньяда яшәве дә кемгә ничек. Кайберәүләргә бомж булу да ошый. Бомж булу да, бер карасаң, рәхәт бит. Беркем

каршысында да җавап бирәсе юк. Тун сорап колак итен ашаучы хатын да юк, мотоцикл сораучы малай да юк. Мең төрле тикшерүләрдән шулчаклы арыйсың, бөтенесен ташлап бомж булып яшисе килә. Андый чакларда ярый әле хоккей белән футбол бар. Күңелеңдә буран уйнаганда, театрга барасы килми бит. Кеше күрәсе килми.

Артист. Монда кешеләр юкмы?

Эшмәкәр. Син юк дисең бит. Бәлки син хаклысыңдыр — монда толпа, монда — кеше көтүе.

Артист. Көтү булса да, кешеләр әле. Тора-бара фанатлар көтүе оешуы бар. Монысы инде куркыныч. Өелешеп сугышалар бит. Ни өчен сугышалар, максатлары ни? Менә син спектакль карап чыккан тамашачыларның икегә бүленеп сугышканнарын күргәнең бармы?

Эшмәкәр. Сугышасы килде бервакыт. Онытттым инде, ниндидер спектакль карадым да сугышасым килде.

Артист. Кем белән?

Эшмәкәр. Кем белән икәнен дә белмим. Әмма сугышасы килде. «Нигә без шулай яшибез?» — дип кемнәргәдер берне тондырасы килде. Шулай булгач, үзегезне әүлиягә санамагыз. Янә дә бер тапкыр ниндидер комедия карагач, кереп сезне кыйнап чыгасы килде. Болай син дөрес әйтәсең — һәр уенның максаты булырга тиештер. Хәтта футбол белән хоккейда да.

Артист. Кайдандыр сатып алынган уенчыкларның уенын караудан мин тәм тапмыйм.

Эшмәкәр. Син тоймасаң, аларны сатып алучылар тәм таба. Йотып куясыңмы?

Артист. Житте. Йә шайба! Шайба! дип кычкыра башлармын. Бу уенда уйнаучыларга да, тамашачыларга да допинг кирәк.

Эшмәкәр. Допинг дигәннән, син Олимпия уеннарын карыйсыңмы?

Артист. Карыйм. Һәм яратып карыйм.

Эшмәкәр. Анда да уен бит.

Артист. Анда башка уен. Ил белән ил көрәшә. Шәхес белән шәхес ярыша. Бу — мәгънәсезгә туп тибү генә түгел.

Эшмәкәр. Мәгънәсез уенны кешеләр уйлап чыгармый.

Артист. Ни кызганыч, чыгара. Карта уеннары, уен автоматлары. Бәлки алар баштарак акылда һәм көчтә үзара сынашу, ярышу булгандыр, бүгенгеләр аны тамашага әйләндерделәр. Аларның мәгънәсе әлләни түгел. Синең хоккееӊ, футболың кешегә ни бирә? Мин, мәсәлән, аларны карамаганнан берни дә югалтмыйм. Син дә югалтмыйсың. Киресенчә, вакытыңны бушка сарыф итәсең. Бу уеннар, дустым, интеллект дәрәҗәсе югары булмаган кешеләр өчен.

Эшмәкәр. Нәрсә, ул уеннарны бетерергә дисеңме?

Артист. Нигә бетерергә. Яшәсен. Әмма бүгенге хәлендә түгел. Син беләсеңме, күпме акча түгелә шул командаларны яшәтер өчен? Безнең авыздан өзеп алынган акчалар ул. Дәүләт җитәкчеләренә фанат булу килешми. Чын спортта акча төп рольне уйнамаска тиеш. Акча, мал аркасында Сабан туйларыбызның яме калмады. Сабан туйларында дан өчен түгел, мал өчен ярышабыз. Менә кайда бәла. Уеннардан дан дигән төшенчә югалды. Дөнья сугышлары мал бүлешә алмаудан башлана.

Эшмәкәр. Син әллә кая барып җиттең.

Артист. Әллә кая түгел. Өченче периодка җиттек. Әнә, чыгып киләләр синекеләр. Кара, аларны трибуна ничек каршы ала? Әйтерсең, Берлинны алып кайтып киләләр. Әйдә, без дә кычкырабыз. Шайба! Шайба! Шайба!

*(Әсәр тәмамланмаган.)*

Туфан Миңнуллин

# ӘБРӘКӘЙ

КОМЕДИЯ

**Катнашалар:**

Гыйбадулла Бәдриев — Кәкре Каен авылы кешесе.

Зөлхиҗә — Гыйбадулланың хатыны.

Хөкемдаров Самуил Иванович — прокурор.

Чистюлькина Аллария Ахметовна — санэпидемстанция башлыгы.

Күмербәков — янгын сүндерүче.

Салымгалиев — салым инспекторы.

Шредер — немец, Германиядән килгән эшмәкәр.

Искәндәр — Шредерның тәрҗемәчесе.

Шофёр.

Хәяли — авыл диванасы.

Беренче хатын-кыз.

Икенче хатын-кыз.

Полицейский.

Кәттә егет.

**Беренче күренеш**

*Федераль дигән исем йөрткән олы юл Кәкре каен авылы яныннан үтә. Гыйбадулла исемле Кәкре Каен авылы кешесенең бакча арты нәкъ менә шул юлга килеп терәлгән. Бакча артында котырып агачлар үскән. Шул агачлык янына ерак һәм якын араларга йөрүче эреле-ваклы автобуслар, машиналар туктап ала. Аларда утырып йөрүчеләр, кысталгач, әлеге агачлыкка сибелеп, кече һәм зур йомышларын үтиләр. Пәрдә ачылганда, шул агачлык янында кулына сәнәк тоткан Гыйбадулла йөренә. Жырлап-биеп авылның диванасы Хәяли керә.*

Хәяли.

Алай яшәек әле дә,
Болай яшәек әле.
Рәхәтлеккә чыдап булмый,
Жырлап яшәек әле.

Исәнмесез, иптәш Бәдриев.

Гыйбадулла. Исәнме, Хәяли.

Хәяли. Автобус килмәдеме әле?

Гыйбадулла. Юк әле, Хәяли.

Хәяли. Син монда сәнәк белән нишлисең?

Гыйбадулла. Таптым әле менә.

Хәяли. Төшеп калганмы?

Гыйбадулла. Калдырганнар.

Хәяли. Жырлыйммы?

Гыйбадулла. Жырла, Хәяли, жырла.

Хәяли. Акча бирәсеңме?

Гыйбадулла. Бирәм, Хәяли, бирәм.

Хәяли. Юк, мин синнән алмыйм.

Гыйбадулла. Нигә, Хәяли?

Хәяли. Син миңа тимисең. Рәхәт яшибез дигәнне жырлыйммы?

Гыйбадулла. Жырла, Хәяли.

Хәяли.

Алай итәрбез әле дә,
Болай итәрбез әле.

Рәхәтлектә яши-яши
Үлеп китәрбез әле.
Алай рәхәт була ул да,
Болай рәхәт була ул.
Авызыңда тешең булса,
Яшәү рәхәт була ул.

Гыйбадулла. Бу җырларны сиңа кем өйрәтә, Хәяли?

Хәяли. Күрше бабай.

Гыйбадулла. Ул рәхәт яшимени?

Хәяли. Әһе. Аның кәҗәсе бар.

Түбәгә кунган күгәрчен,
Тимә аңа — гөрләсен.

Автобус килде. *(Чыгып йөгерә. Бераздан ике хатынга ияреп керә.)* Җырлаган өчен акча бирегез.

Беренче хатын-кыз. Чё, чё?

Хәяли. Маржа икән әле.

*Чыгып йөгерә, хатыннар агачлыкка ашыгалар.*

Гыйбадулла. Кая барасыз?

Беренче хатын-кыз: Чего?

Гыйбадулла. Куда идёте?

Беренче хатын-кыз. Какое твоё дело?

Гыйбадулла. Моё дело есть. Там мой сад, огород.

Икенче хатын-кыз. Без синең бакчаңа кермибез.

Гыйбадулла. Агачлыкка керергә дә ярамый.

Икенче хатын-кыз. Ничек инде ул «ярамый?»

Гыйбадулла. Ярамый дигәч ярамый. Исе бакчага тарала, өйгә керә.

Икенче хатын-кыз. Нәрсә исе?

Гыйбадулла. Нәрсәгә кирәсез соң? Шуның исе. Таптылар җайлы урын. Бөтен Рәсәй сасысын иснәп ятабыз. Киләләр дә тукталалар, киләләр дә тукталалар.

Икенче хатын-кыз. Ә без кая барырга тиеш?

Гыйбадулла. Анда минем эшем юк. Рәсәй иркен.

Беренче хатын-кыз. Что он говорит?

Икенче хатын-кыз. Воняет, говорит.

*Хатын-кызлар көлешә.*

Беренче хатын-кыз. Дяденька, мы по-маленькому.

Гыйбадулла. Маленькиен, большуен белмим, нилзә.

Икенче хатын-кыз. Ну-ка отойди, мужик.

Гыйбадулла. Атайду мин сиңа. Дома надо было кончать.

Беренче хатын-кыз. Уважать надо женщин, абы.

Гыйбадулла. Мин уважаю. Идите на другое место.

*Шофёр керә.*

Шофёр *(Гыйбадуллага).* Тагын чыгып бастыңмы?

Гыйбадулла. Бассам, ни әйтерсең? Бүтән урын беткәнмени сиңа? Киләсең дә туктыйсың.

Шофёр. Миңа түгел, пассажирларга кирәк. Нәрсә, алар асларына җибәрсеннәрмени?

Гыйбадулла. Асларында, өсләрендә эшем юк. Туктама монда.

Шофёр. Йә, ярый, бүтән туктамам. Болар барып килсен дә...

Гыйбадулла *(бераз йомшарып).* Туктамам дисең дә...

Шофёр. Йә инде, вакланма. *(Хатын-кызларга).* Идите. Только быстро. *(Хатын-кызлар киткәч).* Йөз километр, ике йөз километр үтәсең, бер җирдә бәдрәф юк.

Гыйбадулла. Ялганлама. Заправкаларда бар.

Шофёр. Бар... Син анда кереп кара. Ирләр ничек тә җаен таба, хатын-кызларны нишләтим?

Гыйбадулла. Нишләтәсен белмәгәч, утыртып йөрмә.

Шофёр. Син, абзый, порнография белән шөгыльләнмә, ярыймы?!

Гыйбадулла. Нәрсә сөйләгән буласың? Нинди порнография?

Шофёр. Әллә белмисең?

Г ы й б а д у л л а. Белмим дә, нитмим дә.

Ш о ф ё р. Алай димә, абзый, нитәсендер әле.

Г ы й б а д у л л а. Нәрсә әллә кая борасың? Эчәгенне сәнәккә кадап, агачка элеп куярмын. Бозылып беткән хатын-кыз ташып.

Ш о ф ё р. Үзең башладың, абзый.

Г ы й б а д у л л а. Башлатырмын мин сиңа. Киләсең дә туктыйсың. Туктамасаң, түзәләр алар.

Ш о ф ё р. Түзәр хәзерге хатыннар. Син безнең илнең нинди ил икәнен беләсеңме? Безнең ил бит ашамыйэчми, пес итми, тәрәт итми торган кешеләр өчен төзелгән.

Г ы й б а д у л л а. Илеңдә минем эшем юк. Әбрәкәй исе минем өйгә керә.

Ш о ф ё р. Иленнән бәдрәф исе килгәч, синең өйгә генә керми калмас инде.

Г ы й б а д у л л а. Син бик остарма, егет. Руленне тартып алмасыннар.

Ш о ф ё р. Кемнәр?

Г ы й б а д у л л а. Лыгырдаганыңны тыңлап торучылар.

Ш о ф ё р. Синме?

Г ы й б а д у л л а. Бар, печтрихаларыңны утырт та сыпырт.

Ш о ф ё р *(чыгып килгән хатынкызларга).* Всё нормально?

Б е р е н ч е х а т ы н - к ы з *(Гыйбадуллага).* Ты прав, бабай, воняет... Спасибо, бабай.

Г ы й б а д у л л а. Какой бабай булыйм мин сиңа? *(Шоферга).* Икенче туктасаң, тәгәрмәчеңне сәнәк белән тишәм.

Ш о ф ё р. Син сәнәк күтәреп йөрмә, памперс сат, акчаң булыр.

Г ы й б а д у л л а. Өйрәтмә. *(Үткәнсүткән автобусларга сәнәк селкеп калуын дәвам итә.)*

*Хәяли керә.*

Х ә я л и. Күп акча булды. Тагын автобуслар килә әле. Алар монда туктыйлар. Жырлыйммы, иптәш Бәдриев?

Г ы й б а д у л л а. Жырла, Хәяли, жырла.

Х ә я л и.
Алай итәрбез әле дә,
Болай итәрбез әле.
Рәхәтлектә яши-яши
Үлеп китәрбез әле.
Иделләрне кичәбез дә
Аргы якка күчәбез.
Безгә рәхәт тормыш килде,
Аяк тибеп эчәбез.

*Жинел машина килеп туктаган тавыш. Хөкемдаров белән Чистюлькина керәләр. Хәяли алар каршына жырлап-биеп бара.*

Х ә я л и.
Дулкынланып сулар керә
Парахут идәненә.
Мондый рәхәт, матур тормыш
Тик безнең илдә генә.

Акча бирегез!

Г ы й б а д у л л а. Хәяли! Кит аннан. Алардан акча сорамыйлар.

Х ә я л и. Сараннар!

*Китеп бара.*

Х ө к е м д а р о в. Рәхим итегез, Аллария Ахметовна!

Ч и с т ю л ь к и н а. Башта сез рәхим итегез, Самуил Иванович!

Х ө к е м д а р о в. Мин бит, ни дисәң дә, кавалер.

Ч и с т ю л ь к и н а. Хатын-кыз чыдамрак була.

Х ө к е м д а р о в. Хатын-кызның чыдамлылыгыннан явызларча файдаланырга ярамый.

Ч и с т ю л ь к и н а. Хатын-кыз ир-атларны хөрмәт итәргә тиеш. Рәхим итегез.

Х ө к е м д а р о в. Юк инде, сез рәхим итегез.

Ч и с т ю л ь к и н а. Сез рәхим итегез.

Х ө к е м д а р о в. Юк, Аллария ханым. Мин тәмугка гына сездән алда керәм.

Ч и с т ю л ь к и н а. Рәхмәт.

*Агачлыкка юнәлә.*

Г ы й б а д у л л а *(Чистюлькина*

*юлына аркылы төшеп).* Кая барасың?

Чистюлькина. Гафу итегез...

Гыйбадулла. Кая барасың, диләр.

Чистюлькина. Ничек инде, кая барасың. Хатын-кызга шундый сорау бирергә ничек оялмыйсыз?

Гыйбадулла. Оялмыйм. Әгәр йомышыгызны йомышларга булса, анда ярамый.

Чистюлькина. Нинди йомыш турында сөйлисез?

Гыйбадулла. Агачлыкка нигә керәсең соң?

Чистюлькина. Нәрсә, әйтеп бириммени?

Гыйбадулла. Кирәкми. Андый эш белән агачлыкка керергә ярамый.

Чистюлькина. Гафу итегез...

Гыйбадулла. Итмим. Ярамый.

Хөкемдаров *(якынрак килеп).* В чём дело?

Гыйбадулла. Твой баба штули? Туда нилзә.

Хөкемдаров. Син нәрсә?

Гыйбадулла. Нәрсә түгел, кем.

Хөкемдаров. Аңлатып сөйлә.

Гыйбадулла. Арыдым инде аңлата-аңлата. Ангыра сарыклар шикелле әйткән саен шунда чабалар. Күрәсеңме бу бакчаны?

Хөкемдаров. Йә, күрәм...

Гыйбадулла. Алма бакчасы икәнлеген дә күрәсеңме?

Хөкемдаров. Йә, күрәм ди...

Гыйбадулла. Умарталарны да күрәсеңме? Әнә анда куыш тора. Мин шул куышта төннәрен йоклыйм. Әнә анда безнең өй. Без анда җәй көннәре тәрәзәне ачып куеп ашыйбыз. Чәй эчәбез. Врачлар да әйтә — саф һава сулау файдалы, ди.

Хөкемдаров. Шуннан?

Гыйбадулла. Шуннан шул. Бу агачлыктан әбрәкәй ясап бетердегез.

Хөкемдаров. Нинди әбрәкәй?

Гыйбадулла. Сезнеңчә туалит инде. Без нәрсә, шуны иснәп чәй эчикме, йоклыйкмы?

Хөкемдаров. Вон что... Ә кешеләр кая барырга тиеш?

Гыйбадулла. Ә без кешеләр түгелме?

Хөкемдаров. Бу җир синеке түгел. Әнә синең җирең — үзең күрсәткән бакчаң. Кит моннан.

Гыйбадулла. Нәрсә җикеренәсең? Китәрмен мин сиңа. Кәттә машинага утырдым дигәч тә...

Хөкемдаров. Бу агачлык синеке түгел, аңлыйсыңмы? Дәүләтнеке.

Гыйбадулла. Агачларны мин утырттым. Машина газы кермәсен дип. Сез монда...

Хөкемдаров. Агачлар синеке булса, җир дәүләтнеке.

Гыйбадулла. Җир дәүләтнеке булса, сәнәк минеке.

Чистюлькина. Самуил Иванович, китик.

Хөкемдаров. Юк инде, Аллария ханым. Бу гражданин миңа янады бит әле. Син, гражданин, сәнәгеңне бик бутама. Синең каршыңда хатын-кыз тора, томана. Хатын-кызны хөрмәт итәргә кирәк.

Гыйбадулла. Хөрмәт итәргә дип... Әллә мин аны тәпи тотыйммы?

Чистюлькина. Фу, тәрбиясез. Китик, Самуил Иванович.

*Чыгып китә.*

Хөкемдаров. Син беләсеңме минем кем икәнлегемне?

Гыйбадулла. Кемлегеңдә эшем юк, ярамый дигәч, ярамый.

Хөкемдаров. Мин районның прокуроры.

Гыйбадулла. Булмагаең. Минем алдым да, артым да чиста.

Хөкемдаров. Дәүләт җирен үзләштергәнең өчен мин сине, беләсеңме, нишләтә алам?

Гыйбадулла. Куркытма. Астыңа җибәрсәң дә, кертмим.

Хөкемдаров. Мин сине сәнәгең белән бергә утыртып куячакмын.

Гыйбадулла. Мине бабага утыртканнар инде.

Хөкемдаров. Кара аны.

*Чыгып китә.*

Г ы й б а д у л л а. Карарбыз.

З ө л х и җ ә *(агачлар арасындагы сукмактан чыгып).* Сүзе булмас микән, Гыйбади?

Г ы й б а д у л л а. Нинди сүз?

З ө л х и җ ә. Пыркарур, ди бит.

Г ы й б а д у л л а. Пыркарур булса, эшен бетереп чыксын. Әбрәкәйләре бардыр.

З ө л х и җ ә. Аш суына, бар, ашап чык.

Г ы й б а д у л л а. Хәзер моннан автобус үтәсе. Үткәреп җибәрим дә керермен.

З ө л х и җ ә. Аларнын бетәсе юк. Бөтенесен дә саклап булмас.

Г ы й б а д у л л а. Бер биздерсән, туктамыйлар ул. Бер атна сакласак, бизәчәкләр.

З ө л х и җ ә. Бизеп кая барсыннар инде. Агачлык бакча артында гына. Утыртма дидем шул агачларны.

Г ы й б а д у л л а. Син дә нервыда уйнама әле.

З ө л х и җ ә. Утыртып куймасын пракарур.

Г ы й б а д у л л а. Утыртып карасын. Закон бар.

З ө л х и җ ә. Пракарур үзе закон бит инде. Бар, ашап чык, үзем саклый торам.

Г ы й б а д у л л а. Сине тынлыйлармы...

З ө л х и җ ә. Тыңламый карасыннар.

Г ы й б а д у л л а. Берсен дә җибәрмә. Куркытсалар да, курыкма. Эчәгенне сәнәк белән актарып алып, агачка элеп куярмын, диген.

З ө л х и җ ә. Кайгырма, сүзен табарбыз.

Г ы й б а д у л л а. Ул-бу булса, кычкыр.

*Китә.*

З ө л х и җ ә. *(Сәнәген инбашына салып әрле-бирле йөренә.)*

*Җырлап Хәяли керә.*

Х ә я л и.

Әнә килә афтамабил,
Төягәннәр сарыклар.
Бары безнең илдә генә
Рәхәт яши халыклар.

Кая китте иптәш Бәдриев?

З ө л х и җ ә. Ашарга кайтып китте.

Х ә я л и. Хәзер халык саранланды. Элек җырлаган өчен күп акча бирәләр иде. Хәзер бирмиләр. Мин өйгә кайтып ашап киләм, ярыймы? Автобус килсә, әйт, иптәш Хәяли озакламый килә, диген.

*Китә.*

З ө л х и җ ә *(җырлый-җырлый йөренә).*

Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.
Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.

*Машина килеп туктаган тавыш. Салымгалиев йөгереп керә дә агачлыкка чаба.*

З ө л х и җ ә. Стоп!

*Салымгалиев туктап кала, артына борылып карарга курка.*

С а л ы м г а л и е в. Кем син?

З ө л х и җ ә. Тиррарист.

С а л ы м г а л и е в. Ни кирәк миннән?

З ө л х и җ ә. Борыл да сыпырт моннан.

С а л ы м г а л и е в *(борылып Зөлхиҗәне күргәч).* Син кем?.. *(Танып алып).* Бәй, Зөлхиҗә ич син. Зөлхиҗә бит син, әйеме?

З ө л х и җ ә. Мине каян беләсең?

С а л ы м г а л и е в. Бәй, Кушкаен авылыннан ич мин.

З ө л х и җ ә. Танымыйм.

С а л ы м г а л и е в. Син безнең авылга кунакка килгән идең.

З ө л х и җ ә. Кайчан?

С а л ы м г а л и е в. Утыз ел элек. Безнең авыл кызы белән клубка килгән идегез. Васил белән.

Зөлхиҗә. Василә? Ә-ә-ә... Кайда ул хәзер?

Салымгалиев. Белмим. Каядыр киткән бугай. Мин Казанда финансовыйда укый идем. Сезне озата барган идем. Син миңа бик ошаган идең. Василәләр капка төбендә сөйләшеп тә тордык.

Зөлхиҗә. Танымыйм.

Салымгалиев. Кеше танырлык түгел идең шул. Бик чибәр идең. Чибәр кызлар егетләрне танымый бит ул. Миңа да «фи» дип әйтеп кенә кереп киттең Василәләргә.

Зөлхиҗә. Шул бер күрүдән таныйсыңмы?

Салымгалиев. Танымаска. Сурәтең күңелемә сеңеп калды. Бер күрүдә гашыйк булган идем. Авылыгызга килергә дә уйлаган идем, Казанга китәсе булды. Хат та язмакчы идем, нәрсәдер шунда... Аннары Казакъстанга эшкә җибәрделәр. Өч ел элек үзебезнең якларга кайттым, районда эшлим. Кирәк бит, ә, кайда очраттым үзеңне. Нишләп йөрисең сәнәк белән?

Зөлхиҗә. Йөрим инде.

Салымгалиев. Шушы Кәкре Каен авылында яшисеңме?

Зөлхиҗә. Шушында.

Салымгалиев. Кирәк бит, ә... Язмыш кайда очраштырды. Син һаман да әле чибәр.

Зөлхиҗә. Бар инде, керәсе җиреңә кереп чык.

Салымгалиев. Керәсе дип инде...

Зөлхиҗә. Бар инде, бар. Ирем килеп чыкканчы, эшеңне эшлә.

Салымгалиев. Ирем?.. Ничек?

Зөлхиҗә. Картым инде. Без монда аның белән каравылда торабыз.

Салымгалиев. Берәр нәрсә саклыйсызмы?

Зөлхиҗә. Менә бу агачлыкны. Автобуслар, машиналар туктый да, шул агачлыкка кереп чыгалар.

Салымгалиев. Нигә?

Зөлхиҗә. Син нигә чаба идең соң?

Салымгалиев. Ә нәрсә, ярамыймы?

Зөлхиҗә. Ничек ярасын. Анда безнең бакча, өй рәдем.

Салымгалиев. Ә-ә-ә, аңладым, аңладым. Ярый инде алайса... Сау бул, Зөлхиҗә. Син һаман да чибәр.

Зөлхиҗә. Бар инде, кереп чык. Бер кешедән әллә ни булмас. Аяк астына карап бас.

Салымгалиев. Юк инде, рәхмәт.

Зөлхиҗә. Бар инде, бар. Мине ошаткан хакына булыр.

Салымгалиев. Рәхмәт.

*Башын иеп чыгып китә.*

Зөлхиҗә. И Алла...

Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.
Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.

*Күмербәков керә.*

Күмербәков. Исәнмесез. Здрастуйте.

Зөлхиҗә. Исән әлегә.

Күмербәков. Ярый, апа, гел исән бул. *(Агачлыкка юнәлә).* Будь здорова.

Зөлхиҗә. Анда ярамый.

Күмербәков. Нәрсә ярамый? Почему? Ни булган?

Зөлхиҗә. Бу — әбрәкәй түгел.

Күмербәков. Вижу.

Зөлхиҗә. Күргәчтен, нигә анда таба барасың?

Күмербәков. Соң, кирәк бит. Надо, апа.

Зөлхиҗә. Ярамый.

Күмербәков. Мин моннан ничә ел үтеп йөрим, можно было.

Зөлхиҗә. Түздек, түздек тә, түземлегебез бетте. Әбрәкәйдә яшәгән кебек яшибез.

Күмербәков. Запах чтоли?

Зөлхиҗә. Әллә сизмисеңме?

Күмербәков. Да-а-а. Минем ни бит, апа, кече йомыш кына. Малая нужда.

Зөлхиҗә. Барып җиткәнче түзәрсең.

Күмербәков. Мин пожарга чабам. Константиновкада пожар. Пожарда бәдрәф кайгысы юк. Пожарный мин, апа. Поняла, пожарный.

Зөлхижә. Пожар булгач, нәрсә теленә салынып торасын, чап.

Күмербәков. Пожарныйларның башлыгы мин. Сонрак барсам да ярый. Анда егетләр эшли.

Зөлхижә. Ярамый.

Күмербәков. Миндә простата, апа.

Зөлхижә. Анысы нәрсә тагын?

Күмербәков. Такая болезнь. Бәдрәфкә еш йөгертә торган чир.

Зөлхижә. Ир кешедер бит син. Кече йомыш өчен агач арасына кермәскә дә була. Хатын-кыз кебек чүгәләп торасы юк. Машинан янына басып, моторын караган бул да...

Күмербәков *(көлеп)*. Бер дә белмәгәнең юк икән.

Зөлхижә. Барысын да күргән. Бар, юлыңда бул. Пожарың янып бетмәсен.

*Гыйбадулла керә.*

Гыйбадулла. Нәрсә монда?

Зөлхижә. Менә, тыңламый.

Гыйбадулла. Ә-ә, бу бит өй янып беткәнне карап йөрүче.

Күмербәков. Сүндерүче мин, пожарный.

Гыйбадулла. Каенлык янганда сүндердегез инде.

Зөлхижә. Константиновка яна, ди, шунда чабам, ди.

Гыйбадулла. Алайса суыңны монда әрәм итеп торма.

Күмербәков. Ярый кертмәсәң... Өегез янса, килеп тә карамыйм. Понял?

*Китеп бара.*

Зөлхижә. Монда кызык нәрсә булды бит әле, Гыйбади. Кушкаен авылы кешесе туктады. Кайчандыр мине ошаткан булган икән. Финансыга укыдым, ди. Казакъстанда эшләдем, ди, хәзер районга кайттым, ди.

Гыйбадулла. Салымгалиевтер инде. Налуг жыючы.

Зөлхижә. И-и-и, карале, белгән булсам...

Гыйбадулла. Белеп нишлисең?..

Зөлхижә. Соң ни бит. Налуглар күбәйде бит.

Гыйбадулла. Ул нишли ала?

Зөлхижә. Бераз жинеләйтер иде.

Гыйбадулла. Башың бармы синең? Ул ничек жинеләйтсен, налугны Мәскәү сала. Әнә, Мәскәвенә барып пес итсен.

Зөлхижә. И, алай сөйләшмә инде, Гыйбади. Чибәр иден, ди. Хәзер дә чибәр, ди.

Гыйбадулла. Ияреп китәсең калган. Сартир саклап утырмас идең.

Зөлхижә. Юк инде, синнән китеп беркая да барасым юк. Налуг жыючыга бигрәк тә. Аларга бит кеше рәнжешө төшәдер. Кешеләрне жылатып...

Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә,
Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.

Өебезне авылның теге башына саласы калган.

Гыйбадулла. Ул вакытта бу юл юк иде. Бу урынны әллә рәшәткә белән уратып алыйк микән?

*Искәндәр белән Шредер керәләр.*

Искәндәр *(Шредерга)*. Битте ферцайн зи, герр Шредер, вир һабен айне ланге райзе фар. (Сез инде гафу итегез, герр Шредер, бүген барасы юл ерак).

Шредер. Йа, йа, даст ист клар. Эксотишее ланд. *(Әйе, әйе, аңлашыла. Экзотик ил ).*

*Агачлыкка юналәләр.*

Гыйбадулла. Анда ярамый.

Искәндәр. Ни өчен?

Гыйбадулла. Анда әбрәкәй юк.

Искәндәр. Нәрсә ул әбрәкәй?

Гыйбадулла. Татармы соң син?

Искәндәр. Татар.

Гыйбадулла. Әбрәкәй — туалит дигән сүз. Туалит юк агач арасында.

Искәндәр. Беләм. Россия юлларында күп йөрим. Кайда агач — шунда туалет.

Гыйбадулла. Монда андый закон юк. Монда минем закон. Агачлар арасына керергә ярамый. Әнә анда минем өй, анда бакча.

Искәндәр. Бу иптәш Германиядән килгән. Бизнесмен. Немец.

Гыйбадулла. Нимес булса да ярамый, американ булса да ярамый. Фәрештейн?

Шредер. Вас ист даст? (Ни бу?)

Искәндәр. Зи загт, дас айнтратт нихьт мёглихь ист. (Керергә ярамый, ди).

Шредер. Варум? (Нигә?)

Искәндәр. Эс штинкт хар. Унд гер хаус ист ганц гендер нәйе. (Яман ис таралды, ди. Аларның өе якында гына).

Шредер. Унд вэсхальб бенутцет ман дизен платц альс кло? (Алайса нигә бу урынны туалет итеп файдаланалар?)

Искәндәр *(Гыйбадуллага)*. Германиядән килгән кунагыбыз әйтә: нигә сезнең бакчагызны туалет итеп файдаланалар, ди.

Зөлхиҗә. Монысы безнең бакча түгел. Безнең бакчаның башы. Машиналар исе кермәсен дип, бу агачларны Гыйбадулла абыең утыртты. Шул урынны бәдрәф иттеләр. Гыйбадулла абыең әйтә, кисеп ташламыйча булмас, ди.

Гыйбадулла. Күп сөйлисең.

Зөлхиҗә. Нимес ди бит, аңласын.

Гыйбадулла. Бик аңлады инде.

Шредер. Вас ист дас? (Ни бу?)

Искәндәр. Дас ист Вальд эс гибт кайнен платц эр. Дер манн дизер фрау плэнт, алле бойме хир цу феллен. (Якын-тирәдә агачлык юк икән. Ханымның ире дә агачларны кисеп ташларга тели).

Шредер. Варум? Вас фюр шульд хабен ди бойли? Штатд эссен вэрэ эс бессер, хир кло цу эррихьтен.

Гыйбадулла. Нәрсә дигән була ул?

Искәндәр. Нигә туалет эшләп куймыйлар, ди.

Гыйбадулла. Кем?

Искәндәр. Үзегез.

Гыйбадулла. Шул гына житмәгән иде.

Искәндәр. Түләүле бәдрәфләр бар ич. Сез дә эшләп куегыз матур итеп. Керергә теләгәннәр акча түләп керер.

Гыйбадулла. Кешене пес иттереп акча эшләмәсәң, авылда эш калмады шул. Бар инде, кертеп чыгар кунагыңны. Әллә каян килеп сасытмасалар, беткән ди үзебезнекеләр.

Искәндәр. Рәхмәт, абзый кеше. *(Шредерга агачлыкны күрсәтеп)*. Битте шён, херр Шредер.

Шредер *(кулын селкеп)*. Но, но... Данке шён. *(Гыйбадулла белән Зөлхиҗәгә)*. Ауффидерзиен!

*Китәләр.*

Зөлхиҗә. Үпкәләде бугай.

Гыйбадулла. Нимес үпкәли белми ул. Жирәнгәндер.

Зөлхиҗә. Карале, Гыйбади, барыбер эш юк, әллә, мин әйтәм, теге кеше әйткәнчә, берәр нәрсә әмәлләп куясыңмы?

Гыйбадулла. Ай-яй, бик тиз баерга жыена берәү.

Зөлхиҗә. Баюдан түгел инде. Болай кеше көлдереп торганчы.

Гыйбадулла. Бездә бит аның кешесе дә бушка йомышларга өйрәнгән, барыбер агач арасына чабарлар.

Зөлхиҗә. Чапмаслар, каршыларында әбрәкәй торгач.

Хәяли *(җырлап керә)*.
Түбәгә кунган күгәрчен,
Тимә аңа, гөрләсен.

Безнең илдә яшәп кенә
Рәхәтлекне күрәсең.

Автобус килмәдеме?

Гыйбадулла. Юк әле, Хәяли, юк.

Хәяли.

Әфлисуннарның кабыгын
Ашаучылар бар микән?
Безнең кебек рәхәт итеп
Яшәүчеләр бар микән?

*Ут сүнә.*

**Икенче күренеш**

*Шул ук урын. Гыйбадулла белән Зөлхиҗә такталан матур итеп ясалган бәдрәф янында басып торалар. Бәдрәфнең маңгаена «Әбрәкәй» дип язып куйганнар.*

Гыйбадулла *(үз эшенә сокланып карап тора).* Булды бит бу.

Зөлхиҗә. Бик килешле килеп чыкты.

Гыйбадулла. Кысталмаган килеш тә кереп чыгарлык.

Зөлхиҗә *(җирдәге комганнарны рәтләп куеп).* Дүрт комган җитәр микән?

Гыйбадулла. Карарбыз. Җитмәсә, алырбыз. Бәлкем әле торба белән су да кертербез. Шәһәрдәге шикелле итеп эшләрбез. Ялкауланды бит хәзер халык, бөтен эшен утырып эшли.

Зөлхиҗә. Гыйбади, «Әбрәкәй» дигәнне аңларлар микән?

Гыйбадулла. Клуб белән бутамаслар әле.

Зөлхиҗә. «Бәдрәф» дип язасы калган.

Гыйбадулла. Аны аңларлар дисеңме?

Зөлхиҗә. Бәдрәф әйбәтрәк. Фамилиябез дә Бәдриев. Колакка якын ишетелә.

Гыйбадулла. Ишетелгәч, язганчы әйтергә иде.

Зөлхиҗә. Хатын-кыз акылы төштән соң. Үзебезнең ындыр артындагы бәдрәфебездән дә матуррак бу, Гыйбади.

Гыйбадулла. Шулай тиеш. Үзебезгә кайтышы да ярый, халыкка дигәне матур булсын. Акыл бирлен әле, Зөлхи, «Әбрәкәй» янына нимесчә дә язып куябыз. Ни дисәң дә, акылны нимес бирде.

*Җырлап-биеп Хәяли керә.*

Хәяли.

Дулкынланып сулар керә
Пароход идәненә.
Мондый рәхәт, матур тормыш
Тик безнең илдә генә.

Исәнме, иптәш Бәдриев. Исәнме, иптәш Бәдриева.

Зөлхиҗә. Бик әйбәт әле, Хәяли. Үзең нихәлләрдә?

Хәяли. Алда — гөл, артта — кычыткан. *(Үз сүзеннән тәм табып көлә. Җырлап бии).*

Яшәгәне яшәп тора,
Үлгәне үлеп тора.
Тормышлары шундый рәхәт
Көләсе килеп тора.

Бу сыерчык оясын ник зур итеп ясадыгыз?

Зөлхиҗә. Сыерчык оясы түгел ул, Хәяли, әбрәкәй.

Хәяли. Нәрсәгә ул?

Зөлхиҗә. Әллә күргәнең юкмы? Үзегездә дә бардыр.

Хәяли. Ә-ә-ә, белдем.

*Тәмләп көлә дә биеп китә.*

Утырабыз да китәбез
Колхоз арбаларына.
Аңгыра фирма хуҗа булды
Колхоз амбарларына.

*Биеп, бәдрәф эченә кереп китә. Тәрәзәсеннән башын тыгып җырлый.*

Карап калалар икән,
Налут салалар икән;
Налугыны түләмәсәң,
Тартып алалар икән.

*Автобус килеп туктаган тавыш. Хәяли: «Автобус килде, автобус килде!» — дип чыгып чаба. Анда анын жырлаганы ишетелә. Шофёр керә. Анын алдыннан Хәяли жырлап-биеп килә.*

Хәяли.

Биек тауның башларында
Тезелеп үскән әнисләр.
Тезелеп үскән әнис кебек
Яшәсен коммунисләр.

Шофёр. Молодец, Хәяли. *(Кесәсеннән акча алып Хәялигә суза).* Бар, автобуста акчалы кешеләр күп. *(Хәяли чыгып йөгергәч, бәдрәфкә карап тора).* Шәп булган бит бу. Әйттем бит мин сиңа.

Гыйбадулла. Син әйтмәдең, нимес әйтте. Үтеп бара иде бер нимес, әйтте дә китте.

Шофёр. Молодец... Акчалыдыр бит?

Зөлхиҗә. Мең тәнкәлек такта китте. Нигезе кирпечтән. Күпме кирпеч, күпме симент.

Шофёр. Молодцы! Күпме түләргә инде?

Зөлхиҗә. Санаган юк әле.

Шофёр. Санагыз әйбәтләп. Бездә халык бушка өйрәнгән. Бушка эшлиләр, бушка пес итәләр. Кергән кеше бармы әле?

Гыйбадулла. Керсәң — син беренче.

Шофёр. Котлап чыгарбыз. Миңа бушлайдыр инде. Берәр тапкыр бушлай утыртып барырмын.

Зөлхиҗә. Безнең барасы жиребез юк.

Шофёр. Ярый, ярый, түләрбез. Бу юлы мин әле карап кына чыгам.

Гыйбадулла. Музей түгел ул, карарга...

Шофёр. Ярый, ярый, бездән булсын яхшылык. Менә ун сум. Бисмилла әйтеп ал, элеккеләр өчен дә булыр.

Зөлхиҗә *(комган биреп).* Чыкканда алып чык.

Шофёр. Нәрсәгә бу тефаль чәйнеге?

Гыйбадулла. Нинди тефаль... Комган ул. Татар бит син.

Шофёр. Ә белдем, белдем... тефальгә охшаган.

*Комганны тотып кереп китә.*

Гыйбадулла. Күбрәк бирде бугай бу.

Зөлхиҗә. Үзләре талыйлар әле. Ун тәңкә акчамыни хәзер? Суын алып киләсе бар, комганнарга тутырасы бар...

Гыйбадулла. Бар әле, кулга тотып йөри торган радионы алып кил.

Зөлхиҗә. Анысы нигә?

Гыйбадулла. Уйнап торсын. Күңеллерәк була ул.

*Зөлхиҗә китә.*

Шофёр *(бәдрәфтән чыгып).* Шәп килеп чыккан бу, абзый. Чыгасы да килми. *(Автобус ягына карап кычкыра).* Әй, кемнең кереп чыгасы килә?

*Китә.*

*Беренче күренештәге ике хатын керә. Алар алдыннан әлеге дә баягы Хәяли жырлап-биеп килә.*

Хәяли.

Кызлар кия кызыл ыштан,
Безгә карасы да юк.
Кызлар хәзер үзе килә,
Барып аласы да юк.

Беренче хатын. Ну, хватит, хватит. Иди, иди...

Хәяли.

Кызлар, кызлар — кымызлар.
Мәскәүски дуңгызлар.

Гыйбадулла. Хәяли! Булды, житте, бар!

Хәяли. Акча бирсеннәр.

Гыйбадулла. Үзем бирермен, бар.

*Хәяли бии-бии чыгып китә.*

Беренче хатын *(бәдрәфкә карап).* Ба-а-а... Туалет! Когда мы уезжали, не было. *(Гыйбадуллага).* Вы чтоли смастерили?

Гыйбадулла. Сам... Хороший?..

Беренче хатын. Красиво.

Гыйбадулла. Заходи. Гостем будешь.

Беренче хатын. Спасибо.

Гыйбадулла. Кумган бери.

Беренче хатын. А для чего?

*Икенче хатын анын колагына комганнын нигә кирәклеген анлата. Беренче хатын кычкырып көлә дә комгансыз гына бәдрәфкә кереп китә.*

Гыйбадулла *(икенче хатынга)*. Мин бит сезне таныйм.

Икенче хатын. Без дә танылык. Санаторийда идек, кайтып киләбез. Авылда безнең бабайларның шундый ниләре бар.

Гыйбадулла. Булырга тиеш.

Беренче хатын *(бәдрәфтән чыгып)*. Молодец, дяденька. Сколько с меня?

Гыйбадулла. Тебе бесплатно.

Беренче хатын. Почему это?

Гыйбадулла. Потому что красивая. Ещё раз приезжай.

Беренче хатын. Спасибо. Пошли, Резеда.

Гыйбадулла. Погоди. Руки мыть надо. Иди сюда.

*Комганнан су салып торып, икенче хатынның кулын юдырта. Кул сөртергә тастымал бирә.*

Беренче хатын. О-о-о... Комфорт! *(Әбрәкәй язуына ишарә ясап)* Почему только по-татарски? И по-русски надо писать.

Гыйбадулла. Ты писикалмы?

Беренче хатын. Писикала...

Гыйбадулла. Иди тогда гуляй.

*Хатыннар көлешә-көлешә чыгып китәләр. Зөлхиҗә керә.*

Зөлхиҗә. Акча алдыңмы?

Гыйбадулла. Юк. Маржасы бигрәк чибәр.

Зөлхиҗә. Әллә үзең дә ияреп кердеңме?

Гыйбадулла. Түздем, әнисе. Син бар бит. Карале, кара, Зөлхи, теге нимес килә.

*Шредер белән Искәндәр керәләр.*

Шредер *(бәдрәфкә карап соклануын белдерә)*. О-о-о! Гут! Гут!

Искәндәр. Бик тиз өлгерткәнсез.

Гыйбадулла. Куштыгыз бит.

Шредер *(бәдрәфне тикшереп)*. Гут! Гут! *(Комганнарны күреп)*. Вас ист дас?

Искәндәр. Кумган. Ди муслиме бенутцэн дас дэр вэшунг. Нах дэм безул дэр туалет ист аух гут, хэнде цу вашен. (Комган. Мөселманнар тәһарәт алганда куллана. Зур йомыштан соң чистарыныр өчен. Кул юарга да жайлы).

Шредер. Гут, гут, зерр гут!

Гыйбадулла. Кулына салып тор әле шуның.

Зөлхиҗә *(комганны алып, Шредерга)*. Кил мондарак.

Искәндәр *(Зөлхиҗә ягына күрсәтеп)*. Битте шён.

Зөлхиҗә. Битте, битте... *(Шредерның кулына су салып тора. Сөртергә сөлге бирә.)*

Шредер. *(Гел ах-ух килеп тора. Тәмләп көлә)*. Гут! Гут! *(Комганны күрсәтеп)*. Хорошо. Сувенир! Дас кауфе ихь зэр гернэ. (Мин моны сатып алам).

Искәндәр. Комганыгызны оштаты. Сатып алам, ди.

Гыйбадулла. Сатылмый ул. Үзем дә Казаннан, базардан сатып алдым.

Искәндәр *(Шредерга)*. Эс ист мёглихь ин Казан цу кауфен.

Зөлхиҗә *(Шредерга бәдрәфне күрсәтеп)*. Битте туалет.

Шредер. О найн, найн.

Искәндәр. Аның керәсе килми. Туалетны күреп кенә туктадык.

Шредер *(Гыйбадулланың кулын*

*кысып).* Ауффедерзейн. *(Гыйбадуллага акча суза.)*

Гыйбадулла. Юк, юк, кирәкми. Кермәгән өчен акча алмыйлар.

Искәндәр *(Шредерга).* Фюр кайн айнтритт мусс ман нихьт бецален. (Кермәгән өчен акча алмыйлар).

Шредер. Дас ист гешэнк. Фюр ди реализирунг дэр идэе. (Бу — презент. Идеяне тормышка ашырганыгыз өчен). Хорошо. До свидания.

*Китәләр.*

Зөлхиҗә. Ауффидерзейн, гут гут!

Гыйбадулла *(Зөлхиҗәгә).* Нимес булып беттең син.

Зөлхиҗә. Мәктәптә укыттылар ич.

Гыйбадулла. Мине дә укыттылар. Шваеннан бүтәнен белмим.

Зөлхиҗә. Анысы ни дигән сүз соң?

Гыйбадулла. Чучка дигән.

Зөлхиҗә. Иң кирәген беләсең икән. Йәле, күпме бирде?

Гыйбадулла. Ун тәңкә. Нимес акчасы белән.

Зөлхиҗә *(евроны әйләндерепәйләндереп карый).* Безнеке белән күптер бу, Гыйбади.

Гыйбадулла. Күп.

Зөлхиҗә. Бигрәк юмарт кешеләр икән нимесләр. Алырсың безнекеләрдән.

Гыйбадулла. Нимес түгелдер ул. Нимесләр кысмыр халык, дип әйтә иде әти. Мә, бусы сиңа. Үзеңә генә тот. Берәр нәрсә алып җибәр.

Зөлхиҗә. Торсын әле. Кирәге чыгар. *(Акчаны изүенә яшереп куя).* Монда икебез дә тасраеп тормыйк инде, Гыйбади. Чиратлашып торыйк. Әллә соң берәр тартма элеп куйыйк микән? Акчаларын салырлар да керерләр.

Гыйбадулла. Син нәрсә, каберенне казып, кәфенлегеңне салдырып алган заманда... Ашарына пешкәнме анда?

Зөлхиҗә. Иртән үк пешереп куйдым.

Гыйбадулла. Бар әле, алып чык.

Зөлхиҗә. Китсәнә. Әбрәкәй янында ашап утырмасаң... Бар, мин торып торам.

Гыйбадулла. Бик артык саранланма. Авыл кешеләреннән алма. Алар әллә каян күренеп тора.

Зөлхиҗә. Өйрәтмә. Килгәндә чиләк белән су алып кил.

*Гыйбадулла киткәч, комганнарны рәтләп куя. Радионы бар көченә акырта. Машина килеп туктаган тавыш. Хөкемдаров белән Чистюлькина керәләр.*

Хөкемдаров *(бәдрәфкә күрсәтеп).* Нәрсә бу? Әй, апа, акыртма радионны. Нәрсә бу?

Зөлхиҗә. Әбрәкәй.

Чистюлькина. Туалет дигән сүз, Самуил Иванович.

Хөкемдаров. Нигә мин бу турыда белмим?

Чистюлькина. Мин үзем дә беренче тапкыр күрәм.

Хөкемдаров. Кем рөхсәте белән?..

Зөлхиҗә. Ирем ясады.

Хөкемдаров. Теге сәнәк тотып, кеше куркытып йөрүчеме?

Зөлхиҗә. Нишләп куркытсын? Берәүне дә куркытмады. Агачлар арасына гына кертмәде.

Хөкемдаров. Кем рөхсәт итте?

Зөлхиҗә. Ниткән рөхсәт?

Хөкемдаров. Бу туалетны монда куярга кемнән рөхсәт алдыгыз?

Зөлхиҗә. Бәтәч, рөхсәт кирәкмени ана?

Хөкемдаров. Сездән рөхсәт алдылармы, Аллария Ахметовна?

Чистюлькина. Ю-у-ук, Самуил Иванович.

Хөкемдаров. Районда җинаять кылына, сез белмисез. Ростехнадзор ни карый, экологлар нишли? Сез бит санэпидемстанция.

Чистюлькина. Тикшерербез, Самуил Иванович.

Хөкемдаров *(Зөлхижәгә)*. Моны төзүче үзе кайда?

Зөлхижә. Ашарга дип киткән иде.

Хөкемдаров. Чакырыгыз.

Зөлхижә. Гыйбадулла!..

*Кычкырып чыгып китә. Хәяли керә.*

Хәяли. Акча бирсәгез, жырлыйм.

Хөкемдаров *(Чистюлькинага)*. Кем ул?

Чистюлькина. Белмим.

Хәяли. Хәяли мин. СССРның халык артисты. *(Жырлап бии.)*

«СССР» диеп язылган
Самалют канатына.
Яхшы ударниклар сайлыйк
Совет аппаратына.

*Гыйбадулла белән Зөлхижә керәләр.*

Гыйбадулла. Бар, Хәяли, автобуслар килмиме, кара. *(Хәяли киткәч)*. Ни бар?

Хөкемдаров. Кем рөхсәте белән төзеден бу туалетны?

Гыйбадулла. Үземнен рөхсәт белән.

Хөкемдаров. Жирне кем бирде?

Гыйбадулла. Үзем алдым.

Хөкемдаров. Ә син бу жирнен дәүләт жире икәнлеген беләсенме?

Гыйбадулла. Бу жиргә бабайлар килеп урнашканын беләм. Дәүләт булганмы ул чакта, белмим.

Хөкемдаров. Ярый, аңлатырлар. Мин машинада булам, Алларин Ахметовна. Сез үз линиягез буенча аңлатыгыз ана.

*Китә.*

Чистюлькина. Нигә сез анын белән шулай сөйләшәсез? Кем икәнен белмисезме?

Гыйбадулла. Беләм. Синен дә кем икәненне беләм. Теге юлы пес итәргә кертмәгән идем агачлар арасына. Менә син керсен дип ясап куйдым.

Чистюлькина. Нигә безнен санэпидемстанциядән рөхсәт алмадыгыз?

Гыйбадулла. Сезнен эшне эшләгән өчен нигә сездән рөхсәт сорарга?

Чистюлькина. Сез нәрсә, туалетнын тирә-якка нинди ис таратканнын белмисезме?

Зөлхижә. Сон, жаныкаем, белгәнгә күрә ясады бит инде Гыйбадулла. Түзеп булмаганга ясады. Менә хәзер, Аллага шөкер. Ышанмасан, кереп кара.

Чистюлькина. Ә канализация кайда?

Гыйбадулла. Чокыры тирән казылган.

Чистюлькина. Суы кайда?

Зөлхижә. Менә ич комганнар. Чип-чиста су. Чыгып кул югач, сәртергә тастымал.

Чистюлькина. Комган ул водопровод түгел.

Зөлхижә. Беләбез, жаным. Казандагы туганнарым водопровод суын эчәләр. Мин анын белән тәһарәт алырга жирәнәм. Ә болар чишмә суы.

Чистюлькина. Апа, синен белән спорлашырга минем вакытым юк. Алып кит бу комганнарынны, кеше көлдермә.

Гыйбадулла. Нәрсә син комганга бәйләнден? Сина хәтле килгән нимес аны әле сатып алмакчы булды. Син комганнан көләргә ашыкма.

Чистюлькина. Барыбер рөхсәт алырга кирәк. Тиешле акчасын түләгез дә...

Зөлхижә. Акча да түләргә кирәкмени әле?

Чистюлькина. Акчасыз рөхсәтне кем бирә? Менә шул: штраф түләгәнче, рөхсәт өчен түләгез. Кара син аларны, теләсә кайда туалет ясап йөриләр дә, алар өчен жавап бир.

Зөлхижә. Туктале, сенелкәем,

нәрсә алай җикеренәсең? Кем булдың ул кадәрле? Кыланышыңны Казанга язсак, күрсәтерләр штрафыңны.

Чистюлькина. Язып карагыз.

Зөлхиҗә. Язарбыз да. Казанда сине якласалар, Мәскәүгә язарбыз.

Чистюлькина. Ха-ха...

Зөлхиҗә. Нәрсә хахылдыйсың?

Чистюлькина. Ха-ха-ха. Без, гражданка, штрафны Мәскәү кушканча салабыз. Санитария нормаларын бозган өчен. Аңлашыламы?

Зөлхиҗә. Абау кыланышы. Штрафыңны менә бу куаклыкны сасыткан өчен салырга иде.

Чистюлькина. Анда эшегез булмасын.

Зөлхиҗә. Минем эшем бар, синеке — юк. Мә, комган, тәһарәтләнеп чык. Санитар чиста йөрергә тиеш.

Чистюлькина. Йорттерермен әле мин сезне.

*Пырлап чыгып китә. Җырлап-биеп Хәяли керә.*

Хәяли. *(Бәдрәфкә кереп китә. Бәдрәф тәрәзәсеннән башын тыгып җырлый).*

Сандугачым-гөлкәем,
Гөлгә салган күкәен.
Рәхәт тормышларда яшәп
Үтәдер гомеркәем.

Зөлхиҗә. Хәяли, чык аннан.

*Күмербәков керә. Хәяли бәдрәфтән чыгып, аның каршына килә.*

Хәяли. Акча бирсәң, җырлыйм.

Күмербәков. Нинди акча?

Зөлхиҗә. Хәяли, кит аның яныннан. Акчасы юк аның.

Хәяли *(җырлый-җырлый китә).*

Акча безгә — мунча ташы,
Ефәк безгә — мунчала.
Рәхәт тормышларда яшәп
Керсәң иде мунчага.

Күмербәков *(бәдрәфкә карап).* Что это такой?

Зөлхиҗә. Абау. Урысча сөйләшкән була. Урысча белмәгән килеш.

Күмербәков. Мин синнән татарча сорыйм — что это такой?

Зөлхиҗә. Әбрәкәй икәнен күрмисең мәллә?

Күмербәков. Нигә ул монда тора?

Зөлхиҗә. Шунда куйганга тора.

Күмербәков. Нимидлинне убирать!..

Гыйбадулла *(кереп, сөйләшкәнне тыңлап торганнан соң).* Чём дило?

Күмербәков. Син кем?

Гыйбадулла. Менә бу хатынның ире.

Күмербәков. Значит, бу саружиние синеке?

Гыйбадулла. Безнеке.

Күмербәков. И для чиго?

Гыйбадулла. Әллә әбрәкәй күргәнең юкмы?

Күмербәков. Малчать!

Гыйбадулла. Әй-әй, Карамалы малае, малчатланма. Нәрсә кирәк?

Күмербәков. Син миңа зуба ни загаваривай. Нигә бу саружиние монда тора? Кем разришал?

Гыйбадулла. Үзем.

Күмербәков. Ах, үзең... Фидиральный дорога янында пажароопасный обиект. Син кайсы илдә яшисең?

Гыйбадулла. Татарстанда.

Күмербәков. Ошибаешсә, гражданин. Фамилияң ничек?

Гыйбадулла. Путин.

Күмербәков. Ә? *(Як-ягына карангалап).* Ты что? Көләсең, да?

Гыйбадулла. Көләм.

Күмербәков. Кемнән?

Гыйбадулла. Синнән.

Күмербәков. Син минем кем икәнне беләсеңме? Знаешь?

Гыйбадулла. Беләм. Бергә аракы эчкән бар.

Күмербәков. Ни помню.

Гыйбадулла. Минекен эчтең шул. Үзеңнекен эчсәң, хәтерләр идең.

Күмербәков. Короче, убирай моны. Иначы штраф салам, тавариш Бадриев.

Зөлхиҗә. Туктале, җикеренмә,

кем... Ничек безнең әбрәкәй опасный булсын?

Күмербәков. Фидиральный дорогага моннан ничә метр? *(Кесәсеннән лентады метр чыгара).* Тот әле бу башыннан. *(Метр белән юлга каләрле араны үлчәп).* Равны тугыз метр ярым. Әгәр үтеп барган машинанын глушителеннән искра монда таба чәчрәсә, ни була? Бу саружиниегә ут каба. Понял? Әгәр бу саружениегә берәр пьяный кереп тәмәке тартса, аны сүндерми чыкса, ни була? Пожар. Әгәр в это время фидиральный дорогадан правительственный машина үтеп барса, ни була?

Гыйбадулла. Тирраризм.

Күмербәков. Во-во. Үзең дә беләсең.

Гыйбадулла. Дурак син, Күмербәков.

Күмербәков. Что, что?

Гыйбадулла. Дурак, дим.

Күмербәков. Аскарбляешь? Хорошо. Иртәгә кемнең дурак икәнен белербез.

Гыйбадулла. Башың авыртмыймы, Карамалы малае?

Күмербәков. Свалыч.

*Китеп бара.*

Зөлхиҗә. Бик ни сөйләштең, Гыйбади. Штраф, ди.

Гыйбадулла. Салып карасын.

Зөлхиҗә. Былтыр нишләтте. Моржагыз кыек тора дип, күпме түләтте? Күрше Сабирларга моржагыз кыска, дип штраф салды.

Гыйбадулла. Башы төзәтелмәгән анын, вәт бәйләнә.

Зөлхиҗә. Дөньясы тулы башы төзәтелмәгәннәр. Монысы гына аек йөрмәс. Монда әле бер санитар дулап чыгып китте. Санэпидемстанциядән, ди. Ул да штраф дип янады.

Гыйбадулла. Кертергә иде, бушка пес итәсе килгәндер.

*Салымгалиев керә.*

Салымгалиев. Исәнмесез, күршеләр. Менә күреп туктадым әле. Яналык бар икән монда. Котлы булсын. Кәкре Каенныкылар яши белә инде. Каян башыгызга килде? Өстәмә доход. Түләүледер бит?

Гыйбадулла. Бушка булмас инде.

Салымгалиев. Безнен авыл йоклап ята. Беркөн янгын чыккач та сүндерергә килүче булмаган. Янсын, ди берсе, элеккеге колхоз складлары, ди, барыбер салырга әйбер юк, ди. Болай ничек сон? Документлары тәртиптәдер инде?

Гыйбадулла. Нинди документлар?

Салымгалиев. Налог буенча дип әйтүем.

Зөлхиҗә. Тәртиптә. Палитилин пакетта саклыйм. Өйнеке дә тәртиптә, бакчаныкы да. Аллага шөкер, түләп барабыз.

Гыйбадулла. Түләмичә. Олигархларга акча кирәк бит. Ачтан үлә күрмәсеннәр.

Зөлхиҗә. Адәм көлкесе инде. Алла биргән җиргә бездән налог түләтәләр.

Салымгалиев. Алла бит аны сезгә дип атап бирмәгән.

Зөлхиҗә. Кемгә дип атап биргән сон?

Салымгалиев. Кешеләргә дип...

Гыйбадулла. Без кеше түгелмени?

Салымгалиев. Дөресен генә әйткәндә, кеше үк түгел инде, гражданин гына. Аннан сон, сез түләгән налог ул аерым кешегә түгел, кешеләргә... Кешеләр интересын кем яклый? Дәүләт. Кешеләр интересын яклар өчен, дәүләт гражданнарга налог түләтә. Тә-ә-к... күпме җир мәйданын били инде бу әбрәкәй? Икегә ике метр булыр. Ана килә торган сукмак. Тегесе-монысы йөз квадрат метр булырдыр. Яхшы, яхшы. Регистрация үткәнсездер бит? Шәхси милек итеп теркәгәнсездер?

Гыйбадулла. Милек саналамыни бу?

Салымгалиев. Ә нәрсә саналырга тиеш? Бу — сезнен милек.

Милек өчен дә налог түләнергә тиеш. Түләүле дә, дисен. Димәк, бизнес. Анысы өчен аерым налог. Бу культура учагына керү бәясе күпме инде?

Гыйбадулла. Ныклап санаган юк әле.

Салымгалиев. Санарга кирәк. Бөтен нәрсә санаулы булырга тиеш. Тә-ә-әк... Уртача биш сумнан алыйк. Кама күпере янында шулхәтле алалар. Тә-ә-әк... Биш сум. Көненә уртача йөз кеше кереп чыкса, биш йөз сум. Айга уртача унбиш мең... Каядыр уртача биш меңнәр түләргә туры киләчәк.

Зөлхижә. Биш мең? Ни өчен?

Салымгалиев. Бизнес өчен, күрше. Закон. Ә закон үтәлергә тиеш. Шуңа күрә тизрәк регистрация үтегез дә налог түли башлагыз. Югыйсә... Югыйсә, ни буласын беләсез инде — закон чыгаручы илдә яшисез.

Гыйбадулла. Шулай талаттырганчы, мин аны җимереп ташлыйм.

Салымгалиев. Анысын үзегез карагыз инде, әмма закон үтәлергә тиеш. Законлы предприятиегә әйләнгәч, мин моннан үткәндә түләп керермен инде, законсыз булгач, түләмичә генә кереп чыгам. Шулайдыр бит?

Гыйбадулла. Алайса, син бушка бәдрәфкә керергә рөхсәт дигән документыңны күрсәт.

Салымгалиев. Молодец! Чын бизнесмен. Мә, биш сум, вакланып тормыйм.

Зөлхижә. Без дә вакланмыйбыз. Сиңа хәтле кергәннәр ун сум түләде.

Салымгалиев. Молодец хатын син, күрше. Алайса. Мин өйгә хәтле түзәрмен инде. Сау булыгыз, күршеләр. Налог турында онытмагыз. Бәхетсезлеккә юлыгуыгыз бар.

Гыйбадулла. Ярый, бар инде, күрше хакына бушка кереп чык.

Салымгалиев. Ләкин бу сезне налог түләүдән коткармый.

*Бәдрәфкә кереп китә.*

Зөлхижә. Нигә керттең?

Гыйбадулла. Бәласеннән башаяк. Бәйләнчек кеше, диләр аны.

*Биеп-җырлап Хәяли керә.*

Хәяли.

Ак алъяпкыч билләрдә,
Җилфердәми җилләрдә.
Шундый рәхәт, матур тормыш
Без яшәгән илләрдә.

*Бәдрәфкә юнәлә.*

Гыйбадулла. Анда кеше бар, Хәяли.

Хәяли. Нишли?

Гыйбадулла. Нишли дип... Беләсең ич инде, үзең дә күрдең.

Хәяли. Мин тәрәзәсеннән карарга гына кердем.

Зөлхижә. Син, Хәяли, монда җырлап кына тор, ярыймы.

Хәяли. Ярый. Нинди җырны?

Зөлхижә. Рәхәт яшәвебез турында.

Хәяли. Ә-ә-ә... Беләм, беләм.

Әнә килә афтамабил,
Төягәннәр аракы.
Сиңа рәхәт, миңа рәхәт –
Нәрсә җитми, сабакы?

*(Бәдрәфтән чыккан Салымгалиевкә).* Акча бир.

Салымгалиев. Син кем?

Хәяли. Әллә мине белмисеңме?

Гыйбадулла. Моның да акчасы юк, Хәяли. *(Чыгып киткән Салымгалиевкә).* Сау бул, күрше.

Зөлхижә. Бигрәк инде син. Күрше дигән булып шуңа.

Гыйбадулла. Рәхмәт әйт, взятка алмады.

Хәяли. Гыйбадулла абый, хәзер керергә ярыймы?

Гыйбадулла. Бар, Хәяли, бар. *(Хәяли кереп киткәч).* Менә бәхетле кеше. Коттежы да юк, яхтасы да юк.

Хәяли *(бәдрәф тәрәзәсеннән башын тыгып).*

Сандугачлар сайрый чут-чут дип,
Безнең илдән рәхәт ил юк дип.

*Кәттә егет керә.*

Кәттә егет *(Хәялигә).* Нихәл, Хәяли?

Хәяли. Чыкмыйм. Син рекетюр.

*Кәттә егет Хәялине бәдрәфтән сөйрәп чыгарып, артына тибеп озата.*

Гыйбадулла. Ник тиясен ана?

Кәттә егет. Телен тыйсын.

Гыйбадулла. Тилемсә бит ул, беләсең.

Кәттә егет. Тиле булса, тиленәр йортында яшәсен. Нәрсә, Гыйбадулла бабай, баерга уйладыңмыни?

Гыйбадулла. Әтиеннәр котәдер. Күптән күренгәнен юк.

Кәттә егет. Син сүзне икенчегә борма. Баерга уйладыңмы, дим.

Гыйбадулла. Баеса ни.

Кәттә егет. Дөрес эшлисең. Безнең авылда да байлар булырга тиеш. Ату бурычка акча алып торырга кеше юк. Әйбәт нәрсә. Мона кызыгучылар да булыр инде. Көнләшүчеләр. Ут төртә күрмәсеннәр.

Гыйбадулла. Кем төртсен?

Кәттә егет. Беткәнмени. Крыша кирәк мона.

Зөлхиҗә. Түбәсе бар аның.

Кәттә егет. Син, Зөлхиҗә түти, ирләр сөйләшкәндә тик кенә тор. Син, Гыйбадулла бабай, курыкма. Мин булганда, бу нигә беркем тимәс. Тиеп кенә карасыннар. Үзем крыша булам.

Гыйбадулла. Рәхмәт.

Кәттә егет. Андый эш рәхмәткә генә эшләнми ул. Мин күп сорамыйм, аена биш мең җитә.

Зөлхиҗә. Нәрсә-ә-ә? Андый акчаны!..

Кәттә егет. Ярый, Гыйбадулла бабай, әтиләр котәдер, мин киттем. Калганын икәү сөйләшеп бетерерсез. Бераз аванс кирәк булыр, иртәгә сугылырмын.

*Китә.*

Зөлхиҗә. Карале моны, ә? Баемакчы булган. Нәселләре белән әшәке булдылар. Гыйбади, син нигә дәшмисең?

Гыйбадулла. Уйлыйм әле.

Зөлхиҗә. Уйлыйсы-нитәсе юк, бер тиен дә бирмибез.

*Полицейский керә.*

Полицейский. Здравие желаю, Гыйбадулла абый.

Гыйбадулла. Исәнме, Камзулов. Кая барыш?

Полицейский. Менә, эт куып йөрибез. Кушалар. Сиңа җибәрделәр.

Гыйбадулла. Мина ни булган?

Полицейский. Нәрсәдер эшләгәнсеңдерме? Прокуратурадан шалтыратканнар. Нәрсә булды монда?

Гыйбадулла. Нәрсә булсын... Яшибез.

Полицейский. Нәрсәнедер тартып алгансыңмы шунда. Җирме, ди. Самовольно. Булдымы шундый хәл?

Гыйбадулла. Ә-ә-ә... *(Бәдрәфкә күрсәтеп).* Моны әйтәләрдер.

Полицейский. Нәрсә, аны берәрсеннән тартып алдыңмы?

Зөлхиҗә. Ничек инде тартып алсын, үзе эшләде.

Полицейский. Белмим инде, тикшерергә, протокол төзергә куштылар. Ничегрәк язарга икән соң?

Гыйбадулла. Милиция чагында ничек яза идең соң?

Полицейский. Ул чакта җинел иде, хәзер кем белә ничек язасын. Сөйлә инде, Гыйбадулла абый, ничегрәк тартып алдың?

Гыйбадулла. Берни дә тартып алмадым мин, энекәш.

Полицейский. Энекәш димә инде, Гыйбадулла абый. Энекәш дип әйттерергә кушмыйлар.

Гыйбадулла. Ничек кушалар соң?

Полицейский. Начальник үзе дә белеп бетерми әле. Ну, господин полицейский, диген.

Зөлхиҗә. Нинди господин инде син? Ләтчә авылы малае.

Полицейский. Ярый инде. Язык инде, Гыйбадулла абый. Прокурор бик бәйләнчек кеше.

Гыйбадулла. Язма, кирәкми.

Полицейский. Булмый, Гыйбадулла абый. Куып чыгарулары бар. Хәзер район җирендә эш юк. Мин сине беләм. Элек булса, бер яртыны бүлеп салыр идек тә...

Гыйбадулла. Хәзер эчмисеңмени?

Полицейский. Әлегә юк. Тәртипкә салып бетерсеннәр әле. Аннары барысы да элекке урынга кайта ул. Әйдә, утыр әле, эшне бетерик. Ничегрәк тартып алдым дидең?

Гыйбадулла. Син, энекәш, кайт районга, әйт, мин анда бернәрсә дә күрмәдем, диген.

Полицейский. Күрдем бит, Гыйбадулла абый, тора бит. Килеп тикшерсәләр...

Гыйбадулла. Тикшерсәләр, монда бер әйбер дә булмас.

Полицейский. Ничек булмас?

Гыйбадулла. Сүтеп ыргытам мин аны.

Полицейский. Шулаймы? Язмыйм алайса. Алдамассыңмы?

Гыйбадулла. Син нәрсә инде? Әйдә, безгә кереп чыгыйк. Полицай булсаң да, әйбәт егет син. Милиция чагында начар түгел идең.

Полицейский. Юк, рәхмәт, Гыйбадулла абый. Берәр ай үтсен әле, карарбыз. Сүтәсең инде, әйеме?

Гыйбадулла. Әйттем бит.

Полицейский. Сау бул, Гыйбадулла абый.

*Китә.*

Зөлхиҗә. Син чынлап әйттеңме, Гыйбади?

Гыйбадулла. Бар, балта белән чүкечне алып кил. Комганнарыңны алып кит.

Зөлхиҗә. Дурак нимес, йөри шунда кеше котыртып.

*Ут сүнә.*

## Өченче күренеш

*Ут янганда, бәдрәф инде юк. Ул урында Гыйбадулла белән Хәяли басып тора. Гыйбадулланың кулында ау мылтыгы.*

Хәяли. Әйбәт ие ул ни. Тәрәзәсеннән карарга рәхәт иде. Бу мылтык атамы, иптәш Бәдриев?

Гыйбадулла. Сиңа атмый, курыкма.

Хәяли. Бүтәннәргә атамы?

Гыйбадулла. Бүтәннәргә дә атмый, куркытыр өчен генә.

Хәяли. Куркаламы?

Гыйбадулла. Син күп сорашма, Хәяли. Җырла гына син.

Хәяли. Бии-бииме?

Гыйбадулла. Бии-бии.

Хәяли *(җырлый)*

Дулкынланып сулар кервә
Парахут идәненә.
Мондый рәхәт, матур тормыш
Тик безнең илдә генә.

*Хәялигә Гыйбадулла кушыла. Икәүләшеп җырлый-җырлый биилиләр.*

Ак алъяпкыч билләрдә,
Җилфердәми җилләрдә.
Мондый рәхәт, матур тормыш
Без яшәгән илләрдә.

*Пәрдә.*

*2009 ел*

Туфан Миңнуллин

# ХАТ БАШЫ — ЯЗ КАРШЫ

БӘЯН

## 1

Күк йөзендәге бихисап йолдызлар кинәт калтыранып куйдылар да, дәррәү кузгалып өй янына җыйнала башладылар. Яктырак янганнары айның янәшәсенә елышты, тоныграклары читкәрәк урнашты. Арада сабырсызлары да бар — алар кабаланалар, айның өстенә үк менеп утырмакчылар. Ай андыйларны ачулана, этеп җибәрә. Шул чакта миллион очкыннар чыгып галәмгә сибелә.

Ниһаять, барысы да урнашып бетте. Кайдандыр нindидер көй пәйда булды: чың-чың-чың... Йолдызлар ай тирәли әйләнеп биергә тотындылар. Гаҗәеп бию иде бу. Ай елмая, ай көлә, ә йолдызлар түгәрәк уены уйнап биилар: салмак кына, ашыкмый гына бер-ике адым ясыйлар да вак-вак атлап йөгереп китәләр, капылт туктап, бер чүгәләп-чүгәләп алалар.

Чулпанның мондый бию күргәне юк иде әле. Шаккатып, таң калып карап торды ул йолдызларның әйлән-бәйләненә. Аларга кушылып биисе, сикерәсе, очынасы килеп китте.

Кызның уен, теләген ин беренче булып Чулпан йолдыз сизде, биюеннән туктады. Бүтән йолдызлар да тукталылар. Чулпан йолдыз, айның каршына очып төшеп, айга болай диде: «Аебыз — кадерлебез, мин беләм, син мине өзелеп яратасың, шуна күрә үз яныңнан еракка җибәрмисең, миңа да синнән якынрак җисем юк. Күк шаһит, һәр җемелдәвем синең өчен. Бу юлы миңа синең тирәли биемәскә рөхсәт ит. Юк, биисе килмәүдән түгел. Сәбәбе башка. Әнә, күрәсеңме, җирдә — нурларың астында Чулпан исемле кыз сиңа һәм безгә сокланып карап тора. Ул да Чулпан, мин дә Чулпан. Урыннарыбызны алышып торыйк аның белән. Биесен күңеле булганчы».

Ай рөхсәт бирде. Чулпан йолдыз җиргә төште, Чулпан исемле кыз күккә ашты. Йолдызлар ана кулларын суздылар, ай кызның чәченнән сыйпады. Бию дәвам итте.

Биеде дә соң Чулпан! Биюе шундый рәхәт, шундый җиңел. Аяклар үзләреннән-үзләре галәм көенең ритмына баса, куллар — канат.

Бию кызулыгыннан Чулпан түгәрәкнең уртасына килеп чыгып бер урында бөтерелгәнен дә сизмәде. «Чулпан! Чак кына сабыр ит!» дигән тавыш ишетелде. Кыз туктап як-ягына карады: ай да, йолдызлар да аның тирәсендә әйләнә

иде. Чулпанга сабыр итәргә кушучы ай үзе икән, әнә ул тагын кызга эндәште: «Жиргә күз сал», — диде.

Жирдә ике кулын кесәсенә тыгып Иршат басып тора. Башын артка ташлап күккә карый, авызы ачылган, сул күзе кысылган. Бит урталарында, борыны очында һавадагы йолдызлар санынча сипкел.

Кинәт кенә әллә ни булды Чулпанга. Йөзе житдиләнде, күзләре моңсуланды, шашып биюен онытты — хәрәкәтсез калды. «Ни булды аңа?» — дип сорадылар йолдызлар. «Кызның йөрәгендә мәхәббәт дигән олы хис кабынды, Чулпан олыгайды, ул үз гомерендә беренче тапкыр чын-чынлап гашыйк булды», — дип жавап бирде ай.

Чулпан уянып китте. Ни эшләгәнен белештермичә, урыныннан сикереп торды, тәрәзә янына барды. Тышта таң атып килә. Ә Иршат кайда? Әле генә шунда басып тора иде ич. Нигә качты? Тәрәзәне ачып бакчага карады Чулпан. Иршат алмагачлар арасында да юк иде. Тукта, нигә эзли соң әле Чулпан шул Иршатны? Кем соң әле ул Иршат? Нигә кирәк ул? Мәктәптә күреп тә жан бизгән. Каршыга килеп баса да, сул күзен кысып, мыскыллаган сыман карап тик тора. Кит дисәң дә китми, әйткәнеңне ишетми дә. Этеп жибәргәч кенә ике кулын кесәсенә тыгып, ашыкмыйча, сызгырынып китеп бара. Бит урталары, борын очы тулы сипкел.

Чулпан урынына барып ятмакчы иде. Еракта-еракта, таң сызылып килгән офыкта Иршатны күреп туктап калды. Сул күзе кысылган, ике кулы кесәдә, бит урталары, борын очы тулы сипкел. Үзе: «Мин дә сине бик яратам, Чулпан», — дип кычкыра.

Офыкта, әлбәттә, кысылган күзле, сипкелле Иршат юк иде. Яратам дип тә кычкырмый иде. Чулпанга гына күренде ул. Яратам дигән сүз Чулпанга гына ишетелде. Аңа бу иртәдә уналты яшь тулган иде.

*(Ризван Маликовның хикәясеннән өзек).*

2

## Хат башы — яз каршы

*Мәхәббәт ул саф була,*
*Мәхәббәт ул бер генә була.*

Ризван балакаем, күктәге йолдызлар, судагы балыклар санынча күптән-күп, чуктин-чук сәламнәр жибәреп калам. Исемеңнең Ризван икәнен беләм. Фамилияң хәтердән чыккан инде, Чулпаннан сорадым да ул әйтеп бирде. Чулпан — ул безнең бик акыллы кызыбыз. Мин инде үзем Сөембикә атлы булам. Атлы дигән сүз исемле дигән сүз була инде, Ризван балакаем. Мин инде бик олы карчык, тешләрем дә юк инде хәзер, ипинең дә йомшагын гына ашыйм. Катысын Чулпанга бирәм. Чулпан ашамаса, суга салып жебетәбез дә казларга-тавыкларга чыгарып салабыз. Үзем салам инде. Чулпанга әйтәм дә чыгарып сал шул жебегән ипине казларга-тавыкларга дип, дәрес әзерлисем бар ди. Тыңлаусыз бала безнең Чулпаныбыз. Мине түгел, әтисен, әнисен дә бик үк тыңламый. Ә мин аның әбисе булам инде. Әтисенең әнисе. Синең хәлләрең ничек соң, балакаем? Чирләмисеңме? Эчен-башың авыртмыймы? Дус-ишләрең исән-саулармы? Үзләренә күп иттереп сәлам әйт инде. Мөслим районыннан Ишем авылындагы Сөембикә әбидән сәлам диген. Мин сиңа әби тиештер инде. Бик алай карт күренмәгән идең сәхнәдән. Чулпан да әйтеп торды, син Ризван абыйга әби тиеш буласың, диде. Ул әйткәч, дөрестер. Минем үземнең, балакаем, күзләрем дә бик әйбәт күрмиләр шул. Энәгә жепне дә Чулпан кызым

саплап бирә. Бик тә, бик тә игелекле бала үзе ул яктан. Сиңа хат язырга да күзем күрми, Ризван балакаем. Күршедәге Алсу атлы кызга әйтеп торып яздырам. Чулпанга әйткән идем дә, Ризван абыеңа хат язып бир минем өчен дип, тыңламады, хәерсез.

Әйтергә дә онытканмын, хәтерем начарланган. Син мине белмисеңдер дә әле, Ризван балакаем. Язучылар җыелышып килдегез бит күптән түгел генә Мөслимгә? Шунда мине дә алып барган иде Чулпан. Мөслимнең үзенә түгел инде. Безнең авыл бәләкәй. Бәләкәй булганга, аңа артистлар килми. Артистлар карарга колхоз үзәгенә — Балтач авылына барабыз. Шунда алып барды Чулпан. Анда син дә бар идең, балакаем. Бөтен язучыларның уртасында утырдың. Язганыңны укыдың безгә. Бүтәннәр шигырь укыды, син хикәя укыдың. Укыганың миңа бикләр дә ошады инде. Чулпанга да ошады. Әйттем әле шунда Чулпанга, менә алар кебек бул, дидем.

Бу хатны язганым шуның өчен, Ризван балакаем, Чулпанга матур итеп хат язмассыңмы икән, акыл өйрәтеп яз әле шуңа. Менә әле гәҗиттән синең язганыңны укыды Чулпан. Аның исемен әйтеп язгансың. «Чулпан таңны уята» дигәнсең. Әбиләр өчен язылган хикәя инде менә, каплаган да куйган. Укып еладым. Яшь чакларым искә төшеп китте. Шул инде, безнең заман инде, безнең заман. Хәзерге яшьләрнең бүтәнрәк шул. Алар икенче төрлерәк. Чулпан да шулай ди, хәзер алай түгел ди. Ничек икәнен үзе дә белми, балакаем. Бигрәкләр дә яшь шул әле, балакаем, унбишне тулып, уналтынчыга гына чыкты. Быел, Алла боерса, сигезенчене бетерә. Укуы әллә ни куандырырлык түгел түгеллеккә. Тик зиһенле бала. Бер дә генә белмәгәне юк. Уны укып бетерәм шул дип йөри үзе, институтка керәм, ди, синең сыман язучы булам, ди. Кем белә инде аныcын. Үзе болай шигырьләрне бик оста яза. Кайсыберләрен миңа кычкырып та укып җибәрә. Әтисенә, әнисенә укымый, миңа гына укый. Әтиләре, әниләре өйдә юк чакта. Янымa килә дә: «Әби шигырь укыйммы?» — ди. «Укы, балакаем, укы», — дим. Шуннан укый. Болай үзләре ярыйсы кебек. Гәҗиткә басырлыклары да бар сыман. Язучы абыеңнарга күрсәт, дим. Мин аларны белмим бит ди. Ризван абыеңа җибәр, дим. Ул мине белми, ди. Соң, мин әйтәм, кулыңда китабы бар Ризван абыеңның, «Чулпанга! Бәхетле бул». Ризван Маликов», — дип язылган китабы, дим. Белмәгән кешегә шундый сүзләр язалармы, дим. Ул миңа гына түгел, бөтенебезгә дә шулай язды, ди. Ничек инде барыбызны да хәтерләсен, ди. Хәтерлисеңдер дә әле, Ризван балакаем. Кара чәчле, кара кашлы, кара күзле кыз инде. Класстагы малайлары аңа чибәр дип әйтәләр ди, иптәш кызлары көнләшәләр ди.

Ризван, балакаем, сиңа хат язуым шуның өчен, син Чулпанга, шигырьләреңне миңа җибәр, дип хат яз. Оялма, диген. Син, диген, мин язганнарны яратып укыйсың икән, диген, үзең язганнарны да мин укып карыйм әле, диген. Минем шигырь язганымны кайдан беләсең, дип хат язса, әбиең әйтте, диген, ярыймы? Чулпан үзе җибәрәсе шигырьләрне көтәргә бик озак дисәң, мин сиңа аның бер шигырен дәфтәреннән күчертеп алып җибәрәм.

Сорау бирдем бу дөньяга —
Ике генә сорау бары:
Нигә кара кара карга?
Сандугачкай нигә сары?
Дөнья миңа җавап бирде:
Сандугачкай шуңа сары —
Тавышыннан төскә күчкән
Сагышлары, моңы, зары.

Дөнья миңа җавап бирде:
Шуңа кара кара карга —
Көнләшүдән кара көйгән
Сандугачның моңы барга.

Ярый, Ризван балакаем, сау булып тор. Саулык синә да кирәктер. Ничә яшьтә инде үзең? Кирәк инде, яшьләргә дә картларга да кирәк саулык. Хат яз, яме. Миңа атап та яз, Чулпанга да яз. Хатны язучы Ишем авылыннан Сөембикә карчык дип белерсең.

20 сентябрь, 1970 ел.

3

— Сөембикә әби, саумысез? Хатыгызны алдым, рәхмәт. Рәхмәтем шуның өчен, Сөембикә әби, мине хәтерләп калгансыз. Янә дә тагын шуның өчен, оныгың Чулпанга акыл өйрәтеп хат язу эшен ышанып тапшыргансыз. Белмим шул, ничек итеп мин ул кара күзле, кара кашлы кызга акыл өйрәтә алырмын икән. Бигрәк тә читен эш бит ул читтән торып акыл өйрәтү. Кем белә, бәлки ул миннән дә акыллырактыр. Үзегез үк язгансыз — Чулпан безнең бик акыллы кызыбыз, дигәнсез. Әнә мин язган этюдны да тәнкыйтьләп ташлаган. Бәлки ул хаклыдыр да: хәзерге унбиш яшьлекләр икенче төрлерәктер, бездән аерылып торалардыр. Мин үзем дә, әлбәттә, хәзерге яшьләр дип сөйләрлек дәрәҗәдә үк өлкән түгел, шулай да егерме яшь аерма бүгенге заман өчен шактый. Күп нәрсәләрне аңлап бетермәвем табигый. Сезнең турыда әйтеп тә тормыйм, безнең балачак авыррак елларга туры килде — сугыш вакыты. Әниләрнең безне кочакларына алып иркәләргә вакытлары юк иде, азып-тузып китсәк, тузаннарыбызны каккаларга әтиләрнең каешлары да үзләре белән фронтка киткән иде.

Чулпаныгыз — икенче заман кешесе. Шуңа күрә, мин язганны ошатмавына аңа үпкәләмим. Мин бер нәрсәгә сөенәм: Сөембикә әби, шигырьләрен Чулпан сезгә укый икән — димәк, ул Сезгә ышана. Минемчә, бу — зур бәхет. Сезнең өчен дә, аның өчен дә. Ә шигыре Чулпанның миңа ошады. Мин, билгеле, үзем шигырь язучы, ягъни шагыйрь түгел. Аңа болай яз, тегеләй яз дип киңәшләр бирергә куркам. Шулай да шагыйрьләр янында йөргән кеше буларак, әз-мәз аңлыймдыр. Аңламасам да, күңелем белән тоям, сизәм. Ул шигырьнең Сезгә ошавына да куанам. Сез — шигырь җанлы кеше, Сөембикә әби. Чулпанның ни чаклы шигырьләре арасыннан шунысын, иң әйбәтен күчереп җибәрүегез куанычлы. Мин аны шагыйрьләргә күрсәтермен. Тик аларга күрсәткәнче үк Чулпаныгызның әбисе шикелле шигъри күңелле кыз икәненә ышанам. Аңа уңышлар телим. Киләчәктә дә күңеле сүрелмәсен иде, бәхетле булсын иде. Кызганычка каршы, мин аңа китап бүләк иткәнемне хәтерләмим. Ләкин, бәхетле бул, дип дөрес язганмын. Тагын бер кат оныгыгыз бәхетле булсын, Сөембикә әби, дип кабатлыйм. Әйтегез үзенә, тыңлаусыз бала булмасын. Әти-әнисенең сүзен тыңласын, яхшы укысын. Чын шагыйрь булыр өчен күп укырга да кирәк.

Сезгә хат язарга булышкан өчен күршегездәге Алсу атлы кызга минем исемнән рәхмәт әйтегез. Ул да Чулпан кебек үк бәхетле булсын.

Ярый, Сөембикә әби, хатымны тәмамлыйм. Сезгә озын гомер, саулык-сәламәтлек теләп,

Ризван Маликов
1 октябрь, 1970 ел.

## 4

— Исәнмесез, Ризван Фаилович. Шулай дип язганга гаҗәпләнмәвегезне үтенәм. Сезнең әтиегезнең исемен китабыгызның соңгы битеннән укып белдем. Мин үзем Чулпанның әнисе — Кәримуллина Фәһимә Закировна, мәктәптә татар теле һәм әдәбияты фәнен укытам. Сезгә минем әнкәй, Чулпанның әбисе хат язган икән. Сезне борчуы өчен гафу итегез карчыкны. Вакыт табып хат язгансыз, анысына зур рәхмәтемне белдерәм. Әнкәй Сезнең хатны мина да укытты һәм мин дә Сезгә хат язарга булдым. Чөнки Чулпан безнең төпчек кызыбыз һәм аның язмышы, әлбәттә, безне кызыксындыра. Мин әнкәй сыман Чулпанны тәрбияләү мәсьәләсендә Сездән ярдәм сорап Сезне интектермәм. Тик үземне борчыган кайбер мәсьәләләрне Сезнең белән уртаклашырга телим.

Әйе, Чулпан быел сигезенчене тәмамлый, унбиш яшендә. Унбиш яшь — кешенең иң куркыныч чоры, диләр педагоглар. Мин, әлбәттә, өлкән педагогларның әйтүе белән тулысынча килешәм. Мина авыр Чулпан белән. Ана буларак та авыр, укытучы буларак та авыр.

Мин Сезнең «Чулпан таңны уята» исемле хикәягезне укыдым. Сез унбиш яшьлек кызның үзгәрүе турында язарга теләгәнсездер инде. Анысы дөрестер. Унбиш яшь тулгач, Чулпан да бик нык үзгәрде. Кинәт уйчанланды, моңсуланды. Безнең белән аз сөйләшә. Яки дорфа җавап кайтара. Без, әлбәттә, моның сәбәпләрен аңлыйбыз, унбиш яшь тулудан килеп чыккан аңлашылмаучанлыклар. Бәлки киләчәктә үтәр, әмма хәзер читен. Безгә дә читен, үзенә дә читен. Ләкин без, читен дип читтә кала алмыйбыз, без аны тәрбияләргә тиеш. Тиеш кенә түгел, мәҗбүр. Аларны кулдан ычкындырырга ярамый. Югыйсә, ни буласын үзегез дә күз алдына китерә торгансыздыр.

Чулпанның акыллы булуы турында әнкәй сезгә язган булса кирәк. Әйе, ул үз яшенә караганда акыллырак, мәгълүматлырак. Бик күп укый, һәм ни укыганын аңлап укый. Шигырьләр яза. Әмма әнкәйдән һәм Сездән аермалы буларак, шигырьләре мина һич кенә дә ошамый. Дөресрәге, мин аның юк эш белән мавыгуын яратып бетермим. Сез, әлбәттә, язучы кеше, әдәбият укытучысының болай дип әйтүе Сезгә сәеррәк тоелыр. Тик ана буларак Чулпанның шигырь язуына борчылам. Дөресен әйтергә кирәк, шигырь язу житди эш түгел. Әлбәттә, Тукай булган, Такташ булган. Без аларны хөрмәт итәргә тиеш. Шулай булуына карамастан, мин шигырь яратмыйм. Дөньяда житди эш эшләргә кирәк. Шул мәсьәләдә без күпвакыт Чулпан белән бәхәсләшәбез. Һәм үзегезгә генә әйтәм, күнелсезлекләр килеп чыга.

Беркөн минем кызым Чулпан дәрес уртасында партасыннан торды да чыгып китәргә җыенды.

— Кая барсың, Чулпан, — дидем.

— Шагыйрьләр турында сөйләргә синең хакың юк. Син шигырь яратмыйсың, — ди. — Син шигырь яратмаган килеш шагыйрьләр турында сөйлисен, шуңа күрә мин чыгып торам, чөнки мин сине тыңлый алмыйм, — ди.

Күз алдыгызга китерәсезме, класста ни булганын? Минем кызым минем дәресемдә, укучылар алдында шулай ди. Нәтиҗәдә, өйгә кайткач, ул да елады, мин дә еладым.

Сезнең әнкәйгә язган хатыгызда ана карата җылы сүзләр күп. Ләкин, кызганычка каршы, Чулпанны ул боза дисәм дә, ялгыш булмас. Дөресен әйткәндә, Чулпан әнкәй тәрбиясендә үсте, безнең вакыт, үзегез беләсез, бик аз. Карчыкларның вакыты күп. Ул Чулпанга төрле тузга язмаган әкиятләр сөйләп, җырлар җырлап, аны тормыштан аерды. Шигырь язарга өйрәтте аны әнкәй,

ә әнисен, әтисен хөрмәт итәргә өйрәтмәде. Тормышта яшәргә дә өйрәтмәде. Нәтиҗәдә, унбиш яшьлек кыз аш пешерә дә белми. Шигырь яза, аш пешерә белми. Ничек уйлыйсыз. Яхшымы ул?

Сез — язучы кеше. Шигырь турында шулай әйткәнем өчен гаҗәпләнүегез, хәтта ачулануыгыз да мөмкин. Ләкин минем үз карашым бар. Кеше иң элек укырга тиеш, белем алырга, профессия сайларга тиеш. Шагыйрь, профессия түгел. Ул — мавыгу гына. Үз-үзеңне алдап яшәү. Романнарны, повестьларны, драма әсәрләрен аңлыйм — алар житди эш. Ә шигырь...

Сез әнкәйгә Чулпанның шигырен мактап язгансыз. Ә сез беләсезме, кызыбызның укуы әйбәт түгел бит. Укытучылар аңардан канәгать түгел. Аның өчен миңа оят. Укытучы кызы булуына карамастан, дәресләргә әзерләнеп килми, диләр, дәрес вакытында игътибарсыз, диләр. Сәбәбе — шигырь. Югыйсә, әйтеп үттем, күп укый үзе, акыллы. Ләкин күп укыганны файдалана белми, уенда рифмалар гына. Мин Чулпанның киләчәге өчен куркам. Сезгә бәлки читтән караганда кызыктыр, тик миңа аның кызыгы юк. Сезнең хаттан соң мин Чулпанның сандугач турындагы шигырен көндәлегеннән укып чыктым. Нигә ул шигырьне мактагансыздыр, аңлашылмый. Унбиш яшьлек кыз белмәсә дә, сез белергә тиеш ләбаса: сандугач сары түгел — соры. Бәлки Сезнең сандугачны күргәнегез юктыр, минем сандугачны күргәнем бар, тавышы матур булса да, үзе ямьсез. Аннан соң нигә сандугачны мактап, каргадан көләргә? Карганың кара булуына ул үзе гаеплеменни? Карганың кара булуыннан кемгә зыян? Сез, язучы кеше, шуларны аңлатып язган булсагыз, әйбәтрәк буласы иде. Мондый шигырьне мактау зарарлы.

Чулпаныбыз сандугачны сары дип, дөньяны аллы-гөлле дип яшәсә, ни булыр? Дөньяны, тормышны ничек бар, шулай күрергә кирәк. Бервакыт Чулпан сандугачның сары түгеллеген, дөньяның ал түгеллеген күрер дә аптырап, югалып калыр, алданганын аңлар. Коточкыч! Шул уңайдан Сезнең хикәягезгә тагын бер тукталып китәм. Сез дә мәхәббәтне әкият югарылыгына күтәреп, аны бизәп күрсәткәнсез. Мәхәббәт — бик гади нәрсә. Ул ашау, эчү, киенү, йоклау, уяну кебек үк гади. Без үзебез Чулпанның әтисе белән күкләрдә йөзмәдек, йолдызларга кушылып биемәдек. Авыл советына барып язылыштык та яши бирәбез. Берәүдән дә ким түгел. Ә менә минем дус кызым бар иде, сөйгән егетен теленнән төшермәде, хыял дөньясында яшәде. Нәтиҗәдә, ике баласы әтисез үсте.

Гафу итегез, бик эчкәре кереп киттем бугай. Ләкин бу хакта мин кемгә дә булса сөйләргә тиеш идем. Әнкәй белән ул турыда сөйләшә башласам, үпкәләшүдән башка нәтиҗә юк. Чөнки ул — гади колхозчы, укымаган, юк өчен башыңны әйләндермә, дип кенә җавап кайтара.

Күп яздым, ахрысы. Ни әйтергә теләгәнемне аңлата алдым микән.

Сау булыгыз. Иҗатыгызда зур уңышлар теләп, Кәримуллина Фәһимә Закировна.

8 октябрь, 1970.

5

— Хөрмәтле Фәһимә ханым!

Хатыгызны алып дикъкать белән укып чыктым. Хат ахырында, ни әйтергә теләгәнемне аңлата алдым микән, дигәнсез. Дөресен язганга кичерә күрегез, мин аңлап бетермәдем бугай. Сүзләрегез аңлаешлы, шигырьгә мөнәсәбәтегез ачык, әмма ни теләгәнегез аңлашылып житмәде. Сөембикә әби, мәсәлән, ачыктан-ачык язган иде. Мин, әлбәттә, Сезнең кызыгызга берни дә язмадым,

чөнки мин аны белмим, үзен белмәгән кешегә, хәтта ул унбиш яшьтә генә булса да, ничек акыл өйрәтәсең? Сезгә ни дип җавап языйм.

Хәер, Сез җавап язуымны сорамагансыз да. Сезгә үзегезнең уй-борчуларыгызны кем беләндер уртаклашырга кирәк булган. Ышанычыгыз өчен рәхмәт әйтеп, Сезгә ике генә юллы хат җибәрергә дә мөмкин иде. Тик алай гына эшли алмадым. Сез борчылган кебек, мина да борчу төште.

Ни өченме? Шигырь яратмавыгыз өчен түгел. Анысы һәркемнең үз зәвыгы. Ләкин шигырьне сөймәгән килеш әдәбият укытуыгыз... Монысына инде үтерсәгез дә төшенә алмыйм. Гафу итегез, кызыгызның дәрестән чыгып китүен дөрес дип санамасам да, күңелнең кайсыдыр төше аның мондый тәртипсезлеген аклый. Сезнең урында мин булсам, янә дә гафу итегез, башка эшкә күчәр идем. Дөнья булгач, шигырьнең катнашы булмаган эшләр дә бардыр. Сез анда бәлки күбрәк файда китерерсез.

Инде Чулпанның шигырь язуына килик. Ана кешегә кызыгызны алай тәрбияләмәгез дип әйтү — әдәпсезлек билгесе. Кызыгызны теләсәгез ничек тәрбияләргә Сезнең тулы хакыгыз бар. Тик озын-озын вәгазь укымыйча, бер нәрсә турында гына үтенәм: зинһар өчен, шигырь язудан тыя күрмәгез Чулпанны. Зинһар өчен! Зинһар өчен! Күңеле тупасланмасын кызның. Бәлки ул шагыйрь дә булмас, укытучылар аның шигырьләрен дәреслекләрдән укып та интекмәсләр, ләкин кайда гына эшләсә дә, Чулпан күңелендә шигырь йөртер. Аңлагыз, күңелендә шигырь йөрткән кеше — бәхетле ул. Кызыгызның киләчәге өчен борчылмагыз.

Зинһар өчен, Чулпан сандугачны соры итеп күрмәсен, дөньяны төссез итеп күрергә өйрәнмәсен.

Инде килеп, кем әйтте Сезгә сандугачны соры дип? Минем, әлбәттә, сандугачны үзен күреп сөйләшкәнем юк. Шулай да аны сары, дим. Мина хәтле ничаклы кешеләр аны сары итеп күргәннәр.

Сары сандугач баласы
Сары була микәнни?
Кошлар да моңлы сайрамый —
Сабыр була микәнни?

Халык шулай дип җырлаган, шулай дип җырлый, шулай дип җырлаячак. Сезгә ышаныйммы, халыккамы? Сандугач соры түгел, Фәһимә Закировна, сары. Сап-сары!

Сез бик яхшы беләсез, каен утыны әйбәт яна, күмере дә самовар чыжлату өчен начар түгел шикелле, ә мунчала чабынырга каен себеркесен ни алыштыра?! Әмма каен утынга кисәр өчен, себеркегә тунар өчен генә үсми ләбаса. Без сылу каенга карап сокланабыз да каен кызы дип җырлар да җырлыйбыз. Дөньяда матурлык бар, Фәһимә ханым!

Мин артык төче телләнеп киттем ахры. Сезгә ул нәрсәләр ятрак тоеладыр. Миннән бәлки көләрсез дә. Көлсәгез көләсез инде, мин барыбер сары диячәкмен. Шагыйрь профессия түгелдер, әмма мин шагыйрьләрдән үлеп көнләшәм. Дүртьюллык шигырь яза алмавыма гарьләнәм, хурланам. Хикәяләремне шигырь итәргә азапланам, барып чыкмый. Ходай бирмәгән. Ходай дип ялгыш ычкындырып ташладым, юк ич ул, әйеме? Йолдызлар да биеми, ай да көлми. Бөтенесе дә гап-гади: ике икең — дүрт.

Үзегез әйтмешли, гафу итегез, эчкәрегә кереп киттем бугай.

Сезгә исәнлек-саулык, Чулпанга ак бәхет теләп, Ризван Маликов.

20 октябрь, 1970 ел.

6

— Хөрмәтле Ризван абый Маликов, исәнмесез!

Сезгә Мөслим районы Балтач урта мәктәбенең сигезенче класс укучысы Кәримуллина Чулпан яза. Хатымны ничек дип башлыйм икән, Ризван абый? Көлкеле хат килеп чыкса, көлмәгез, ярыймы? Мин үзем күп көлмим дә, күп сөйләшмим дә, ни өчендер миннән көләләр.

Язучылар белән хат алышкан булмагач, ничек язарга да белмим. Әллә ничек итеп язасым килә. Язучылар белән хат язышасым килә минем, Ризван абый. Сез, зинһар, көлмәгез.

Шулай килеп чыга кайвакытларда: олы кешеләр акылсыз сүз сөйләсәләр дә, алардан көләргә ярамый, бәләкәйләр акыллы сүз әйтсәләр дә, олы кешеләргә алардан көләргә рөхсәт бар. Нигә ул алай? Бәләкәйләрне кешегә санамаудан микән? Алай гына да түгел әле. Бик карт кешеләрнең сүзләренә дә көлеп карыйлар. Бик картларны да кешегә санамыйлар микән? Шуна күрә без әби белән бик дуслар. Әбиемә әйбәт сүзләр язуыгыз өчен Сезгә бик зур, бик зур рәхмәт.

Сезнең «Чулпан таңны уята» дигән хикәягезне укыгач, Сезгә хат язмакчы идем, куркып тордым. Әбиемә язган хатыгызны әбием миңа укып күрсәткәч, куркуым бетте.

Сезнең хикәягез ошады дисәм, дөрес үк булмас, ошамады дисәм, ни өчен ошамаганын әйтә алмыйм. Минем шулай туры сөйли торган гадәтем бар, ачулана күрмәгез. Ә мин Сез язганнарны яратып укып барам.

Әбием әйтә, Язучы абыеңа зарланып та яздым, ди, үзебезне тыңламый дип әйттем, ди. Ышанмагыз, Ризван абый, болай гына язган ул. Минем әбием зарлана белми. Аннан соң, аның кушканын рәхәтләнеп эшлим мин. Кайвакытта кушмаганны да эшләп ташлыйм. Әбием үзе дә шулай миңа охшаган. Кайвакытта кушмаганны эшләп ташлый. Шигыремне күчереп сезгә җибәргәне өчен ачуландым. Мин аны уйнап кына язган идем. Кайсы вакытларда шулай мин. Әллә нишләп кенә китәм дә язасым килә. Хат языширга кеше юк. Сезнең шулай була микән, менә минем нәрсәдер әйтәсем килә. Кычкырып әйтер идем, әллә ничек. Шуны шигырь итеп язып куям. Рәхәт булып китә. Аннан соң аны әбиемә укыйм. Ул кайвакытта елый. Мин аны елатыр өчен укымыйм да югыйсә. Минем әбием бик күп әкиятләр, җырлар, бәетләр белә. Китапта чыкмаган әкиятләр сөйли. Тик йөрәге чирле шул үзенең. Бабай турында күп сөйли, аңа бәет тә чыгарган. Мин бабайны белмим шул. Сугышта үлгән ул. Аның язган хатлары да күп.

Әй, мин сөйлим дә сөйлим, сезгә кызык та түгелдер. Ачуланмагыз, Ризван абый, минем сөйлисем килә. Бөтен кешеләрнең бүтән кешеләргә сөйлисе сүзләре күптер. Тыңлаучылар булмаганга гына сөйләмиләрдер. Сез шулай микән, мин шулай — кайвакытларда уйлап куям: кешенең сөйлисе сүзләре кешенең кайсы җирендә җыелып тора икән? Башында микән, йөрәгендә микән? Әбием әйтә: күңелдә, ди. Күңел нәрсә ул, Ризван абый?

Ризван абый, әгәр дә миңа хат язсагыз, ничек итеп яза башлавыгыз турында языгыз әле. Ничә яшьтә яза башладыгыз? Әниегез ачуланмый идеме?

Сез мине ачуланмагыз, Ризван абый, мин бик күп сораулар бирергә яратам. Шуның өчен кайвакытларда укытучылар ачуланып ташлыйлар. Бервакыт табигать белеме дәресендә агачларның, үләннәрнең яфраклары нигә яшел дигән сорауга җавап бирдек. Шуннан укытучы апага мин китапта язылганга ышанмыйм дигән идем, икеле куйды.

Чыннан да, Ризван абый. Менә бер җирдә, бер туфракта өч төрле чәчәк үсә. Бер-берсенә орынып үсәләр. Барысының да диярлек яфраклары яшел, ә чәчәкләре төрле төстә. Берсе сары, берсе кызыл, берсе шәмәхә. Ни өчен алай? Аның серен белеп булмыйдыр? Ничек кенә аңлатып язсалар да ышанмыйм. Төсләр — чәчәкләрнең күңеледер ул. Ә күңел нәрсә?

Менә шулай кешеләрнең башын ватам инде мин, Ризван абый.

Тагын да языйм микән, әллә туктыйм микән? Язар идем дә, Сез ачуланырсыз дип куркам. Хат укып утырырга Сезнең вакытыгыз юктыр. Ризван абый, вакытыгыз булса, миңа озын-озын итеп хат языгыз, ярыймы?

Сезгә тормышыгызда, иҗади хезмәтегездә зур уңышлар теләп, түземсезлек белән җавап көтеп, Чулпан.

18 октябрь, 1970.

Сорыйсы соравым калган икән, Ризван абый. Сез хикәягезнең героинясын нигә Чулпан дип атадыгыз?

7

Чулпан сеңлем, саумы, исәнме!

Хатыңны алдым, бик сөендем. Вакытым күп минем, килгән хатларны рәхәтләнеп укыйм, җавапны да рәхәтләнеп язам.

Сораулар биреп кешеләрнең башын ватучыларны бигрәк тә яратам. Сорау бирмәгән кеше — яки бөтен нәрсәне дә белгән кеше, яки бер нәрсәне белергә теләмәгән кеше. Дөньядагы бөтен нәрсәне белгән кеше юк һәм булмаячак та. Белергә теләгәннәр күп. Дөньяны шулар җитәкләп алып бара.

Бүтәннәр җавап бирә алмаслык сорауларны бирүчеләр миңа аеруча ошый. Күңел нәрсә ул, дип ике урында сорагансың. Син, хәйләкәр кызый, минем җавабым юклыкны белеп, юри сорагансың бит. Күңелнең нәрсә икәнлеген аңлатып биргән кешене очратсаң, миңа да хәбәр ит, яме.

Ә яфракларның, чәчәкләрнең төсе турында фәндә аңлатмалар бар шикелле. Китапларга ышанмыйм дию дөрес микән? Сорау бирү бик яхшы, тик һичнигә ышанмау, минемчә, килешеп үк бетә торган эш түгел.

Син дөрес әйтәсең, Чулпан сеңлем, олы кешеләр дә кайвакыт акылсыз сүз әйтеп куя. Ләкин алардан көләргә ярамый. Гомумән, кешедән көлү — начар эш. Кеше дигәндә, мин син әйткән «бәләкәй»ләрне дә күздә тотам. Кешенең ялгышын кешеләргә төзәтергә кирәктер ул, әйеме?

«Кешенең сөйлисе сүзләре кешенең кайсы җирендә җыелып тора икән?» Гаҗәеп авыр сорау. Җавап бирә алмасам, ачуланма, ярыймы? Әйе, кешеләрнең кешеләргә сөйлисе сүзләре күп, аның исәбе-хисабы юк. Нигә тыңлаучылар юк дисең? Сөйли белеп сөйләсәң, тыңлыйлар. Берәүләр кычкырып сөйли, икенчеләр язып сөйли. Әнә бит син бик матур шигырь язгансың, матур итеп сөйләгәнсең. Мин шатланып укыдым. Уку — шул тыңлау буладыр инде.

Чулпан! Сөйлисе сүзләрең күп булгач, язган шигырьләрең дә шактыйдыр. Син аларны күчереп миңа җибәр әле. Мин үзем, син беләсеңдер, шагыйрь түгел, ләкин шигырьне әйбәт язучы дусларым бар. Аларга да укытырмын. Онытма, ярыймы?

Мин ничек итеп яза башладыммы? Белмим шул, Чулпан сеңлем. Һич кенә дә алдамыйча әйтәм — белмим. Мәктәптә укыганда, стена газетасында шигырьләрем чыга иде. Аннан соң район газетасында басыла башладылар. Казан газеталары шигырьләремне басмагач, язуны ташладым. Алты-җиде ел үткәч кенә хикәяләр язарга тотындым. Басыла башладылар. Шуннан китте бугай инде. Ничек итеп яза башлавымны белмәсәм дә, синең хаттан соң ни өчен язганымны бераз ачыкладым шикелле: күрәсең, күңелдә җыелган сүзләремне кешеләргә

сөйлисем килгәндер, сөйлисем киләдер. Аларны шигырь итеп сөйли алмагач, хикәя итеп сөйләргә керешкәнмен. Минем теләк шул сиңа, Чулпан сеңлем: сөйлисе сүзләрең бетмәсен һәм син аларны шигырь теле белән сөйләсәң иде. Зинһар, җибәр шигырьләреңне.

Мин тагын бер нәрсәгә шатланам әле, Чулпан сеңлем. Хикәямдәге (мин аны этюд дип атаган идем) Чулпан синең исемне йөртә. Ни өчен шулай дип атадыммы? Таң белән Чулпан гел бергә йөриләр бит. Үзең дә беләсеңдер.

Таң ата, чулпан калка,
Чулпан таңны уята,

дигән җыр да бар. Миңа ул җыр ошый. Дөньяның уянуы күз алдыма килә.

Хикәямне ошатмавың өчен ачуланмыйм. Сиңа ошамаслык булгач, әйбәт язылмаган, күрәсең. Күңелемдәгеен сөйләп бирә алмаганмын. Киләсе юлы андый ялгышлык эшләмәскә тырышырмын.

Сиңа һавадагы йолдызлар санынча сәлам җибәреп, бәхет теләп, Ризван абыең Маликов.

26 октябрь, 1970.

**8**

Хөрмәтле Ризван абый!

Хатыгыз килеп төште. Мин аны нык көттем. Күңелем шундый шат — әллә нишлисем килә. Җүләр сүзләр булса, язган хатымда, артык шатланганнан икән, дип уйларсыз.

Беренчедән, мин Сезне тәнкыйтьлим. Сез миңа Син дип язгансыз. Син дип кемгә әйтәләр? Үзеннән түбән санаган кешегә әйтәләр. Яки культурасы җитмәгән кешеләр шулай сөйләшә. Яки бик якын кешеләр берсе-берсенә син дип дәшәләр.

Сез — культуралы кеше. Сез мине якыннан белмисез. Шулай булгач, ни кала? Сез мине түбәнсетәсез яки бала-чагага саныйсызмы? Мин бала-чага түгел, Ризван абый. Хат язганда, Чулпан сеңлем дисәгез дә, үзегезгә тиң күреп, Сез дип языгыз. Кимсеткән кешеләрне мин яратмыйм. Бу сүзләрем өчен ачуланмагыз, ярыймы?

Аннан соң, мин чыннан да хәйләкәр. Әти миңа астыртын, ди. Ул хәйләкәр дигән сүзне астыртын дигән сүздән аера белми. Минемчә, астыртын — начар сүз, ә хәйләкәр алай ук начар түгел. Хәйләкәр булу өчен, акыллы булырга кирәк. Дөрес әйтәмме? Хәйләкәр булып мин шушы гомеремдә берәүгә дә яманлык кылганым юк.

Сорауны мин сезгә хәйләләп бирдем. Җавап бирә алмавыгызны белеп яздым. Тик бу яманлык түгел ич.

Әни миңа ике сүзнең берендә унбиш кенә яшь, унбиш кенә яшь дип бәйләнә. Беренчедән, унбиш кенә яшь түгел. Унбиш яшь тә бер ай. Бу аз түгел бит, әйеме, Ризван абый. Ләкин Сез хатыгызны бәләкәйләргә язган төсле итеп язгансыз. Укыгач көләсе килдергән җирләре бар. Киләсе хатларыгызны олыларга язган кебек итеп языгыз.

Шигырьләремне җибәрәм. Тик аларны Сез үзегез генә укыгыз, берәүгә дә күрсәтмәгез. Якын дустыгызга күрсәтсәгез ярый.

Мин шигырьләремне Сезгә генә җибәрәм. Берәүгә дә җибәрмим. Элек газеталарга җибәрә идем дә, хәзер аларга да җибәрмим. Чөнки барыбер басмыйлар. Ни өчен басмаганнарын әйтәләр дә, алар әйткәнне мин аңламыйм шул. Үзегез күргән, үзегез белгән нәрсәләр турында языгыз, диләр. Ничек инде ул алай?

Күптән түгел генә журналда 7нче класс укучысының шигырен басып чыгардылар.

Тезелешеп бара үрдәк бәбкәләре
Алдан бара аларның әнкәләре,

дигән шигырь. Үзен күргән нәрсәләр турында язу шулай була микәнни?! Үрдәк бәбкәләренең тезелешеп йөргәнен бөтен кешеләр дә күрә ич. Бөтен кешеләр дә күргәч, үзен күргән буламыни? Аннан соң үрдәк бәбкәләре генә тезелешеп йөрми, каз бәбкәләре дә тезелешеп йөри.

Мин, Ризван абый, болай итеп уйлыйм. Ни өчен үрдәк һәм каз бәбкәләре тезелешеп йөри, ни өчен тавык һәм күркә чебиләре өерләре белән йөри? Беләсезме ни өчен? Казлар, үрдәкләр — оча торган кошлар. Очканда, алар тезелеп очалар. Тезелеп очарга нәни чактан ук өйрәнәләр. Ә тавыклар, күркәләр очмыйлар, аларга ничек йөрсәләр дә ярый. Менә шул хакта бер шигырь язарга йөрим әле. Язып бетерә алсам, Сезгә дә җибәрермен. Мин үзем оча торган кошларны яратам. Ошамаса, очалар да китәләр.

Ризван абый! Мин бик күп китаплар укыйм. Инде район библиотекасының да китапларын укып бетердем. Тик әни миңа кайсыбер китапларны укытмый, сиңа әле иртә ди. Сез ничек уйлыйсыз бу турыда? Укырга ярамый торган китаплар буламы? Әгәр дә булса, нигә аларны чыгаралар?

Ризван абый, тагын бер нәрсәне сорыйм да хатымны тәмамлыйм. Хатын-кызлардан зур шагыйрьләр чыгамы? Ник алай сораганымны әйтеп бирәм.

Мин укыган китаплар арасында хатын-кызларның да китаплары бар. Юка-юка гына шигырь китаплары. Калын китаплар юк. Без укый торган дәреслекләрдә хатын-кызлардан чыккан бөек язучыларның исемнәре күренми. Нигә алай икән? Хатын-кызның чәче озын, акылы кыска дигән сүз әллә чынлап та дөрес микән? Әгәр дә дөрес дип уйласагыз, исбатлап күрсәтегез. Коры сүзгә генә мин ышанмыйм.

Тагын да язасы сүзләрем калды, Ризван абый. Бөтенесен дә язып бетермим әле. Киләчәктә язылачак хатларга калдырам. Юкса, барысын бер хатка язып бетергәч, кызыгы да калмый.

Сез миңа һавадагы йолдызлар санынча сәлам җибәргәнсез. Бик күп дип уйлагансыздыр инде. Ә мин Сезгә океаннардагы тамчылар санынча сәлам җибәрәм, ак бәхетләр телим, озын гомер телим.

Чулпан Кәримуллина.

Бәйрәм белән котламыйм. Открытка җибәрергә уйлап торам. Сез дә миңа матур открытка җибәрегез, ярыймы.

2 ноябрь, 1970 ел.

**9**

Исәнмесез, хөрмәтле вә гыйззәтле Чулпан туташ Кәримуллина!

Сезгә Син дип язганым өчен океаннардагы тамчылар санынча гафу үтенәм. Мин һич кенә дә Сезне түбәнсетергә яки бала-чага санарга уйлаганым булмады. Димәк, миндә культура җитеп бетми. Кисәтүегез өчен триллион рәхмәт.

Шигырьләрегезне алгач ук укып чыктым. Ничек телисез? Мактыйммы, тәнкыйтьлимме? Тәнкыйтьләр идем дә, куркам. Тәнкыйтьләвегез исбатланмаган дип әйтүегездән өркәм. Мактар идем, мин мактауга мохтаҗ түгел дип әйтерсез төсле. Мин аларны Сезнең рөхсәтегез белән үземнең шагыйрь дустыма укытам. Сезнең кебек хәйләкәр кыз белән шуннан соң сөйләшербез, яме?

Ул чакта инде саклаnыгыз, бәләкәйләргә язган кебек язмам. Чыннан да, Сезнең белән олылар телендә сөйләшергә кирәк булыр. Сезнең яшь өчен яхшымыдыр, начармыдыр — шигырьләрегез һәм фикер йөртүегез зурларча. Ни генә дисәгез дә, Чулпан сеңлем, унбиш яшь кеше өчен әллә ни күп түгел. Әниегез сезгә кайсы китапларны укырга ярамый дип әйтәдер, белмим. Әмма әни әйтә икән, аны тыңларга кирәктер. Чөнки кайбер кинофильмнарны карарга да уналты яшь тулмыйча рөхсәт ителми.

Минем уйлавымча, укырга ярамый торган китаплар юк. Әгәр дә аны чын кешеләр язган икән, нигә укымаска, әйе бит? Ләкин укыган һәр кеше китапны үзенчә аңлап укый. Шулай, язучы бер әйбер уйлап яза, ә кайбер укучы аны икенче төрле укый. Язучының ни турында язганын дөрес аңлар өчен хәзерлек тә кирәк. Өч яшьтәге балага хәзер Сез укый торган китапларны укып булмый ич инде. Үсә-үсә кеше күбрәк аңлый, күбрәк укый, хәзерлеге арта, ул чакта бөтен китапны да рәхәтләнеп укы. Аңлата алдыммы?

Аңлата алмасам, үзегез аңлатып языгыз. Сезнең сорауларга җавап бирергә шүрлим хәзер. Шуңа күрә хатын-кыз шагыйрьләр турындагы соравыгызга да җавап бирмим. Әйе, әгәр ялгышмасам, Гейне, Пушкин, Тукайлар белән рәттән куеп сөйләрлек хатын-кыз шагыйрьләр юк шикелле. Ни өчен икәнен әйтә алмыйм. Аны аңлатучы галимнәр бардыр да, китапларын укырга туры килгәне юк. Чулпан сеңлем, Сез дөньяга сорау биреп, җавабын да үзегез табарга яратасыз. Үзегезнең соравыгызга үзегездән җавап көтәм. Ә инде озын чәч, кыска акыл турындагы мәкальне күптән искергән дип санасам, ачуланмассызмы?

Барысын да бер хатка язып бетергәч, кызыгы калмый, дигәнсез. Шулай булгач, Сезгә галәмдәге молекулалар санынча сәлам җибәреп, нокта куям.

Открытка җибәрсәм дә, бәйрәм белән тагын бер мәртәбә котлыйм. Ризван абыең.

6 ноябрь, 1970.

## 10

Исәнмесез, Ризван абый!

Хәерле көн яки хәерле кич!

Хәерле иртә дип юри әйтмим, чөнки почтаны иртән китермиләр.

Хатыгызны алдым. Открыткагызны да алдым. Бик зур рәхмәт Сезгә.

Сез дә хәйләкәр кеше икән, Ризван абый. Үзегездән бер сүз дә язмыйсыз. Мин язганнарны гына тикшереп язасыз. Алай ярамый. Үзегездән дә чыгарып языгыз. Шигырьләрем турында да әллә ничек кенә язгансыз. Мактауга мохтаж түгел дип әйтәм инде, әйеме? Нигә инде алай дип әйтим ди.

Мин, Ризван абый, мактаганны бик яратам. Юри кыланып мактаганны гына яратмыйм. Әгәр дә тарих укытучысы Ибраһим Салихович мактаса, ачуым чыга. Белеп, күреп, сизеп торам ич мин, әни укытучы булганга гына мактый мине, үзе әнине дә, мине дә яратмый.

Әгәр дә чынлап мактасагыз, курыкмагыз, Ризван абый. Болай гына булса, барыбер сизәчәкмен. Сизә торган сөягем бар минем. Әбием шулай ди.

Тәнкыйтьләгәннән мин өрекмим. Өрекмим дигән сүз кызык сүз, әйеме, Ризван абый? Өрек җимеше дә бар, өрәк тә бар. Өрек — тәмле, өрәк — куркыныч. Беләсезме, мин өрәк барлыгына кайчакларда ышанып куйгалыйм. Үзе комсомолка, үзе юк нәрсәләргә ышана дип көлмәгез тагын. Чынлап ышанмыйм мин ана, кайчакларда бардыр кебек кенә тоелган сыман. Былтыр микән, өченче ел микән бер китаптан өрәк сүзен укыдым да, аңламагач, әбиемнән сорадым. Әбием аңлатып бирде. Үзе әйтә, юк нәрсә ул, ди, әкиятләрдәге җеннәр кебек

кенә, уйлап кына чыгарылган, ди. Ә мин йокламыйча өрәкләр турында уйлап ятканымны хәтерлим. Мин болай уйлыйм: әгәр дә ул юк икән, нигә мине уйлата? Әгәр аны кеше уйлап чыгарган икән, бардыр инде нәрсә дә булса, әйеме, Ризван абый? Күнел дигән сүз дә бар ич, ә күнел үзе юк. Кызык: бар да, юк та.

Тәнкыйтьләгәннән өрекмим дигән идем, әллә кая кереп киттем. Шулай инде мин кайвакытларда: бер яктан башлыйм, икенче яктан килеп чыгам. Безнең класста минем шигырьләрдән көләләр. Минем исем дә китми. Рәхәтләнеп көлегез, мин барыбер язасым килсә, язам. Язасым килмәсә, мактасагыз да язмыйм. Әни дә миңа үзсүзле эгоистка, ди. Китап турында аңлата алмагансыз. Кайчакларда өч яшьлек балалар аңлаганны олы кеше дә аңламый. Алар аңлаган булып кыланалар гына. Миңа әни мәхәббәт турында язылган китапларны укытмаска тырыша. Ә мин, беләсегез килсә, мәхәббәтне әнидән күбрәк аңлыйм. Ә сез, Ризван абый, беләсезме, мәхәббәт нәрсә ул? Китаплардан укып җавап бирмәгез, үзегезчә әйтегез. Унбиш яшьлек кыз гашыйк була аламы?

Менә Сезгә сораулар. Өстәмә тагын бер сорау. Бәхет нәрсә ул? Киләсе хатыгызда мин бу сорауларга тулы җавап көтәм. Белмим дип котылып калырга уйламагыз. Хатын-кыз шагыйрьләр турында да оста гына хәйләләгәнсез. Сез миннән дә артык хәйләкәр булмакчы буласыз. Ә мин хатын-кыз шагыйрьләр ни өчен бөек булмаганын беләм. Әбием әйтеп бирде инде. Беләсезме ул нәрсә диде? Әйтим микән? Юк, әйтмим, йә көләрсез. Сез аны әбиемнең үзеннән сорап языгыз әле, кызык ул минем әбием.

Ризван абый! Әгәр дә миңа язарга сүзләрегез бетсә, әйдәгез, болай эшлибез. Сез миңа үзегезнең әбиегез турында языгыз, мин үземнең әбием турында язам. Менә сүз табыла. Мин Сезгә күп-күп иҗат уңышлары телим, Ризван абый. Сау булыгыз. Чулпан.

16 ноябрь, 1970 ел.

## 11

— Гутен морген! Гутен таг! Мистер Зәйнуллин! Хатның авторын әйтеп торыйммы икән. Әйтим әле, чөнки хәзергесе көндә шырдый-бырдый язучы Ризван Маликов еллар, гасырлар үткәч, классикка әйләнәчәк бит. Аның каләме язган һәр хәрефне тикшерәчәкләр. Менә шул чакта шушы мәктүбне табып алачаклар. Кара аны, югалтма, киләчәк каршында яманатлы булырсың.

Син, кәнишне, уйлап куйдың инде: Ризван мине сагынып хат язган дип. Өметләнмә, сагынмадым. Тәк, болай гына, форма өчен генә. Тик шулай да озакладың. Ничә айлык соң ул синең курсларың? Булган белемең житмәгәнмени?! Аннан соң, нәмәстәгә шагыйрьгә белем? Шагыйрьне күп укытсаң, шигырь язуын ташлый. Шагыйрь профессия түгел (монысы минем афоризм, эмде). Кайт тизрәк.

Ары барыр юлыңның
Алты ай булсын арасы:
Бире килер юлыңның
Бер көн булсын арасы.

Шигырь язган дип уйлама, андый ахмаклыкка барып житкәнем юк. Алтай тауларында яшәүче туганнарыбызның халык авыз иҗаты ул. Һәм өстәвенә, ул дүртьюллык бу хатның дәвамы миңа кирәк булачак.

Тимердән булса — кыска кис, агачтан булса — озын кис, дигәндәй, сүздән эшкә күчәм.

Мәсьәлә шунда тора, иптәш Зәйнуллин: мин сиңа бер кызның бер кочак шигырьләрен җибәрәм. Кем ул кыз дип сорама, күргәнем юк.

Шигырьләр миңа бик ошый. Әмма, үзең беләсең, шигырь өлкәсендә мин кем? Дөрес әйтәсең, шыр надан (хәер, башка өлкәдә дә әллә кем түгел. Монысы — тыйнаклык).

Шигырьләрнең авторын күрмәсәм дә, биографиясенең кайбер моментларын беләм. Чулпанга бүгенге көндә 15 яшь.

Сигезенче классны тәмамлаячак.

Ышанмыйсыңмы? Мин дә ышанып җитмим. Унбиш яшьтә, минемчә, болай ук булмыйлардыр. Ул инде дөньяны фәлсәфи яктан тикшереп, абстрактно уйлау дәрәҗәсенә җиткән. Унбиш яшьтә мөмкинме ул хәл? Син бит яшьләр өчен бик күп шигырь, поэмалар язган кеше, аларны беләсеңдер, аңлыйсыңдыр.

Бәхет!
Килсәң, ээләп кил —
Йөрәгем чирле минем.
Кайгы!
Килсәң, күпләп кил —
Йөрәгем чирле минем.

Кара син, ничек! Шигырь буларак (ягъни рифмасы, фәләне-төгәне) ничектер, ләкин фикер кызыклы бит. Һәм аңлар өчен шактый катлаулы. Янә дә кызыклы факт: мин алдарак Алтай халкының халык авыз иҗатыннан үрнәк китергән идем. Бармы охшашлык аның белән Чулпан шигыре арасында. Бар диген, югыйсә, мин сиңа беркайчан да ышанмаячакмын.

Кыскасы, Харис дус, син Чулпан кызның язганнарын җентекләп укып анализлап, киңәшләр әйтеп миңа хат яз әле. Авторның үзенә язсаң да була. Тик, зинһар өчен, сак кылан, әллә кем булып китеп, күсәк белән кизәнмә. Ул бит синең сыман кырыкка җитеп килә торган, шәфи шикәре сыман шомарып беткән шагыйрь түгел. Иң мөһиме, Харис дус, шигырь язуын ташламасын иде ул. Бәлки киләчәктә безнең әдәбиятны шаккатырырлык нәрсәләр дә язмас (анысына да өметем юк түгел), әмма кызның тумыштан шагыйрь икәнлеге, минемчә, бәхәссез. Сакларга иде аны, канатларын сындырмасыннар иде. Чөнки, укыгач, үзең дә күрерсең, шигырьләрендә уйчанлык белән бергә, ниндидер төшенкелек (пессимизм) бар. Шул чирдән арынсын иде ул. Син мине аңла, дускай, тиле сыман кычкырып көлеп йөреп, иха-ха да миха-ха дигән шигырьләр язсын димим, төшенкелек — яман чир. Кешене күпвакыт шул харап итә. Әгәр дә дөнья елаклар кулына калса, үз күз яшьләренә үзләре батып үләрләр иде кешеләр.

Фәлсәфә тәмам дияр идем, сорыйсы сүзләрем бар икән әле. Чулпан белән без хат алышабыз (алышабыз дип әйтү — зурдан кубу, әлегә икене генә язды).

Күрдеңме инде минем кем икәнлегемне?! Син гомереңбуе шигырь тукып, кызлардан хат алганың бармы? Мин чыпчык борыны чаклы гына бер этюд язып гәҗиттә бастырдым, һәм — кызлардан хат. Шаярма хәзер абзаң белән.

Әмма дә ләкин шунысы яман икән кызлар белән хат язышуның: алар сораулар биреп җанга тияләр икән. Мине дә Чулпан сораулар белән күмә: Нәрсә ул бәхет? Нәрсә ул мәхәббәт? Унбиш яшьтә гашыйк булырга ярыймы? Һәм ни дип җавап языйм ул кызга? Син беләсеңме, нәрсә ул бәхет? Мин белмим. Бәлки мәхәббәтнең ни икәнен беләсеңдер. Мин белмим. Хатыннан

сораган идем, күзләрен тутырып карады, мин сина әйтим, котым ботыма төште (син минем хатынның күзләрен беләсен инде — тәлинкә-тәлинкә). Нигә шулай карады икән ул, Харис дус? Картаеп барган көнеңдә ни пычагыма сиңа мәхәббәт, дип әйтергә теләде микән? Теле белән әйтсә, ни була инде, әйеме? Кайбер ирләр күп сөйләшүче хатыннарыннан зарланалар, сөйләшмәгән хатын белән дә яшәүләре бик үк жинел түгел. Ярый әле кызым үзем сыман тел бистәсе, рәхәтләнеп сөйләшәбез. Иң кызыгы шунда: мистер Зәйнуллин, ул сөйләшмәгән хатынга мине беркем дә өйләндермәде ич. Үзем өйләндем. Дүрт ел буе артыннан чабып йөрдем. Ул чакта да сүзен сөзеп кенә чыгара иде. Янәмәсе, ул чакта тыйнаклыктан сөйләшмәгән, хәзер усаллыктан сөйләшми. Алай булмый бит ул. Менә сиңа дөнья, менә сиңа мәхәббәт. Унбиш яшьлек кызга ни дип жавап бирим инде, йә?

Бәлки берәр акыллы фикер әйтерсен, ә? Хәер, миндә булмаган фикер синдә ничек булсын инде. Ха-ха! Хат яз, дускай. Исәнлек-саулык сиңа. Күнелен көр булсын, уен бер булсын: уку, уку, уку.

Ауф фезер Зейн(уллин)!

P.S. Синен жырлар дәфтәренә ике жыр. Себергә барган идем, шунда Минзифа Әгъләмовадан ишетеп кайттым. Ә син Ризван Маликов бүләк итте дип язып куй.

Рукавица, рукавица,
Рукавица — бияли;
Бүре түгел, ашамамын,
Якынырак кил әли.

Дайте ходу пароходу —
Первый номер киләдер;
Я люблю твою породу —
Сөйкемле күренәдер.

Үзенә янә дә тагын бер сәлам кундырып, шагыйрь йөрәкле прозаик — иптәш Маликов.

23 ноябрь, 1970 ел.

## 12

Шагыйрь йөрәкле прозаик, иптәш Маликов!

Шигырь язудан тәмам туеп, гарык булып, бүтән ярты юл да язмыйм дип тәүбә итеп утырганда, ә башкалар язганны мәңге-мәңге укымам дип торганда, синнән бер колач шигырь килеп төште. Кансыз кеше син, иптәш Маликов. Жибәргән дәфтәрләренне караватт астына тондырдым да урамга чыгып киттем.

Баш әз-мәз генә аязлангач, бүлмәгә кайттым да сузылып яттым. Сине эт итеп сүгәргә тотындым. Кайчан туктар икән бу шигырь белән женләнүеннән дип сүктем. Он да жон да чыкмый бит үзеннән, нигә проза-мрозасын гына язмый, нигә белмәгән эшенә тыкшына дип жикерендем.

Шулай да караватт астына керергә туры килде. Гафу ит, Ризванушка Маликушка, үзең язганнар түгел икән.

Син боларны унбиш яшьлек кыз язган дисенме? Шигем бар! «Сәнең мөселманлыгыңда мәнем шигем бар». Син, эттән туган чучка баласы, үз шигырьләренне унбиш яшьлек кыз псевдонимы белән сырлый башладыңмы әллә? Алай дисәм, мондый шигырь язу синең кулдан килер микән.

Синен шаяртмавына ышанып, житди сүз әйтәм: әлеге дәфтәрдә нидер бар, Ризван. Борынын бу юлы дөрес сизгән. Тик тикшер әле син, чынлап

та унбиш яшьтә микән автор. Әгәр шулай булса — шактый ук зур табыш. Кулдан ычкындырмаска кирәк ул эре җәнлекне. Югыйсә, шигърият капкынына вак-төякләр күп эләгә башлаган иде (шул исәптән бәлки үземдәдер).

Әлбәттә, ул шигырьләрне шигырь итәргә кирәк әле. Ләкин унбиш яшь бит, малай, унбиш яшь. Минемчә, нормальный хәл түгел бу. Яки зур талант, яки фальсификация, яки...

Авторны син тапкансың, дәфтәрен яңадан үзенә юллыйм. Мин бик җыйнаксыз кеше. Йә югалтып куярмын. Шигырьләргә кул тыкмадым, әлегә ничек язылганнар, шулай торсыннар.

Бер киңәш: ул кызның үзе янына бер өлкән абзыйны (яше буенча түгел, сәләте буенча) җибәрергә, яки кызны Казанга чакырып, кара-каршы утырып сөйләшергә иде. Ничек дип атала әле ул? Индивидуальный семинар дип йөртәләр бугай.

Кыскасы, үзең кара инде. Элек мәдрәсәгә баланы илткәндә, аны хәлфә кулына тапшырганда, ничек дигәннәр? Ите сиңа, сөяге безгә дигәннәрме? Мәшәкате синә ул кызның, шигыре безгә (әгәр дә синең һәм минем өметне аклый алса).

Хат тәмам. Сезне сагынып өлгердем, чучка танаулар, кайтып муллагызны (председатель була инде, безнеңчә) үбеп киләсе килә. Үбеп урынына кыйнап сүзен ишетәсең килгәндер инде синең?

Шиш!

С салямом без салям.

Хариус Зайнуллин

26 ноябрь, 1970.

P.S. Сорауларга җаваплар.

1 сорау: Бәхет нәрсә ул? Җавап: Шагыйрь Харис Зәйнуллин белән дус булу.

2 сорау: Мәхәббәт нәрсә ул? Җавап: Шагыйрь Харис Зәйнуллинны төненә өч мәртәбә төштә күрү.

3 сорау: Унбиш яшьтә гашыйк булырга ярыймы? Җавап: Ярый. Әгәр дә гашыйк булган кешең шагыйрь Харис Зәйнуллин булса.

P.S. җырларың өчен спасибо. Миңзифа Әгъләмовага миннән рукавица зурлыгы сәлам!

Кызлар белән чуала башладың әле, Ризванушка. Берсеннән — җыр, икенчесеннән — шигырь. Саклан!

## 13

Ризван иптәш Маликов!

Хәтерлисездер, мин сезгә хат язган идем — Чулпанның әнисе Фәһимә Кәримуллина. Сез дә миңа җавап яздыгыз. Сез инде язучылар матур итеп сырлап-сырлап яза беләсез. Сезнең белән сүз көрәштереп буламы соң, шуңа күрә җавап бирмәдем, кирәк дип тә санамадым.

Бу хатны язуымның сәбәбе бер генә. Чулпан белән Сезнең даими хат алышуыгыз миңа ошамый башлады. Минем сизенүемчә, Сезне Чулпанның шигырьләреннән бигрәк үзе кызыксындыра. Алай дип уйларга хакым бар, чөнки мин Чулпанга килгән хатларыгызны укып барам. Сез аларда рифма турында сөйлисе урынга фәлсәфә сатасыз. Сезнең фәлсәфәне унбиш яшьлек кыз түгел, мин дә аңлап җиткерә алмыйм. Нигә баланың башын әйләндерергә.

Минем Сезгә киңәшем һәм үтенечем шул: Чулпанга хат язуыгызны

туктатыгыз. Ул болай да буталчык бала. Бүтәннәргә охшамаган. Сез аның бәхет нәрсә ул дигән соравына мәгънәсез җавап биргәнсез, ә мәхәббәт турында ана шундый сүзләр язарга Сезнең хакыгыз юк иде. Имештер, Сез бәхет белән мәхәббәтнең ни икәнен аңламыйсыз. Алдашасыздырмы, юкмыдыр, белмим, ләкин безнең кызыбыз аларны аңларга тиеш. Аның өчен бәхет — яхшы уку, мәхәббәт — без. Артыгын белергә әлегә кирәкми.

Иң аянычы — Сезнең белән языша башлаганнан соң, Чулпанның безгә мөнәсәбәте тагын да үзгәрде. Минем сүзләрдән көлә яки тыңлап та тормый. Классташларын санга сукмый, дус кызлары белән бөтенләй диярлек аралашмый. Шигырь белән тәмам җенләнде. Дәфтәрләренең һәрберендә шигырь. Мәгънәсез шигырьләр.

Ярый, сандугачны сары дип әйтмим ди мин, мин — ахмак. Сез сары, диегез, Сез — акыллы. Ләкин, кыланмыйча гына әйтегез, шигырь нигә кирәк. Нишләп була аның белән бу дөньяда? Без тарихтан укып беләбез — акыллы кешеләр шигырь чыгарып вакыт уздырмаганнар. Әгәр дә бөтен кеше рифма эзләп утырса, кем эшләр иде.

Шигырь язуның аракы эчү, тәмәке тартудан ни аермасы бар.

Тагын Сезнең ачуыгызны китерә торган сүзләр яздым. Әгәр киләчәктә дә шундый сүзләр ишетергә теләмәсәгез, Чулпанны һәм, гомумән, безнең семьяны тынычлыкта калдырыгыз. Үтенеп сорыйм Сездән.

Шунысын да белегез, иптәш Маликов: Чулпан Сезгә бүтән хат язмаячак.

Ф.Кәримуллина.

## 14

Хөрмәтле Фәһимә ханым!

Мин Сезнең үзегезгә хат язган идем, җавап бирүне кирәк санамагансыз. Кызыгыз Чулпанга атап язылган хатка җавап бирүне кирәк санагансыз. Миңа бераз аңлашылып җитми мондый нәрсә. Ничек инде ул берәүгә атап язган хатка икенче берәү җавап яза? Шуңа күрә Сезгә язылган сүзләр Сезгә генә мәгълүм булсын өчен, адреска (лично в руки) дип яздым. Әлбәттә, Сез — ана кеше, кызыгызның ниләр эшләве, кемнәр белән аралашу, кемнәр белән хат алышуы турында хәбәрдар булырга тиешсездер. Ләкин, беренчедән, Чулпаныгызга ышанмыйча, Сез аны тәрбияләү урынына, үзегездән читләштерәсез дип уйлыйм, икенчедән, гафу итегез, мин бала-чага түгел: кемгә нинди сүзләр язарга кирәклеген әз-мәз чамалыйм. Һәрхәлдә, унбиш яшьлек кызга ни язганымны аңлап язарга тырышам. Әгәр дә Чулпанга ниләр турында язганымны белергә теләсәгез, үзеннән сорагыз. Әйтми икән, димәк, кызыгыз Сездән курка, Сезгә ышанмый. Әгәр дә инде ни әйтмәгән килеш тә кызыксынсагыз, миннән сорагыз, әйтеп язармын. Минем Чулпан мәсьәләсендә Сездән яшерен серем юк. Мин ана мәхәббәт тә аңлатмыйм, Сезгә каршы котыртырга да җыенмыйм. Минем бердәнбер теләгем: кызыгызны шигырьдән биздермәү. Дөньяга шагыйрьләр кирәк. Бусы — бер. Икенчесе — Чулпан язган хатларны мин җавапсыз калдыра алмыйм. Әгәр дә язып та мин дәшмәсәм, яки, Чулпан сеңлем, син миңа хат язма инде, сиңа җавап язасым килми дисәм, ул минем турыда, кешеләр турында ни уйлар? Дөресен әйтәм, минем вакытым бик үк иркен түгел, Чулпанга һәм Сезгә эч пошканлыктан язмыйм. Кызыгызның хатларына җавап бирүне мин бурычым дип саныйм. Кайчан да кайчан ул хат язудан туктар, мин дә... Хәер, кем белә, ул чакта да бәлки, Чулпан, нигә югалдың, дип язырга туры килер. Сезнең кебек үк мин дә Чулпанның югалуын теләмим.

Сезнең бер җөмләгез мине уйга калдырды: «Шигырь нигә кирәк», — дигәнсез.

Формасы белән сорау җөмлә булса да, сорау билгесе куймагансыз — димәк, фикерегезне раслап, һаман саен шигырьгә каршы чыгасыз. Ә мин ул җөмлә артыннан сорау билгесе куям. Чыннан да, шигырь нигә кирәк? Яшермичә әйтәм, Сез аңласагыз да, мин ул сорауга төгәл җавап бирә алмыйм.

Мин бәләкәй чакта, сугыш вакытында безнең авылда Мулланур исемле егет бар иде. Җәйге кыска төн булсын, кышкы салкын төн булсын, безнең тәрәзә каршыннан җырлап үтә торган иде. Ни өчен җырлап йөргәндер, көе нинди булгандыр, белмим, хәтерләмим, әмма әниемнең: «Әле дә Мулланур бар авылда, җырлап күңелне юата», — дигән сүзләре һаман да истә. Күп нәрсәләр онытылган, Мулланур абыйның:

Өй артына суган чәчтем,
Уңды микән суганым?
Бер җырламый булмый инде,
Бар да минем туганым, —

дигән җыры онытылмаган. Тавышым булмаса да, дуслар җыелган мәҗлесләрдә мин аны җырлыйм.

Нигә кирәк? Белмим. Бәлки Сез беләсездер.

Янә дә шунысы бар: Фәһимә ханым, адәм баласы үз гомерендә әллә никадәр кирәкмәгән нәрсәләр эшли. Уйлап −уйлап торасың да аптырашта каласың. Нигә кирәк? Кеше үлгәч, аны сабынлап юалар, ап-ак кәфенгә төреп яисә костюм, ак-күлмәк кигезеп, галстук тагып кадерләп күмәләр. Нигә кирәк? Үлгән кешегә җир астында ничек ятса да, барыбер түгелмени? Җитмәсә, кабере өстенә чардуган корып, таш куялар, чәчәкләр, агачлар утырталар. Нигә кирәк? Үлгән кеше аларны күрәмени?

Кешенең «җүләрлеген», кирәкмәгән эш эшләп вакытын уздырган мисалларның саны юк. Һәм шуларның барысының да нигезендә шигырь ята.

Аннан соң, һич кенә дә аңламыйм мин Сезне, Фәһимә ханым. Сүз шигырь яратмавыгыз турында бармый. Минем әни мәрхүмә дә шигырь укып кына ятмый иде. Хәтта ул шигырьнең ни икәнлеген дә белми иде, бугай. Әмма бервакытны минем шигырь (хәзер беләм: аның шигырь дип әйтерлеге дә булмаган) район газетасында басылгач, әни утырып елады. Бер атна буе газетаны алъяпкыч түшенә кыстырып йөрде, эшләгән җирендә, инеш буенда, урамда шул газетаны тартып чыгарып кешеләргә күрсәтә иде. Минем улым язган, дип мактана иде.

Газета-журнал редакцияләренә балалардан бик күп кулъязмалар килә. Аларның кайберләрен балаларның әниләре, әтиләре җибәрә. Шатлыклары эчләренә сыймаганга җибәрәләр: балалары шигырь язган бит! Укып карасаң, шигырьләре әллә ни дә түгел:

Сара салма сала,
Гата мылтык ата.

Ләкин ни генә булмасын, ул — шигырь! Ә сез? Аңламыйм, Фәһимә ханым, үтерегез, аңламыйм! Минем дә нәни кызым бар. Әгәр дә ул үсеп, Чулпанныкы кебек шигырьләр язсамы?

Уйлагыз әле, Фәһимә ханым, ныклап уйлагыз.

Тарихны укыганда да дикъкать беләнрәк укыгыз. Институтта әйткәннәрдер, мин Сезгә ике генә кешенең фамилиясен атыйм. Ломоносов һәм Маркс. Ярый,

Хәйям, Гейне, Пушкин, Тукайны тиләләр дип атыйк ди, әмма Карл Марксны акылсыз кеше дип әйтүе печтик кенә унайсыз. Арттырып ук җибәрмәгез инде, зинһар. Шигырьне аракы эчү, тәмәке тарту белән янәшә куюыгызга, әлбәттә, ышанмадым, юри, мине үртәр өчен язгансыз дип уйладым. Мин чынлап та үртәлдем. Юри генә дә андый сүзләрне әйтергә ярамый.

Менә шул, Фәһимә ханым. Сездән үтенеп сорыйм: зинһар, Чулпанга язылган хатларны Чулпан үзе генә укысын.

Исәнлек-саулык, сабырлык теләп,
Ризван Маликов.

15

Иптәш Маликов!

Акыл өйрәтүегез өчен рәхмәт. Тик үз баламны үземә тәрбияләргә рөхсәт итүегезне үтенәм. Сез кайда укыгансыздыр, кызыксынмыйм. Мин — педагогия институтын тәмамлаган кеше. Сез үз кызыгызны тәрбияләгез. Нәрсәнең кирәк, ни-нәрсәнең кирәк түгеллеген дә сездән ким белмим. Чулпанның ике абыйсын да мин тәрбияләдем. Берсе химия-технология институтын тәмамлады, икенчесе КАИда укый.

Сезгә сүзем шул: Чулпанга хат язудан туктагыз. Соңыннан үпкәләрлек булмасын. Әгәр дә шигырь турында акыл сатарга телисез икән, әнә, минем каенанам белән языштыгыз. Эше юк, вакыты күп, акыл сатарга да ярата. Сездән ким түгел. Артык булмаса.

Мин бит Сезнең эшегезгә кысылмыйм, нигә безнең эшкә тыгыласыз. Үзебез ничек телибез, шулай яшибез. Менә шул.

Шигырь... Шагыйрь... Беләм мин сезнең кебекләрне. Матур сүз сөйләп, кеше башын әйләндерүчеләр. Үзегемә үткән нәрсәләр турында әйтергә мәҗбүр итәсез. Мин дә ярата идем берәүнең шигырь сөйләгәнен. Авыз ачып тыңлый идем. Авызымны ачып калдым, ул икенче берәүгә сөйли башлады. Икебез дә әтисез балалар үстердек. Калганнары нишләгәндер — белмим. Ә ул һаман шигырь сөйләп йөри, диләр. Женем сөйми! Ишетәсем килми!

Кем белә сезнең уегызны. Башта сеңлем-фәлән дип хат язарсыз да, аннан соң... Мин кызымның акыллы булуын телим. Хәзер хыялыйлар заманы түгел. Чәчәкләр базарда сатыла торган заман.

Мине сез, әлбәттә, тупас, ахмак, надан диярсез. Теләсә ничек дип атагыз, мин курыкмыйм. Мин бары тик кызым өчен генә куркам. Ир бала булса, көненә иллешәр хат языщсагыз да исем китмәс иде.

Сез Чулпанны белмисез. Мин беләм. Бәлки тагын акыл өйрәтерсез, балаларның көндәлеген укырга ярамый, диярсез. Зинһар өчен, гафу итегез, зинһар өчен, кичерегез, мин кызымның көндәлеген укып барам. Кирәк булса, аның көндәлегеннән бер хат күчереп җибәрәм. Укыгач күрерсез, менә нинди ул минем кызым. Әллә кайчан үлгән Тукайга мәхәббәт хаты язганны Сезгә язмас дип ничек ышаныйм. Ярый ла Тукай өчен җавапны Чулпан үзе язган, Сез бит япь-яшь кызның мәхәббәт аңлатуын ишеткәч эреп төшәчәксез, җай чыкканын көтеп йөриячәксез.

Тагын бер кабатлыйм, Чулпанга килгән хатларны ана унсигез яшь тулганчы мин укып барачакмын. Унсигез яшь тулгач, үзе карар. Иң яхшысы, хат язудан туктагыз. Әгәр мин язганнар гына җитмәсә, тормыш иптәшем — Чулпанның әтисе язган хатны да җибәрәм.

Ачуланышмыйк, иптәш Маликов. Югыйсә Язучылар союзына Сезнең кем икәнлегегезне әйтеп язачакмын.

Фәһимә Кәримуллина.

***

— Агай-эне. Син анда безнең кызга хат язып ятасың икән. Ташла ул эшеңне яхшы чакта. Мин күп сөйләп тормыйм. Бер әйтәм, берәгәйле әйтәм. Кызларга хат язасың килсә, Казаныңдагы кызларга яз. Бетмәгән анда кыл койрыклар. Алдалап ятмагыз безнең кызларны. Мин күп сөйләп тормыйм. Казанга барып, муеныңны борып кайтырга да күп сорамыйм. Бер хатының гына җитмимени? Яшьрәкләр кирәкмени? Булдымы? Булса шул. Ташла ул эшеңне. Мин күп сөйләп тормыйм. Мине кем дип сорасаң, Фәйзрахман исемле булырмын. Синең эше шәләй-вәләйләргә бармагым белән генә чиртәм. Мин күп сөйләп тормыйм. Бер әйтәм, берәгәйле әйтәм. Бетте.

***

Чулпанның Тукайга хаты:

— Исәнмесез, Тукай абый! Бу хатны сезгә таныш булмаган кыз Чулпан яза. Өйдә үзем генә. Каршымда сезнең фоторәсемегез көлемсерәп миңа карап тора. Миннән көләсездер инде. Җүләр кыз дип әйтәсездер. Мин чыннан да җүләр, Тукай абый. Әти дә миңа җүләр, ди, әни дә миңа җүләр, ди. (Күрдегезме инде, иптәш Маликов, шигырьнең кая илткәнен? Без, имеш, аңа җүләр, дибез?)

— Тукай абый, Сезгә бер сорау бирергә буламы? Сезгә гашыйк булырга ярыймы, Тукай абый? Мин Сезне бик яратам. Сез миннән башка берәүне дә яратмагыз, ярыймы? Минеке генә булыгыз. Мин Сезне иркәләрмен, чәчләрегездән сыйпармын.

(Күрдегезме? Сезгә бәлки көлкедер, миңа көлке түгел кызымның мондый саташуы).

— Сез көлмәгез, Тукай абый. Иркәли беләм мин. Телевизордан күргәнем бар. Гашыйк булган кешеләр берсен-берсе иркәлиләр. Тукай абый, мин дә сезнең кебек шигырь язам. Минеке әле начаррак чыга, гаеп итмәгез. Менә берсен Сезгә дә җибәрәм.

Очып менгәч әтәч койма башына,
Кычкырып җибәргән бар тавышына:
«Бөркет түгел мин, ләкин шулай да
Канатларым бар, рәхмәт Ходайга».

(Күрдегезме? Яңа гына 7 класс тәмамлаган укучы бала Ходай дигән сүз өйрәнгән. Кемнән? Мәктәптә без өйрәнмибез.)

— Сау булыгыз, Тукай абый. Миңа хат языгыз. Сезгә озын гомер теләп калучы Чулпан Кәримуллина.

7 июль, 1970 ел.

***

Тукайның Чулпанга Чулпан кулы белән язган хаты:

— Исәнмесез, минем өчен дә бик тә, бик тә кадерле булган Чулпан. Хатыгызны алгач, сөенечемнән нишләргә белмәдем. Мин дә Сезне бик-бик яратам. Сезне бик күрәсем килә.

(Күрдегезме? Тукай ук булмасагыз да, Чулпан Сездән дә шундый сүзләр язылган хат көтәчәк.)

— Авылыгызга килергә җыенам. Тик әлегә бераз гына чирләп торам. Салкын тидергән идем. Терелгәч тә киләм. Сез мин килгәнне көтегез, ярыймы? Көтмәсәгез үпкәлим.

Шигыregез мина бик тә, бик тә ошады. Дөрес әйткән әтәч. Койма башына очып менәргә дә канат кирәк шул. Әбиегезгә күп итеп сәлам әйтегез, Чулпан. (Күрдегезме? Әти, әни дигән сүз юк. Менә ул Сез мактаган «шигырь җанлы карчыкның тәрбиясе.)

— Ярый, сау булыгыз, Чулпан. Мине көтегез. Габдулла Тукай. Сезгә дә мин бер шигырь җибәрәм.

***

Хат башы — яз каршы.

— Сәлам, Зәйнүш! Мин бу — Ризван. Син анда мина хат язмыйсың икән. Ташла ул эшенне яхшы чакта. Мин күп сорап тормыйм. Бер әйтәм, берәгәйле әйтәм. Хат язмасаң, Мәскәвенә барып, муеныңны борып кайтырга да күп сорамам.

Тагын бер сәлам әйтәм дә житди сүзләргә күчәм. Менә сина дүрт хат. Чулпанның әнисе, әтисе һәм Чулпанның — Тукайга, Тукайның Чулпанга хатлары. Фикерең ничек. Мина нишләргә? Аптыраган хәл. Һични аңламыйм.

Татар әдәбияты укытучысының шигырь яратмавын калдырып та торыйк ди. Дөнья булгач, төрлесе була. Җирне яратмаган агрономны, дуңгыздан җирәнгән зоотехникны, китап укырга авырсынган язучыны да очратканым бар. Өстәвенә, Сезнең халыкның (шагыйрь халкының) берсе ул укытучыга күңел ярасы салган. Укытучы шул әдәми затка үч саклап, шигырьгә дә нәфрәт уятсын ди. Психологик яктан бәлки моны да аңлап буладыр. (Сүз уңаеннан, кем булуы мөмкин ул шагыйрьнең? Мин эзләп-эзләп карадым — андыйны тапмадым. Киресенчә, безнең шагыйрьләр кирәгеннән артык тыйнаклар, басынкылар, тәртиплеләр. Белсәң аны, мина да әйт әле — күрәсем килә ул азгынны.)

Чулпанның әтисе язган хатка да әллә ни коелып төшмәдем. Аңлыйм бугай мин аны. Хатыны бик нык әгитләгәч, кызып киткән. Кызыбызны бер дуңгыз харап итәргә җыена, дип хатының еласа, кем дә уйланыр. Бу инде, күрәсең, күп уйларга яратмый торган кеше — турыдан сыптыра. Димәк, анысына гаҗәпләнмим.

Мине гаҗәпләндергәне — ничек шушы гаиләдә шундый кыз үсә? Каян килгән ана шигырь? Тукай белән «язышуы» мине тетрәндерде. Моны, минемчә, хәтта әйтеп тә бирә алмыйм, кемнең башына шундый нәрсә килергә мөмкин? Әллә ул бераз ычкынган микән? Әллә унбиш яшьтә бөтен кешеләр дә шулай була микән? Мин үзем унбиш яшьтәге уй-хисләремне хәтерләмим.

Иң куркынычы шунда, Зәйнүш: ата белән ана балаларын харап итүләре мөмкин бит, сизәсеңме? Кызганычка каршы, Чулпанның Тукайга язган хатын тулысынча укып булмый. Әдәбият укытучысы, әлбәттә, аны күчергәндә редакцияләгән, үзенә файдалы урыннарын гына күчергән. Бәлки анда Чулпанның безгә аңлашылырлык серләре бардыр.

Нишләргә? Кинәш бир. Хат язудан туктасам, ничек булыр? Туктамасам, ничек булыр? Аңлыйсыңмы, Чулпанны югалтудан куркам мин. Әллә нинди җинаять эшләрмен кебек.

Карале, бәлки син хат язып карарсың. Тик чамалап, син — максималист кеше. Син язган хаттан соң «бер әйттем Фәйзрахман» чынлап торып кыйнап китмәсен. Безне кыйнаса да түзәрбез, безнең аркада кызын тотып кыйнавы бар. Андый кешедән теләсә нинди ахмаклык көтеп була.

Шундый-шундый эшләр, бара-тора нишләр дигән, ә?!.

Чулпанның шигырьләрен редакцияләргә алып барып карыйм микән, ничек уйлыйсын?

Хат яз. Синең кинәшеңне көтәм.

Кулыңны кысып, Ризван хәзрәтләре.

***

— Дон Жуан әфәндегә Мәскәүски сәлам!

Укып чыктым җибәргән нәрсәләрне. Ха-ха-ха! дип көләр идем, хәсрәт-кайгым булмаса, дип әйткән ди берәү. Тормыш бу, агай-эне. Тормыш — колагыңны бормыш. Син генә ул кешеләрне, тормышны идеаллаштырасың, шуңа күрә хикәяләреңнең күбесеннән прәннек тәме килә.

Син дөрес сукалыйсың, миңа хат язырга ярамый ул хатынга. Язсам, бары тик райкомга гына яза алам. Ике сәгать тә тормый куарга кирәк ул хатынны мәктәптән. Эзе булмасын.

Иренә дә хат язмыйм. Кеше сүзен аңлый торган иргә охшамаган ул адәм. Күрәсең, хатыны аның барлы-юклы акылыннан да мәхрүм иткән.

Чулпан өчен борчылма. Син уйлаганча, акылдан ычкынмаган ул. Аның яшендә Тукайга хат язуы табигый. Безнең мәктәптә бер кыз бар иде. Ньютонга гашыйк иде. Без көлә идек. Һәм кем булды дип уйлыйсың хәзер ул кызны? Физика-математика фәннәре кандидаты.

Нишләргә дисеңме? Дөрес әйтәсең, кызны югалтырга ярамый. Элемтәне өзмәскә кирәк. Ничек? Анысын уйлашыйк. Бәлки кызның өенә язмаскадыр? Район җирендә «До востребования» бар микән? (Авылдан аерылганмын — шуны да белмим.) Таптым! Эврика! Бездә бит хатын-кыз шагыйрьләр бар. Берәрсе белән сөйләш, алар язсыннар. Бәлки ул чакта тегеләр йомшарлар (кызларын «аздыручы» булмый бит).

Шигырьләрне редакцияләргә ташырга ашыкма. Беренчедән, синең Чулпаның ничаклы гына гениаль булмасын, язганнары матбугатта чыгарырлык түгел дип саныйм. Чыраеңны сытма, әлегә түгел дип төзәтәм. Ул эзләнә. Интуитив эзләнә. Үсә-үсә менә дигәннәрен язар, Алла боерса.

Икенчедән, Чулпан яшендәгеләр бик тиз масаючан булалар — бер-ике шигыре газета битендә күренү белән, үзләрен бөек саныйлар, һәм, нәтиҗәдә, шул «бөеклектән» ары китә алмыйлар. Бәлки Чулпан андый түгелдер — шактый төпле күренә. Шулай да саклангнаны саклармын дип әйткән ди берәү. Янә дә шул: Чулпан шигырьне «гәҗиттә бастыру» өчен язмый, үзе өчен яза. Бастыру өчен язса, үзе дә җибәргән булыр иде. Шулай дигәннән, сораш әле, редакцияләрдә юк микән шигырьләре. Булса, редакцияләрдәге иптәш-товарищлар авторга ни дип җавап бирделәр икән?

Ярый, Дон-Ризван, адью. Күктә йолдызлар биетүеңне дәвам ит. Дус-ишкә сәлам күндыр.

Зәйнүш. Мәскәү.

# УЛ БИТ БЕЗНЕҢ КҮҢЕЛ ТУФАНЫ

Шәүкәт **ГАЛИЕВ**

## Югалмас сүз

*Хәсән Туфанга һәм аның*
*әдәби энесе Туфан Миңнуллинга*

Мәңгелеккә хөкем чыгаргандай
Ялтырады алтын күзлекләр —
«Туфан — искергән сүз», диеп хәтта
Әйттерделәр алар сүзлектән.
Күпме авазларны йотты микән
Сикәлтәле чорның юллары?
Нидер сизгән сыман, бер авылда
Туфан атлы малай елады...
Бер сәбәпсез ярсый бит нарасый,
Хәерлегә булсын, диделәр.
Белмәделәр, алаш абыйсының
Эчкә йоткан яше иде лә...
Үсә төшкәч, малай көннәр буе
Кыр-болынны күпме гизмәде.
Борчылудан гаҗизләнгән ана:
«Туфан, кайт!» — дип, көн дә эзләде...
«Туфан, кайт!» — дип кабатлады урман —
Зур Туфанны эзли кайтаваз!
Көткән җырлар сыман каңгылдашып,
Ничәнче кат илгә кайта яз...
Бала Туфан үсте Тау ягында,
Тиешлесен инде белде ул —
«Туфан — искергән», дип үртәгәндә
Сер бирмәде, бары көлде ул.
Бер сәбәпсез көлә бит бу бала,
Хәерлегә булсын, диделәр.
«Хәсән Туфан кайткан», дигән сүзләр
Гәзитләрне узып килделәр.
Бер сүзе дә югалмасын, диеп,
Туган телгә кайтты җан атып —
Сүз-намусны, җыр-вөҗданны мәңге
Искермәслек итеп яңартып.

Очрашыла икән исән булгач,
Озын юллар да ул тар икән.
Иңнән кагып әйтте олы Туфан:
— Әдәбиятта энем бар икән!
Яшь Туфанның елгыр, шаян чагы,
Ул үзенчә булмас дисеңме:
— Рәхмәт, — диде адаш абыйсына,
— Акладыгыз минем исемне!
Ә чал шагыйрь, узган бар юлларын,
Бар моңнарын җыйган шикелле,
Җитди иде. Олы миссиясен
Шул мизгелдә тойган шикелле...
...Сүз-намусны, җыр-вөҗданны инде
Энеләргә хәзер саклыйсы.
Ул аклады халык ышанычын,
Безгә әле, безгә аклыйсы...

**Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ**

## Бәһасез зат

Әйтәләр бит: кояшта да
Гыйбрәтле таплар була —
Халыкта да мәңге калыр
Бәһасез затлар була.

Андыйлар бездә дә бар ул —
Тарихта кала торган:
Әлдермештән — Әлмәндәр карт,
Мәрәтхуҗадан — Туфан.

Кайсы кайсын тудырган соң?
Бу — кечкенә мәсьәлә!
Алар яши,
Ә калганын
Белү безгә нәрсәгә!

Кайсы кайсына охшаган? —
Бәхәс кузгату — юкка:
Берсе Миннуллинга тарткан,
Берсе — Биктимеровка.

Менләп татар баласыннан
Актарып табып алып,
Зирәклек, тапкырлык дигән
Мәгънәви орлык салып,
Аларны безнең күнелгә
Алган да чөйгән халык.

Гыйбрәтләр ала торган шул,
Таңнарга кала торган:
Әлдермештән — Әлмәндәр карт,
Мәрәтхуҗадан — Туфан.

Гәрәй РӘХИМ

## Туфан–Әлмәндәр

*Туфан Миңнуллинның 70 яшьлегенә*

Жирне, күкне, чиксез дәрьяларны
Пыр туздырып йөри туфаннар.
Ә татарда безнең күңелләрне
Пыр туздырып дәртләндерә торган,
Моңландыра торган Туфан бар.

Һәр күңелгә жилкән килеп керә —
Ул бит безнең күңел Туфаны.
Һәр татарның рухи карендәше,
Һәр татарның рухи туганы.

Мәрәтхужа дигән жилле жирдән
Купкан Туфан, татар Туфаны...
Дөнья буйлап исә чистарта ул
Күңелләргә кунган тузанны.

Әлмәндәрне күреп, күпме меңнәр
Моңланганнар, елап-көлгәннәр.
Бүген инде безнең Туфан үзе
Житмеш яшьлек бөек Әлмәндәр!
Житмеш яшьлек Туфан-Әлмәндәр!

Роберт МИҢНУЛЛИН

## Туфанга килешә ул!

*Драматург һәм депутат*
*Туфан Миңнуллинның 70 яшенә*

Бу нәрсә бу? Туфан таша,
Татарны Туфан баса:
Театр гына ярар иде,
Парламент туфанлаша.

Парламент дигән театр...
Ул анда йөзә генә.
Өзә генә — түрәләрнең
Ну үтә үзәгенә.

Сессияләрдә дә Туфан
Еш кына кызыштыра,
Әзер сценарийларны
Еш кына бозыштыра.

Министрлар уянсынга,
Түрәләр оялсынга,
Таяк тыга парламентның
Кырмыска оясына.

Туфан кирәк дөньяларны
Болгатып торыр өчен,
Маңкортларның кайчагында
Колагын борыр өчен.

Нишлисең бит, ул шундыйрак,
Ул шундыйрак гадәтле.
Парламентта арыслан ул,
Парламентта — гайрәтле.

Әйе шул, усал гына ул,
Югыйсә тешле генә...
Тик театрда утыра
Ул песи төсле генә.

Ул анда актёр түгел шул,
Автор гына ул анда.
Яшәр Камал театры,
Андый автор булганда.

Театр түренә Туфан
Үрләде Камал аша.
Камал туфанлашкан саен,
Туфан да камаллаша.

Туфан ага! Бу татарны
Гел бәхетле ит әле!
Тик Туфан гына булсаң да,
Син Миңнуллин бит әле!

**Асия ЮНЫСОВА**

## Кычкырасы килә яңгыратып

*(Мәрсия)*

Кычкырасы килә яңгыратып,
Кычкырасы килә шәр ярып:
Туфан абый, алай уйнамыйлар,
Әҗәл белән йөрмә шаярып!

Әйткән идең, анысы, әйткән идең:
«Туфан абыең да гел булмас!
Сайрыйм гына дигән сандугачка,
Куныйм гына дисә, гөл булмас!»

Ник кайтмадым икән чакырганда?
Ник карадым җаем югына?
Юбилейга түгел, бүтән вакыт —
Күз көнендә, балаң җыйганда.

Ак чәчәккә күмеп киттең җирне,
Ул чәчәкләр хәзер җимештә.

Мөлдерәмә сагыш баланнарда,
Сагыш ачысы бар миләштә.

Балан-миләш белән бер халәттә,
Мөлдерәмә керәм күземә.
«Бәгырькәем», — диеп кемнәр әйтер,
Кем эретер жылы сүзенә?

Кычкырасы килә янгыратып,
Сискәнерлек итеп тал-тирәк:
«Жирдә язлар кабатлансын өчен,
Туфан абый, Жирдә син кирәк!»

**Флёра ТАРХАНОВА**

## Туфан

Ике Туфан күңелемдә яши:
Берсе анын — шагыйрь якташым.
Икенчесе исә — гомере буе
Милләт өчен янган ут ташы.

Яшь чакларын анын хәтерләмим —
Шактый кече идем мин аннан.
Шунысын беләм: тирән акылы белән
Туфанлыгы йөрде гел алдан.

Ә бит анын шушы сыйфатлары
Соң минутынача сакланды.
Акыл-дәрте гел бербөтен булып,
Бар гамәле илдә яклады.

Заманында Гаяз Исхакыйлар
Кайгырткан күк үзенең милләтен,
Гел көрәштә булды: саклыйк, диеп,
Халкыбызның телен, кыйммәтен.

Күпме бала укый үз телендә
Ул салдырткан күпме мәктәптә.
Йөрмәсә ул,
Татар мәктәпләре инде күптән
Беткән булыр иде, әлбәттә.

Чакматашнын утлы очкыннарын
Йөрәгендә жыеп йөрткәнгә,
Наданнарның кара йөзен борды
Киләчәккә, шанлы үткәнгә.

«Үткәненә борылып карамаса,
Киләчәге юк бит халыкнын», —
Дия-дия, милли дулкыннарда
Алып батыр булып калыкты.

Һәрбер сүзе аның үткен чакма —
Кадалды ул һәрчак ук булып,
Кайберәүнең хәтта түн йөрәген
Ялмап алды ялкын-ут булып.

Бармы бездә хәзер мондый шәхес —
Кем күтәрә милли әдәпне,
Кем кайгырта милли горурлыкны,
Чын хакыйкый милли сәнгатьне?

Туфан булып үтте бар гомере,
Туфан булды һәрбер чорында.
Өермәләр тузгып калды хәтта
Мәңгелеккә киткән юлында.

**Ләбиб ЛЕРОН**

## Туфанлык

*Туфан Миңнуллин ядкаре*

Бу дөньяда ныклы терәк кирәк:
Кирәк дуслар, кирәк туганлык...
Халкын хакын яклап, янып, көеп
Яшәү өчен кирәк туфанлык!

Яшибез дә кебек терәк белән —
Дуслар, туганнар да бар сыман...
Сәхнә белән мәйдан гына түгел,
Дөньясы да безгә тар сыман.

Зур сәхнәдә уйнап яшибез күк,
Мөнбәрләрдән сөйләп туйган юк...
Түрәләрне әмма уятырлык
Гайрәт җитми, җитми туфанлык!

Милләтемне тагын йокы басты —
Кабат алыштырып куйган күк:
Яшәү өчен иң кадерле булган
Ирек-азатлыктан туйган күк!

Дус-ишләрне читкә тибәргән чак,
Ераклаша бара туганлык...
Хәлләр — җитди...
Безгә Туфан җитми!
Җитми безгә гаярь туфанлык!

...Мин Туфанны сагынамын бүген,
Килә Ана «Кайт!» дип дәшәсе...
Кайтмасын да беләм, ә бит безгә
Яшисе бар әле, яшисе...

Рифә РАХМАН

## Туфан абыйга эндәшү

Бордын йөзне фанилыктан бакыйлыкка,
Тынычланып калдыңмы син аннан ары?
Ризыкларың арта алмый акчага да,
Гомереннен узып китсә кәрваннары...

Яшәр көннен исәпләре артмый һичбер,
Язмышына язылганнан да арыга.
Анысына ризалашып күз йомганда,
Мизгел житәр милләт өчен кайгырырга!

Татарым һич яши алмас бу шартларда,
Кайгыртучы кирәк аның алдагысын.
Инде хәзер беләсендер, әйт жавабын:
Безнең алда яшәр көннәр калганмы соң?

Бордын йөзне вакытлыдан мәңгелеккә,
Бормадың син милләтеңнән аны һичбер.
Аллаһыга әгәр араң якын булса,
Яшәтә күр миннән сон да, дип ирештер.
Өметләрнең тамырлары корымаган,
Язмыш аны төбеннән үк кубармасын.
Югалттык без күп нәрсәне, бәрабәргә
Милләт, Ватан киләчәккә имин барсын.

Кайвакытта аһлар кылам, башны тотып:
Югалттык без олыларны, шанлыларны...
Кулыбызда юк чарасы туктатырлык:
Һәркемнең дә бара тора кәрваннары...

Вакыйгалар челтәренә карыйм да мин,
Тарихларның көзгеләрен кулга тотып:
Юллар, илләр кәрваннары... узган киткән...
Шул кәрванда — милләтләр, дим, утлар йотып.

Ленар ШӘЕХ

## Туфаннар

*Хәсән Туфан һәм*
*Туфан Миңнуллин рухына*

Туфан килә, туфан калка, дибез,
Туфан баса, дибез, дөньяны.
Татар гавәменең Туфаннарын
Жаным-тәнем белән тоямын!

Туфан — шагыйрь, Туфан — сәхнә күрке,
Икесе дә олпат алыплар.
Мәгърур бөекләре белән
тагын
Лаф орамы башка халыклар?

Ике Туфан, татар Туфаннары —
Күзе кызсын чит-ят милләтнең!..
«Күңелләрдә кояш булып яна
Икесе тиң!» — диеп ил әйтте.

Ватан дәште зәңгәр күккә карап,
Туфаннарга дога укыды,
Бер Аллаһка сәждә, рәхмәт кылды...
Ап-ак болытларны җил куды.

Баш очында — болыт агышлары,
Татар юлы — кояш гомере.
Тау башында шаулый имәннәре,
Учагында көйри күмере.

Туфан килә, туфан калка, дибез,
Туфан күмә, дибез, җиһанны.
Йөрәгемдә ак кульяулык белән
Төреп йөртәм ике Туфанны.

Туфан — шагыйрь, Туфан — сәхнә күрке,
Килерләрме тагын Туфаннар?
Янә калкыр алар. Язмыш исә:
«Татар барда, дияр, Туфан бар!..» —
Кабат-кабат таңнар атарлар. —
«Туфан барда, дияр, татар бар!..»

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ**

## Классиклар китә

*Т.Миңнуллин вафатыннан соң*

Бүген Әҗәл үзе елый сыман:
«Төшме бу, — дип, — өнме, әйтче, Алла?»
Классиклар китә дәвер белән,
Әсәрләре нәүмизләнеп кала...

Дәвер, чорлар китә, буын китә...
Мәңге истә кала торган буын.
Әллә нинди булды шунда бу ел,
Ирексездән күккә кулым суздым.

Ирексездән сәхнә тузаннарын
Милләт яше бүген басылдырган,
Менә кабат «Татар зираты»ның
Түр башына басып дога кылам.

Дога кылам: «Милләтемне, Ходам,
Ятим итмә берүк, сакла!» — диеп.
...Кангылдашып кыр казлары очты,
Каурыйлары белән күкне сөеп.

# ӘЛМӘНДӘРНЕҢ МУТ КАРАШЫ

*Һич көтмәгәндә Туфан Миңнуллин «Робагыйлар» китабы бастырып чыгарган иде. Пьесалар арасында уйнап кына язылган шигырьләр, дип «акланса» да, гомерен шигърияткә багышлаган шактый шагыйрьләрне шомландырды бугай аның әлеге уч китабы. Мин үзем дә сокланып-тәэсирләнеп укып чыккач, бераз шаяртып, болай дип язып куйганмын: «Туфан робагыйларын укыгач, Гомәр Хәйямне кызганып куйдым...»*

*Робагый — шигъриятнең йөзек кашы, нибары дүрт юлга тыгызланып сыйган, фәкать Шәрыккә генә хас хикмәти акыл һәм хиснең тантана итүе...*

*Туфан робагыйлары — гашыйк була белү халәтенә, хатын-кызның, пәри зат буларак, әллә нинди батырлыклар, уйламаган җүләрлекләр кылырга котырта, очындыра белү сәләтенә мәдхия җырлау. Олыгайган йөрәкнең мәңгелек хисләрне, чәчәк-гөлләргә төрмичә, үз кәефен кытыклап та, дөньядан көлеп тә, ачыктан-ачык, эчкерсез фаш итүе ул. Шигъриятнең төш-үзәге яшәешнең кадер-тәме нәкъ менә шул илаһи хис кабынышыннан ярала да. Ә калганы ... Библиядә әйтелгәнчә: суета сует...*

*Шигырьләрдәге исерткеч сүз-рәшә тирбәлеше аша хәйран дәртле Әлмәндәр карт, үткен-җәте күзләрен кысып, дөнья кызыкларын ээрлекләп, мут елмаеп карап тора.*

*Гомәр Хәйям робагыйлары бөек шагыйрьләр теле саналган фарсы телендә дөньяга таралган. «Идегәй» кебек үлмәс дастаннар тудырган татар теленең дә шагыйранә бөеклеген күрсәтергә дип, Туфан мәйданга алышка чыккан һәм... билен дә, телен дә, илен дә бирмәслек сүз егәренә ия икәнлеген горуранә раслый алган.*

*Бәлки әле... Дәверләр үтәр дә... Бу шигырьләрне вакыт агымыннан өскә калкытып, Туфан уйнап кына пьесалар язган арада туган бөек робагыйлар, дип бәя чыгарырлар...*

*Күңел күген аязлата торган табигый фикер югарылыгына ирешкән бу шигырьләрне елмаеп, рәхәт чигеп укыйсың да, «шәп бит, чукынчык!» дип, иңеңнән еллар йөген кагып төшереп, хыялдагы яшьлек күкрәгенә башны куясың.*

*Күңелгә — Алтайдан алып Альп кыяларына кадәрге киңлекләрдә айлы дага эзе калдырган шанлы төрки бабаларыбыздан күчкән рух-дәрман, олыгаюны оялтырлык ихтыяр көче, теге дөньяга күчкәч тә хатын-кыз өммәтенә битараф кала алмаган Әлмәндәр мутлыгы иңә: йөрәк тулпарлана, зиһен елгырлана, фикер куәсе йомрылана, күз карашы елдырымлана; көйле сүз аһәңеннән күңел илһамлана... Һәм мин татарның матур олыгая белгән милләт аксакалы Әлмәндәр-Туфан тавышын ишетәм:*

*Әйдә әле, сүзне шуннан башлыйк, мадам:*
*Яратылган бит син минем кабыргадан.*
*Шул кабырга бүген минем җитеп бетми,*
*Үз урыныңа, бәгырькәем, кер яңадан.*

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Туфан Миңнуллин

### Робагыйлар

* * *

Бу дөньяда кимлегеңне белдертәләр.
Елаталар, кирәк икән, көлдертәләр.
Әнә, кара: атка камыт кидергәндә,
Анын башын ничек итеп идертәләр.

* * *

Картлык ни ул? Тик торганнан колак тону,
Җәйнең кызу чилләсендә аяк туну,
Боларына түзеп була, иң яманы —
Һәр чибәргә результатсыз гашыйк булу.

* * *

Пәйгамбәрдән кайсы җирем минем ким?
Хәдискә тиң акыллы сүз әйтим, дим.
Сүзне әйткәч, мәгълүм була соңыннан —
Аны күптән әйткән икән Гайнетдин.

* * *

Кичерегез, яшьтәш кызлар, сеңелләрем,
Нурияләр, Сәрияләр, Сөмбелләрем...
Гомер кыска — никадәрле ашкынсам да,
Барыгызны да яратып өлгермәдем.

* * *

«Кирәк сезгә безнең кебек яшәргә!!!
Күк күкрәтеп, яшен булып яшьнәргә!!!»
Картаюның галәмәте инде бу —
Юк акылны сатып йөрим яшьләргә.

* * *

Сүз уйнатам: алам бер сүз — «икеле»
Шуңа өстим тагын бер сүз — «микеле».
Килеп чыга «икеле дә микеле»,
Безнең заманның нәкъ үзе шикелле.

* * *

Мәңгелек бер сорау — ни ул бәхет?
Берәүләргә иң зур бәхет — тәхет.
Ә бит өч сүз җинел рифмалаша —
Бәхет белән тәхет һәм дә ләхет.

* * *

Бу тормышның татыйм дисәң өресен,
Өйрәтимме ничек яшәү дәресен?
Яшисегез килми икән бу илдә,
Әйтегез дә салыгыз чын дөресен.

* * *

Ирексезнең күзләрендә күпме моң-зар,
«Ирек» дигән сүздән татлы нинди сүз бар?
«Мин ирекле жан», диеп бер әйтеп кара, —
Эзәрлекләүче ирекне күпме күз бар.

* * *

Жырдагыча — кызлар күрсәм кызамын,
Кызамын да уң кулымны сузамын.
Сузамын да тартып алам тиз генә —
Кузгатудан куркам картлык тузанын.

* * *

«Картайдым», дип әйтер көннәр житте инде,
Еллар йөге ныграк баса бара инне.
Урман, болын, басуларны урап түгел,
Ишегалдында тибенеп табам жимне.

* * *

Орден белән медаль тагып түшемә,
Бәя бирделәр эшләгән эшемә.
Кәефләнеп талган идем йокыга,
Шайтан белән Иблис керде төшемә.

* * *

Әй, гүзәлләр! Уйлап-санап карагыз да
Алыгызчы мин гашыйкны арагызга.
«Син карт шул», дип чыркылдарга ашыкмагыз,
Житмеш яшь бит яңа тулды бабагызга.

* * *

Сыерчыклар кунып сайрый кыекка...
Төкердем дә күнелләрем боекка —
Язын кызлар дәртләнгәнен чамалап,
Парижски хушбуй сөрттем мыекка.

***

Тарихта бар Чыңгыз ханның битеге,
Музейда бар Пётр патша итеге.
Дөнья бит ул көтүченең таягы —
Ул таякта һәркемнең үз киртеге.



*Минтимер Шәймиевнең икенче тапкыр Татарстан Республикасы Президенты булып сайлануы уңаеннан Ант биргән көне. Уңда — Россия Федерациясе Премьер-министры Виктор Черномырдин. М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры. 3 апрель, 1996 ел.*



*Татарстан бәйрәмендә, ачык сәхнәдә Батулла гармун уйный, улы Нурбәк бии, журналист Ирек Нигъмәти аларның чыгышын магнитофонга яздырып бара. 1991 ел.*



*Парламентыбыз түбәсенә ТР халык депутатларының Татарстан әләмен беркетү мизгелләре. 1991 ел.*



*СССР язучыларының VIII съездында катнашкан Татарстан язучылары делегациясе. Мәскәү Кремле залы. 1986 ел.*

# ТАТАРНЫҢ ӘХЛАКЫЙ КОДЕКСЫ

**1. Татар кешесе! Хәтереңә ал! Синең үз мөстәкыйль дәүләтең булган. Дәүләтле милләтнең генә җир йөзендә кадере була. Һәр татарның күңелендә йөргән дәүләтчелек идеясе саклансын. Шушы тарихи гаделлек өчен үзең һәм нәселең көрәшергә тиеш.**

**2. Татар кешесе! Кайда яшәвеңә карамастан, халыклар арасында үз урыныңны онытма, үз кадереңне бел. Тарихи традицияләрне, ата-бабадан калган гореф-гадәтләрне хөрмәтлә, дин-иманыңны сакла.**

**3. Татар кешесе! Бел! Син сөйләшкән тел дистәләгән гасырлар буенча чарланып, иң камил телләр дәрәҗәсенә күтәрелгән. Синең телеңдә катлаулы фәнни хезмәтләр дә, илаһи төшенчәләр дә, гүзәл әдәби әсәрләр дә язылган. Аны хөрмәт ит, сакла һәм үстер!**

**4. Татар кешесе! Горурлан! Син җир йөзендәге барлык халыклар белән дә тыныч һәм тату яши беләсең. Синең өчен барлык халыклар да тигез. Әмма бүтәннәрне хөрмәт иткәндә, үзеңнең дә гадел хөрмәткә лаек икәнлегеңне онытма.**

**5. Татар кешесе! Уяу бул! Кайбер милләтләрне үз куллары белән юк итү сәясәте әле һаман да бетмәгән. Тарихтагы ялгышлар кабатлана күрмәсен. Хөсетлек, көнчелек, вак мәнфәгатьләрдән өстен торыйк. Бер-беребезгә игътибарлы һәм ярдәмчел булыйк. Бергә булыйк, бердәм булыйк.**

**6. Татар кешесе! Укы! Гыйлемле-белемле бул! Дәүләт төзү, аның белән идарә итү өчен дә, рухи һәм матди байлык туплау өчен дә аң-белем кирәк. Кушканны гына эшләүче түгел, үзең дә иҗади дәрәҗәдә эшләрлек зур белемгә ия бул.**

**7. Татар кешесе! Сак бул! Безнең тирәбездә эчүчелек, наркоманлык, рухи пычраклык кебек куркыныч афәтләр йөри. Бу афәтләргә каршы торыр өчен, сиңа айнык акыл, сәламәт рух кирәк. Үзеңдә яшьтән үк ихтыяр көче тәрбиялә.**

**8. Татар кешесе! Тирә-ягыңа кара! Без ата-бабаларыбыздан калган матур һәм бай җирдә яшибез. Үзең яшәгән җирнең кадерен бел, аны киләчәк буыннарга пычранмаган килеш тапшыр.**

**9. Татар кешесе! Киләчәккә кара! Киләсе буынның язмышы өчен дә җаваплы икәнеңне исеңнән чыгарма. Нәселеңнең рухы, физик һәм милли сәламәт булуы синең кулыңда. Халыкның киләчәге ишле, тәрбияле гаиләдә. Гаилә корганда җавапсыз һәм талымсыз булма.**

**10. Татар кешесе! Онытма! Кешелек дөньясы, кызганычка каршы, камил түгел. Халыкларны сортларга бүлеп, аларны үзара каршы кую дәвам итә. Татарлыгыбызны сынарга теләүчеләр табыла икән, көрәш мәйданына чыгарга әзер бул!**

**11. Татар кешесе! Син — төркиләр токымыннан. Туганнарыңның күплеген онытма. Туганнарыңа сыен һәм туганнарыңны сыендыр.**

**12. Татар кешесе! Зур гаделлеккә ирешер өчен, алдынгы һәм прогрессив җәмгыятьләр белән элемтәдә бул. Аларның уңай тәҗрибәләрен үзләштер һәм башкаларга да ирештер.**

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

# ЯКТАШЫБЫЗНЫ ЯД ИТӘБЕЗ



Авылны, районны, төбәкне шушында үскән, шушында яшәгән күренекле шәхесләр данлый. Алар шул җирдән аерылгысыз.

Толстой — Ясная Поляна.

Чехов — Мелихово.

Тукай — Арча.

Кама Тамагы дигәндә, ин әүвәл Туфан Миннуллин күз алдына килә. Бу төбәк халкы аның белән чын-чынлап горурлана. Әдип үзе дә туган ягын гомере буена яратып-сагынып яшәде. Аның күңел дөньясы — уй-гамәлләре, әрнү-шатлыклары, өмет-ышанычлары, сагыш-кичерешләре туган як белән һәрвакыт бәйле булды. Кама Тамагына, Олы Мәрәтхуҗага һәр кайтуының төбендә шушы якны ихлас ярату, олы шәфкать, тирән мәгънә, кайнар хәтер ята иде.

Туфан Миннуллинның районыбыз белән бәйләнышлары күпкырлы, масштаблы булды. Беренчедән, ул монда ял итеп, күңеленә рухи көч, илһам алып китә иде. Икенчедән, язарына азыкны да ул нигездә шушында тапты. Бу хакта үзе дә гел әйтеп торды. Туфан аганың шундый сүзләре бар: «Үз моңын оныткан бүтәннәр моңын ишетми». Кечкенәдән авылдашларының серле әкиятләрен, моңлы җырларын күңеленә сеңдереп, гореф-гадәтләрен күреп үскән язучы иҗатын да халкының күңел җәүһәрләре чишмәсе белән сугарды, илһамына егәр алды. Авылның олы җанлы, киң күңелле, рәхим-шәфкатьле, борын салындырмый, сүзгә кесәгә керми, тоткан җирдән сындыра белә торган, эшчән, сабыр агайлары әдипнең әсәрләрендәге Әлмәндәр, Минһаҗлар кебек гаҗәеп образларга әверелеп, халкыбызның яраткан, үлемсез геройлары булып тарихта калдылар. Өченчедән, ул авылын, туган ягын ярату белән генә чикләнмәде, хәл кадәри булышырга тырышты. Аның ярдәме белән Олы Мәрәтхуҗа авылына кадәр электр линиясе янартылды. Бу авыл районда беренчеләрдән булып газ челтәренә тоташтырылды. Тагын әле Кама Тамагында китапханә-музей комплексын төзү өчен акча табарга булышты ул. Олы Салтыкта яна мәктәп салуның да башында Татарстан Республикасы халык депутаты (ул вакытта шулай дип атала иде) Туфан Миннуллин торды. Мәктәп 9 айда төзелеп бетте. Ибен — ипкә, җеген җеккә китереп салынган бу бина шәһәр укучыларын һәм укытучыларын да көнләштерерлек. Без Т.Миннуллинның игелеген бер район мисалында гына күрсәттек. СССР халык депутаты булганда да, ТР парламентында эшләгәндә дә, бөтен республикабыз мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәгән бу шәхеснең изге эш-гамәлләре бихисап.

Кече ватанына мөнәсәбәте изгелек, ихласлык, игелеклелек белән бәйле, авылдашлары алдында гали дә, гади дә була белгән Туфан аганы якташлары да яратты. Бервакыт җәй көне Олы Мәрәтхуҗа авылы кешеләре аның юбилеена бүләк ясарга — драматургның бер пьесасын сәхнәдә куярга уйлыйлар. Сәхнәне

урамда коралар. Август аенда көн салкынча, болытлы була. Ярый әле яңгыр яумый. Спектакль куела. Тамашадан соң авылдашлары Туфан Миңнуллинны сәхнәгә чыгарып, урындыкка утырталар, бүләкләр бирәләр. Кыйммәтле булмаса да, бик кирәкле бүләкләр: жылы оекбашлар, ялтырап торган галошлар. Ул көннәрдә еш кына яңгыр явып тора. Авылда галошсыз буламыни?! Туфан ага бүләкләрне рәхмәт әйтеп ала.

Бүген безнең максат — Туфан Миңнуллинның мирасын саклау, яшь буынны ул калдырган үлемсез әдәби рухта, әдәби мохиттә тәрбияләү.

Кама Тамагының үзәк урамыннан узганда, челтәрле тәрәзә йөзлекләре куелган бик матур агач бүрәнәле йорт игътибарны җәлеп итә. Бу — Туфан Миңнуллин музее, ул авыл йорты стилендә төзелгән. Аңардан агач исе аңкый, тәрәзәләргә ак челтәрле пәрдәләр эленгән. Ишегалдында — кое, сарайда — чын арба һәм чана. Йорт тирәли — җиләк-җимеш бакчасы. Ул әле үсеп кенә килә, тиздән зур бакча булыр. Агачлар ышыгында әдипнең иҗатын сөючеләр һәм әдәбият белгечләре җыелыр. Бакчада, агач яфраклары шавына кушылып, аның әсәрләреннән өзекләр яңгырар.

Туфан Миңнуллин турында якты хатирә-истәлекләр, ул язып калдырган һәр җөмләсе гыйбарәгә тиң әсәрләр тиздән ачылачак, бистәдә яшәүчеләрнең яраткан ял урынына әйләнәчәк өр-яңа паркта да яңгырар.

Язучының Санкт-Петербург сынчылары койган һәйкәлен ачу кичектерелде. Аның өчен сайланган урын — музей ишегалды кулай булып чыкмады: һәйкәл урамнан күренми. Ул һәрьяктан күренеп торырга тиеш. Туфан Миңнуллин үзе ачык китап кебек иде, беркайчан карашларын һәм фикерләрен яшермәде. Шуңа күрә һәйкәлне дә яңа паркка, кешеләр йөри торган җиргә күчерергә карар кылынды.

Безнең якта әдәбиятка-сәнгатькә, җыр-моңга мөкиббән кешеләр яши. Сагыналар алар Туфан аганы. Мин моны һәрдаим искәреп, сизеп, күреп торам. Әдип җиен дә, кышын да, язын да, көзен дә шау-гөр килеп, дәррәү кайтып төшә торган булган. Бүген аның булмавы үзен гел сиздерә. «Нихәлләрегез бар, егетләр? Эш барамы?» — дип мыек астыннан сөйкемле елмаеп күрешүче, районның уңышларына сабыйларча куана белүче, ил агайлары, аксакаллар белән ихлас сөйләшеп утыручы, балаларның башларыннан сыйпап иркәләүче, сүзен кистереп, турысын әйтә белүче, якташларының күңелен үстереп, аларны рухландырып торучы Туфан Миңнуллинның арабызда юклыгына әлегәчә ышанасы килми. Бу күренекле шәхеснең бай, колачлы иҗаты, аның турында онытылмас истәлекләр, якты хатирәләр — барысы да якташлары күңеленә җуелмаслык булып уелган шул!

Әйе, якташлары олуг шәхеснең бәрәкәтле тәэсирен яд итеп, аның белән горурланып, ул калдырган әдәби мирасның илаһи көче белән канатланып яшәр!

**Павел ЛОХАНОВ,**
*Кама Тамагы муниципаль районы*
*башкарма комитеты җитәкчесе*

# «ҮЗЕН ТЕАТР ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ СИЗДЕ...»

2002 ел. Татар театры өчен җинел булмаган вакыт. Марсель Хәкимович Сәлимжанов бу дөньядан китте. Каушау, югалып калу... Гомумән, татар театрының язмышы турында актёрлар һәм төрле буын тамашачылары да, республикада гына түгел, аннан читтә дә Татарстан мәдәниятенә кагылышы булган һәр кеше тирән борчылган чак. Бу процесс сызланулы, тынычсыз барды. Һәм, әлбәттә инде, Туфан Миннуллинның тавышы, фикере арада хәлиткечләрдән санала иде. Иң сөенечлесе — минем кандидатура белән бәйле хафалануларын ул яшереп тормады. Дөресен әйткәндә, ул каршы иде! Сәбәпләреме? Бу вазифага килгәч, мин аның иҗаты белән озак вакытлы хезмәттәшлектән ваз кичәрмен, пьесаларын куймый башлармын дип уйларга мөмкин иде. Тик ана кадәр минем тарафтан аның «Хушыгыз», «Җанкисәккәем», «Шәҗәрә» дигән пьесалары сәхнәләштерелгән иде бит инде. Ул еш кына минем, «асфальт баласы» булып, шәһәрчә фикерләвемә һәм чын татарлыктан ерак торуыма басым ясады... Ә бит Марсель Хәкимович та, башка күп режиссёрлар да шәһәр шартларында туып-үскән — аларны санап чыгудан мәгънә юк, бу хакыйкать минем шәхесемә каршы тору өчен нигез була алмый иде...

Вакытлар узды. Туфан абый белән аралашуымның кайбер мизгелләрен торган саен ешрак искә төшерәм. Аларның мин югарыда сөйләп үткәннәр белән бернинди бәйләнеше юк һәм, мөгаен, шул сәбәпле аның миңа булган каршылыклы мөнәсәбәтләренә җавап та бирә торгандыр.

Хельсинки, 2002 елның августы. Театр коллективының бик житди бер өлеше Финляндия татарлары янына Сәлимжанов истәлегенә багышланган программа белән килде. Спектакльләрдән өзекләр, истәлекләр... Болардан тыш, бу минем өчен үз-үземне күрсәтү очрагы да — мин дә арабыздан мәңгелеккә киткән остазым турында истәлекләрем, фикерләрем белән уртаклашырга тиеш бит. Тик мәсьәләнең катлаулы ягы шунда: беренчедән, мин татарча сөйләргә тиеш — Финляндия татарлары русча аңламый, һәм, гомумән, төп татар театрының баш режиссёры нинди телдә сөйләргә тиешлеге турында сүз куертасы бармыни? Яшереп тормыйм — «асфальт баласы» буларак, әлегәчә ана теле белән проблемаларым бар шул. Икенчедән, безнең төркемдә — Туфан ага. Кич якынлашкан саен, дулкынлануым көчәя барды, мин, чыгыш ясамас өчен, төрле акланулар уйлап баш ваттым. Без, бөтен төркемебез белән, шәһәр буйлап мәхәлләгә таба барабыз, ә мин үземнен куркакларча чигенүемне аңлатырга теләп, әйләнеп карый-карый, арадан берәрсен эзлим. Карашым белән Туфан Абдулловичка тукталам һәм аңлап алам: сәхнәгә чыкмый гарьлеккә калуымнан соң, Туфан абыйның көлүенә дучар булганчы, хәзер нәкъ менә аның янына барырга кирәк! Үземнең бик борчылуым турында каушый-каушый аңлатырга да өлгермәдем, ул мине култыклап алды да (нәрсә-нәрсә, мин аннан монысын ук көтмәгән идем), тынычландырырга кереште. Соңыннан, сәхнәгә чыккач та, аның минем өчен ихлас борчылуын сизеп тордым. Ә хәзер — күп еллар үткәч — ул минем өчен генә түгел, ә бөтен театр өчен борчылгандыр дип уйлыйм.

Театр өчен ул үзен бик җаваплы сизә иде. Марсель Хәкимович киткәннән соң — бигрәк тә. Ул берничә тапкыр миңа — инде баш режиссёр итеп билгеләнгәч — барлык драматургларны җыярга, репертуарны тикшерергә тәкъдим итте. Соңыннан әдәби бүлек мөдире буларак хезмәт күрсәтергә дә теләк белдерде, ягъни озак вакытлар буена контроль ясарга тырышты димим, бәлки, аның карашы, театрда үзе булмаса да, һәрвакыт сизелеп торды.

Бер яктан, бу бик рәхәт түгел иде, икенчедән, моның аңа бик кирәк булуын һәм үзен җаваплы сизүен мин аңлый идем. Тик шунысы бар: ул озак вакытлар миңа пьесалары белән турыдан-туры мөрәҗәгать итмәде. Алай гына да түгел. Мәсәлән, 7 ноябрьдә Марсель Хәкимовичның туган көненә куелып, бу традициянең башлангычы булган «Кара чикмән» спектакленнән соң, «Шулай булды шул» пьесасын аннан чын мәгънәсендә сорап алдым. Мин аны Түбән Кама театрына, Рөстәм Галиевка

биргәнен ишеттем дә беркадәр үпкә белән мөрәҗәгать иттем. Ничек инде, Туфан Абдуллович, Сез пьесаларыгызны, беренче чиратта, бирегә китерә идегез һәм укулар була иде, дим. Ул чакта, хәзер аңлыйм, аның тарафыннан нииндидер үпкә булган. «Саташу» пьесасын укырга китергәч, труппа аны кабул итмәгән иде, шул исәптән, мин дә пьесаны бик үк камил түгел дип таптым һәм репертуарга керә алмастыр дигән шигемне белдергән идем. Бу тәнкыйть аны үпкәләткән һәм ул икенче пьесасын Түбән Кама театрына биргән булып чыкты. Менә шул. Ул пьесаны укып карарга бирде. Мина ул кабат укыгач кызыклы гына тоелды. Аның пьесаларын актёрлар һәрвакыт яратты. Пьесаларын ул үзе бик шәп итеп укый, һәм укыган чакта ук якынча кем нинди урында булачагы аңлашыла иде. Туфан Миннуллинның теле безнең актёрлар табигатенә бик якын, чөнки актёрларның тулы буыннары аның драматургиясендә үскән, тәрбияләнгән иде. Аның персонажлары яхшы таныла, алар ачык, төгәл тел белән сөйләшәләр, бу актёрларның күнеленә май кебек ягыла. Укыган чакта ук, алар бу текстларны уйнаудан да бигрәк, сөйләргә дә кызык булуын аңлыйлар иде. Әйе, «Шулай булды шул»ны кабат укуымнан ул миңа ошады. Бердәнбер төртелгәнем — төш күрү күренеше булды. Ул әллә ни кызык эшләнмәгән кебек тоелды, шуна аны кабат язуын сорадым. Бергәләп киңәшкәч, яңа вариант язып китерде. Әмма анысы да беренчесеннән бик үк аерылмый иде. Дөньяда үз пьесаларын рәхәтләнеп янадан язучы драматурглар бик аздыр дип уйлыйм. Бу мәсьәләдә без Туфан Абдуллович белән шактый бәхәсләшсәк тә, ул «әзерләмәләр» түгел, бәлки, әдәби әсәрләр иҗат итәм дип санады һәм бу хакта матбугатта да язып чыкты — һәм ул, мөгаен, хаклы булгандыр. Әмма мин, «әзерләмә» сүзе, бәлки, драматургиягә бик туры килмәсә дә, бу материалны барыбер уйнау өчен дип санадым һәм саныйм. Пьеса сәхнәдән яңгыраганчы, укылырмы әле ул, юкмы?! Шулай килеп чыкты да. Озакка сузылган тәнәфестән соң, бу безнең сәхнәдәге беренче очрашуыбыз булды. Аннары инде ул үзе миңа мөрәҗәгать итә башлады.

Щепкинчыларның чираттагы юбилее якынлаша иде, ул «Галиябану сылуым-иркәм» дигән пьесасын язды. Гомумән, Туфан ага «Галиябану» пьесасы турында еш сөйли иде. Ни өчендер ул «Галиябану»ны татар драматургиясе, театрының бер символы дип саный иде, һәм үзенең шушы пьесага мәхәббәтен Фәйзинең классик тексты белән берләштерергә булды. Туфан ага бу текстны алып килде, гаҗәбрәк текст иде ул, чөнки ярты пьеса Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану»ыннан алынган кисәкләрдән тора иде диярлек. Тулы күренешләр белән. Калганы — өлкән артистларның, аның геройларының диалоглары. Персонажның бөтен хәрәкәтләрен берләштерүче иң мөһим нәрсә җитеп бетми һәм мин шуны өстәүне сорадым. Менә шунда инде безнең хезмәттәшлек башланды. Менә шулай. Чөнки мин аңлыйм, җиңел түгел иде, авыр иде аңа. Күпме еллар, бер-берсен ярты сүздән аңлашып, Сәлимҗанов белән хезмәттәшлек иткәннән соң... Татар совет театрының бу чоры күп яктан бик яхшы аңлаешлы. Ул чорда байтак пьесалар заказ белән — Җәлил, Тукай һәм башкалар турында язылды... Театр шушы юл белән барырга мәҗбүр иде. Марсель Хәкимович нефтьчеләр турындагы пьесаны чыгармаса, Островскийны куя алмый иде. Ягъни, барысы да ачык аңлашыла. Аннары, вакытның үзгәрүен дә исәпкә алырга кирәк, һәм Туфан Абдулловичның яңа дулкынга бик тә эләгәсе килә иде.

Бераздан без Шамил Закиров белән «Яңа татар пьесасы» конкурсын уйлап таптык. Ул әлеге идеяне катлаулы караш белән кабул итте. Минемчә, бу аның театрга контроль дилбегәсен үз кулыннан ычкындырасы килмәве белән дә бәйле иде. Ә без монда тоттык та аннан башка уйлап чыгардык. Баштарак ул пьесаларын конкурска бирмәде, аннары гына бирә башлады. Барыбер аның йогынтысын тоя идек. Төрлечә. Кайчакта конкурс турында үз фикерен ачык һәм төгәл белдерә иде. Әмма мин аны аңлыйм — күпме еллар буена драматургиядә, язучылар арасында лидер бул да, ә монда кинәт нииндидер конкурслар пәйда була, өстәвенә, ябык конкурслар.

Туфан Абдуллович, гомумән, катлаулы кеше иде. Аның иң авырткан темасы — шәһәр һәм авыл. Шундый бер кызык хәл булды. Без аның туган авылына ачык һавада «Гөргөри кияүләре»н уйнарга киттек. Мондый эшләр хәзер генә традициягә әйләнде ул, ә бу юлы — беренче тапкыр, ул да безнең белән. Менә ул безгә үзенең авылын күрсәтеп йөри. Суын бөтен кеше эчәрлек итеп үзе яңарткан чишмәне.



Киләчәктә шунда яшәргә, иҗат итәргә дип төзегән йортын. Ә без бит аның һәрвакыт санаторийларда язганын, иҗат иткәнен беләбез. Ул беркайчан да туган авылында язмады. Һәм менә бу йорт. Ул тулысынча яхшы итеп, тышлап эшләнгән, тик анда беркайчан да беркем яшәмәгән. Анда озаклап яшәр өчен барысы да әзер югыйсә — миче дә бар, җылытыла. Чардакта кипкән алмалары, гөмбәләре, төрле үләннәренә кадәр саклана. Тик ул ташландыклыгы белән шаккатыра. Бу миңа аның авылдагы тамырларын, андагы башлангычны, авыл мәдәниятен шәһәрнеке белән берләштерергә омтылуы... тик чынлыкта барып чыкмавы булып тоела. Ә пьесаларында ул шәһәр — бик начар, ә авыл яхшы дип тәкрарлый. Миңа исә каршылык аның үзендәдер кебек тоела. Аның пьесаларында нәсыйхәт бирү өстенлек итсә дә, моның артында аның үз-үзе белән килешмәүчәнлеге сизелә иде... Аннары без аның шәһәрдәге фатирында кунакта булдык. Анда авыл исе сакланган иде. Оекта суган эленеп тора... Көнкүреш гел авылча. Ә авыл йортында шәһәрчә уңайлыклар тудырылган иде. Тик бакчасы каралмаган. Шулчакта мин аннан: «Сез монда еш кайтасызмы?» — дип сорадым. «Юк, вакыт җитми», — диде. Мин аны аңлыйм — ул депутат булды, ул авылга кайта алмый иде, авылдашлары аңа үтенечләр белән еш киләләр, менә бу чишмә дә шулай барлыкка килгән, ул зиратны койма белән әйләндерткән, мәктәпләргә булышкан, күп эшләгән, болар барысы да хак. Әмма ул анда иҗат итә алмый иде. Шуңа да мин «шәһәр-авыл» магистраль темасы үзен дә бик борчыгандыр, дип уйлыйм.

Аның мин куйган соңгы пьесасы, әлбәттә, «Мулла», ул гадәти түгел. Бер үк вакытта ул «Дивана»ны язды. Бу пьесалар укылгач, труппа үз тавышын «Мулла»га бирде. Мин исә коллектив теләгенә каршы чыгып, «Дивана»га тотындым. Хәер, бу пьеса да башкаларга бик охшаган иде. Әмма күпчелек «Мулла»ны теләде. Тик бу вакытта миңа «Дивана» кызыклырак тоелды. Моннан соң Туфан Абдуллович миннән берничә тапкыр ни өчен «Мулла»ны куймавым турында сорады. Мин аңа бу тема минем өчен бик кызыклы түгеллеген һәм, өстәвенә, финал белән килешмәвемне аңлаттым. Тагын шуның өчен дә: бу пьесага үзенең эчке конфликты салынган кебек тоелды. Чөнки ул — атеист, бу хакта үзе дә еш әйтә иде. Бу темага мөрәҗәгать итүе аның үзе белән авыр яраша иде. Мин аңа финал белән килешмәвемне әйттем. «Ярар, — диде ул, — ничек тә бер куярсың әле». Аннары без аның белән Уфага, Гафури театрында куелган «Мулла» спектакленә киттек, яңадан спектакльне Әтнә театрында карадык, аннан Минзәлә булды, ягъни аның соңгы елларында «Мулла» тирәсендә без гел бергә йөрдек. Һәм ул һәрвакыт минем кайчан куячагым белән кызыксынды. Вакыты җиткәч, дия идем. Менә ул соңгы тапкыр минем яныма килде, бергәләп чәй эчкәндә, сүз тагын «Мулла»га барып тоташты. Шунда мин, әгәр аны куйсам, финалда геройны үтерәчәкмен, дидем. Туфан Миңнуллин шунда үзе, ярар, мин риза, үзең теләгәнчә эшлә, диде. Берникадәр вакыттан соң ул китте. Бөтенләйгә.

Аннан жыелыш булды. Мин Туфан Миннуллин исталегенә моны эшләячәгебезне белдердем. Бераз гына соңрак, август аенда, менә нинди вакыйгалар килеп чыкты: Вәлиулла хәзрәт үтерелде, мөфтигә һөҗүм иттеләр. Нәкъ шул чакта пьеса миңа ачылып китте. Тематик планда түгел, ә бәлки аңа керү мөмкинлеге. Театрда бит һәрвакыт ниндидер мистик хәлләр булып тора. Туфан Абдуллович үзе китеп, без репетицияләргә керешкәч, пьесаның актуальлеген раслагандай, барысын да, бөтен татар дөньясын тетрәндергән шушы вакыйгалар килеп чыкты. Шуңа күрә мин Туфан Абдулловичның дин, иман турындагы уйланулар планындагы ихлас ниятләре мәсьәләсендә гөнаһ кылмадым. Мин аның халкыбызның әлегә Исламга, Иманга әзер түгеллеге турындагы төп идеясен житкерә алдым кебек тоела. Бәлки, беренче чиратта, имамнар, муллалар үзләре үк әзер түгелдер. Бу процесс озын һәм катлаулы. Туфан Абдуллович моны барысыннан да яхшырак аңлый иде. Ә бит үз вакытында ул коммунист булган кеше, дингә кайту аның өчен бик катлаулы иде. Ул, мөгаен, дингә кабат шулай тиз кайту мөмкинлегенә аптырагандыр. Бу күчүнең мондый ашыгычлыгында гайре табигыйлекне тойгандыр. Менә шушы гайре табигыйлек төп персонаж аша үтә. Автор аңа мондый биографияне юкка гына бирмәгән бит инде. Ул зонада утырган һәм кинәт үзенең барыр юлын ачыклаган да авылга, бөтенесе бу диннән куркучылар янына кайткан. Һәм ул төп геройның антогонисты Вәлиәхмәтне уйлап чыгара, ә ул муллага караганда ышандыручанрак. Спектакль куелгач, безнең адреска претензияләр бик күп булды. Ни гажәп, ни өчендер барысы да, Туфан Абдулловичның үз образын, аның фикерләрен, уйлануларын искә алмыйча, бу пьесаның нәрсә турында икәнен, нәрсә турында язылуын белә иде. Ә бит аның белән беркем дә театр кешеләреннән дә якынрак һәм тыгызрак аралашмады. Чөнки художник һәрвакыт ялгыз. Әйе, ул депутат, жәмәгать эшлеклесе иде. Әмма болар барысы да шундый уен иде. Үз-үзен ул театр аша гына ачарга омтылды.

Әлбәттә, аның иҗаты белән иң дулкынландыргыч очрашу ул — «Хушыгыз» дигән пьесасы иде. Бу минем өчен чын ачыш булды. Анда бөтенесе дә шундый көтелмәгәнчә. Миңа бу циклның Миләүшә турындагы беренче ике пьесасы бик ошый иде. Мин хәтта, ГИТИСта укыган чагымда ук, щепкинчыларның яңа студиясе белән «Дуслар кабат җыела»га репетиция ясый башладым. Театрга «Хушыгыз»ны алып килгәч, укыганнан соң, Марсель Хәкимович: «Мин бу пьесаны куймыйм», — дип белдерде. Янына килдем дә: «Мин укыдым, миңа ул бик кызыклы тоелды», — дидем. Аның җавабы: «Алайса, үзең куй», — булды. Ә бит Миннуллин үзе бу пьесаны күңелендә бик озак йөрткән. Нәҗибә апа сөйләвенчә, ул аны тешләрен шыгырдата-шыгырдата, күз яшьләре аралаш, каны белән язгандай иҗат иткән. Шуңа күрә дә, Марсель Хәкимович мондый Миннуллинны укып, каушап калгандыр, дип уйлыйм. Анда әлеге буын белән хушлашу бар иде. Бер үк вакытта, анда аларның икесен — режиссёр белән драматургны да үз эченә алган буын белән гади хушлашу гына түгел, ә бәлки аның әхлакый эгосы да юкка чыгуы чагыла иде. Кинәт шундый фикер — аларның бөтен идеаллары җимерелгән. Авылны күптән ташлаган шәһәр актрисасы да, авыл егете дә барысы да юкка булганын, барысы да иллюзия булганын шулай ук аңлыйлар. Марсель Хәкимович бу фикер белән катгый килешми иде. Ул ачыктан-ачык чагылмый, штрихлар белән сизелер-сизелмәс үткәрелә, әмма аермачык укыла. Әйе, анда баштагы ике пьеса темасы дәвам итә. Фабула алдагы өлешләрдән чыгып корыла. Авыл кызы шәһәргә актриса булыр өчен килгән, әмма үзенең соңгы көннәрен бөтенләй онытылган хәлдә үткәрә, һәм шул чакта авыл егете, беренче мәхәббәте, аның иң якын кешесе булып чыга. Әлбәттә, кабат Миннуллинның «авыл-шәһәр» магистраль темасы калкып чыга, житмәсә, шундый сентименталь яңгырашта. Әмма... пьесаның геройлары, авылдан чыгып, шәһәрдә тамырланган бөтен татар интеллигенциясе үз-үзләрен югалткан. Шагыйрь шагыйрь булудан туктаган, рәссам эчүчегә әверелгән, героиня актёрлык профессиясен ташлаган. Шуңа күрә минем өчен дә, театр өчен дә, Миннуллинның бөтен иҗаты өчен дә «Хушыгыз!» пьесасы бик көчле яңгырашлы фикер иде. Миләүшәнең язмышын шулай хәл итү һәм аның авызыннан шундый сүзләр әйттерү... Ул чакта миңа бу бик якын иде. Алар гаепләү кебек яңгырады. Миләүшәнең финалдагы монологыннан шундый гажәп гыйбарә: «Миңа һәрвакыт әйтәләр иде — халыкка

хезмәт ит, мин анламый идем, нинди халыкка, ни өчен ана хезмәт итәргә? Мин бары тик җырладым да җырладым гына. Ә халыкка хезмәт итүнең нәрсә икәнен мин сәхнәгә чыкмый башлагач кына анладым. Мине танымый башладылар, минем хакта гайбәтләр тараттылар». Һәм ул сүзен ике төрле анлап булган җөмлә белән тәмамлый. «Ә бәлки, — ди ул, — мин җырламасам, ә халыкка хезмәт итсәм, башкача булыр идеме?» Менә шундый гаять куркыныч тема. Ягъни Туфан беренче тапкыр художникнын җаваплылыгы, чынлыкта ана нәрсә белән шөгыльләнергә кирәклеге турында сүз алып бара. Ул чакта мина, мөгаен, ин кызыклысы шул булгандыр. Спектакль вакыйгага әверелде, яшереп торасы юк. Ихсанова, Дунаев, Шакиров, мин Тукай премиясе алдык. Ин мөһиме — ул җәмәгатьчелекне дулкынландырды. Шуна да мин анын өчен авторга бик рәхмәтле.

«Җанкисәккәем» — әлегәчә сәхнәдән төшми торган пьеса. Ул заказ белән язылган иде. Мин үзем укыткан беренче студентлар — Искәндәр Хәйруллин, Фәнис Җиһаншин, Радик Бариевлар курсы өчен Туфан Абдулловичтан берәр нәрсә язуын сораган идем. Бу — 1994 ел, озакламый чыгарылыш буласы. Мин ана «Диләфрүз»нен дә нәкъ студентлар курсы өчен язылганын белүемне әйттем. Ник әле минем студентларга да язмаска? Ул башта каршы килеп карады, янәсе, студентлар өчен заказга язмый. Мин ана: «Ә бит язгансыз!» — дим. Ул исә: «Әллә кайчан бит инде ул!» — ди. Килешә алмадык, шулай да анын хәтерендә уелып калды бугай. Беркадәр вакыт узгач, очрашкан идек, нәрсә турында, нинди темага язарга, дип сорады. Мин, «Гамлет» бар, «дәвам-пьесалар» бар, дидем. Стоппардның «Розенкранц һәм Гильденстерн үле» әсәре, актёрлар турында, пьеса турында сөйли башладым. Ә ул: «Йә, шуннан?» — ди. Мин әйтәм: «Тукайнын Шүрәле турындагы классик сюжеты бар. Менә Былтыр беркатлы Шүрәлене хәйлә белән җингән дә, ул кысылган бармагы белән калган, ә аннары? Вакыйгалар ничек дәвам итә ала? Аннан сон нидер булгандыр бит инде?» Һәм ул язды. Алып килде. Мин, курсны җыеп, рольләрне бүлеп бирдем, һәм менә 20 ел инде спектакль аншлаг белән дәвам итә. Бу — Миннуллинны минем беренче куюым иде.

Актёр булган чагымда мин үзем беркайчан да анын пьесаларында уйнамадым. Туры килмәде. Анын каравы, улым уйнады. «Әлмәндәр»дә. Ә анда Туфанны кеше буларак ачкан дулкынландыргыч бер мизгел булды. Театр кешесе буларак. Анын кайбер какшамас постулатлары бар иде. Мәсәлән, әгәр драматург театрнын бер генә актрисасына да гашыйк түгел икән, ул бу театр өчен яза алмый, ди торган иде. Бу — шәхси фикер. Әмма ул шулай саный иде. Бу — ир кешенен хатын-кызга гашыйклыгыннан кинрәк хис. Әгәр дә пьесаларыңның куелуын теләсәң, син театрда яшәргә, актрисаларга, актёрларга хатын-кыз яисә ир-кеше итеп түгел, нәкъ менә актёрлар буларак гашыйк булырга кирәк, дип саный иде. Йосыф өчен «Әлмәндәр» премьера булды һәм спектакль тәмамлангач, Туфан Абдуллович Йосыфка «Туфан агайдан» дип язылган шахматлар бүләк итте. Анын ягыннан бу кин күнеллелек чагылышы иде. Йосыфка кадәр малай ролен Туфан Абдулловичнын оныгы уйнады һәм бик озак уйнады. Ул инде үсеп яшүсмер булды, бу рольгә туры килми башлады. Марсель Хәкимовичка, күрәсен, автор алдында да, Нәҗибә апа алдында да аларның оныгын рольдән төшерү унайсыз булгандыр. Билгеле инде, ул аларның мөнәсәбәтеннән курыкмагандыр, бу бит мәгънәви билге — Туфан оныгы анын ин яхшы пьесасында уйный. Шундый символ. Әмма һәрнәрсәнең чиге бар. Һәм менә Бикчәнтәй оныгы — премьерада. Ә бит Миннуллинның беренче пьесасын безнең театрда минем әти, Рәфкать Бикчәнтәев куйган. Ин беренчесен — балалар өчен язылган «Азат» пьесасын. Беренче әйләнә әнә шулай йомылды. Аллагылары насыйп булсын. Әле Туфан аганын бик күп пьесалары безнен сәхнәгә кабаттан әйләнеп кайтыр, барлык төрки халыклар театрлары сәхнәсенә дә... Талантлы иҗатчынын бәхете инде бу!

**Фәрит БИКЧӘНТӘЕВ,**
*Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссёры*

# ДРАМАТУРГ-ФИЛОСОФ



Үзеннән соң гаять бай драматургия мирасы калдырса да, кемне югалтуыбызны без — театрлар, шул исәптән, Г.Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры да, үз жилкәбездә татып, тоеп яшибез.

Без, аның әсәрләренә кабат-кабат әйләнеп кайтып, сәхнәләштерә башладык. Туфан абый драматург буларак кайсы яктан көчле соң ул? Аның һәр язган пьесасында тирән, төптән уйланган фикер ята. Вакыйгалар тормышның үзеннән алынган булуы белән кыйммәтле. Ул беркайчан да бер көнлек пьесалар язмады. Нинди генә заман булмасын, аның әсәрләре Шекспирныкы кебек актуаль.

Мәдәният һәм сәнгать институтында Шамил Бариев белән укыткан вакытта мин беренче тапкыр Т.Миннуллинның «Дуслар жыелган жирдә» драматик новелласына мөрәжәгать иттем. Ул студентларның диплом эше булды. Аннан соң Чаллыда эшләгәндә, әлеге әсәрне профессиональ артистлар белән сәхнәләштердем. Шәкертләр белән куясынмы, артистлар беләнме — аның әсәрләре көчле янгыраш таба. «Дуслар жыелган жирдә» Чаллы театрында дүрт сезон рәттән иң актуаль һәм иң күп тамашачы жыйган спектакль булып барды.

Г.Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры өчен Туфан абый махсус «Авыл эте Акбай»ның дәвамын, алтынчы сериясен минем соравым буенча тәкъдим итте. Ул «Гашыйк буласым килә!» дип атала. Авылда яшәүче ятим көчек: «Минем шәһәргә барып гашыйк буласым килә, югыйсә, авылда андыйлар юк», — ди Акбайга. Ышанычлы дусты буларак, Акбай белән шәһәрдә булып, үзе кебек ятим көчекне табып, янадан авылга әйләнеп кайта. Шушы кечкенә генә әкият аша да Туфан абый балаларга, яшьләргә авыл мохитенең көчен житкерә алды.

Нуриәхмәт Сафиннын 60 яшьлек юбилеена әсәр эзлибез. Нуриәхмәт абый Т.Миннуллинның «Нигез ташлары» пьесасын алып килгән. Укып чыктым, 70 нче елларда язылган, бүгенге көнгә бик актуаль түгел. «Ярар, Туфан абый белән киңәшләшик тә, бүгенге көнгә яраклаштырмасмы?» — дибез. Ә Туфан ага исә: «Һай, нәрсәгә этәрәсен, мин бер язган әйбергә кире кайтырга яратмыйм», — дип карышты. Аның 30 ел элек язган әсәрен янадан янартуы барыбыз өчен дә шатлык булды. Туфан абыйның авыл жирендә үскән драматург буларак авыл жирлегенә, аның мохитенә, кешеләренә ихтирамы бик зур. Ул үз әсәрләрендә авыл кешеләрен романтик, көчле итеп күрергә тели. Аның фикере буенча, мәдәниятне авылда тәрбияләнгән шәкертләр тудыра. Татар авыллары — милләтнең нигезе, дип саный ул. «Нигез ташлары»нда Гарифулла карт образы аша әлеге фикерне әйттереп, театрга бөтенләй яна рух өрде. Бөтен театрларның нигезләрен ныгытып, Туфан абый фани дөньядан китеп тә барды. Туфан Миннуллин — драматург-философ.

Безнең театр репертуарында Г.Тукай турында «Печән базары», «Зәйтүнәкәй» спектакльләре булды. Эзлеклелекне дәвам итеп, Апушның балачагы, Казанга китү чорын да чагылдырырга кирәк иде. Туфан абый 12-15 көн эчендә Тукайның балачагын чагылдырган әсәр язып бирде. Әмма, ни кызганыч, үзе исән чакта мин аны сәхнәләштерә алмадым. Безнең репертуар папкасына башка әсәрләр керде. Ул шулай чигенде дә чигенде.

Узган елның декабрь аенда «Әйт әле, күбәләк»нең премьерасы булды. Бу аның рухына дога булып барсын! Гаиләсе, Нәжибә ханым, кызы да: «Монда нәкъ Туфан әйтергә теләгән фикер ишетелә. Ул үзенең жаны фани дөньяга күбәләк булып күченәсен сизенде кебек», — диделәр.

**Ренат ӘЮПОВ,**
*Г.Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театрының баш режиссёры*

# ТЕАТР ДИП ЯШӘДЕ...



*Туфан Миңнуллин (уңда), Фаил Ибраһимов.*

Режиссёр буларак беренче мөстәкыйль эшем 1976 елда Туфан Миннуллинның «Ир-егетләр» пьесасы буенча Актаныш халык театрында куелган спектакль булды. Алай гына да түгел, премьерага бер атна калды дигәндә, төп герой Әхтәм ролен башкаручы энем Илфак Ибраһимовны Совет Армиясенә хезмәткә алдылар. Тиз арада Әхтәмне мина уйнарга туры килде. Спектакльне ни дәрәҗәдә «бозганмындыр», әмма калган «Әхтәмнең» үзсүзлелеге, үз дөреслеге, беркемгә дә буйсынмас холкы мина — булачак режиссёрга ярап куйды тагын. Ни кызганыч, спектакльне карарга Туфан абыйның үзен Актанышка чакырырга җөрьәт итә алмадык ул чакта...

1983 ел. Чаллы шәһәрендә Энергетик мәдәният сарае каршында эшләп килгән Халык театрында, Чаллыда эшләвемнең икенче елында, Туфан Миннуллинның «Нигез ташлары» пьесасын сәхнәләштердем. Спектакль тамашачылар тарафыннан да, театр җәмәгатьчелеге тарафыннан да (ул вакытларда Халык театрларына профессионаллар да хәерхаһлы яшәделәр) югары бәяләнде... Энергетик мәдәният сарае каршындагы Халык театрының безнең куелышта К.Тинчуринның «Американ», Т.Миннуллинның «Нигез ташлары» спектакльләрен караган, күргән, югары бәя биргән Празат Исәнбәт, Минзәлә театрында эшли башлагач та, мина һәрдаим: «Чаллыдагы Халык театрыгыз профессиональ коллектив булып эшләп китә ала иде бит», — дип гел искә төшереп тора иде. Боларны ни өчен язам, чөнки без татарның артык тыйнаклыгы әле һаман драматург Туфан Миннуллин белән очрашудан тоткарлап тора...

2007 ел. Ниһаять, Туфан абыйга Чаллы Татар дәүләт драма театрында куелган «Саташу» спектакленең премьерасын күрсәтү бәхетенә ирешелде без фәкыйрегезгә. Чаллы телевидениесе фондында спектакльдән соң Туфан абый белән булган сөйләшү саклана. Менә ниләр сөйләгән иде анда Туфан абый: «Спектакль карарга мин бераз сагаебрак килгән идем. Чөнки ул бик катлаулы әйбер, мин аны бик озак уйлануларлан соң яздым, ничек кабул итәрләр, ничек куярлар дип. Минем бөтен көткәннәремнән дә артык спектакль карадым. Заманында «Ай булмаса, йолдыз бар» спектакле белән Дамира Кузаева шаккатырган иде, менә бүген дә Чаллы театры үзен бу спектакль белән чын мәгънәсендә югары профессиональ театр икәнен күрсәтте. Шуна күрә мин бик шат — шушындый катлаулы рольләрне, кешеләп темперамент һәм үз күнеленен бөтен нечкә җирләре белән уйнарга таләп ителгән пьесада алар нәкъ мин көткәннәрне күрсәттеләр. Драматургның әсәре берничә шәхес җимеше — анда режиссёр, артистлар, анда композитор, рәссам да бар. Шуна мин кабатлап әйтәм, театр бүген мина һәм үзенә бик зур бүләк ясады».

...Күнелемнән Туфан абый белән булган очрашуларны барлыйм. Менә тагын берсе.

Түбән Камадан Рөстәм Галиев шалтырата. «Без хәзер Туфан абый белән Чаллыга, синен янга киләбез!» Дүрт-биш минут та үтми, көлә-көлә, минем эш бүлмәсенә килеп тә керделәр. «Каушама-каушама, безгә бернинди әзерлек тә кирәкми, без ял итәргә килдек! Рәхәтләнеп сөйләшеп утырыйк әле. Эчемлекләр кирәкми! Әмма чәйсез булмас.

Туфан абый Түбән Камала да, Чаллы шәһәрендә дә театрларның иҗади эшләрен күзәтеп, уңышларына сөенеп, җитешмәгән якларына көенеп яшәде. Бу ике шәһәрдә дә театрлар өчен махсус биналар булмауга рәнҗеп яшәде. Бакый дөньяга күчәргә берничә көн калыр алдыннан да, Дәүләт Советы сессиясендә, бары тик Чаллы һәм Түбән Кама театрларына тиз көннәрдә, кичекмәстән махсус театр биналары салу хәстәренә керешергә кирәклегенә басым ясый-ясый, ачынып сөйләде. Урыны җәннәттә булсын!

**Фаил ИБРАҺИМОВ,**
*Чаллы Татар дәүләт драма театрының баш режиссёры*

# ТУФАН КҮЗЛЕГЕ



*Хәлил Мәхмүтов (сулдан уңга), Туфан Миңнуллин, Рөстәм Галиев.*

Кайда икән ул мине гомере буе озатып килгән, мең катлы кыллардан эшләнгән серле күзлек? Гаҗәп, күз алдымнан югалганына байтак вакыт узса да, күңелне үтәләй кисеп, радиоалгыч дулкыннары кебек нурлары белән бәреп уй-хисләрне, хатирәләрне, узган гомер юлларын искәртеп сагындырып тора ул.

Гомеремнең бер матур мизгелендә, мин ул күзлекне беренче тапкыр күргәч, гаҗәеп бер могҗизаи көч белән очрашканымны сиздем. Ниндидер төпсез күзлек. Күзлекнең төбе юк: иге-чиге булмаган ком далалары, башыңны күтәреп өскә карасаң да, биеклеге күренмәгән таулар, үтеп чыга алмаслык кара урманнар.

Туфан ага шул күзлекне кулъяулыгы белән сөртергә дип салгач, мин аның нәни баланыкыдай күзләрен күреп гаҗәпләнгән идем.

Ул күзлек мине яшәешем буена озата килде, нәрсә эшләргә алынсам да, иҗаттамы, тормыш-көнкүрештәме, яраган-ярамаган эшләрне читтән үзенең дулкыннары белән төзәтә торды, күзләде, ул күзләрдән мин һәрвакыт яшәешнең хакыйкате барлыгын, шуңа буйсынып яшәргә кирәклеген аңладым.

Күзлек мине яшәештә сизгер-сак яшәргә өндәде. Мин күзлек белән очрашкан саен тормышның катлы-катлы проблемаларын, дөньяның бөтен галәмәтен күргән кебек була идем. Анда — кайгы, анда — сагыш, ил язмышы, халык язмышы, иксез-чиксез иҗат җимешләре. Ул күзлек трибуналарга менеп, җәмгыятьне, кешеләрне үзенә әсир итә, гипнозлый, яшәешнең унай нурларын сибә. Ул күзлек газета-журналларда, радио-телевидениеләрдә тапкыр чыгышлар сөйли, дөньяны матур итеп күреп, пьесалар, хикәятләр иҗат итә. Күзлек театрларга үтеп кереп, матур спектакльләр барлыкка китерә, адәм балаларының рухын күтәрә, театрларны үзеннән туган балалары кебек күзләп, хәстәрләп, тора. Ул күзлек космик киңлекләрдә асылынып тора, усаллана, җырлый, елый, уйный, күз яшьләре белән көлдерә. Күпләргә ул күзлек ошый, күпләргә ошамый. Ләкин күзлек барыбер үзенең көчле нурлары белән кешеләрне табигый юлдан барырга өнди, ярамаган юлны кисәтә.

Дөрестән дә, кайда икән ул күзлек, хәзер дә бик күрәсе килә, ятимлекне азга гына булса да оныттырып, сагынганны бастырып торыр иде ул...

**Рөстәм ГАЛИЕВ,**
*Т.Миңнуллин исемендәге Түбән Кама*
*Татар дәүләт драма театрының баш режиссёры*

# САГЫНДЫРАСЫҢ, ТУФАН АГА...



*Олег Ханов (сулдан уңга), Туфан Миңнуллин, Рифкат Исрафилов.*

Туфан Миннуллин белән беренче очрашу 1976 елда булды. Безнең театр Туфан аганың «Үзебез сайлаган язмыш» спектаклен куйды. Биредә Рифкат Исрафилов мина Илгиз Туктаров ролен бирде. Бу роль шунысы белән истә калды: әлеге рольгә мин ижади яктан киллдем, монда характерлы образ тудырырга кирәк иде. Әлеге образ өстендә эшләп, артист буларак ачылдым, тамашачы таный башлады. Премьерага Туфан ага да килде. Туфан ага гадилеге белән үзенә җәлеп итте, аңлашу-сөйләшү жинел булды.

Баштарак аның артист икәнен белмәдем дә әле. Казанга гастрольгә килгәч, ул мине танылган кешеләр белән бергә үзенә кунакка чакырды, бу минем өчен зур дәрәҗә булды. Ул бөтен кешегә дә тигез карады. Шулай бервакыт Чабаксар каласында фестиваль үтә. Килеп төштек. Туфан ага әйтә: «Син базарга бармыйсынмы?» — ди. «Юк, — мин әйтәм, — репетиция бит хәзер», — дим. Ярата иде ул базарга йөрергә, халыкның яшәү рәвешен,чын тормышын базарларда белергә мөмкин, дип әйтә иде. Ул минем өчен тормышны белүе белән дә кызыклы булды. Мин «Салават» театрында эшли башлагач, тагын да ныграк аралаша башладык, берара, ул депутат булып сайлангач, азрак бәйләнеш өзелеп торса да, аның «Шулай булды шул» әсәрен сәхнәләштергәндә үзе килде Салават каласына, бик канәгать булды». Салават» театрын махсус рәвештә Казанга чакырды, гастрольләрне оештыруда зур ярдәм итте. 2009 елда «Риваять»не куйдык. Әсәр көчле романтик алымнар белән язылган, гомумән, Туфан ага драманың төзелешен яхшы белә, пьеса башындагы фикерне ахырына кадәр дәвам иттерә, конфликтларны кора белә иде. Мин кайчак гажәпләнеп, кайлардан табып бетерәсез темаларны, Туфан ага, дип тә сораганым булды, ул исә, бер дә исе китмәгәндәй, әй, алар бит безнен янәшәдә генә, игътибарлы гына булырга кирәк, ди иде. «Риваять»не Казанда да күрсәттек. 2012 елда «Салават» театрында «Нәзер»не куйдык. 2 майда Туфан ага үзе килергә тиеш иде, чөнки 4 майга премьера билгеләнгән, һәм без күңелсез хәбәр алдык. Бу — һәммәбез өчен — татар халкы өчен дә, башкорт халкы өчен дә зур югалту иде. Соныннан без аны Туфан аганың туган авылында куйдык. Туфан ага туган авылын, Казанны, татар халкын нык ярата иде. Бер мәжлестә утырганда: «Иртәгә Казаныма кайтып китәм», — дигән сүзе истә калды. Шушы бер сүздә генә дә шәһәренә, туган халкына мөнәсәбәте күренә. Төп позициясе — милләт мәсьәләсе иде. Ачык күңелле кеше иде Туфан ага. Аны югалткач, күңелдә сагыш калды. Ни гажәп, күз алдына гел тере булып килеп баса. Якты, киң күңелле булып.

**Олег ХАНОВ,**
*М.Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия драма театрының сәнгать җитәкчесе*

# ӘЛМӘТ СӘХНӘСЕНДӘ ТУФАН ӘСӘРЛӘРЕ

70 еллык тарихка ия Әлмәт Татар дәүләт драма театрында танылган драматург Туфан Миңнуллинның 11 әсәре сәхнәләштерелгән. 1965 елда беренчеләрдән булып режиссёр Гали Йосыпов аның «Күрше кызы» драмасы буенча «Очканда, кагынганда» спектаклен куя. 1970 елда Зәкия Туешева «Диләфрүзгә дүрт кияү» комедиясен сәхнәләштерә. Татар театрлары репертуарында даими «кунак» булган әлеге спектакль Әлмәт театрында камалларныкына караганда да иртәрәк пәйда булды. Казан тамашачысы Марсель Сәлимҗанов куйган комедияне тәүге тапкыр 1972 елда күрде. Ә әлмәтлеләр исә режиссёр Зәкия Туешева сәхнәләштергән тамашаны ике елга иртәрәк алкышлады.

— Ул спектакльне тамашачы бик яратты. Шуңа күрә озак еллар уңыш белән барды сәхнәдә, — дип искә ала Әлмәт театрының легендасы Зәкия Туешева. — Җитмешенче еллар ахыры. Безнең театр Казанга гастрольгә җыена. Баш режиссёр Гали Хәсәенов репертуар туплый. Камал сәхнәсендә барганга, «Диләфрүз»не алмаска булдык. Шулай тиеш иде. Ләкин безнең киләсен ишеткән драматург Туфан Миңнуллин, миңа шалтыратып, спектакльне гастроль репертуарына кертүне сорады һәм үзе үк кертү-кертмәү проблемасын хәл итте дә. Бик ошатты ул безнең «Диләфрүз»не.

Егерме сигез елдан соң комедия театр репертуарына Илдар Хәйруллин куелышында «Әрәмәлек кияүләре» исеме белән кайтты. Төрле буын театр сөючеләр яратып өлгергән ике пәрдәлек музыкаль комедия Әлмәт Татар дәүләт драма театры афишаларында 2015 елда янә пәйда булды. Бу юлы аны режиссёр Нәфисә Исмәгыйлева һәм театр яшьләре яңартты.

Туфан абыйның Әлмәт сәхнәсенә өч тапкыр «кайткан» тагын бер әсәре — балалар өчен «Авыл эте Акбай» әкияте. 1993, 2002 елда аны сәхнәгә Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Камил Вәлиев куя. Ә 2012 елда режиссёр Гүзәл Акбердина (Әбүшаһманова) кабат сәхнәләштерде.

— 2010 елда театрда Туфан аганың 75 яшьлек юбилеен уздырдык. Котлаулар, хатирәләр, аның әсәрләреннән өзекләр күп булды. Ул вакытта «Авыл эте Акбай» әкияте өзегендә Бәрәнне яшь артистка Эльмира Яһудина башкарды. Туфан ага аның уенын бик яратып, балаларча ихлас сөенеп, актрисаның пластикасына таң калып, рәхәтләнеп көлеп караган иде. Әкиятнең Әлмәт сәхнәсенә өченче тапкыр кайтуына драматургның шундый самими реакциясе дә этәргеч булгандыр. Нәкъ шул вакыттан без дә театрга яшь тамашачы әзерләү хәстәренә керештек, — дип Туфан ага белән бәйле истәлекләрен барлый театр директоры Фәридә Исмәгыйлева. — Әлмәт театрында балалар өчен спектакльләр булмады түгел. Әмма театр киләчәген күз уңында тотып, үз тамашачыбызны әзерләү өчен, биш ел элек максатчан эш башладык. «Туфан мәктәбе» проекты шул бурычны күздә тоткан башлангычның берсе.

Туфан ага халкыбызның намусы булса, аның исемен йөрткән проект — ул тел, әдәбият, татар һәм театр дөньясы. Анда матур итеп сөйләшергә, Туфан Миңнуллин иҗаты белән танышырга, үзенә сәхнәгә чыгып уйнарга мөмкинлек тудырылды. 2012 елның 14 маенда Т.Миңнуллинның «Акбай һәм сарык малае» әкияте премьерасы белән «Туфан мәктәбе» проектын тәкъдир иттек. Залга проектта катнашырга теләгән балалар җыелган иде. Уку елы башыннан шәһәрнең 10 мәктәбенең 10 түгәрәгендә театр дәресләре башланды. Артистлар балаларны актёрлык осталыгына өйрәттеләр. Бер ел дигәндә аларның һәммәсе Туфан абый әсәрләрен сәхнәләштереп, тамашачыга күрсәтте. «Туфан мәктәбе» проекты эшендә драматург үзе дә катнашыр дип уйлаган идек. «Шәп уйлагансыз. Киләм», — дип вәгъдә дә иткән иде. Әмма тәкъдир итүгә санаулы көн кала кайгылы хәбәр килеп ирешә. Проект белән бәйле эшләрне Туфан Миңнуллинның якты истәлегенә багышладык.

## Дөньяны ихласлык коткарыр

— Туфан абый белән Әлмәттә дә, Казан гастрольләрендә дә очрашып тордык. Күрешкән саен сөйләшми, әдәбият, милләт, театр турында фикерләшми калмадык, — дип дәвам итә Фәридә Исмәгыйлева. — Шундый очрашуларның берсендә ул,



*Туфан Миңнуллин премьерадан соң Әлмәт Татар дәүләт драма театры сәхнәсендә.*

фәлсәфи уйларына нокта куеп: «Дөньяны бит матурлык түгел, ихласлык коткарыр», — дигән иде. Ул мең хаклы. Ихласлык юк бит: бер төрле уйлыйбыз, икенче төрле сөйлибез, ә гамәлләребез бөтенләй башка... Ә Туфан ага үзе ихлас шәхес иде. Аның Әлмәт театрын яратуы ихлас иде. Без моны һәрвакыт сизеп яшәдек. Ул ана хәтта «зат (женес)» ярлыгы да такты. «Әлмәт театры — хатын-кызлар театры. Ана элек-электән хатын-кызлар баш булды, театрны гүзәл затлар танытты», — диде.

Казан гастрольләре вакытында «Монда тудык, монда үстек» спектаклен янәшә утырып карадык. Бик яратып тамаша кылды ул аны. «Эх, әйбәт бу спектаклегез», — дип утырды. Әлмәт театрында Фаил Ибраһимов куйган «Исәнмесез» әсәрен дә 70 яшьлек юбилеенда үзенә күрсәттек.

Әлмәт татар дәүләт драма театрынын 70 еллык юбилеена багышлап чыгарылган китапта драматург Туфан Миннуллиннын театр эше турында сокланып әйткән шундый сүзләре бар: «Бу көннәрдә без бик зур шатлык кичерәбез, Әлмәт театрынын ижади яктан яңадан тууына без шаһитбыз. Әлмәтлеләр безне матур мәгънәсендә гажәпләндереп кенә калмадылар, ә бәлки күп нәрсә хакында уйланырга да мәжбүр иттеләр. Хәзер без үзләренен сәнгатьләренә бернинди ташлама таләп итмәгән коллектив белән эш йөртәбез». Чыннан да, тиздән театр Т.Миннуллиннын «Ай булмаса, йолдыз бар» спектакле белән бу фикерне тагы бер кат раслый, сәнгать дөньясында үз сүзен янгыратып әйтә.

«Ай булмаса, йолдыз бар» әсәрен автор Туфан Миннуллин да, режиссёр Гали Хөсәенов та, төп рольне башкаручы артистка Дамира Кузаева да катлаулы яшәеш тарихы буларак аңлата, аны фәлсәфи гомумкешелек проблемалары тәсмерендә чагылдыра. Шул сәбәпле бу спектакль җәмәгатьчелектә киң яңгыраш, югары бәя алды һәм алар өчесе дә 1979 елда ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә ия булды.

Ул бит бу әсәрен махсус Дамира өчен язган. Пермь өлкәсе Барда районына барып кайтканнан соң да шалтыратып: «Дамира Кузаеванын каберенә таш куйдыргансыз икән. Рәхмәт. Мин дә чәчәкләр салып кайттым», — дип илтифатын белдерде. Бу да соңгы сөйләшүләрнен берсе булгандыр.

**Ләйләгөл МИНАЕВА,**
*Әлмәт Татар дәүләт драма*
*театрының әдәби бүлек мөдире*

# ТУФРАКТАН ЯРАЛГАН ТУФАН

ТУФАН МИҢНУЛЛИННЫҢ ГАМӘЛ ДӘФТӘРЕННӘН
КАЙБЕР СӘХИФӘЛӘР

*Туфан Миңнуллинны иң беренче чиратта без язучы, драматург, депутат буларак беләбез. Язган әсәрләре, сәхнәгә куелган пьесалары буенча аңа бәя бирәбез. Әмма, Тукайчарак итеп әйтсәк, Туфан коеп куйган драматург кына түгел, Туфан зур ул, бөек ул, аның күзе күпне күрә, колагы күпне ишетә.*

*Бу язмамда мин Туфан Миңнуллинның иҗаты хакында түгел, ә үзе турында, аның күпләргә билгеле булмаган кайбер сыйфатлары, соңгы елларда майтарган игелекле гамәлләре, үзенчәлекле гадәтләре турында сөйләргә булдым. Кырык елга якын аралашып-күрешеп, киңәш-табыш итешеп яшәгән энекәше буларак, минем моңа хакым бардыр дип уйлыйм.*

## Туфан холкы

Беренче күрүемдә мин иң элек Туфанның чәчләренә игътибар иттем. Урманчытырман сыман уралып-бөтерелеп үскән, тимер тарак та кермәслек бу куе кара чәчләр астында гадәти генә баш була алмавы көн кебек ачык иде. Тора-бара аның холкы да чәченә охшаш икәнне аңлый башладым. Дөрес, еллар узган саен, бу чәч дулкыннары, үзләренең ярсулыгын бераз югалтып, салмаклана, тынычлана төштеләр. Әмма аңа карап Туфанның холкы үзгәрмәде, ул һаман йөрәк кайнарлыгын, яшьлек бунтарьлыгын югалтмыйча, үз исеменә бәрабәр булып кала бирде.

Шактый вакыт мин Туфанның гел кычкырып сөйләшүенә ияләшә алмый йөрдем. Телефоннан сөйләшкәндә болай да Кама Тамагына ишетелерлек итеп кычкыруы, өч кешелек мәҗлестә өч йөз кешелек залда сөйләгән кимәлдә нотык тотуы минем өчен сәер дә, кызык та тоела иде. Баштарак моны артистлык сәнгатен үзләштергән кешенең һөнәри сыйфаты дип кабул иттем. Алай дисәң, башка артистлар кычкырып та, пышылдап та сөйләшә-гәпләшә беләләр бит. Яши-аралаша торгач, монын да серенә төшендем бугай. Беренчедән, үзе әйтүенчә, аларның гаиләсендә һәммәсе дә һәрчак шулай кычкырып сөйләшкән икән. Мәрәтхуҗа авылында боларның өе яныннан узып барган кешеләр «Габдулланыкыларда тавыш чыккан» дип уйлый торган булганнар. Ә чынлыкта, алар бөтен гаилә белән рәхәтләнеп, чөкердәшеп чәй эчеп утыралар икән. Димәк, бу читтән кергән, өйрәнелгән гадәт түгел, әлеге дә баягы үҗәт холык, әти-әнидән, нәселдән мирас булып күчкән Туфан холкы икән. Ә ул холыкның төбендә, минемчә, шәхесне шәхес иткән иң олы ике сыйфат — ихласлык һәм үз-үзенә ышаныч ята. Үз-үзенә ышанган кеше генә шулай бар дөньяга ишетелерлек итеп аваз сала, бары тик ихлас күңел аша узган әсәрләр генә башкаларның күңеленә юл таба.

## Туфан киеме

Халыкта «кешене киеменә карап каршы алалар» дигән гыйбарә бар. Бу сүзләрдә хаклык булса да, алар нигәдер Туфанга кагылмый кебек. Чөнки Туфанның халәте төрледән-төрле булган кебек, аның киенүе дә гадәти кешенеке төсле түгел. Хәләл җефете, күренекле артисткабыз Нәҗибә ханым берзаман:



*Туфан Миңнуллин (уңда) һәм Разил Вәлиев.*

«Туфан гаҗәеп зәвыклы итеп киенә белә», — дип язып чыккан иде. Аны укыгач, мин көлемсерәп куйдым, чөнки Дәүләт Советы Рәисе, гаҗәеп пөхтә киенүче Фәрит Мөхәммәтшинның: «Туфан, бу чалбарыңның үтүк күргәне бармы?» — дигәнен ишеткәнем бар иде. Ә чынлыкта, алар икесе дә хаклы. Көндәлек гадәти халәттә Туфан бик гади киенә, ул таушалган джинсы чалбар белән чәчәкле-чуклы күлмәк киеп, башына ковбой эшләпәсе элеп тә урамга чыгарга мөмкин. Тантаналы кичәдә яисә мәҗлестә — Туфанны танырлык түгел: аның өстендә яңа гына манекен иңнәреннән төшкән модалы костюм, күз явын алырдай галстук булыр! Ә Сабан туенда, милли бәйрәмнәребездә бөдрә чәчле тубал башына татар түбәтәе менеп кунаклар. Түбәтәйнең дә теләсә кайсын кими: көндәлеккә бизәксез кара түбәтәй сайлый, ә бәйрәмнәрдә чигелгәнен киярга ярата. Язучыларның Германиядә һәм Австриядә узган халыкара конгрессларында да башыннан төшмәде аның түбәтәй. Татар язучыларын анда иң беренче чиратта Туфан түбәтәе аша танып алалар иде.

Кыскасы, Туфан кайда, кем янында ничек киенергә кирәклеген яхшы белә. Бер караганда, ул киемгә бөтенләй игътибар да итми кебек. Әмма бу беренче карашка гына шулай. Туфан авылга кайтканда — чын авылча итеп, президент янына барганда — президентларча, халыкара форумнарда Европа фраерларыча киенә.

Минем уйлавымча, күңелендә гармония, тәртип булган кеше тышкы вак-төяк тәртипсезлекләргә артык игътибар итми, ә күңеленә тынычлык таба алмаган, күңелендә болгавырлык хөкем сөргән кеше исә тирә-юнендә, шул исәптән киемендә, бүлмәсендә һәрчак идеаль тәртип урнаштырырга тырыша. Ә Туфан Миңнуллин — үзенең тынгысыз күңелендә үзе тәртип урнаштыра, күңеле белән идарә итә белә торган шәхес. Шуңа күрә дә аның киеме һәрчак күңел халәтенә бәрабәр, шуңа күрә дә Туфанның киеме аның үзенә охшаган.

## Туфан гадәтләре

Туфан, гадәттә, кешеләр белән елмаеп, ике куллап күрешә. Озак күрми торган якын дусларын, очрашканда, кайчак кочаклап та ала. Әмма саубуллашканда беркайчан да кешегә кулын сузмый. Кул биреп саубуллашсаң, бөтенләйгә аерылышкан кебек буласың дип үзенчә юрый ул. Аның таныш-белешләре исәпсез-хисапсыз, дуслары да шактый, ә дошманнары, булса да, берничә генәдер. Алары да, шәхси мөнәсәбәтләрдән бигрәк, милләткә мөнәсәбәт белән бәйләнгән. Ул зур гөнаһ, иң зур җинаять дип үз милләтенә хыянәт итүне саный. Андыйлар белән Туфан бернинди мөнәсәбәткә дә керми, ялгыш очрашканда да кул биреп исәнләшми.

Телефоннан сөйләшкәндә, ничек сәламләвенә карап кына да аның кем белән әңгәмә корганын аңлап була. Әгәр тыныч кына бер тапкыр «Исәнмесез!» дисә, димәк, ул гадәти танышы яисә бөтенләй белмәгән кеше белән сөйләшә дигән сүз. Әгәр инде йөзенә елмаю иңдереп, тавышына җылылык өстәп рәттән ике мәртәбә «Исәнмесез!» дип кабатласа, теге баштагы әңгәмәдәш якын кешесе яисә хөрмәт иткән мәртәбәле шәхес була. Ә инде тавышына яшьлек дәрте биреп, илаһи серлелек

белән өч мәртәбә «Исәнмесез!»не тәкрарласа, димәк, ул ниндидер илаһи зат — хатын-кыз заты белән сөйләшә дигәнне аңлата.

Хәләл җефете Нәҗибә ханым белән Туфан мөнәсәбәте хакында аерым бер фәлсәфи трактат язарлык. Үзара аралашканда, әңгәмә корганда, Туфан Нәҗибә ханымга карата шактый кырыс булып та күренергә мөмкин. Ә инде кемдер Нәҗибә апага катырак кагылып, аны кыерсыта башласа, Туфан кинәт кенә нәсел-нәсәбен саклаучы җәнлек-җанвар затына әверелә. Шуңа күрә дә Нәҗибә ханым һәрчак мәгърур, горур кыяфәтле, шуңа күрә дә ул җиргә аягын нык басып йөри, шуңа күрә дә ул сәхнә тутырып рәхәтләнеп иҗат итә.

Еш кына безгә Туфан белән төрле мәҗлесләрдә бергә булырга туры килә. Аны һәркем белә, һәр җирдә аны колач җәеп каршы алалар. Ул теләсә кайда теләсә кем белән уртак тел таба ала. Туфан һәр кешенең күңел түренә юл таба белә, чөнки ул аңа гади әңгәмәдәш дип кенә түгел, ә булачак, язылачак әсәренең фарази бер герое, үз туганы итеп карый сыман.

Шунысы гаҗәп: мәҗлес өстәле янына килеп утыруга, ул, уңга-сулга карамыйча, бар дөньясын онытып ашарга тотына. Шулай бераз тамак ялгап алгач, өстәлдән башын күтәреп, ярамас эш эшләгән малай сыман оялып кына, тирә-юньгә күз сала. Мәҗлес әле башланмаган, кунаклар утырышып та бетмәгән, ә Туфанның инде тамагы яртылаш туеп та өлгергән. Теләсә кайсы мәҗлеснең язылмаган кануннарын бозу булса да, мин аның бу гадәтен аңлап, эчтән генә үземчә аклап утырам. Чөнки Туфан буынының (шулай ук өлешчә безнең буынның да) тамак туйганчы ашарга зар-интизар булып, ачлы-туклы узган балачак һәм яшьлек елларын бик яхшы беләм. Ул елларда без, итагать саклауны онытып, алга куелган барлы-юклы ризыкны тизрәк ашап калырга, ач корсакны тизрәк тутырырга тырыша идек. «Чир китә, гадәт кала», — дип юкка гына әйтмиләрдер инде халыкта.

Ашыгу гадәте тора-бара аның бөтен яшәү рәвешенә әверелгән кебек тоела миңа. Ул ашыгып ашый, ашыгып эшли, ашыгып иҗат итә, ашыгып яши. Балачактагы барлы-юклы саран ризык кебек, кеше гомеренең дә бик исәпле булуын, санаулы еллардан гына торуын яши-яши бик яхшы төшенгән Туфан. Төрле дәрәҗәдәге җыелышларда, хәтта Дәүләт Советы сессияләрендә дә, һич көтмәгәндә, залдан кинәт кенә кычкырып-кычкырып куюы да әйтәсе фикеренең нәкъ менә шушы мизгелдә кирәк булуын, вакыт кадерен, вакыт мәгънәсен аңлаудан, кыскасы, ашыгып яшәүдән киләдер, ахрысы.

Аның беренче карауга сәер булып тоелган бик күп гадәтләрен мин еллар үткән саен үземчә шәрехләп, үземчә аңларга тырыша идем. Финляндиягә Хельсинки каласына Конгресска баргач, бөтен юлдашлар кибетләрдән кием-салым, төрле сувенирлар эзләп йөргәндә, олпат язучы Туфан Миңнуллинның утын яра торган балта сатып алуын күреп, һәммәбез дә аптырашта калган идек. Ә киләсе сәяхәтебездә аның бөтен Берлин каласын бетереп чылбырлы кесә сәгате эзләве дә сәер тоелды безгә. Ныклап уйласаң, ул күпләр кебек бүгенге көн белән генә яшәми, ә шулай итеп балачакта эшли алмаган эшләрен бүген эшләргә, балачак өметләрен, балачак хыялларын бүген булса да тормышка ашырырга ашыга икән ләбаса.

## Депутат Туфан

Безнең җәмгыятьтә иң нык сүгелгән, иң күп каһәрләнгән кеше кем дисәгез, ул депутат булыр. Ни өчен шулай бу? Чөнки депутат — халык күзенә иң еш чалынучы зат. Аны көн саен диярлек телевизордан күрсәтеп торалар, аны сайлаучылар белән очрашуларга чакыралар, ул безнең тормышыбызны җайга салырга тиешле законнар кабул итә, халык аны «үзем сайладым, шуңа күрә аннан таләп итәргә хакым бар» дип уйлый. (Мәшһүр Тарас Бульба әйтмешли, «үзем тудырдым, үзем үтерәм» була инде бу.) Ә президентлар, премьер-министрлар ерак, аларга буй җитәрлек, сүз үтәрлек түгел. Министрларны халык бары тик өстәгеләрнең әмерләрен үтәүче, кушканны эшләүче дип кенә кабул итә. Шуңа күрә кемгә буе җитә — шуңа кизәнә, кем аны тыңлый, сүзен шуңа сөйли инде халык, моның өчен үпкәләргә ярамый. Ә чынлыкта

Рәсәй дигән илдә дәүләт белән халык сайлаган депутатлар түгел, ә президентлар, хөкүмәт идарә итә. Депутатлар закон чыгара, димәк, өстәл әзерләп, ашъяулык җәеп куя, ә өстәлгә ризыкны әлеге дә баягы президент һәм хөкүмәт әһелләре китерергә тиеш була. Ә халык табында булганы өчен хөкүмәткә рәхмәт әйтә, булмаганын әлеге дә баягы депутатлардан таптыра.

Туфан Миңнуллин заманында шәһәр Советына да, СССР Югары Советына да депутат булып сайланды, инде менә унбиш елдан артык Дәүләт Советы депутаты. Законнар кабул иткәндә, Дәүләт программалары хакында фикер алышканда, бигрәк тә авыл проблемалары, милли мәсьәләләр хакында сүз барганда битараф булган, үз фикерен кистереп әйтми калган чагы юктыр аның. Парламентта чыгыш ясыйсы булсам, мин үзем, гадәттә, алдан әзерләнеп, чыгышымның һич югы тезисларын язып куям. Ә ул сессия барган чакта сикереп тора да үзенә ошамаган законны берничә минутта сүтеп ташлый, үз фикерен, тәкъдимен тавышка куйдырта һәм еш кына яклаучыларын да таба. Мин: «Ничек болай законны кат-кат укымыйча, әзерләнмичә генә шулай нигезле, саллы чыгыш ясый аласың син?» — дигәч, ул чалара башлаган мыегы астыннан елмаеп кына куя. Үзе әйтмәсә дә, аңлыйм, ул бит мондый чыгышларга бер-ике көн эчендә генә түгел, инде гомере буе әзерләнгән; күңел сизгерлеге, язучы күрәзәлеге, депутатлык тәҗрибәсе аны теләсә кайсы вакытта халык мәнфәгатен якларлык дәрәҗәгә җиткергән.

Дәүләт Советында халык борчуы белән борчылучы, милләт кайгысын кайгыртучы иң фидакарь депутатларның берсе Туфан Миңнуллин икәнен барыбыз да күреп-белеп торабыз. Әмма иң күп тәнкыйть сүзе ишетүче, төрле югары органнарга өстеннән иң күп шикаятьләр язылучы депутат та шул ук Туфан Миңнуллин... Кызык бит: берәүләр еллар буе авыз ачып сүз әйтмичә, бер генә игелекле гамәл дә кылмыйча сессияләрдә оеп утыра, аларга сүз әйтүче юк, аларны тәнкыйть итүче дә күренми. Көне-төне милләт мәнфәгатен кайгыртып та, кемнәрдер синнән булмаган гаепне эзләп, өстенә бертуктаусыз пычрак атып торганда, тешне кысып түзү өчен зур түземлек һәм егетлек кирәктер. «Алмалы алмагачны гына шулай селкетәләр» дип, үз-үзеңне юатырга гына кала инде андый чакта.

Соңгы 15-20 ел эчендә депутат Туфан Миңнуллин тәкъдиме һәм тырышлыгы белән эшләнгән эшләрне саный китсәм, язмам бик озынга сузылыр. Шуларның берсен генә атыйм... 2002 елда, Республикабыз Конституциясенең яңа редакциясен әзерләгәндә, Туфан ага Төп Законга бер маддә өстәргә тәкъдим итте. Белгәнебезчә, татарларның күпчелеге Татарстаннан читтә яши. Россия төбәкләрендәге милләттәшләребезгә балаларын татар мәктәбендә укыту, туган телләрен, гореф-гадәтләрен саклау, кыскасы, чын милли тормыш белән яшәү елдан-ел кыенлаша бара. Туфан ага тәкъдим иткән әлеге маддә нәкъ менә шушы мәсьәләне хәл итәргә тиеш иде. Бик озак бәхәсләр һәм фикер алышулардан соң, ул, ниһаять, 14 нче маддә булып, Конституциябездә урын алды. Анда: «Татарстан Республикасы Татарстаннан читтә яшәүче татарларга милли мәдәниятләрен үстерүдә, туган телләрен һәм милли үзенчәлекләрен саклауда ярдәм итә», — дип язылган иде. Дөньяга сибелгән татарны бер йодрыкка туплау, бердәм милләт итеп яшәтү һәм саклау өчен үтә дә кирәкле маддә иде бу. Соңрак «Россия хөкүмәте белән берлектә» дигән сүзләр өстәлеп, әлеге статья Татарстан һәм Россия арасындагы вәкаләтләр бүлешү хакындагы Шартнамәдә дә урын алды, һәм ул федераль закон белән расланды.

Еш кына «Язучының төп эше — иҗат, ул үз талантын депутатлык яисә башка җәмәгать эшләренә сарыф итмәскә тиеш» дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Мондый кинаяләргә бөек Тукай инде моннан йөз ел элек бик ачык итеп җавап биргән. Чыннан да, әгәр бүген Татарстан парламентында Туфан Миңнуллин кебек милләтпәрвәр язучы-депутатларыбыз булмаса, туган телебезне, милли мәктәпләребезне, милли матбугатыбызны, милли мәдәниятебезне, динебезне яклап кем сүз әйтер иде икән?! Дөрес, эшләнәсе эшләр бихисап, әмма эшләнгәннәрен дә күреп, игелекле гамәл кылучыларга вакытында рәхмәтле була белү дә кирәк.

## Юлчы Туфан

Туфан Миңнуллинның беркайчан да самолётта очмавы, бары җир өстеннән йөри торган транспортта хәрәкәт итүе хакында бер тапкыр язган идем инде. Чыннан да, ул үзенең бөтен яшәү рәвеше белән Җир кешесе, аның язган әсәрләре дә Җир кешесе хакында, үзе дә бөтен килеш-килбәте белән коеп куйган авыл баласы.

Ел саен яз җитүгә, аның, Казандагы бөтен эшләрен ташлап, туган авылы Мәрәтхуҗага бәрәңге утыртырга кайтуын сөйләгәч, баштарак миңа ышанмаганнар иде. Мәскәүләрдә яшәп югары белем алган, инде ярты гасырдан артык Казан каласында гомер иткән мәшһүр драматург, депутат, илкүләм танылган шәхес үз куллары белән бәрәңге утыртып йөрсен, имеш. Нигә кирәк аңа бәрәңге? Теләсә, вагоны белән сатып алырга хәленнән килә, сораса, дуслары машинасы белән китереп аудара ала. Юк шул, Туфанга, тамыры җиргә береккән авыл малаена, үзе утырткан, үзе үстергән бәрәңге тәмлерәк. «Мин буш яткан җирне кызганам, җир дә безнең кебек эшләргә, уңыш китереп яшәргә тиеш», — ди ул... Инде ничә гасыр буе галимнәр кешенең маймылдан килеп чыгуын исбатларга тырыша. Кем ничектер, белмим, ә Туфан нәселе, Туфан кавеме, һичшиксез, җирдән, туфрактан яралган булырга тиеш.

Самолётта очмаса да, шактый ерак сәяхәтләргә чыгарга туры килде безгә аның белән. Иң беренче сәяхәтебез, атлы арбага утырып, Азнакайдан Кама Тамагына, дөресрәге, Мәрәтхуҗага кадәр кайту булды. Ракеталы, самолётлы, машиналы заманда тагын кемнәрнең ярты Татарстанны ат койрыгына карап гизгәне бардыр, белмим, әмма бу мәгънәле һәм маҗаралы сәяхәт язучы Марсель Галиев белән миңа гомер буе сөйләрлек истәлек булып калды.

Кайберәүләр юл йөрүне бушка узган вакытка саный, тизрәк барып яисә кайтып җитәм дә чынлап торып яши башлыйм дип уйлый. Ә Туфан өчен юл гизү дә тормыш, ул юлда да бушка вакыт уздырмый, киресенчә, сәяхәттә тагын да дәртләнебрәк яши башлый. Аның юл капчыгында яшәү өчен бөтен нәрсә дә була: барып җиткәнче юлдашлары белән бергә тукланырлык төрледән-төрле ризык, ипи кисәргә пычак-пәке, чәй эчәргә кружка, хәтта күкрәк кесәсенә сыя торган яссы шешәсен дә онытмый. Ул һәр тукталышта, төшеп, тирә-юньне күзәтә, кешеләрдән нидер сораша. Поезд кузгалгач, купега кереп, өстәл янына утыра да куен дәфтәренә нидер теркәп куя. Ул юлда да ашкынып яши, юлда да дәртләнеп иҗат итә.

Берлинга килеп төшү белән, Туфан безне кибет карарга алып китте. «Ресторанда болай да әйбәт ашаталар, ашамлык кибетендә нәрсә алырга ниятли тагын?» — дисәм, аның нияте бөтенләй башкада икән. Ипинең бәясе күпме, ит-сөт-каймак кыйммәтме икәнне белешә Туфан, андагы бәяләрне безнеке белән чагыштыра. Ана монда бөтен нәрсә яңа, бөтен нәрсә кызык. Ул таныш булмаган дөньяны балаларча кызыксынып күзәтә, аңа олыларча бәя бирә, язучы буларак һәр күргәнен күңеленә теркәп бара.

Австриянең Линц шәһәренә Бөтендөнья язучылар корылтаена баргач, ул безне шәһәр базарына ияртеп китте. Мона кадәр дә аның «халык ничек яшәгәнне беләсең килсә, аның базарын кара», дип әйткәне бар иде. Бу юлы да бәя сорашып, чагыштырып кына йөрер, дип уйлый-уйлый барганда, моның күзе кабак сатучы рәткә төште. Соңгы елларда Туфан агайга «кабак җене» кагылганны белгәнгә күрә, минем моңа әллә ни исем китмәде. Әмма ым-ишарәләр белән аңлатырга тырыша-тырыша, татарча-русча-алманчаны бергә бутап, сатучыдан кабак төше соравын ишеткәч, мин дә колакны шомрайттым. «Бакчамда әллә ничә төрле кабак үсә, ә мондые юк, — дип, сабыйларча еламсырап әйтеп куйды ул безгә. — Кабагы белән алсаң, күтәреп кайтуы авыр, ә бу немец төшен генә бирми». Билгеле, әлеге хикмәтле кабакны бөтенләе белән сатып алып, эчендәге орлыкларын гына да алып кайтырга мөмкин иде. Тик Туфан агай андыйлардан түгел, ризыкны, малны әрәм-шәрәм итү аның өчен гөнаһ санала. Ул, гомумән, акча саный белә торган кеше. Беренче һөнәре бухгалтер булгангамы, аның маңгай тире белән тапкан һәр тиенесумы санаулы. Әмма кайчакларда, тугарылып китеп, чиктән тыш юмартланган

чаклары да була Туфанның... Ә немец базарында без барыбер үзебезнекен иттек, мен хәйлә белән теге кабак орлыгын юнәтеп, Казанга хәтле алып кайттык. Хәзер инде тизрәк көз житкәнен, Австрия кабагының Туфан бакчасында уныш биргәнен көтәбез.

## Төзүче Туфан

Заманында Туфанның туган авылы Мәрәтхужа «перспективасыз, ягъни киләчәксез авыллар» исәбенә кертелеп, фани дөнья белән хушлашу халенә житкән иде. Туган авылны ничек саклап калырга? Аның өчен нишләргә? Мин нәрсә эшли алам? Шундый уйлар белән гасабиланып йөргән Туфан авылга иң элек юл салырга кирәк дигән карарга килә. Мен мәшәкатьләр белән юл салынгач, мәчет-мәктәпкә дә чират житә. Менә миннән үрнәк алыгыз дигәндәй, шыгырдап торган нараттан төп нигезләренә йорт та салып куя. Аннан күреп, булдыклырак авыл агайлары да каралты-куралларын янарта башлыйлар. Шулай итеп, авылга әкренләп төс куна, жан керә.

Төзүчелек дәрте Туфанга шул көннәрдә ингәндерме, белмим, үзем шаһит булган 30-40 ел дәверендә мин аның нәрсәдер кормыйча, нәрсәдер төземичә торган чагын хәтерләмим. Шушы чорда гына ул, эреле-ваклы дачаларын-йортларын бергә исәпләгәндә, үзенә биш тапкыр нигез корды. Берсен төзеп бетергәч, анысын кемгәдер тапшырып, икенчесенә тотынды. Тора-бара масштаблары зурая барып, туган районындагы атаклы Олы Салтык авылында хан сараедай мәктәп салдырды, аны жиһазлауны да өлешчә үз өстенә алды. Кама Тамагындагы район китапханәсе, музей һәм китап кибете урнашкан мәһабәт бина да аның тырышлыгы белән житкерелде. Кәрим Тинчурин театрын ремонтлауда, Татар яшьләр театрына жылылык кертүдә, Язучылар берлеге бинасын төзекләндерүдә, Тәтеш татар гимназиясен торгызуда, Казандагы 12 нче кызлар гимназиясенә яңа бина коруда да турыдан-туры депутат һәм язучы Туфан Миңнуллинның катнашы бар. Ә бүген ул Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрендәге татар театрларына яңа биналар төзү хәстәрен күреп йөри. Кемнәрдер борынгы һәйкәлләребезне, халкыбызның изге хатирәләрен, аның әхлак нигезләрен жимерү, таркату белән шөгыльләнгәндә, Туфан, алны-ялны белмичә, төзи дә төзи. Язучы белән төзүче һөнәренең бер-берсенә охшаш булуын ул инде бездән әллә кайчан алданрак аңлагандыр кебек.

Бу язмамда мин Туфан Миңнуллинның бинниһая бай ижат дөньясына кагылмаска, аның исәпсез-сансыз әсәрләре хакында сүз алып бармаска тырыштым. Чөнки аның ижаты барыбызның да күз алдында, аның пьесалары барча татар театрларында гөрләп бара. Халкыбыз инде язучы, драматург Туфан Миңнуллинга күптән үзенең лаеклы бәясен бирде, «Туфан» исемен күңел түрендәге иң кадерле урынга салып куйды.

Бу юлы мин өлкән мәсләктәшем Туфан Миңнуллинның күземә чалынган кайбер гадәтләрен, яшәү рәвешен генә бераз тасвирлап, шәрехләп үтәргә, аның Гамәл дәфтәрен актарып карарга ният кылдым. Мәгънәле һәм бәрәкәтле гомеренең — язмыш юлының яртысыннан артыгына шаһит кеше буларак, аларны үзем күргәнчә, үзем аңлаганча укучыларга житкерергә жөрьәт иттем. Ә аның иң тулы язмыш юлы, тәржемәи хәле — ижат иткән әсәрләрендә. «Язу» белән «язмыш» сүзләре юкка гына бер тамырдан түгелләр инде.

**Равил ВӘЛИЕВ,**
*Татарстанның халык шагыйре.*
*2010 ел.*

# МИН БЕЛГӘН ТУФАН

*Таяну ноктасын эзли, тап дисәме,*
*Уеннан уймак чыгармакта исәбе.*
*Фатихасын Шекспирның алып ул,*
*Ат уйната тур сәхнәдә – Алып ул!*
*Ни әйтмә – татар Туфанлы халык шул!*
М.Мирза

— Туфан турында син дә язарга тиеш, — диделәр дә, уйга калдым. «Тиеш» — өстән төшкән бурыч булып ишетелде. Үзеннен күнелендә «Мин анын турында язарга тиеш!» — дигән уй, теләк булуы ин мөһиме, әлбәттә.

«Син тиеш!» диючегә мин бер җавап та бирмәдем. Үзләре дә кабат искә төшермәделәр. Шулай итеп, Туфан ага Миннуллин истәлекләренә багышланган беренче китапка минем мәкаләм кермәде.

Күнелемдә «мин анын турында язарга тиеш!» дигән уй-теләгем өлгереп килә иде югыйсә.

...Олпат әдибебез бик тә катлаулы шәхес... олы талант иярәренә хас сыйфаттыр инде ул... алар беркатлы гына, гади генә булалмыйлардыр да...

«Туфан ага гади иде!» — дип искә алучылар бик күп тә бит... гадиләр белән гади, катлаулылар белән ул да беркатлы гына булмагандыр. Үзен хуп күргәннәргә хөрмәтле, үзенә аркылы килгәннәргә ул да гел унай гына тормагандыр.

Бу — бар кешеләргә дә хас сыйфат... «Туфан ага гади иде», — диючеләр күп мәртәбәләр күбрәк икәне бәхәссез... Гади була алу, яхшы мәгънәдә гади булып таныла алу — үзе үк талантлылык сыйфатыдыр.

Туфан ага турында язарга үземне әзерләп бетерү өчен дә елдан артык вакыт кирәк булды... Ни-нәрсә язсам да, анын кешеләргә билгесез булган якларын күрсәтә алмам кебек тоелды гел... Алай дисән, язып торунын кирәге дә калмый... Бу юлларны язганда шундый фикер йөгереп үтте. Баксан, Туфан ага турында һәркем ни дә булса яза алыр иде... һәркемнен күнелендә үз Туфаны бар кебек тоелды. «Мин белгән Туфан» — язмамнын исеме шулай булыр, дип тәгаенләп куйдым. Мин белгән Туфан сез белгән Туфаннан аерылмас та... Олуг замандашыбызнын портреты һәркайсыбызнын истәлекләре белән тулыланыр шәт!..

Туфан ага турында истәлекләр язу өчен аны көнкүрештә белү, күзәтү, бәяләү бер мәсьәлә. Анын шәхесенә иҗаты аша килеп, иҗатына бәйле аерым билгеләрен табу бөтенләй икенче мәсьәлә... Туфан ага белән әнгәмәдәш булу өчен хәтта анын иҗатыннан хәбәрдар булу гына җитми кебек... Ул әнгәмәдәше белән милли әдәбият, сәнгать турында һәрчак ин югары таләпләр куеп сөйләшергә әзер. Үз әнгәмәдәшенен дә шундый әзерлектә булуын тели иде ул.

2001 елнын декабрь азаклары. Казанга кучеп килеп эшли башлаганыма бер айлап кына булыр. Арча районындагы авылда башлангыч мәктәп, клуб, китапханә, медпункт, балалар бакчасын бер түбә астына алып төзелгән бинаны ачуга чакырдылар. Казаннан бер көтү булып килгән «чакырылучылар» берничә авылда эш белән танышканнан сон, Ашытбаш авылына килеп әлеге бинаны ачтык. Авыл халкынын куанычы эченә сыймый. Чыннан да, өр-яна мәчет белән рәттән төзелгән өр-яна бу үзәк Ашытбаш авылын инкыйраздан коткарып калырга мөмкинлекләр ача иде. Әлеге эшләрдә халык депутаты буларак Туфан аганын да саллы өлеше керүен кат-кат рәхмәтләр әйтеп искә алдылар.

Башкаладан чакырылган кунакларны озатуга районнын хакимият башлыгы Алмас Нәзиров Туфан аганы, Разил Вәлиев һәм мине: «Тагын бер бинаны карыйсыбыз

бар», — дип урманлыктагы кунак йортына алып китте... Сүзебез милли мәктәпләр, милли әдәбият, сәнгать турында булды, әлбәттә. Бөек Тукаебызның Ватаны буларак Кушлавыч, Кырлайны, Арчаның үзен милли әдәбиятыбызның башкаласы итеп күрәсе килде барыбызның да.

Г.Тукайның алдагы 120 еллык юбилее барлык эшләнәчәк эшләрнең сәбәпчесе булырга тиешлеген бердәй хупладык. Президент М.Ш.Шәймиевкә Габдулла Тукайның тууына 120 ел тулуны каршылау һәм үткәрү буенча бөтен фикерләрне туплап хат әзерләргә килешендек тә, матур гына сыйланып, Казаныбызга юл алдык. Шунда Туфан ага:



— Мин анда нәрсә эшләргә тиешлегемне белеп бардым...
...А что, субъектам остаются только прачечные и бани?
А недры, земля, леса, луга, нефть не являются что ли
собственностью коренного народа?..

— Илфак, син минем машинага күчеп утыр, сөйләшеп кайтырбыз, — диде. Кузгалып китүгә:

— Менә Арча — Бөек Тукайның туган йорты. Әле күпме авылларда мәктәпләрне яңартасы, төзисе бар. Авылларны, районнарны карыйсы иде. Син район мәдәнияте өчен җаваплы министр урынбасары, әле кайларда булдың? — дип сорады.

— Рөстәм Миңнеханов та эшкә билгеләгәндә: «Син капитан дальнего плавания! Январьда чыгып кит тә республика авылларына — декабрьдә генә кайт!» — диде. Саба, Баулы, Кама Тамагы районнарында, авылларында булдым. Иң аянычлы хәлләр Кама Тамагында, Туфан ага, кышка керәләр, ярты районда клублар гел җылытылмый... хәтта клубларының тәрәзә пәрдәләре дә юк, — дидем. Туфан ага дәшмәде.

— Авылларның хәлләре шәптән түгел... Безнең Актанышта да җылытылмый торган клублар бар. Хәзер һәркайда газ кертәләр. Иң башта газны мәктәпләр, балалар бакчалары, больницаларга кертәчәкбез, — диләр. — Клуб, китапханәләр дә шул исемлектә булсын, — дип сөйләшәм районнарга баргач... Бик тыңлыйсылары гына килми, — дим.

— Разил да, мин дә беләбез бу хәлләрне. 1998 елда өч еллык программа кабул итте Кабмин. Икенче елга Кабминда яңа Программа төзиләр. Монысында район мәдәният бүлекләре турыдан-туры Мәдәният министрлыгы карамагына күчүне күздә тотып эшләнә. Бәлки файдасы да булыр әле... Иҗат яклары ничек, язылмы? — дип сорап куйды ул кинәт кенә.

— Күп вакыт юлда үтә. Бик язылмый шул, эш күп икән монда, — дим.

— Ничек инде язылмый?.. Иҗат — синең төп эшең. Юлда барыбыз да йөри. Юл ул — эш урыны.

— Үзегез нәрсәләр язасыз? «Кызыл тышлы дәфтәр»ләрдән тыш? — дип сорап куям мин үз чиратымда.

— Дәфтәрләр алар — заготовка. Анда мин көн дә язам. Менә көнозын йөреп, бераз сыйланып алдык... ә мин өйгә кайтып керүгә үк өстәл артына утырам. Эшлисемне алдан ук белеп торам... Шуңа күрә мәҗлесләрдә рюмканы да гел күтәреп кире куям... Сессиядә утырганда да, бик җитди, үзебезгә кагылышлы мәсьәлә каралмаса, язып йә язарымны уйлап утырам. Эш-эш, дип кенә йөрсәң язып булмый. Ә язып эшкә килсәң, эш тә эшләнә...

— Мәскәүдә СССР Верховный Советында депутат булып алгач, сессияләрдә гел иҗат турында уйлап утырган кешегә охшамый идегез. Ул елларда көннәр буе Сессия барышын телевизордан турыдан-туры күрсәтеп баралар иде. Сез арттагы югары рәттә, аерым берүзегез утырасыз. Каршы як креслога ике кулыгызны да алга сузып салгансыз. Калын күзлегегез астында сынган кашларыгыз, уртәлү-борчылулы йөзегезне гел күрсәтеп-күрсәтеп алалар. Сезне күреп, танып белмәгәннәр: «Бу депутат бик борчулы, авырыйдыр ахры?» — дип тә уйлаганнардыр әле...

Менә бермәл Сез, җәһәт торып, микрофонга чират бастыгыз... Көн тәртибендә милек мәсьәләләре карала иде ахры... Сезнең микрофонга «сүз бирделәр». Сез: «Депутат Миннуллин — Татарстан», — дидегез дә: — А что, субъектам остаются только прачечные и бани? А недры, земля, леса, луга, нефть не являются что ли собственностью коренного народа? — дидегез. Тагын нидер әйттегез. Сезгә карата нәфрәтле, ачулы карашлы чырайларны күрсәтеп алдылар, — дип хәтерен яңарттым аның.

— СССРның череп таркаласына, бу дәүләтнең үз халкына, бөтен милләтләргә, шул исәптән урыс милләтенә дә дошман булуына бөтенләе белән ышанып кайттым мин... Минем хәзерге бу дәүләткә дә ышанычым юк. Халык өчен, милләтләр өчен берни эшләми бит ул... Шуңа үзебезнекен ныгытырга кирәк.

Туфан ага шактый кызып китте... СССР депутаты булып сайлангандагы, үзе әйткәнчә, «әкәмәт»ләрне сөйләп алды.

— Мин анда баргач ни-нәрсәләр эшләремне алдан белеп бардым... Нишләмәк кирәк, әйе, мин дә, әнә Фәндәс тә үзебезнекен раслау өчен шактый тартыштык, файдасы гына тимәде.

— Шулар хакында язарсыз бәлки?

— Аның нәрсәсен язасың, барысы да бөтен халык күз алдында бит...

— Чехов пьесаларын, хикәяләрен авыруларны кабул иткәндә язган, диләр.

— Алай ук түгел... Авыруларны кабул иткәндә дә язу турында онытмаган дисәң, дөресрәк булыр. Кешеләрне игътибар белән күзәтеп, холык-фигыленә игътибар итәсең — алар синең геройларыңа мач килеп утыра ул... Мин пьеса язганда бүленгәнне яратмыйм... Язарга бөтен материаллар җитәрлек тупланганын тойгач кына язарга керешәм. Шуңа күрә пьеса язарга авылдагы йортка йә берәр санаторийга барып бикләнәм. Үзем генә. Кеше комачауласа әйбәт түгел.

Без җимерек, салкын клубларны читкә куеп, иҗат турында гәпләшеп кайтабыз. Туфан аганың һәрбер әйткәнен үтәргә күнеккән карусыз шофёры тизлекне арттырмыйча юлын да күзәтеп, безне дә рәхәтләнеп тыңлап бара. Туфан аганың ара-тирә:

— Шулаймы, Ришат, син бик кума! — дигәненә елмаеп кына башын селки дә:

— Ярый, Туфан абый, — дип куя...

— Туфан ага, куелган, басылган пьесаларыгызның барысын да укып, карап бардым бугай. Башыннан азагына кадәр туктаусыз елап утырганым, «Син бит минем бер генәм»...

— Китче, син шулай бик хисчәнмени?

— Ул пьеса минем әткәй турында бит. Аның яшь, егет чагы... Әткәйнең өйләнер алдыннан әнкәйгә үзенең мәхәббәтен аңлаткан кичерешләрен мин үземчә юрап утырдым. Әткәй 18 яше тулган көндә Днепр ярында ике аягын тездән югалта. Баку госпиталендә ике ел дәваланганнан соң, туган авылына кайтып төшә. Бер елдан күрше авыл кызы — булачак әнкәйне аңа димлиләр. Әнкәй артыннан йөрүчеләр дә була аңысы. Әткәй бу авылның Сабан туена килә. Яңа Кормаш авылында әткәй ягыннан да туганнар күп безнең... Менә шул Сабантуйда әткәй мәйдан уртасына чыгып, таякларын читкә атып, биеп күрсәтә. Әнкәйнең һушын ала...

— Минем өчен дә бик кадерле бу пьеса.

— Аның прототиплары бардыр бит?

— Бар, бар! Ничек кенә бар. Синең әтиең батырлыгын минем героиням кабатлый. Булачак иренә: «Аяксыз хатынга ник өйләнәсең?» — дигән сүзләрне әйтүләрен ишетә бу. Ишетә дә тегеләр капкасы турыннан үтеп көн озыны чишмәдән көянтә

белән су ташый. Протезлы кыз бала... Мин аларның тормышларын үз күзләрем белән күрдем... Алардагы чисталык!.. Бер-береңә хөрмәт!..

Туфан аганың тавышы калтыранып чыкты. Ни күрәм — аның да күзләре дымлы иде.

— Язганда да шулай чыланып язылды. Спектакль дә бик уңышлы чыкты... Кара, син бик хисчән икән, әйе...

— Рамил Төхвәтуллин көчле актёр. Ул төс-кыяфәте белән дә гел әткәйгә охшаган. Бу спектакльне үзе күрсә, нишләр иде икән, мәрхүм?

— Синең әнкәң дә чын герой шул. Яз шулар турында. Яздыңмы әле?

— Яздым. «Әнкәй» исемле поэмам алар турында.

— Укырмын әле...

— Минем әнкәй турында Сез дә яздыгыз. Сездән уздырып язып булмас.

«Әниләр һәм бәбиләр»дә Гөлфинә Ана — минем әнкәйнең күчермәсе. Анда да еларлык урыннар җитәрлек. Тик анда рәхәтләнеп елмаеп карап утырасың. Хәтта теге баласын имезмәгән хатын да әлләни нәфрәт уятмый. Алар Гөлфинә янында булгач, барыбер рәткә керерләр кебек... Хатын-кыз образлары Сезнең һәр пьесагызда бик көчле. «Ай булмаса, йолдыз бар» — дөнья новеллаларына торырлык. Мәдинәнең прототибы булмаса да ярар иде.

— Гөлфинә дә, Мәдинә дә алар инде җыелмарак образлар. Ләкин аларның да прототибы бар. Менә, мин белмәгән идем, әйе, син дә үз әниеңә охшаткансың бит. Мин бу пьесалар буенча бик күп хатлар да алдым, әйе... һәр пьесаның умырткасы драматик ситуациядә... Тормыш дигәнең гел драмадан гына тора... Дамира Кузаева, җаным, җанын биреп уйнады шул... Яшәү өчен көчле ихтыяр кирәк... Ул пьесаны Тинчурин театры куймакчы иде... Нигәдер ашыкмыйлар... Артистлары да бар югыйсә...

***

...Юл — эш урыны дигәннән, Язучылар берлеге рәисе булып сайлангач та республика авыллары, район, шәһәрләренә бару һич кенә дә кимемәде. Юкса базар шартларында авылларга мал-туар җыючылар, контрафакт товарларын авыл кешесенә төртергә яраклашкан алыпсатарлар гына килә.

Авыл клублары, авыл мәктәпләрендә тере язучылар, тере сәнгать әһелләре белән очрашулар бик тансыклаган иде. Шәһәр авылдан читләште... Шуңадырмы, авылның үзенең шәһәргә бик исе китми башлады.

Китап укучылар, матбугат алдыручылар саны елдан-ел кими. Бу телевидение, Интернетка гына бәйле түгел... Адәм баласы, авылда яшәсенме, шәһәрдәме, аңа тере язучы белән очрашу, артистның тере тавышын ишетү, тыңлау ихтыяҗы бетмәде... Авыл кешесенә дә, шәһәр кешесенә дә арзанлы товар, азык-төлек, ялган дарулар тәкъдим иткән кебек компьютерда клонлаштырылган җыр-көйләр, сериаллардан сипләнгән тамашалар, роман-повестьлар тәкъдим итүләренә эчке протестларын белдерепме, күпләре шул эшкә үзләре алына башладылар. Һәр төбәкнең үз композиторы, үз шагыйрьләре барлыкка килде. Алар ук төрледән-төрле корпоратив сандугачлары, тамадалары булып алдылар. Бу — массовый үзешчән сәнгатьнең әрнанадан калыккан буыны иде...

Һәркайда яңа йолдызлар пәйда булды. Яңа йолдызлар башта үз районнарында, аннары республика радиосын яулап алдылар... Тәүлегенә 24 сәгать «эшләп торучы» татар радиосында Бакырбаев, Юкәбаев, Фәләнбаевларның үзләре башкаруындагы «бүләкләре» яңгырап торды. Алар үзләренең иҗат кичәләрен, юбилейларын билгеләп үтәләр. Төрле юллар белән дәүләт бүләкләрен даулыйлар... алалар да... Интернетта үз порталларын ачып, «йолдызларның шәхси тормышларын» яраткан укучыларны, тамашачыларына җиткереп торалар...

Менә шундый шартларда халыкны әлеге балаләрдән коткарып калуны күздә тотып та юлга чыгалар иде Туфан ага һәм аның юлдашлары... Туфан ага үзе авыллардагы очрашуларга бик теләп йөрде. Кайсыдыр авылда, ниндидер башлангыч мәктәптә очрашуга чакырсалар да бара иде ул үз укучысы, үз тамашачысы янына. Уртак сәфәрләребез, шөкер, күп булды.

***

Туфан аганың үз иҗатына нинди җаваплылыкта каравын аның 70 яшен үткәрүгә әзерләнгән көннәрдә күреп тагын бер гаҗәпләндем, аның шәхесенең яңа якларын ачтым...

— Илфак, идарәдә мине халык язучысы исеменә тәкъдим итәргә җыенасыз икән, ташла бу уенны, мин каршы, — ди бу. — Сәбәбе бер генә: мин ул исемгә лаек түгел әлегә.

— Сез дә лаек булмагач, кем генә лаек соң аңа? — дип сорыйм аптырап.

— Бу олы, мактаулы исемне булдыру заманында минем үземнән дә чыккан иде, әйе, хәзер үкенәм, әйе!..

— Аңламадым, Туфан абый... Үткәнгә үкенеп яшәүдә мәгънә юк, бүгенге көненне, киләчәк көненне үкенүсез үткәрү турында уйла, — дип үзегез әйттегез түгелме соң?

— Мин халык язучысы, халык шагыйре исемен Әмирхан ага Еники, әйе, Хәсән Туфан, әйе, Илдар Юзеев кебек язучылар, шагыйрьләргә бирербез, дип уйлаган идем... Инде такмак язучылар да халыкныкы булып бетте. Вакламыйк әле бу олы исемне, әйе, — дип кызып китте бу.

— Андый югары исемне сорап та алмыйлар, ул исемнән баш та тартмыйлар... Идарә хөкеменә Сез берничек тә каршы килә алмыйсыз... Мактаулы исем Президент Указы белән бирелә, үзегез беләсез.

— Минем бүләкләрем җитәрлек. Кичәмә Президент килеп котласа, халык залны тутырып килсә — шул булыр бүләк. Әйт Зилә Вәлиевага да, мин үз сүземнән кайтмыйм, син мине үгетләп маташма, — ди бу.

Идарә утырышында исә тагын да үҗәтләнеп, бу мәсьәләне көн тәртибенә дә керттермәде:

— Идарәне ташлыйм да чыгып китәм, әйе, и бүтән кермим дә, әйе, — дип кызды.

Юбилей кичәсенә бер атна кала Зилә Вәлиева да телефоннан:

— Илфак, Туфан Абдуллович на самом деле «Халык язучысы» исеменнән баш тарта что ли? — дип сорады.

— Теше-тырнагы белән, — дим.

— Инде нишлибез, Сезнең представлениене күтәп тормадык. Президент Указына кул куелган. Кичәдә кыен хәлдә калмабызмы? — ди Зилә ханым чын-чынлап хафаланып.

— Президент үзе кичәдә катнашып, үзе тапшырса, тавышсыз гына үтәр, — дим, үзем дә ышанып бетмичә.

— Президент однозначно була. Йә, Аллага тапшырдык, үзе белмичә торсын иде...

Юбилей кичәсе зур тантана булып үтте. Минтимер Шәрипович Туфан аганың бөтен тормыш юлын, тормышына бәйләп иҗатын барлап чыкты... Хәзер, инде дистә ел вакыт узгач, уйлап куйдым: Президентыбыз Туфан Миңнуллин иҗаты буенча тамашачы алдында үзе дә имтихан тотты бугай. Ул, юбилярның дистәгә якын пьеса-спектакльләренә тукталып, геройларының исемнәрен, рольләрне башкарган артистларның исемнәрен атады... Геройларның сүзләрен, әйтем, афоризмнарын мисалга китерде. Соныннан: «Шулай яшәгәндә генә, шулай иҗат иткәндә генә Халык мәхәббәтен яулап була. Син инде, Туфан, үзеңнеке, гаиләңнеке генә түгел, Син бөтен татар халкыныкы. Бу — синең тәкъдирең. Халкыбыз исеменнән Рәхмәт Сина, Халкыбызның шундый улы булган өчен! — диде дә аның түшенә Республиканың югары орденын һәм без теләгән «Халык язучысы» билгесен такты...

Кичәдән соң чәй эчкәндә Туфан ага:

— Илфак, үз сүземне сүз иттем дисеңме? — диде.

— Туфан абый, бөтен претензияләренне — Президентка! — дидем мин.

— Ярар, хәерле булсын! — диде ул, инде булган хәлләр белән килешеп...

***

Туфан ага өчен алынмый торган крепостьлар юк иде. Ул теләсә нинди олы чиновникның күзенә карап үз фикерен, үз гозерен әйтә ала... Әйтә дә иде. Әмма сораныргa яратмый иде.

Казаныбызның 1000 еллыгы бәйрәме көннәре. Бәйсез дәүләтләр берлеге илләренең Саммиты узгач, Пирамидада Россия Президентының кабул итү мәҗлесендә безнең өстәлебез Башкортстан Президенты Мортаза Рәхимов һәм башка субъект җитәкчеләре Р.Аушев, Э.Россель, В.Аяцков, В.Маркушиннар өстәле белән янәшә туры килде. Мәҗлестә протокол буенча бердәнбер сүзне В.В.Путин гына әйтте дә, соңыннан сыйлану башланды. Ринат Тажетдинов, Абрек Абзгильдин, Рәшит Кәлимуллин, мин фәкыйрегез һәм Туфан ага олы кунакларны барлап утырабыз. Шунда кинәт кенә Туфаныбыз:

— Мин Рәхимовны «пешереп» киләм әле, нигә алар татар артистларын Башкортстанга кертмиләр, и нигә безнең пьесаларны башкорт театрлары куймый. Без бит аларныкын куябыз. Без бит бер халык, — дип сөйләнә-сөйләнә торып китмәсенме?..

Туфан ага Мортаза Рәхимовлар янына килеп җитүгә, алар кочаклашып күрештеләр дә, шунда ук тамашаны алып баручылар кунакларны, Пирамида балконына чыгып, Казан Кремле диварында күрсәтеләчәк пиротехника тамашасын, бәйрәм салютларын карарга чакырдылар. Туфан агаебыз белән Башкортстан Президенты кочаклашкан хәлдә балконга юнәлделәр.

Меңьеллык мәйданы йөзләрчә мең халык белән тулган. Казан Кремленә ут капкан диярсең. Салют артыннан салют... Кол Шәриф мәчете өстенә күктән йолдызлар яңгыры ява. Йөзләрчә мең халык «Ур-р-а-а» кычкырып бер-берсен котлый, тәбрикли. Салютлар балкышында Владимир Путин янәшәсендә Минтимер ага Шәймиев, Назарбаев, Примаковларның йөзләрен шәйләп алам... һәм Туфан ага белән Мортаза Рәхимовларның да йөзләре балкый: әллә һаман да кочаклашып торалар инде?!.

— Йә, Туфан, кирәген бирдеңме Мортазага? — дип бер дә шаяртмыйча сорады Ринат Тажетдинов.

— Аның бар кирәге дә үзе белән, әйе, юкка гына Президентмени ул? — диде Туфан ага.

Алар ни-нәрсәләр сөйләшкәндер, гомумән, нәрсә дә булса сөйләштеләр микән әле ул шау-шуда.

Туфан аганың кәефе күтәренке иде:

— Әйдәгез әле, ике Республиканың президентлары исәнлеге өчен бер күтәрик, — диде ул. Туфан сүзе сүз, без ана карусыз кушылдык.

Күрәсең, Мортаза Рәхимов белән дә сүзсез генә аңлашканнар булар.

Икенче көнне Владимир Путин катнашында узган киңәшмәдә Башкортстанда татар мәктәпләрен ябу, татарларга карата мөнәсәбәтләрдә шактый кискен тәнкыйть сүзләре ишетеп кайтып киткән Мортаза Рәхимов Туфан ага белән килешүләреннән чигенмәде. Ике-өч ай дигәндә Башкортстан театрларыннан Туфан ага Миннуллинга хатлар ява башлаган, «илчеләр» килгән. Шуннан Башкортстанның барлык театрларында диярлек аның пьесалары сәхнәгә менде... Шулай ук башка драматургларга да Башкортстан театрларының ишекләре киереп ачылды... Туфан ага ел саен Уфага, Туймазыга премьераларга йөри башлады. Үзе генә түгел. «Әниләр һәм бәбиләр» М.Гафури театрында куелгач, башкортча Гөлфинә ролен башкарырга Нәҗибә апа да барды.

Туфан ага кайчагында: «Мин бухгалтер булып эшләгән кеше, саный беләм, исәп-хисапны беләм — язучы булмасам да ачтан үлмәс идем, берәр колхозда бухгалтер булып та эшләр идем», — дип әйтергә ярата иде.

Язучы булмаса, кем булыр иде — анысын бер Алла үзе генә белә. Ә менә, һичшиксез, әйбәт кенә дипломат буласы икән бит Туфан агабыз. Татарның үз Чечериныммы, Примаковымы, Громыкосымы? Мөгаен, Громыкосыдыр. Андрей Андреевич Громыкога чит ил коллегалары «господин нет» кушаматы таккаңнар, дип ишеткәнем бар иде. Туфанның исә «господин нет»лыгы Татарстан Язучылар оешмасы белән Россия Язучылар оешмасы мөнәсәбәтләрендә бик ачык күренде.

Россия һәм Татарстан Язучылар берләшмаләренең оешу принциплары бер үк булса да, яшьләре төрлечә иде. Татарстан язучыларын 1934 елны берләштерәләр. РСФСР

Язучылар берлеге 24 ел сонарып, 1958 елны гына оешты. Иҗат берләшмәләренең оешу тарихына тирәнтен кереп тормастан, шуны да әйтү житә: алар Жир шарының алтыдан бер өлешен биләгән мәйданда өр-яңа җәмгыятьне төзүдә, аны саклап яшәтүдә, коммунистик тәгълиматны бар итүдә төп корал булдылар... «Урак белән чүкеч», «Штык белән каләм» массаларны берләштерүдә, аларның активлыгын уятуда чыннан да могжизалар тудырды. Урак-чүкеч өчен Стахановчы, сугышчылар өчен төзатар-мәргән Ворошиловчы мактаулы исемнәре һәм билгеләре, ә каләм ияләре, галимнәр өчен милләтләр атасының үз исеме белән — Сталин премияләре билгеләнде... Әлеге абруйлы исемнәрне, биеклекләрне яулау өчен һәркайсының үз матбугат чаралары — «коллектив оештыручысы» — газета-журналлары гамәлгә куелды. Эшче, крестьян хәбәрчеләреннән алып, барлык каләм ияләре — зур әдипләр бердәнбер хак идеология өчен хезмәт итәргә тиешләр иде.

СССРдагы яңа җәмгыять «искене тулысынча җимереп» төзелгән «өр-яңа җәмгыять» булса да, аның төп асылы — империячел асылы искедән — Россиядән калган булып чыкты... СССР Язучылар союзы дәүләт эчендәге дәүләт, империя эчендәге империя иде...

«Дошман бирелми икән — аны юк итәләр!» дигән афоризм-лозунг СССР Язучылар берлеген төзүче баш архитектор, Казан пешекчесе, бөтен дөнья пролетариатының атаклы әдибе Максим Горький авызыннан әйтелде... Яңаны төзүчеләр дошманнарын читтән дә, үз иле халкыннан да эзләделәр, таптылар һәм юк иттеләр. Бигрәк тә милли республикаларның зыялылары арасыннан табылды дошманнар. Икенче бөтендөнья сугышы афәте кабынгач, СССР сугыш мәйданына әверелде.

Сугышның беренче елында ук Татарстанның бөтен каләм ияләре фронтка җибәрелде. Аларның 34е яу кырында, әсирлектә һәлак булса, калганнары сугыш яралары, имгәнүләреннән вакытсыз дөнья куйдылар... Сугышта Рәсәй язучылары да катнашты анысы. Әмма алар арасында Җәлилләре, Алишлары, Кәримнәре, Кутуйлары, Баяннары, Мөҗәйләре юк иде... Сугыш башлануга, СССР Язучылар союзы Татарстанга, Чистай шәһәренә күчерелде. Үзебезнекеләр исә, әйтелгәнчә, «үзләре теләп» фронтка киттеләр. Болар һәркем өчен мәгълүм... Алай дисәң, китаптан бизенеп Интернетка чумган яңа буын өчен билгелеме һәм әһәмиятлеме икән бу белешмәләр...

СССР, РСФСР Язучылар берлегенең милли республика иҗатчыларына булган мөнәсәбәте — дәүләтнең милли азчылыгына булган мөнәсәбәтләренең чагылышы иде, әлбәттә... Өлкән агайның күзе күп күрә, колагы күп ишетә. Шул шартларда да милли республикаларның иҗатчылары, шул исәптән татар язучылары мең еллык әдәбиятыбыз, сәнгатебезнең йөзен, кыйбласын саклап калдылар...

Инде бүгенге вазгыятькә һәм мөнәсәбәтләргә әйләнеп кайтыйк. Узган гасырның азагында СССР дәүләте таркалуга, аның Язучылар берлеге дә яшәүдән туктый. Аның урынына бәйсез дәүләтләр Язучылар берлекләре һәм Татарстан Язучылар берлеге үзара килешенеп Язучылар оешмаларының Халыкара ассоциацияләрен төзиләр — урысчалап әйткәндә, Международное сообщество писательских союзов — МСПС төзелә. Аның рәисе итеп күп еллар Россия Язучылар берлеге рәисе булып эшләгән, СССР һәм Россия дәүләтенә 3 гимн тексты язып биргән, «Дядя Стёпа» поэмасының авторы Сергей Владимирович Михалков сайлана. Россия Язучылар берлеге үзе дә дүрт оешмага бүленеп, һәркайсы мөстәкыйль рәвештә МСПС составына керә... Ә Россия составындагы барлык милли республикалар өлкә, край оешмалары элеккечә Россия Язучылар берлегендә кала.

Россия дәүләте белән вәкаләтләрне бүлешү турында килешү төзегән, мөстәкыйльлеккә омтылган Татарстан Республикасының Язучылар берлеге дә Россия Язучылар берлеге белән шундый ук договорны төзи. Ул договор 1994 елда имзалана.

Илләге вазгыять 2000 елдан соң элеккеге эзенә төшә башлый. Мөстәкыйль кануннар кабул иткән Татарстан бөтен кануннарын Россиянекенә яраклаштырып үзгәртүгә күчә. Россия Язучылар берлеге белән төзелгән килешү дә кәгазьдә генә калып, хезмәттәшлек бөтенләй туктала. Татарстан язучылары үз казанында кай-

ный... Россия Язучылары оешмасы исә дәүләт структураларының читләшеп, Православие чиркәве белән якынаеп, аның белән хезмәттәшлеккә күчә. Менә шундый хәлләр.


*Муса Җәлилнең кызы Чулпан ханым белән. 25 август, 2011 ел.*

Россия һәм Татарстан Язучылары берлеген берникадәр бәйләп торучы МСПС һәм Россия әдәби фондлары да таланып таралып бетү чигенә җитә. МСПС әдәби фондының Россия әдәби фонды белән кушылуы аркасында бу бәйләнеш тәмам тукталa. Болай да исемдә генә булган Татарстан әдәби фонды бөтенләй эшләүдән туктый.

Без үз чиратыбызда бу бәйләнешләрне югалтмау өчен аерым тырышлыклар да куеп карадык. МСПС әдәби фонды Россиянеке белән берләштерелгәч, без дә ул фондка керергә ризалаштык. Безне фондка теркәделәр, әмма аның финанс чыгымнары исәбенә штатлар тоту, чаралар үткәрү, язучыларның социаль-көнкүреше өчен финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарттылар... Моның өчен, яна устав буенча, Татарстан Язучылар оешмасының Россия Язучылар оешмасында торуы шарт икән...

МСПС белән берникадәр элемтәләр калды әле. Безнең тәкъдим белән дисәк тә була, МСПС үзенең әдәби басмасын — «Литературная Россия» газетасын булдырды. Халыкара әдәби мохиткә керүнең бер юлы буларак, без ул газета белән эшлекле элемтәләр урнаштырдык. Татар язучыларының тәрҗемәдәге иҗат үрнәкләре бу басмада күренә башлады. МСПС шулай ук «Гасырдан гасырга» сериясе белән милли шигърият үрнәкләреннән рус һәм милли телләрдәге антологияләрен чыгарырга алынды. Татарстан шагыйрьләреннән антологиясе 117 шагыйрьнең иҗат үрнәкләре тупланган иң саллы басма булды.

Яшь иҗатчылар белән семинарлар үткәрүгә дә алынды МСПС. Әмма монарчы бөтен эшчәнлеген МСПС әдәби фонды ярдәмендә алып барган халыкара оешманың эше алга таба бик сүлпәнләнде. Чөнки Россия әдәби фонды инде ана үз өлешен тиешенчә бирми башлады, һәм, әйтергә кирәк, 70 ел буе СССРның барлык әдәбиятчылары хәерендә, химаячелегендә тупланган байлыкны талау, таркату өр-яңадан башланды; милли республикаларның язучылары тагы да ярык тагарак янында утырып калдылар.

Әлбәттә, талану-таркалуда каләм ияләренең үзләренең гаепләре, сүлпән эшчәнлеге, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә битарафлыгы, социаль-иҗтимагый активлыклары кимүе дә тискәре йогынтысын ясамый калмады. Мондый шартларда дәүләт эчендә дәүләт, империя эчендә империя булган язучылар оешмасы, әйткәнебезчә, үз-үзен саклап кала алмады. Үз-үзен саклап калу һәркемнең үз эше, суга батучыны суга батучы үзе генә коткара ала иде.

Бу турыда бертуктаусыз сәгатьләр буе сөйләп була, бу хакта томнар-томнар язып өяргә була. Озын сүзнең кыскасы, үзәк регион-төбәкләр өчен бернәрсә дә бирмәгәндә дә, аларны үз тирәсенә туплауны тели, таләп итә. Ә төбәкләр үзәктән әллә ни таммаса да, барыбер, дөнья үзгәрер, элеккечә үк булмаса да, тәртипләр кире кайтыр, дип өметләнә иделәр... «Өметсез шайтан гына», диләр. Әлегә Россия Язучылар оешмасы үзе өч оешмага бүленеп һәм Татарстан үзал булып көн итә бирә. Үзал булу өчен, әлбәттә, Республиканың дәүләти кайгыртуы кирәк шул. Татарстаныбыз, шөкер, төшеп калганнардан булмады... Язучыларның

китапларын бастыру, милли әдәби басмаларны дәүләт исәбенә чыгару элеккечә үк калды. Республикабыз барлык иҗат оешмаларына Мәдәният министрлыгы аша субсидияләр, грантлар бирүен дәвам итә.

Менә шундый шартларда очны-очка ялгап, яшәп — көн итеп, иҗат итеп ятканда, Россия Язучылар берлеге үзенең оешуына 50 ел тулуын һәм чираттагы съездны үткәрүне игълан итте. Съездга һәр төбәктән 2-3 делегат сайланырга тиеш иде... Татарстан Язучылар берлеге идарәсе дә алды бу чакыруны. «Съездга делегатлар җибәрегез, без киләчәктә бер-бердәм оешма булабыз», дигән чакыру, таләп иде ул.

Әлеге мәсьәләне Республика Язучылар берлеге идарәсе махсус өч утырыш җыеп тикшерде. Ягъни, без нишлибез, Россия Язучылар берлегенә керәбезме, әллә үзал калабызмы? Мин Республика Язучылар берлеге рәисе буларак, Россия Язучылар берлеге белән бердәм кушылырга каршы түгеллегемне әйттем. Монын өчен үземнең дәлилләремне дә житкердем.

Б е р е н ч е д ә н: Россия Язучылар берлегендә әүвәлге кебек кырыс вертикаль тәртипләр юк. Бүгенге көндә аларның мәҗбүр итә торган иҗат принциплары, ниндидер бердәнбер идеологиягә буйсындырылган карарлары юк һәм була да алмый.

И к е н ч е д ә н: Россия Язучылар берлеге һәм Россия әдәби фонды бердәм структурага әверелде. Хәзер Россия хөкүмәтенең максатчан Программаларга билгеләнгән финанс бүлүләре һәм грантлар шул оешма һәм фондлар аша алып барыла, һәм, әйтергә кирәк, соңгы елларда ул грантларның саны һәм күләме шактый зур. Ул грантлар Россия Язучылар оешмасы белән килештереп кенә бирелә. Россия Язучылар берлеге һәм әдәби премияләре дә фәкать Россия Язучылар берлеге составындагылар өчен генә. Мөмкинлектән Башкортстан, Якутия, Төньяк Кавказ республикаларының иҗат оешмалары файда күрә башлады... Бу фондлар, грантлар салымны иң күп түләүче Татарстан Республикасы химаясеннән да тупланган бит... Нигә без үз әҗеребезне алмаска тиеш?

Ө ч е н ч е д ә н: Россия Язучылар берлеге халыкара аралашу, хезмәттәшлекне яңартып җибәрде. Европа, Азия, дөньякүләм әһәмияткә ия форумнарга Алтай, Адыгей, Якутия, Чувашия кебек кеп-кечкенә Язучылар берлекләре вәкилләре дә чакырыла башлады.

Д ү р т е н ч е д ә н: Бөтендөнья әдәби мохитенә керү өчен барыбер дә рус теленә тәржемәләр хәл иткеч урын алып тора. Әйткәнемчә, Россия Язучылар оешмасы аша билгеләнгән грантларның шактые тәрҗемә буенча да...

Бәхәсләр уятты бу чакыру дигәннәре. Идарә әгъзаләренең фикерләре капма-каршы һәм үзгәрүчән иде... Барыбызның да: «Юк!» — дип әйттерерлек сәбәпләр дә бар. Бигрәк тә дәүләтнең мәктәпләрдә белем бирү буенча яңа бердәм дәүләт стандартларын кабул итү һәм мәктәпләрдә милли компонентларны юкка чыгару иде. Россия Язучылар берлеге бу уңайдан бер сүз дә әйтмәде... Ана теле укытылмагач, әдәбиятка милли язучыларның яңа буыны килмәячәге көн кебек ачык бит инде. Гомумән, «Россия Язучылары оешмасы бу мәсьәләләрдә гел дә борчылмый!» — диючеләр — без — барыбыз да хаклы идек. Әмма без үз сүзебезне аларга ничек ирештерик? Хатлар, телеграммалар, белдерүләр җибәрикме? Бүрәнә аркылы бүре куыпмы?

Бу фикерләрне әйтүчеләр: «Россия Язучылары съездын трибуна буларак файдалану өчен булса да куллану кирәк», — диделәр.

Әлеге мәсьәлә, әлбәттә, Туфан аганы да борчый иде.

— Мин Россия Язучылар оешмасыннан бер генә өметле эш тә көтмим. Әмма аларның съездында катнашып, бер тузынып кайтсаң ярар иде, әйе. Ниләр сөйләрләр икән? Аларга милли әдәбиятлар элек тә кирәкмәде, әйе, хәзер тем паче кирәкми, әйе...

Бәхәсләр күп булды. Өчәр сәгатькә сузылган утырышта бер генә идарә әгъзасы да авызына су кабып утырмады... Ахырда: Россия Язучылар съездына «кунак булып» барырга дигән фикер хупланды. Анда «кунак булып» баручыларга «Милли мәктәпләр һәм милли мәдәниятләр» мәсьәләсен бөтен чынбарлыгын күтәреп

чыгыш ясау шарт итеп куелды. «Кунаклар» өчәү идек: Туфан ага Миннуллин, Нәбирә Гыйматдинова һәм Берлек рәисе буларак мин үзем... Юлга чыгарга 2 көн кала Нәбирәбез «каты авырып» китү сәбәпле, Мәскәүгә без Туфан ага белән икәү генә кузгалдык...

***

Россия Язучылар оешмасынын юбилейлы съезды Комсомольская урамы, 13 нче йорттагы бинасында үтәчәген чакыру кәгазеннән белә идек... Безне ишектән вахтёр азәрбайжанлы ачып кертте... Анын урыс кешесе түгеллеге төс-кыяфәтеннән үк күренеп тора... Керә-керешкә Туфан ага үзебезчә ана:

— Нихәл? — диде.

— Хуш киләсенез! — дип җавапланды өммәттәшебез.

Икенче катка күтәреләбез. Текә баскычларның як-як диварлары зур булмаган иконалар белән чуарланган... Иртәнге поездан туп-туры бирегә килүчеләр без генә түгел икән. Күпчелек төбәкләрдән кичтән үк килгәннәрне Переделкинога кунарга алып киткәннәр. Болары исә безнен хәлдәшләр иде.

Иртәнге чәйсез генә съезд башлануын көтәргә мәҗбүр идек... Менә бермәл шау-шу купты. Переделкинодан ике автобуска төялеп чын делегатлар килеп җиткән икән...

Күпчелеге өлкән яшьтәгеләр. Туфан ага:

— Иллә мәгәр урыс үзенә хас исем-атаманы таба белә инде. СССР Язучылар берлегенен дистәләгән иҗат йортларыннан берданбер «Переделкино» калды. Аны да переделить итеп бетерсәләр, бүләргә берниләре дә калмый, — дип каһкаһәләп көлеп алды.

— Анын каравы вахтада үзебезнекеләр. Матур итеп сорасак, бер чынаяк чәй дә биргән булыр иде... Без кунак кына булгач, тыйнаклык сакларга туры килер, — дим мин үз чиратымда. Шунда янәбызга Мөдәррис Әгъләмов кебек җыйнак кына гәүдәле бер урыс язучысы килеп басты:

— О Туфан, дорогой! Сколько зим! — дип, Туфан аганы кочаклап алды. — С приездом, дип тагын берсе килеп асылынды...

Баксан, аны белмәгән делегатлар юк бугай. Кайсы кочаклап, кайсы кулга-кул бирешеп исәнләштеләр үзе белән.

— Вот, пригласили... Настоящий русский писатель Владимир Личутин, это — наш председатель Союза, — дип, аларны — минем белән, мине алар белән таныштыра башлады Туфан ага.

Шуннан китте, кочаклашулар, күрешүләр... Мин үз чиратымда яшьрәк дип саналганнар белән, милли республикалардан килгәннәре белән таныштырдым үзен...

Мине Россия Язучылар берлегенен секретариаты бүлмәсенә дәшеп алдылар. Рәиснен беренче урынбасары Геннадий Иванов:

— Илфак Мирзаевич, нужны паспортные данные Туфана Миннуллина и Ваши. Мы хотим избрать Миннуллина секретарём Союза писателей РФ, а Вас просим войти в состав исполкома, — диде. Мин үз чиратымда:

— Без, Татарстан язучылары, съездга делегатлар булып түгел, ә кунаклар буларак катнашабыз, — дидем.

— Как же так? Съезд собирается один раз в пять лет. Значит, мы опять разделены что ли?

— Быть избранным — не сама цель... Пока нам не дали такое полномочие, — дим.

— Мы дадим, — ди Иванов һәм без залга узабыз.

***

Залга кереп утыргач та алдагы рәттән борылып күрешүчеләр, арттагы рәттән җилкәсенә кул куеп:

— Привет, Миннуллин, — диючеләр күп иде.

— Менә бит урыслар безне ничек яраталар, — дим ана. — Сезне — Союзнын

секретариатына, мине башкарма комитетка тәкъдим итмәкчеләр. Без делегатлар түгел, — дидем.

— Урыс язучыларының хәле безнекеннән дә авыр. Мин бит урысны гаепләмим... Әнә, Владимир Карпов СССР Язучылар союзы рәисе булганда милли язучылар өчен, бигрәк тә безнең Татарстан өчен нидер эшләргә тырышты. Ана да ирек бирмәделәр. Мин урыс дәүләтенең великороссларын гаеплим... Күрмисеңмени, Язучылар союзы бинасыннан чиркәү ясап бетергәннәр. Дин өчен чиркәү, мәчет бар, әйе. Тамаша өчен театр бар, белем алу өчен мәктәп, институтлар бар... Элек съездлар Колонналы залларда үтә иде. Болар тынчу залда, каты урындыкларга утырттылар безне.

Чыннан да, зал съезд кадәр съезд үткәрү өчен кысан иде. Президиум өчен куелган кызыл җәймә җәелгән озын өстәл артына бер рәт булып унбишләп кеше бер-берсенә тыгызланып утырганнар иде.

Ниһаять, башланды съезд эше. Докладчы — рәис Валерий Николаевич Ганичев... Докладчының кереш сүзе котлау телеграммаларын укудан башланды. Иң беренче котлау хаты, әлбәттә, бөтенроссия православие чиркәве архиепископыныкы иде.

Котлаулардан соң докладчыбыз Россия Язучылар берлеге бинасының язучыларныкы булмавын, ә арендага алып файдалануларын әйтте. Шуңа ишек алдындагы мәйданнарны азәрбайҗан эшмәкәрләренә субарендага биреп торулары икән. Аннан кергән акчалар гына җитмәгәнлектән, коммуналь чыгымнар өчен 20 миллион әҗәткә баткан булганнар. Сергей Филатов җитәкләгән фонд съезд алдыннан бу бурычларны түләү өчен дә, съездны үткәрү өчен дә җитәрлек акча биргән икән... Делегатлар дәррәү кул чабып алдылар...

Докладчы сүзен дәвам итеп, мандат комиссиясе вазифаларына кереп, делегатлар турында белешмәләр җиткерде һәм:

— Мы рады, что с нами на съезде после пятнадцатилетнего перерыва присутствуют делегаты из Республики Татарстан, — диде. Аның бу хәбәренә дә кул чабып алдылар...

Без Туфан ага белән бер-беребезгә карашып алдык. «Бу кайсыбызның эше, янәсе?»

Валерий Николаевич үз докладында Язучылар берлегенең иҗат процессын оештыру, китаплар бастыру, каләм хакларын түләү, язучыларның көнкүрешен кайгырту турында сөйләүне кирәк тапмады... Шулай да ул регионнарда Язучылар оешмаларының эшләре өчен аларга рәхмәт сүзен әйтте. Башкортстан, Санкт-Петербург, Төньяк Кавказ республикалары Язучылар оешмаларының эшенә унай бәя биреп, докладын тәмамлады.

— Син безнең съездда шундый доклад сөйләсәң, нишләтәләр инде сине? — дип, үртәлеп утыра башлады Туфан ага.

Ревкомиссия отчёты да бик кыска булды. Фикер алышулар башланды. Өченче булып Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Равил Бикбаев чыгыш ясады. Ул үз эшләре турында сөйләгәндә, әлбәттә, күпләр аңардан көнләшеп тә утыргандыр.

Равил Бикбаев сөйләгәндә, мин съезд президиумына «сүз сорап» хатымны язып җибәрдем. Бикбаевтан соң чыгыш ясаучыга сүз биргәндә, В.Ганичев: «Следующим готовиться председателю Союза писателей Татарстана Ибрагимову», — диде.

Мин трибунадан Татарстан язучыларының кайнар сәламнәрен җиткердем дә, үзебезнең делегат булып түгел, ә Украина, Белоруссия, Казакъстаннан килгән каләмдәшләребез кебек съездда кунак буларак катнашуыбызны искәрттем. Зал тынып калды. Татарстан Язучылар берлеге һәм, гомумән, республикабыздагы иҗат оешмаларын дәүләтнең кайгыртуын, әдәби журналларның, китап нәшриятенең тулысынча хөкүмәт тарафыннан финанслануын, әдәбиятка яшь иҗатчыларның килүен кыскача гына сөйләп биргәннән соң, Россия Язучылар берлеге һәм төбәкләрнең иҗат берлекләре белән хезмәттәшлеге турында үзебезнең карашларны аңлатурга күчтем.

— Россия Язучылар берлегенең эшчәнлегендә кырыс вертикаль идарә принциплары куелмавы безгә киләчәктә, һичшиксез, бергә булу өчен төп шарт булып тора. Әмма Россия язучылары бүген 3-4 оешмага бүленгән һәм аларның берсе



*...Туфан ага үзе очрашуларга бик теләп йөрде. Кайсыдыр авылда, ниндидер башлангыч мәктәптә очрашуга чакырсалар да, бара иде ул үз укучысы, үз тамашачысы янына...*

дә милли әдәбиятларны саклап калу һәм үстерүне үзләренең төп эшләренә санамыйлар. Әгәр һәр милләт кешесе үз ана телендә белем ала алмый икән, бу милләтнең, әдәбиятның киләчәге юк. Хәтта бу милли әдәбиятның тарихы меңнәрчә еллар белән исәпләнсә дә, милли мәгарифе булмаса, бу милләтне фәкать инкыйраз гына көтә.

Безнең Татарстанда һәр милләт кешесенә үз ана телендә белем алу мөмкинлекләре тудырылган... Безнең республика Язучылар берлегендә рус әдәбияты һәм әдәби тәрҗемәләр секцияләре эшли... Бүген Россия берлеге иң әүвәл шуны үзенең төп эше дип игълан итәргә һәм милли әдәбиятларның иминлеген гарантияләргә тиеш. Татарстан Язучылар берлеге бүген МСПС составында... Без бүлгәләнгән бер оешманың бер бүлекчәсе булырга риза түгел, — дидем. Зал тынлый иде. — Россия күләмендә әдәби багланышлар, әдәби тәрҗемәләрне оештыру ни өчен беркем вәкаләтендә дә түгел?.. Татарстан Язучылар берлеге Россия Язучылар берлеге составында тормаганда да, без, Идел буе федераль округында андый хезмәттәшлекне оештырабыз. Иң тыгыз элемтәләр, әлбәттә, Башкортстан язучылары белән. Узган ел Казанда федераль округка кергән 6 республика язучылары катнашында әдәби тәрҗемәләр буенча зур конференция үткәрдек. Берләшү өчен шундый бердәм чараларны үткәрү зарур. Киләчәктә шундый чараларны үзәктән бүленгән финанслауга таянып үткәрәсебез килә... Бит барыбыз да салымнарны үзәккә түлибез...

Россия Язучылар берлеге, берләштерүче үзәк буларак, бөтен Ил күләмендә әдәбиятчыларның социаль статусын билгеләүне дә кайгыртырга тиеш. Моның өчен «Иҗат берлекләре» турында әр-яна федераль закон кирәк.

Бүген Мәскәүдәге үзәк матбугат басмалары төбәк язучыларының әдәби әсәрләрен бастырырга бер дә атлыгып тормыйлар. Аның өчен түләү кирәк икән. Әйдәгез, Язучылар берлегенең үз әдәби басмасын булдырыйк. Дәүләт финанслары җитмәсә, регионнарның взносларын кертик, — дидем.

— Всё о чём вы говорите, это очень важно! — диде Валерий Ганичев, минем чыгышым тәмамлануга. Всё это хорошо, но всё это достигается общими усилиями. Со стороны регионов должны быть встречные действия... Мы надеялись, что Татарстан после длительного перерыва снова будет вместе с нами. Вот ведь как получается. Спасибо за выступление! — диде.

Шактый гына кул чабуларны кузгатып, урыныма килеп утыруга, Туфан агам:

— Син барыбер дә җибеттең әле, Илфак, — диде.

— Кире менеп, барысын да кыйнап төшимме, Туфан абый? — дим, бераз үпкәләп.

— Алар сугышырга синең белән миннән остарак, әйе. Алар сугышудан рәхәт таба торган халык, әйе. Аларның кайсы бәйрәме сугышсыз үтә...

Агаебыз күен кесәсеннән зур гына блокнотын тартып чыгарды да эре хәрефләр белән тиз-тиз яза башлады. Батырып ноктасын куеп, кәгазен икегә бөкләп, президиумга җибәрде. Хаты тиз барып җитте тагы... Ганичев аның хатын укуга аягүрә басты...

Трибунадагы чыгыш ясаучы рәис регламентны кисәтә дип кабул итте ахрысы:

— Заканчиваю, спасибо за внимание, — дип, трибунадан төшеп китте.

Валерий Николаевич баскан килеш залны «актара» башлады. Туфан аганы эзли иде ул.

— Тут писатель из Татарстана Туфан Миннуллин направил записку и спрашивает: Как я отношусь к Федеральному Закону № 309 — это об образовательных стандартах... Как я могу относиться?.. Я так скажу... — Валерий Николаевичка бик үк унайлы түгел иде бу сорау... — Я прямо скажу, это антинародный закон! — диде урыс агаебыз!

Ике йөз кешелек зал бертын гына тын торды да Ганичевнын җавабын чынчынлап алкышларга күмде.

— Как я могу хорошо относиться тому, что совсем исключает сдачи ЕГЭ по русской литературе, — дип йомгаклады сүзен рәис. Залдагылар анын җавабынын икенче өлешен ишетмәделәр дә бугай. Шау-шу купты, үзара сөйләшүләр, бәхәсләшүләр китте. Ниһаять, Ганичев залны тынычландырып, сүзне Карачай-Черкес республикасыннан килгән профессор ханымга бирде. Апаебыз беренче сүзен:

— Да, это — антинародный закон, а Фурсенко — антинародный министр! — дип башлады. Ул да, башкалар да язучыларнын социаль статусын билгеләүче яңа закон, милли мәктәпләрдә ана телендә укытуны гарантияләүче закон кирәк, дип, чыгыш ясадылар. Урыс язучылары да ЕГЭда, һичшиксез, урыс әдәбиятыннан имтихан булырга тиеш, диделәр. Ганичевнын үзен дә тәнкыйтьләүчеләр табылды.

Ниһаять, төшке ашка тәнәфес игълан ителеп, безне ярым подвалдагы залга чакырдылар. Озын-озын өстәлләрдәге салкын кабымлыклар, бер кулланышка исәпләнгән полиэтилен стакан, кашык-чәнечкеләр күреп, Туфан ага:

— Әллә шушымы обедлары? Без иртәдән бер ризык капкан кеше түгел, — диде гаҗәпләнеп. — Әйдә, Илфак, берәр кафега барып кешечә ашап килик. Кара инде, син шулар белән бергә булырга каршы түгел, дисен. Син безнең съездда шундый әбәд әзерләсән, нишләтәләр инде Сине? — дип, үртәлүен чыгарып, бер үк вакытта мине үчекләп алды...

— Обедларын ташка үлчим. Анын каравы без аларга съездда чәйнәргә азык бирдек... Кара әле, Кавказлар, Якутлар ничек бөтереп алды компонентлар мәсьәләсен?!

Без әйләнеп керүгә, съезднын икенче утырышы башланган иде... Президиумнан төшеп, Геннадий Иванов безнең уртабызга килеп утырды да:

— Вот ведь, ваше присутствие, ваши выступления так не хватают здесь... Сейчас начнутся выборы председателя и исполкома Союза писателей России. Мы очень хотим, чтоб вы приняли участие в выборах и сами вошли в руководящие органы.

Туфан ага тыныч кына, әмма бик анлаешлы итеп:

— Я пока воздержусь, Илфак Мирзаевич пусть сам решает за себя, — диде...

— Мы очень надеемся на тесное сотрудничество, — дидем мин үз чиратымда. — Войти в состав не обязательно именно на съезде. Мы у себя ещё раз посоветуемся... А главное — хотим видеть хоть маленькие результаты наших сегодняшних предложений, — дидем.

— Жаль, ой как жаль. Ведь нет больше такой сильной организации как Ваше... Мы бы горы свернули вместе, — дип сөйләнә-сөйләнә үз тарафына юнәлде Иванов...

— Кәнишне, жәлке урыслар. Әзергә-бәзер яшәделәр дә... Яһүдләр бөтенесен үз кулларына алып бетерделәр. Болар һаман да зарланудан узалмыйлар. Йә, кая боларнын яшьләре? Ник кумыйлар бу карт коммунист-попларны? Теләсә нишләсеннәр, мин болар белән бер кашыктан ашамыйм, — диде Туфан ага. — Килдек, күрдек, үз сүзебезне әйттек! Син мина ачуланма баягы сүз өчен. Син башта аларга отчёт биргән кебек тоелдын, әйе... Ә син аларга: «Без Сездән башка да әйбәт кенә яшәп, иҗат итеп ятабыз!» — дигән фикер житкердең. Дөресе дә шулай бит!.. Чыгышын бик әйбәт булды, анлаган кешегә, — дип йомгаклады сүзен.

***

Иҗат берлекләренең киләчәк язмышы әлегәчә билгесезлектә кала... Иллә вазгыять ничек кенә үзгәрсә дә, иҗатчыларның бер түбә астына җыелу ихтыяҗы калачак инде... Әнә, аерым төбәкләрдә, әйтик, Себер, Ерак Көнчыгыш төбәкләрендә, Төньяк Кавказ, Балтыйк буе язучыларының аерым ассоциацияләре төзелгәнен ишетеп беләбез. Идел буе — Урал регионы язучыларының аерым юнәлешләр буенча конгрессларын төзү фикерләрен әйтүчеләр булды... Хәтта бөтендөнья татар конгрессы үрнәгендә Бөтендөнья Татар Язучылары оешмасы төзергә теләүчеләр дә юк түгел.

Әдәби процесс аерым шәхеснең иҗади эше генә түгел күрәсең... Россия күләмендә тарихи темаларга язучыларның үз ассоциациясен Александр Сегин дигән әдип оештырды... Үзе — «Аксак тимер», «Куликово кыры» һ.б. романнар авторы. «Куликово кыры»н экранлаштырулары турында ишеткәч — бер очрашуыбызда мин аннардан:

— Александр Юрьевич, как можно снимать исторический фильм о том, в истории событий которого очень много белых пятен... Всё таки было ли сражение? — дигән сорау куйдым. Ул җавабында:

— Минем романымда Куликово сугышына кадәрге вакыйгалар сурәтләнә... Роман ике гаскәрнең капма-каршы тезелеп басулары, алгы планга Пересвет белән Челубейның чыгып барулары белән тәмамлана... Ә бу ике баһадир бер-берсен малай чакларыннан ук белеп, бергә уйнап үскәннәр икән... Җәмгыятьтәге хәлләр аларны капма-каршы бастырган...

— Бу хәлләр чыннан да тарихта булганмы соң, нинди документлар бар? — дигән соравыма Александр Юрьевич:

— Тарихта Мамай белән Дмитрий, Пересвет белән Челубей исемнәре бар... Ә нәфис роман өчен шулары җитә... Мин романымда аларны сугыштырмыйм. Капма-каршы бастырам... Капма-каршы басып тору — ул мәңгелек тема. Ул безнең чынбарлыгыбыз, — дигән иде.

Мин аңа:

— Әйдәгез, Сезнең оешмага Татарстаннан тарихи темага язучыларны да кертик, бу мәңгелек теманы үзара өйрәник! — дигән фикеремә ул:

— Мин риза... Сездә бармы тарихи темага язучылар? — дип сорады.

Мин аңа:

— Бездә тарих институты бар. Бездә һәр галим — язучы, — дидем... Ни кызганыч, сүзебез сүздән узмады... Уйлап карасаң, кирәк, бик кирәк бит бүген андый очрашулар, андый оешмалар, бүлекләр.

Төрки телле әдәбиятларны берләштерүче Аурасия Язучылар оешмасын Төркиядә Якуп Демироглы оештырды. Бу оешма, төрки телле мәдәниятләрне берләштерүче «ТЮРКСОЙ» халыкара оешмасы белән, димәк, турыдан-туры дәүләтләр төзегән оешма белән тыгыз бәйләнештә тора. Алар да «Кардәш әдәбиятлар» исемле әдәби журнал булдырды. Татарстан Язучылар берлеге белән бик теләп хезмәттәшлектә алар...

Туфан ага Миңнуллин Татарстанда «Халыкара Пен-клуб» дип аталган, Бөтендөньяда каләм ияләренең хокукларын яклый торган оешманың бүлекчәсен төзүдә башлап йөрде. Ул оешманың җитәкчесе булды. Дөнья күләмендә дәүләт структураларына оппозициядә торган бу оешмага Республикабызда бик лояль караш формалашты. Хәтта аларга матди ярдәм дә күрсәтелде һәм күрсәтелеп килә. Бу инде фәкать Туфан аганың шәхесенә булган мөнәсәбәттән шулай икәнен республика «Пен»чылары аңлыйлар...

Республикабыз «Пен»чылары бүген дә халыкара форумнарда катнашалар. Татар әдәбияты-мәдәниятен дөньяга танытуда үзләренең өлешләрен кертәләр.

Ачыктан-ачык әйтү зарур: Туфан ага «Пен-клуб»ның милли әдәбиятларның язмышын хәл итәрдәй оешма түгеллеген белде һәм үзе дә:

— Безгә ничек тә үзебезнең иҗат берлеген сакларга кирәк... Милли җанлы җитәкчеләребез барда аларның ярдәме белән ныгып, үз аягыбызда басып торырга кирәк, әйе, алда ни киләсен бер Алла белә... Дөнья ул бер алдын, бер артын күрсәтә. Яшьләрне балалыктан җәһәтрәк чыгарасы иде, — дия иде.

***

Туфан Ага турында сәгатьләр, көннәр буе сөйләп булыр иде... Үзенең соңгы иҗат кичәсендә:

— Инде күп яшәлде, күп эшләнде... Чемоданны җыя башларга да вакыт, — дип әйтүе барыбызны да сискәндереп җибәргәне бүгенгедәй хәтердә. Нишлисең, килү-китү дөньясы шуннан гыйбарәт бит. Язмамны олуг әдибебезне мәңгелеккә озатканда сөйләгән сүзләрем белән тәмамларга булдым...

*Бүген бөтен татар халкы үзенең затлы улын, бөек язучысын соңгы юлга озата.*

*Бу кадәрле сагышлы матәм, мөгаен, моннан 99 ел элек Габдулла Тукайны озатканда гына булгандыр!*

*Туфан ага Тукай һәм Туфан иҗатына мөкиббән иде. Аңар Тукай турылыгы, Тукай тапкырлыгы, Туфан үҗәтлеге, Туфан олпатлыгы хас иде!!!*

*Туфан ага Халык язучысы исемен йөрткән әдипләр арасында Халыкка иң якын торган, Халык күңеленең түренә үк кергән әдип иде! Ул моны үзе дә тоя, үзе дә сиземли иде. Халык төшенчәсе аның өчен газизләрдән газиз — татар милләте иде. Ул һәрчакта: «Минем милләтем, минем халкым җир йөзендәге бер генә милләттән дә, бер генә халыктан да өстен түгел, әмма ул бер генә халыктан да түбән дә түгел», — дияр иде.*

*Ул тагы да: «Татар язучылары холыклары, сәләтләре белән төрледән-төрле, ә милләт ихтыяҗлары дигәндә, алар һәрчак бер уйда, бер теләктә, бердәм», — дияр иде.*

*Ул тагы да: «Халыкны толпа белән бутарга ярамый», — дияр иде. Баксаң, ул безгә, иң беренче чиратта язучыларга, үзенең иҗат итү мәсләген төшендергән, безне үз иҗаты үрнәгендә халыкның үзаңын үстерергә чакырган, өйрәткән икән бит!!!*

*Бүген Туфан Ага белән бөтен сәнгать дөньясы хушлаша. Туфан татар әдәбиятына, аның драматургиясенә хакыйкый чынбарлыкны, фәлсәфи чынбарлыкны алып кергән новатор булды. Ул милли драматургиябездә үз мәктәбен булдырды. Ул үзе ярты гасыр буена бөтен бер милләтне, аркадаш милләтләрне театрлы итте.*

*Ул үзе сәнгатьнең, әдәбиятның бер сурәте иде. Һәм ул үзе иҗат иткән йөзьяшәр Әлмәндәр булып та, самими Минһаҗ булып та, Каһарман Бәхтияр булып та, Тукай, Туфан, Җәлилләрнең образы булып та халык хәтерендә, халык күңелендә яшәячәк, халыкны искәртеп, уяу тотачак!!!*

*Туфан Ага соңгы елларда Милли әдәбиятыбызга өр-яңа яшь буын килүенә чиксез куанып яшәде. Аларның иҗатын күзәтә иде, аларны барлады, аларны нидәндер кисәтте, аларга үзенең киңәшләрен, фатихасын биреп калдырды.*

*Без бүген аның белән хушлашабыз.*

*Очрашканда кул биреп күрешсә дә, ул аерылышканда кулын биреп саубуллашмый иде. Кул биреп саубуллашсаң, озак күрешмисең дия иде...*

*Бүген олуг остазыбыз белән хушлашканда, барыбыз да аның безнең белән мәңгегә каласын тоябыз ич!!! Бу ышаныч безне, шөкер, кайгы-сагыштан да алып чыгар. Күңелебездә фәкать халкыбызның шундый бөек улы белән горурлану хисләре генә калыр!*

*Хушыгыз, Туфан ага!*

*Җаныгыз җәннәттә булсын!!!*

**Илфак ИБРАҺИМОВ**

# ДРАМАТУРГ–РЕЖИССЁР

Минем үземә театр сәнгате өлкәсенә килеп керү әлләни катлаулы булмады. Танылган әдипләребез Г.Тукай, А.Алиш, Г.Ибраһимов, Ш.Камал һәм башка язучыларыбызның әсәрләрен укып үскән, Г.Камал исемендәге Академия театрына йөреп төрле спектакльләр караган үсмернең күпмедер дәрәҗәдә татар әдәбиятыннан әзерлеге бар иде. Өстәвенә, Туфан Миннуллинның яңа пьесасы куелса, класс җитәкчебез Әлфия апа, кемнәрдер аша билетлар юнәтеп, безне, ике сыйныфны бер итеп, тамаша карарга алып бара иде. Әдәбият-сәнгать белән кызыксына торгач, 1974 елны М.Сәлимҗанов җыйган төркемгә Казан театр училищесына укырга керергә ниятләдем. Бу еллар — татар театрларының алтын чоры. Шыгрым тулы заллар, кызыклы әсәрләр, данлыклы режиссёрлар. Әлмәттә — Г.Хөсәенов, Минзәләдә — С.Өметбаев белән Л.Садриев, Кучмә театрда — театраль теоретик Р.Тумашев, Камалда кабатланмас П.Исәнбәт белән татар театр сәнгатен югары биеклеккә күтәргән күпкырлы талант иясе М.Сәлимҗановлар җиң сызганып иҗат итәләр. Алар урнәгендә яшьләр, талантлы шәхесләр — Д.Сиражиев, Ф.Ибраһимов, Ф.Бикчәнтәев, Ә.Камалиев, Р.Әюповлар бер-бер артлы күтәрелеп чыкты. Ләкин, спектакль куяр өчен җанлы әсәрләр дә кирәк! Драматурглар яза, режиссёрлар, актёрларның мөмкинлекләренә туры китереп спектакль куя. Ул чорларда төрле театрларда Р.Хәмид, Ә.Гаффар, Ф.Садриев, Ю.Сафиуллин, Ю.Әминов кебек язучыларның әсәрләре гөрләп барды. Академия театрына килсәк, Ш.Хөсәенов, Р.Батулла, Х.Вахид, А.Гыйләҗев, Н.Исәнбәт кебек әдипләребезнең әсәрләре елатты да, көлдерде дә тамашачыны ул елларда. Төп урынны Г.Камал театрында, әлбәттә, легендар шәхесебез Туфан ага Миннуллин тотты. Тик аның заманында күренекле режиссёрыбыз Марсель аганы Ходай Тәгалә сәнгать аренасына чыгармаган булса, драматургыбызның иҗаты кайсы юлдан киткән булыр иде, әйтә алмыйм. Бу ике шәхеснең бердәм иҗаты Татар Академия театрын республикада гына түгел, гомумән, СССР җирлегендә дә зурдан танытты. Мәшһүр М.Сәлимҗановны Г.Товстоногов белән бер рәткә куялар иде Мәскәү театр белгечләре. Ул елларда Туфан аганың бер-бер артлы М.Сәлимҗанов режиссёрлыгында «Канкай углы Бәхтияр», «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Моңлы бер җыр», «Әлдермештән Әлмәндәр» кебек әсәрләре куелып татар дөньясын шаулатты. Драматургның «Без бит авыл малае» комедиясе Кучмә (бүгенге көндә — К.Тинчурин) театрында Р.Тумашев тарафыннан сәхнәләштерелеп, дистә еллар буена дөнья гизде. Гали ага Хөсәенов җан өргән «Ай булмаса, йолдыз бар» спектакле өчен (Әлмәт театры) 1979 елда автор Т.Миннуллин, төп рольне башкаручы Д.Кузаева, режиссёры Г.Хөсәеновлар Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Без, ул еллардагы студент халкы, Академия театрына көн аралаш барып, Туфан аганың әсәрләрен кабат-кабат карап соклану кичерәбез. «Диләфрүзгә дүрт кияү»не карап, Н.Гәрәевага охшаган кызларга гашыйк булабыз, «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендәге җырларны яттан беләбез, үзебез үк башкарабыз да. Бу спектакльләрнең һәрберсенә һәрчак аншлаг, кассада чират, ерактан килгән тамашачыларның хәленә кереп, урындыклар тезәләр. Аның өчен пожарниклар ачуланалар. Иң авыры — без студент халкына, аншлаг булса, «икенче юлы килерсез» дип, безне төп ишектән кертмиләр. Әле берәр Диләфрүзгә охшаган чибәркәенне ияртеп килеп, шулай дисәләр, оятыңнан җир тишегенә кереп китәрдәй буласың. Безнең кайбер курсташлар Марсель абыйга: «Академия театрында кеше күп булса, безне кертмиләр. Марсель абый, сез бит баш режиссёр, ярдәм итегез әле», — дигәнгә курс җитәкчесе: «Андый көннәрне забор аша керегез», — дип кинәшен бирә. Тора-бара Марсель Хәкимович безнең эшне



*«Гармун уйный беләсеңме?» комедиясе.*
*Сулдан уңга: Т.Нуруллин, Р.Сәгъдиев, И.Хәсәнов.*

жайлый, ач йөрмәсеннәр дип, массовкага чакыра, һәр спектакльдә катнашкан өчен бер сум да илле тиен түлиләр. Ай буена йөри торгач, шактый гына жыела, жайлап кына тотсаң, ике-өч атна рәтләп кенә әбәт ашарга житә. Туфан аганың әсәрләренә кабат-кабат йөри торгач, күпчелек рольләрне яттан беләбез, әйдәп баручы артистларны инде якыннан белүебезгә горурланабыз. Аларның уеннарын читтән генә сокланып карыйбыз, өйрәнәбез. Спектакль тәмамланып, баш ияргә чыккан мәшһүр драматургыбыз Туфан абый безгә бөтенләй буй житмәслек тоела.

1984 елда мин, армия сафларында йөреп кайтып, 1981-1984 елларда Әлмәт драма театрында эшләп алгач, кире Казанга — Күчмә театрга килдем. Озакламый, 1986 елда, Казан дәүләт университетына читтән торып укырга да кердем. Менә кайда кирәк булды миңа Т.Миңнуллинның әсәрләрен, анда уйнаган артистларны белү! Иншa язганда иреклe тема: «Минем яраткан язучым» иде. Бәхет басты, күп уйлап тормастан, Туфан ага пьесаларына багышлап инша язам, артистларның исем-фамилияләре белән бирәм. Диләфрүзне уйнаган Н.Гәрәева иҗатына да тукталам, Әлмәндәр карт — Ш.Биктимеров образын да үзем белгәнчә анализлыйм, аларның хезмәтенә, талантларына соклануымны да белдерәм. Нәтиҗәдә, имтиханга «бишле» куйдылар, тырышлыгым юкка китмәде. Куюын куйдылар, алуын да алдылар данлыклы уку йортына, тик ошбу хәлне белгән Күчмә театр администрациясе генә пошаманга төште бит! Аларны да аңларга була, чөнки коллектив өч-дүрт труппага бүленеп, төрле спектакльләр белән төрле якларга СССР буйлап 30-40 көнгә гастрольгә чыгып китә. Өстәвенә, яшәү шартлары начар, хезмәт хакы «мизерный», кадрлар житешми, шуның өстенә яшь артистлары, әле алды кереп, арты кермәгән бәндә, ел саен ике мәртәбә сессиягә имтиханнар бирергә китәргә дә тиеш. Тарихта күренмәгән хәл! «Йә эшлә, йә укы!» диеп тә әйткәлиләр. Ярый әле, кануннар бар, укыган кешене куа алмыйлар икән. Ләкин юлын таптылар, рольләр генә бирмиләр, уйнау тәтеми миңа. Шулай да яна спектакльләр куйганда, өченче-дүртенче состав итеп билгеләп куялар тагын үзе. Бу инде сина репетиция мәңге тәтемәячәк дигән сүз. Шундый хәерсез көннәрнең берсендә, төгәлрәк әйтсәм, 1986 елны Туфан Миңнуллинның яна әсәре — «Гармун уйный беләсеңме?» дигәне безнең труппага куелачак икән, шул ук әсәрне Минзәлә театрында «Гармун белән скрипкә» исеме астында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Л.Садриевның инде куеп ятуы да мәгълүм булды. Режиссёрына килгәндә, без бөтенләй белмәгән, Урта Азиядән күчеп кайткан яна кеше сәхнәләштерәчәк икән.

Менә, ниһаять, репетицияләр башланды. Искитмәле сәнгать әсәре, авыл күренешен якты итеп чагылдырган декорация, матур итеп көйләр язылган, рәхәтләнеп бирелгән роленне уйна гына инде. Ләкин режиссёрыбызның гына эшләре бармый бит. Нәрсә эшләргә теләгәнен үзе дә аңламый. Соныннан билгеле булганча, ул Урта Азиядә үзешчән сәнгатьтә генә нәрсәдер куйган булган. «Аптыраган үрдәк суга арты белән чума» дигәндәй, театрның режиссёрларсыз калган чоры бу, кеше булмагач, әлеге иптәшне сынап караулары икән. Куючының кемлеген белеп алган, азау теше чыгарган артистлар бөтенләй санга сукмый башладылар үзен. Минем генә исем китми, чөнки өченче состав. Мәңге репетиция ясамыйсын дигән мөһер сугылу

бу. Ләкин бер «ләкин»е бар икән әле, әгәр синең беренче, икенче составларын авырып йә булмаса декрет ялына китсә, сине репетициясез-нисез «ввод»ка төртеп кертәчәкләр. Монда да мина яктылык юк, чөнки ирләр декрет ялына китә алмыйлар, берсе чирләсә, икенчесе бар. Шулай итеп, төп рольдә Мәрдине уйнасам да, мин барыбер читтән карап утыручы гына. Укуым да читтән торып, уйнавым да шул чама. Көн артыннан көн үтә, эшнең рәте-башы юк, өлкәнрәк актёрлар кул селтәп кайтып китәләр, режиссёр аларга бер сүз дә әйтә дә алмый, чөнки үзе бик кызганыч халдә. Бу турыда берәү түзмәгән, Туфан агага: «Әсәрең чыга алмый бит, куя алмый. Туфан, һич булмаса үзең сәхнәләштереп бетер, әрәм булмасын», — дип хәбәр иткән. Драматург, ниһаять, үзе театрга килеп керде. Якташымның пәйда булуы минем бәхеткә икән. Иң беренче итеп барыбызны да сәхнәгә чыгартып, уйнатып караттьі. Мәрдиләргә тальянда да сыздыртырга кирәк. Шуннан Туфан ага әйтә: «Үпкаләмәгез, егетләр, Рәдиф армияләрдә дә йөреп кайткан, тальянда да әйбәт уйный, гәүдәгә дә нык, Мәрди кебек», — диеп, мине беренче составка күчерде дә куйды. Театр директоры Әбелмәмбетов: «Туфан абый, ул бит университетта укый, елга ике тапкыр эшне өзеп китеп барачак, ә гастрольгә кем чыгар?» — дип каршы төшә.

— Роберт, син чакырдыңмы куярга — куям. Пьесамның ничек чыгуы өчен мин җавап бирәмме — бирәм, чөнки аны, иң беренче чиратта, таләпчән Казан тамашачысына күрсәтәчәкбез. Соңыннан, Рәдиф укырга киткәч, әнә, кемнән ким, Рәсил Акбашов уйнар, — диеп бәхәскә нокта куя. Минем өчен дусларым, якташларым Ринат Мифтахов белән Илгизәр Хәсәнов та куана...

Үзебезнең якның берәр шәхесен күз алдына китерсәм, тау ягының гүзәл табигате, алма-чия бакчалары, чишмә-күлләре һәм, әлбәттә, ике мәһабәт елга кушылып диңгез ясаган киңлекләре, дулкын өстендә тибрәнеп йөзгән ак пароходлары, акчарлаклары, мал-туар төяп каядыр юнәлгән судно-баржалары да искә төшә. Искиткеч гүзәл табигать! Ошбу илаһи төбәк күпме талантлы язучыларны, хәрбиләрне, дәүләт эшлеклеләрен, фән кешеләрен биргән. Шулар арасында, әлбәттә, Туфан ага Миңнуллин — татар әдәбияты тарихында зур мирас калдырган шәхес.

Ярата иде мәшһүр драматургыбыз үзебезнең гүзәл туган ягыбыз — Кама Тамагын. Ул бит аннан үз гомерендә күңеле сыкрап күпме генә китмәгән дә соңыннан, сагынып, Иделем акчарлагы кебек күпме генә кайтмаган. Ә бит безнең туган ягыбыз белән саубуллашып китеп баруның һәр очрагы үзе бер романтика. Син утырган су корабы, пароход булсынмы ул, Метеор, Ракетамы яисә Буревестникмы, кычкыртып сәлам бирә дә, тавышы Кама Тамагының текә тауларына барып бәрелеп, аһәң булып кире әйләнеп кайта. Тау башыннан сиңа дусларың, туганнарың, сөйгән ярың кул болгап, «яңадан кайт» дип озатып кала. Ә инде кире кайтканда, жигүле атлар белән каршы алырга килгән туганнарың, авылдашларың кабат сине көтә. Өстәвенә бер көтү акчарлаклар: «Озак йөрдең, озак йөрдең, чит җирләрдә ниләр күрдең?» дигәндәй чыркылдашып каршы алалар. Трактор-машина, мотоцикл, ат кешнәгән, су буенда сату иткән апайларның яңгыравык тавышлары бергә кушылып үзенә бертөрле моң булып яңгырый. Симфония! Елга ярына зур көймәләре белән бер-бер артлы балыкчылар кайтып, пристаньның өске ягына туктаталар. Бер төркем халык шул якка омтыла. Саклау складлары да ерак түгел, арып-талып кайткан елгачылар, ашыкмый гына тоткан байлыкларын төрен-төргә, сортын-сортка аерып тартмаларга тутыралар, аны ат арбасына төяп, саклау урынына озаталар. Ләкин, бар тауар да складка барып житми, әле балыкчыларның үз өлешләре дә аерым өелгән. Төяүле ат кузгалып киткәч, халык бер-берсен төрткәләп, шаулашып: «Безнең Салтыкка, Балчыклыга хәтле кайтасы бар, чиратсыз кермәгез әле», — дип, шаулашып сатып алу эшенә керешәләр. Зур кәрҗиннәр күтәргән, башкалабыз Казанда груша-алмасын, чия-сливасын, кыяр-помидорын сатып кайтып килүче түтәйләр дә, кемнедер каршы алырга килгән эшләпә-түбәтәйле авыл абзыйлары да, кунаклар да балык сайлый. Кайсысыдыр тозларга, кемдер кыздырырга, икенче берәүләре шулпа пешерергә сорый. Гөж килә су буе...

Туфан ага да текә яр башына басып ошбу гүзәллеккә, тормыш агышына сокланып карап торырга ярата иде. «Әй, егетләр, тагын кайда бар соң мондый илаһилык, мондый нечкә гүзәллек?! Җәннәт бит, билләһи, җәннәт», — дип, ташып чыккан

хис-тойгыларын безгә белдерә. «Мин бит Казакъстанда эшләгәндә дә, Мәскәүдә Щепкин училищесында укыганда да, елларымда да очып, сагынып кайта идем, ошбу табигатьне кабат күрергә. Күреп тә, сагынып та, туеп та бетәрлек түгел икән бу Кама Тамагын», — дия иде әдип, чын күңеленнән шатланып. Аны танып районлашлары, танышлары уратып ала: «Әллә Туфан Миннуллиныбыз инде?! Нишләп үзең генә сон?» дигәннәргә: «Авылның матурлыгын аңлап бетерәме соң ул Нәҗибә апагыз! Ана жылы суы агып торган фатиры да театры гына булсын», — дия, яртылаш чынлап, яртылаш шаяртып. Атна саен авылына чапса да, айга бер генә тапкыр булса да, Мөштәри урамында урнашкан Язучылар берлегенә дә кереп чыккалый ул. Без, яшь язучыларның, барлык әсәрләрен укып, куелган пьесаларыбызны да карап барырга тырыша иде, фикерен әйтә, бәяләмә бирә. К.Тинчурин исемендәге театрда куелган «Яз галәмәте», «Сынган беләзек» әсәрләрен карагач, миңа: «Бик жылы, бик тәрбияви пьесалар. Кара, якташ, синдә лирика көчле икән бит», — дип мактап та жибәрә, аның бу сүзләре күңелгә сары май булып ята. Әле «Идел» журналында басыла килгән детектив роман-повестьларымны да укып барган: «Афәрин, якташ, Нәҗибә апаң белән берсен дә калдырмыйбыз, чиратлашып укыйбыз, татарда чын мәгънәсендә детектив жанрында рәтле-башлы яза белүче юк иде, ташлама, дәвам ит», — дип, күңелне күтәрә. Үткән гасырның соңгы елларында Кама Тамагының Яңа Сала авылында үткәрелгән фәнни-гамәли әдәби конференциядә дә: «Рәдиф Сәгъдинең үз теле, үз стиле бар», — дип, жылы сүз әйтеп үткән иде. Олпат язучы авызыннан моны ишетү тагын да тырышыбрак иҗат итәргә этәргеч булды, әлбәттә. Соныннан: «Ринат Мифтах белән авылга кайтсагыз, онытмагыз, миңа да кереп чыгыгыз, бер иркенләп сөйләшеп утырырбыз», — дип Мәрәтхуҗага кунакка чакырды. Озакламый, чынлап та, туган якларга Ринат абый белән бергә кайтырга туры килде. Шул форсаттан файдаланып, Туфан аганың авылына да барып килергә булдык. Бәхеткә, драматургыбыз өйдә иде. Ул үзе салдырган мәчете, үзе укыган мәктәп бинасы, үзе өчен кадерле хатирәләре булган авыл почмаклары белән безне таныштырып йөрде. «Әнә, теге казлар коенган сай инештә без малай-шалай да анадан тума ләмдә аунап, чучка балаларына әйләнеп өйгә кайта торган идек. Кыш көннәрендә зимагур малайлар теге биек Олы Салтык тавына зур ат чанасы сөйрәп менеп, төялешеп шуып төшә идек, соныннан, хәле беткән эт балалары кебек авызны ачып еш-еш сулап, әнкәй кырына кайтып егыла идек. Әнә тегендә — Карамал ягы, әй малай, анда җиләкнең күплекләре, малай чакта ирендермәгән дә бит, өлкәннәргә ияреп барып ярыша-ярыша жыябыз. Үзе эре, үзе ишле иде ул чакларда. Хәзер дә бар, диләр, тик ирендерә инде, малай, яшь тә житәрлек бит инде, үзегез беләсез», — ди. Соныннан безнең сәяхәт өй тирәсендә дәвам итә. «Менә элек биредә безнең бәрәңге бакчасы иде. Син, Рәдиф, Келәнчедән Алтыш Рафаэлен беләсендер инде, шуның белән кинәштек тә зур итеп, менә, күл казыттык, теге инеш суын траншея казып бирегә юнәлттек тә менә дигән сулык барлыкка килде, артык суы агып чыгып, элеккеге эзеннән бая күрсәткән казлар буасына төшә тора. Әле алып кайтып карап маймычлар да жибәрдек, ни булыр, белгән юк, бер-ике елдан, менә, балык тотып карарга да килсәгез була», — ди Туфан ага.

Ул авыл жирлеген генә түгел, аның үткен телле, тырыш халкын да бик ярата иде. Шуңа күрә бирегә кайтса, язарга илһамын да таба, сала халкыннан жыя барып, төрле гыйбарәләр, кызык хәлләрне дә әсәрләренә кертә тора. Шуңа күрә аның күпчелек әсәрләре авыл тормышына багышланган, аның кешеләренә, уңганнарына мәдхия уку да житәрлек пьесаларында. «Без бит авыл малае», «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Кырларым-тугайларым», «Гөргөри кияүләре», «Йөрәк маем» кебек пьесалары — авыл темасына багышланганнарының бер өлеше генә!

Туфан Миннуллинны күпчелегебез драматург, язучы итеп кенә беләбез. Ләкин аның әле режиссёрларга кытлык чорында Минзәлә һәм башка провинциаль театрларга барып та үз әсәрләрен сәхнәләштергәнен ишетеп беләм. Безнең К.Тинчурин театрында да ул режиссёр буларак җиң сызганып эшкә керешә. Дәрте ташып тора, гөрелдәп чыккан яңгыравык тавышы белән: «Яле, якташ, менә сул яктан хатынынны ияртеп чык та, күршең Мозаффарлар тәрәзә төбенә килеп, сыздыртып тальян гармуныңда урам көен уйнап жибәр!» — ди. Мозаффарны исә театрның ул чактагы

әйдәп баручы, Татарстанның халык артисты Ринат Мифтахов башкара. Олпат гәүдәле, матур, моңлы бас тавышлы, өстәвенә ул да Туфан аганың якташы, Чаллы авылыннан. Авылның магнитофон акыртып йөрүче зимагур малае Хисамны уйнаучы Илгизәр Хәсәнов та драматургка якташ, әтисе — Балчыклыдан, әнисе — Олы Бортастан. Язучының үзенә ничектер, әмма дә ләкин без, якташларына Миннуллинның үзе белән спектакль чыгаруы күңелле дә, җинел дә. Акырмый, мыскыл итми, җайлап кына



*«Гармун уйный беләсеңме?» комедиясе. Сулдан уңга: Ә.Хәсәнова, Р.Мифтахов, Н.Вәлиева, Р.Сәгъдиев.*

төшендерә бара. Сәхнәдәге вакыйгалар җыр-биюләргә уралып агыла. Безнең уеннан канәгать калып Туфан ага сөенә, аның ошатканын күреп, труппа да күңел күтәренкелеге кичерә. Вакыт-вакыт: «Молодцы, егетләр, бик шәп, якташлар», — дип тә мактап җибәрә. Әбине уйнаган Һаҗәр Шәкүрова: «Әй, Туфан абый, гел якташларыңны гына мактыйсың, нишләп без дә Кама Тамагыннан чыкмаганбыз икән!» — дип төрттерә. Җор телле режиссёрыбыз югалып калмый: «Якташларымны, Һаҗәр, мин мактамасам, кемнәр мактар икән?» — ди. Аннан: «Ну, син дә молодец, Һаҗәр, Сабадан булсаң да», — дип, гөрелдәтеп көлеп җибәрә. Репетицияләр уйный-көлә дәвам итә. Ниһаять, премьера, сәхнә артына Туфан ага үзе кереп: «Зал шыгрым тулы, җәмәгать, иркенләп, каушамыйча уйнагыз», — дип, соңгы күрсәтмәләрен бирә. Халыкка матур декорацияле, тапкыр сүзле, җырлы-биюле тамаша күрсәтелә. Алар ял итеп, күңелләре күтәрелеп, безне аягүрә алкышлап кайтып китәләр иде. Әдибебез үзе дә «Гармун уйный беләсеңме?» спектаклен бик яратты. Спектакльдән спектакльгә дусларын, академия театры артистларын бик еш ияртеп килә иде. Бик озак еллар буена барды аның бу пьесасы, халыкның кабат-кабат караган әсәрләренең берсенә әйләнде. Ошбу пьесасын үзе куеп Туфан Миннуллин безгә яхшы язучы гына түгел, талантлы режиссёр икәнлеген дә күрсәтте.

Шул елларда телестудия җирлегендә ачылган «Кадр» дигән оешмада режиссёр булып эшләүче Илдар Матуров миңа: «Белмәгән кешең юк, берәр атаклысын табып бир әле, документаль фильм төшерербез», — дип мөрәҗәгать итте. «Әйдә, Туфан агадан башлап карыйк алайса, район җитәкчеләренә дә үзем чыгам, артистлар кирәк булса, дирекция белән дә сөйләшәм», — дим. Кинога төшерү мәсьәләсен Туфан аганың үзенә җиткердем. Ул: «Мин каршы түгел, төшерегез, җитәкчеләр белән аралашчы булырга да риза», — ди. Язу-сызу мәсьәләсенә тукталгач кына: «Энекәш, каләмең бар бит инде, үзем турында үземә яздыртмагыз инде», — дип, кырт кисә. «Сценарийны эшләп бетер дә, ә сезнең белән районга, әлбәттә, чыгам, тик язмана минем авыл Мәрәтхуҗаны да кертергә онытма, мәчетне дә, мәктәпне дә калдырма», — дип кинәшләрен бирде.

Бер атнадан булачак фильмның сценарие әзер иде. Туфан ага әз-мәз генә төзәтмәләр ясаса да, язмадан канәгать калды. Эш башланыр алдыннан мин үзебезнең Кама Тамагы районына кайтып, аның җитәкчесе Миндел Шәмсетдинов, язучының үз колхозы рәисе Рафаэль Гыймадиев белән дә сөйләшеп, гастрольләр ясап кайтам. «Безнең кулдан нәрсә килә, борчылмагыз, барысын да эшләрбез», — дип, озатып калдылар. Бу вакытта «Гармун уйный беләсеңме?» комедиясе, артистлар эштән китү сәбәпле, уйналмый башлаган иде. Туфан абый ике көн рәттән театрга килеп, яңа рольгә кертелгән артистлар белән репетиция ясады да: «Хәерле сәгатьтә, егетләр!» — дип, яхшы теләк теләп өенә кайтып китте. Безне алда кар-буранлы, салкын кышлы Кама Тамагы районы һәм якташлар көтә иде. Колхозларның әле исән чагы, авылларда хезмәт хакы түләнгәч, эш булгач, яшьләрнең дә бер өлеше туган

жирендә кала торган чагы, зурдан кубып, тулы заллар белән каршы алдылар. Район тамашачылары Туфан аганың әсәрен дә, анда тагын өч якташлары уйнавын да зур горурлык, көчле алкышлар белән каршыладылар. Авыл саен шатланып клубка киләләр, хөрмәт итеп, кунак итеп озатып калалар. Үзәк юлдан читтәге кайбер авылларга көрт салып аркылы төшсә дә, шундук колхоз житәкчеләре бульдозерлар жибәреп аны чистарттыралар, спектакльдән соң тракторлар озата чыга. Көнгә икешәр тапкыр уйныйбыз, шуңа тәнгәл кинорежиссёр Илдар Матуров төшерү эшләре алып бара, ә көннәрдән бер көнне район кунакханәсенә Туфан ага иртүк килеп керде: «Якташ, бер яхшылык эшләгез инде, авыл халкы бит, Туфан, үзебезнең клубта да спектакленне уйнат инде, дип сорыйлар», — ди. Әлбәттә, бу үтенеч безнең труппага кыенлыклар тудыра торган хәл иде. Чөнки авыл йорты хәтле генә клубның сәхнәсе дә, кечерәйтеп әйтсәк, мунча ләүкәсе хәтле генә, тамашачы залы да илле кеше сыярлык кына. «Декорация дә сыймаячак, артистларга хәрәкәт итәргә урын да юк бит анда, Туфан абый», — дим.

— Декорациясез генә уйнарсыз, халык аны шул килеш тә яратачак, кабул итәчәк. Мин үзем ашау-эчү, мунча кирәк мәсьәләләрен хәл итәм, район житәкчеләре дә авылга килеп котларга булдылар, шунда Илдар кино өчен материал да төшерер, — ди.

— Туфан абый, шундый шыксыз клубыгызда уйнап, бәябез төшмәс микән соң?

— Менә минем алда бәягез төшмәсә, халык алдында күтәреләчәк кенә инде, — ди.

— Яхшы, Туфан абый, мин хәзер бүлмәләргә кереп хатын-кызлар белән сөйләшәм, ирләр белән мәшәкать булмас, анысына иманым камил. Алар, без сорасак, икене генә түгел, өч спектакль дә уйнаячаклар көненә, — дип, бүлмәдән чыгып китәм. Труппаның иң өлкән артисткасы Һ.Шәкүрова: «Туфан абыең өчен кирәк булса, урамда да, буранда да уйнарбыз инде», — дип, ризалыгын бирә. Икенче көнне көндезгә унбердә без, Мәрәтхужаның сәнгать сарае дисәм, хәтере калыр, берәр агайның терлек абзары хәтле клубына спектакль уйнарга киттек. Төп декорацияне бушатып та тормадык, сәхнәгә кечкенә генә рәшәткә, бер куак, ике озын эскәмия урнаштырдык. Тамаша залының да алгы урындыкларын алып урамга чыгардык, чөнки башкача булмый, жырлы-биюле урыннарны сәхнәдән төшеп башкарсак кына. Туфан ага яшь егетләр кебек очып йөри, әле безгә килеп булыша, йә булмаса хатын-кызларга: «Нурия, менә син теге урынны монда алыштырырсың, син, Әлфия, менә моннан керерсең», — дип мизансцена куя. Соңгы мәртәбә Мәрәтхужада кайчан спектакль булганын карт бабайлар да хәтерләмидер инде, ә без уйныйбыз. Халык мөкиббән, вакыйгалар эченә кереп китеп, бирелеп карыйлар. Чөнки колакларына туган якларының атамалары, авыл исемнәре дә килеп керә. Алар бар да шигырь итеп язылып, жырга салынган. Барыш та, Келәнче дә, Кыртапа да, Салтык та һәм башка күп кенә авыл исемнәре жырларда яңгырый. Без, ниһаять, тальян, баян моннары белән үрелеп барган спектаклебезне уйнап бетерәбез. Халык, ягъни арткы рәтләрдә утырган 30-40 тамашачы, рәхәтләндереп кул чаба, Туфан ага безнең алга чыгып авылдашларына да, артистларга да, район житәкчеләренә дә тирән рәхмәтен белдерә. Кыен шартларда эшләп чыксак та, без бик канәгать. Яхшы язучы язган, автор үзе үк режиссёр булган затлы спектакльдә уйныйбыз, бөтен мәшәкатьләрен, эшләрен калдырып безне карарга килгән тамашачылар баскан килеш рәхмәт йөзеннән кул чаба. Район житәкчесе, кыш булуга карамастан, чәчәкләр дә юнәткән. Тере чәчәкләр!

Быел да, район үзәгенә кайтып, пароходтан төшүгә, текә ярына, гүзәллегенә сокланып карап тордым. Куе, шомырт кара көдрә чәчләрен артка сыйпап, Идел киңлекләренә төбәлеп, Туфан ага басып тора сыман.

**Рәдиф СӘГЪДИ,**
*драматург*

# ЯШЬНӘП ЯШӘГӘН ЯШЬТӘШЕМ ЯДКАРЕ

Аның драматургия әсәрләрен тикшереп, анализларга махсус кешеләр бар, чит бакчага керәсем килми. Депутат буларак эшчәнлегенә бәһа бирү өчен, гомумән, Госсовет функцияләрен тикшерү лазем; шунда гына аерым депутатлар эше яисә эшсезлеге турында фикер йөртеп була. Анысын да үзара, кухня сөйләшүләрендә генә, читкә ишеттерми генә.

Ин дөресе — яшьтәшем белән аралашып, очрашып сөйләшкәннәрдән хәтеремдә сакланган кайбер вакыйгаларны тәкъдим итү булыр.

Шәхес буларак, аның тулы биографиясен язганда, кемдер шуларга таяна икән — бу минем өчен мәртәбә-дәрәҗә булса, күпсанлы җанатарлары өчен әдипнең бай тормыш юлындагы кызыклы штрихлар буларак укылыр.

Галәттә, данлыклы шәхесләрнең тормыш юлы турында язганда, аның бала чагыннан, яшьлегеннән башлыйлар. Ә мин бала чагын Туфанның үзе язганнарыннан укып кына беләм. Әйе, яшьлегенең күпмедер өлешенә шаһитлык насыйп булды. (Әгәр 21 яшьтән 28 яшькә кадәрле араны яшьлек дип санасак.) Язмамда күбрәк шуларга таянырмын.

Ләкин ул елларны, студент чакка туры килгәнлектән, кызыклы узды дип әйтеп булмый. «Җепшеклек» еллары иде. Ядкаремне соңгы очрашу, соңгы сөйләшүләрне хәтерләүдән башлау кирәктер. Үзеннән-үзе аңлашылганча, соңгы сөйләшүләр — соңгы очрашулар вакытына туры килә. Очрашуларның берсе Фирдәвес Әхтәмованың «кырыгын» уздыру мәҗлесендә, мәрхүмә фатирында. Ничәнче числода икәнен хәтерләмим — «Щепкинчылар» дип йөртелгән сабакташларның барсы да килгән, бер Туфан гына юк. Күпмедер вакыт, галәт буенча, көттерүченең «гайбәтен» саткач, ниһаять, «гаепле» килеп керә. Ашыккан, кызарган. Без: «Начальство не опаздывает, а задерживается», — дип аны «чеметкәләргә» керештек.

— Бер җирдә бик борынгы кәнәфи тәкъдим иткәннәр иде. «Италиянең Милан шәһәре осталары эшләгән шедевр», дигәч, барып карадым. Италиядән булуы ышандырса да, XVIII гасыр дигәне шикле. Алдарга өйрәнде антикварлар.

— Матур булса, ничәнче елны эшләнсә дә, барыбер түгелмени? — диде кемдер беребез.

— Хәзер кибетләрдә дә менә дигән матур-матур креслолар очрый, — диде икенчебез.

— Юк, очрамый! Барысы бер калыптан, стандарт. Ә борынгыларның мебельләре утыргыч функциясен генә үтәми, алар — чын сәнгать әсәре. Ә сәнгать әсәре искерми, — диде Туфан өздереп.

Шунда мин дә, яшьтәшемне якламакчы булып, үзем очраткан бер «сәнгать әсәре» турында сөйләдем.

...«Габбас хәзрәт» фильмын төшергәндә, борынгы заман мебеле кирәклегенә игълан биргәч, җавап озак көттермәде: тәмәке фабрикасы ишегалдындагы элеккеге чиркәү әһелләре яшәгән йортта бар икән. Шунда юл тоттык (инде мәрхүм художник Үзбәк Мөхетдинов белән). Барып керсәк — шаккатырлык чын сәнгать әсәрләре күтә! ...Пыяласы чатнаган зур көзгенең рамы зәйтүн-чикләвек агачларыннан юнып, кырып, чокып ясалган җимешләр белән урап алынган, ике тартмалы өстәленең берсендә хатын-кыз сыны, икенчесендә яшь егет сыны. Тартмалар ябылуга, аларның иреннәре иренгә туры килеп, үбешкәндәй булалар. Могҗиза!

Калган ике мебельдәге матурлыкларны сурәтләргә батырлыгым да, тел байлыгым да җитми. Шуларның өчесенә алмашка яңа шкаф белән язу өстәле сорадылар, «китерәсез дә алып китәсез», — диделәр мираска ия әби белән бабай.

Кайтып әйттек, ялындык, ялвардык. Бухгалтериябез артык «законлы»лардан гына торганлыктан, алып булмады, әрәм булды шедеврлар.



*«Ялкын» журналы редакциясендә очрашу. Сулдан уңга: Туфан Миңнуллин, Рабит Батулла, Ринат Таҗетдинов, Наил Дунаев, Рәшит Галиәкбәров, Әхтәм Зарипов. 1963 ел.*

— Монда бухгалтерия гаепле түгел — син гаепле, син ышандыра алмагансың, — диде Туфан, ачулангандай кызарып-бүртенеп, — режиссёрның төп сыйфаты — ышандыру!

— Соныннан, үз акчама алам дип барсам да, табышларым «очкан» иде шул.

— Димәк, Казанда чын матурлыкны аңлаучыларга бухгалтерия дә, закон да киртә түгел!

...Туфанның бу төртмәсенә җавап табарга өлгергәнче, мәҗлес башланды.

Инде хәзер бүген уйланып утырганда, яшьтәшемнең хаклы булуын аңлап, шундый нәтиҗәгә килэм: аның өчен тормышта очраган һәр гамәл, һәр нәрсәнең артында нинди дер мәгънә ята, буш очраклылык юк, була да алмый иде кебек. Максатчан яшәде, шуна өнләде ул.

...Март аенда кесә телефонына шалтыратсам, Туфан больницада ята икән, йөрәк белән, ди.

— Бераз соңрак шалтырат. Мин пока процедурадамын, — диде ул.

«Бераз» дигәннең күпме булуын белми көтеп утырганда, үзе шалтырата: «Нәрсә әйтмәкче идең?» — ди.

Мин, шул ел Тукай бүләгенә кандидатлар исемлегендә лаеклы булмаганнарны атап, берсенә аерата озаграк тукталдым да, ахырда:

— Сине Берлек рәисе итеп сайлаган елны катер белән Идел буйлап сәяхәткә чыккач, исереп кешелеген җуйган кәсепчегә, татарча белмәгән графоманга дәүләт бүләге бирүне ничек аңларга, депутат әфәнде? — дигән сорау бирдем, үземчә бик акыллы сорау иде.

— Тукай бүләгенә лаеклыларны сайлау комитеты «иптәшләр суды» түгел, анда әччелек, хатыннар белән йөрү гайбәте тикшерелми. Әсәрнең әдәби кыйммәте бармы? Әгәр кандидатның әсәрләренә карата синең төпле фикерең бар икән — син шуны исбатла, шәхси якларына тимә. Беребез дә фәрештә түгел, — диде Туфан.

Аптырап калдым. Чөнки «бу язучының әсәрләрен тәрҗемәдә «Казан утлары»нда бастыру милләткә ямь өстәми», дип, «Мәдәни җомга»да язган иде ул. Шуңа таянып, үз фикеремә терәк эзләгән идем. «Терәк» дигәнем сузылмалы — эластик булдымы, әллә яшьтәшем инде яшьнәмичә ажаган гына уйнатучымы?

— Фәрештә булмау үзенә хыянәт итәргә ярый дигән сүз түгел бит, яшьти, — дидем мин, һаман үземнекен алга сөреп.

— Минем үземә хыянәт иткәнем юк.

— Ә «Болгар жилләре» фильмына сценарийсыз килеш акча бирдергәндә, «бирергә» дигән төп сүзне син әйткәнсең ич! Ничә миллионны җилгә очыртуны фәрештә булмау гына аклыймы?

— Бәндә хатадан хали түгел, бульнистән чыккач сөйләшербез...

...Сөйләшә алмадык. 2 майда, кинәт, яшьтәшемнең гомере өзелеп, күпме әйтелмәгән сүзе, җырланмаган җыры үзе белән китте.

Тагы бер сөйләшүебезне хәтерләп узмасам, Туфан холкына хас булган бер төс кермәү аның сурәтен тоныкландырыр кебек.

Щепкинчыларның Мәскәүдән кайтып, театрда эшли башлауларына 50 ел тулуны зурлап уздыруның башында депутат Туфан Миннуллин булуын барыбыз да сизенә идек. Котлап, һәркайсыбызга йөзәр мең акча биреләчәген дә белгәч, сабакташыбыз

безнен өчен чын кодрәт иясенә, могжизалар тудыручыга әверелде. Театрдагы кичәдән соң анын һәммәбезне зур банкетка — ресторанга чакыруы нур өстенә нур гына түгел, Туфанны безнен каршыда «яктылык чыганагы» — тылсым иясе ясады.

— Һәркем үзе белән өч кунак алып килә ала! — диде ул, без — сүзсезләрне ушсыз да калдырып.

Мәжлес бик мулдан әзерләнеп, шома гына узды. Мәдхия кирәгеннән тыш «сибелде».

Сонынннан, һәркем бу бәйрәмне оештыручыларга, аеруча Туфанга рәхмәт әйтүне үзенен бурычы саный. Ана котлау сүзләре әйтә. Ә мин дәшмим.

— Сина ошамадымыни? — ди Туфан.

— Мәжлеснен өстәле әйбәт, оештырылуы — куелышы башкача кирәк иде, — дидем мин, бик мөһим фикер әйткәндәй.

— Ничек кирәк иде?

— Һәр өстәлдә бер гаилә булу — хәйрия ашына килгән кебек итте... Ашар өчен.

— Ну и что?

— Ну бит ашау — бәйрәм түгел, бәйрәм мәжлесе оригинальлек сорый. Әйтик, мин синен Нәжибәнне ухаживать итәм, син минем Жәмиләне...

— Синен ухажёрлыгынны Нәжибә кабул итмәсә нишләрсен? — диде Туфан.

Мин жавапсыз калдым, чыннан да шулай бит. Туфан, һәрвакыттагыча, жинүче булуыннан канәгать иде.

Советлар чорында да, Россия генә булып калгач та, Татарстаныбызда да, башка республикаларда да анын исеме ин дәрәжәле булып, алырга мөмкин булган бүләкләрнен һәркайсына ия булса да, Туфан алар белән «козырять» итмәде. Исем-дәрәжәләр анын өчен «әллә бар, әллә юк» иде. Анын өчен ин мөһиме — кеше үзе, анын язмышы, эшләре, ижаты булгандыр. Болардан да өстен күргәне, максаты, шиксез, милләт язмышы булуы анын һәр танышына таныш.

Анын таланты тормышта очраган детальләрне әсәрләрендә дөрес һәм урынлы куллана белүдә генә түгел, ижатында чагылдырган чорда шәхеснен яшәү мәгънәсеннән, тормыш логикасыннан читкә чыкмавында булгандыр, мөгаен. Әдип әсәрләренен геройлары тормышта еш очраган геройлармы? — дигәндә, тамашачынын «юк» жавабы дөрестер: Туфан гади кешеләрне сәхнәгә чыгарып, халык телендә сөйләтүе белән мәхәббәт казанды, үзе шунын белән заман герое булды.

Гади авыл крестьяны гаиләсендә туып үскән, бөтенләй уйламаганда театр дөньясына килеп эләккән бүгенге классик язучыбызнын яшьлек елларына йөгерек күзәтү ясасак, без аларда да «героизм» очкыннарын очратырбыз. Билгеле булганча, очкыннан ялкын кабына.

Туфан белән бәйле тагын бер вакыйгага тукталасым килә. Мәскәүдә укыганда, Мәскәү күрергә дип, йөргән кызым отпускага килде һәм без... загска кердек. ...Үзе бер кызыклы тарих булса да, анысы турында язып тормыйм. Никахлашкан кызым, ничек килсә, шулай — саф кыз килеш кайтып китте. Жәйге каникуллар вакытында туй ясарга килешеп, мин Мәскәүдә калдым. Химзаводтан «куылып», икенче эш эзләп йөргәндә, телефонга сөйләшергә чакыралар: каләшем! Елый! «Кая югалдын?» — ди. Мин инде өйләнгән «ир» булуымны онытып бара идем. «Паспорттагы печатьне әни күргән, ана ни дип анлатырга?» — ди. Хәзер моны язарга жинел. Ул чактагы хәлләремне анлатырга психолог булырга кирәк. Кинәшләрен сорап, иптәшләргә мөрәжәгать итәм. Әлеге дә баягы — үз тәжрибәсе дә булган Туфан әйтә: «Синен, ашыгып, загска керүенне тикшерергә сон инде. Жена — бремя, которое невозможно ни нести, ни сбросить, — ди. — Законлы каләшенне башка егет эләктереп, «алимит» түләп ятасын килмәсә, сонга калганчы, кайтып, туй итегез. Кагазьдә түгел — чынлап өйләнешегез...» — ди. «Складчина» белән мине туйга озаталар. Менә шул кыз белән никахыбызнын 60 нчы елын каршыларга жыенабыз. Өч бала үстердек. Дүрт оныгыбыз, оныкларнын балалары бар. Әгәр Туфан сүзен тотмаган булсам — туйга кайтмасам — ни булыр иде икән?!.

...Гомер буе Туфанга рәхмәт укып яшәдек дип әйтүем түгел бу. Төрле чак булды. Хәтта, анын сүзен тынлаганым өчен үкенгән чаклар да булгандыр. Бу хәлне искә төшерүем — сабакташымнын тормыш жепләре йомгагынын очын

табудагы зирәклеген танудан. Зирәк тә, рискованный да, ягъни, хәтәр тәвәккәл дә егет иде. Әйтә икән — өзеп әйтә. Ике төрле уйларга урын калдырмый. Әмма бу аның үз тормышындагы «йомгак очларын» югалтканы булмады дигән сүз түгел. Автобиографик язмаларында үзе язып чыккандырмы, юкмы — күргәнем дә, ишеткәнем дә булмады. Шулай булгач, мин дә Туфан тормышындагы кайбер «йомгакларга» тукталмый-тими узам.

Ул ниятләгәнен гамәлгә ашыруда кинәшләшеп, икеләнеп торуны белмәгән мөстәкыйль шәхес иде. Чая, әмма дуамал түгел. («Сүзен — сүз» итү өчен барган электричкадан сикерү очрагы бу фикеремә каршы килми.) Вакланмый, туннан бөрчә эзләми. Гомумән, Туфан «егетләрчә поступкаларга» саран түгел — теләгәненә ирешү өчен акча да кызганып тормый иде.

...Театрның спектакльләре күп төрле була. Аларның кызыклылары, яхшы сыйфатлы, тамашачы яратып йөри торган, яратмый йөри торганнары да, арада поступокка тиңләрлекләре дә була. Тик алары бик сирәк була. Туфан язган пьесаларның төрлесе бар. «Скучная» дигәне генә юк. Аларның күбесе кызыклы, кайберләре кызык-мәзәк, әмма барысына да хас уртак сыйфат: үзенчәлекле, мәгънәле, оригинально. Чөнки аның һәр эше, кеше буларак һәр гамәле поступоклар тезмәсеннән иде, дисәк арттыру булмастыр. Тик... «тормышта үзенең кирәкле чын урынын тапканчы» дигән җөмлә өстәп, урынын тапкач, ул инде әсәрләрен поступок итәргә тырышып язды. Әлбәттә, ул һәр язганы поступокка тиң түгеллеген дә белә иде.

Эзләнүләре чоры турында үзе һәм башка белгечләрнең язганнарына шикләнеп укырга безнең сәбәп-нигезебез юк. Драматург буларак, үзенең гомерлек урынын алгач, һөнәрен әсәрдән-әсәргә камилләштерә, шомарта барып, соңгы пьесаларында чын оста иде ул. Осталык турында сүз чыкканда, гади генә итеп, «мин инде бу эшнең җаен да таптым, тәмен дә беләм», дия иде.

Гомумән, эчендәге — тышында булса да, «сер тотмас үрдәк» тә түгел иде ул. Яшьлек дуамаллыгы белән кылган гөнаһлы гамәлләре өчен, тиеш булмаса да, курсташларыннан гафу үтенүе хәтердә. Компанийский, күндәм егет иде. Минминлегенә тимәгәндә, тәкъдимнәргә юмарт (аның тәкъдиме белән 1 курсны без коммуна булып яшәдек), мактанучыларга сизгер, мактауларга саран, кемнең дә булса, хаталанып, ялгышуларын тикшерү җыелышларында, кызып китеп, «куарга», «чыгарырга» дими (андыйлар да булды), ә кешенең киләчәге «ноктаиназарыннан» чыгып, үз фикерен әйтә һәм җәмәгать шуңа ризалаша иде.

Ул гомере буе өйрәнүдән туктамады, шуннан тәм тапты. Ләкин аңа кемнедер, нәрсәгәдер өйрәтү, акыл сату, ин өлгергән чакларында да белгәнен белдерергә ашыгу, табышларын кабатлау ят иде.

Туфанны, кеше буларак, сабакташ буларак, күпмедер микъдарда коллегам буларак белгәнем шулар: ул әйтәсен — кистереп әйтә, бирәсен — бирә, аласын — ала. Шикләнүләргә, ике төрле уйлауларга, ялгыш аңлауларга урын калдырмаучы ихлас егет иде. Әмма беркатлы, бер «каптырмалы» кеше түгел иде ул. Никадәр генә гади булып калырга, ачык булырга тырышса да, күңелендә аның әйтелмәгән серләре, ачылмаган «бөреләре» калгандыр, ясалмалык микроблары йоккандыр дигән шиккә дә урын бар иде. Дөрес, «милләт сакчысы» дигән имиджны Туфан, шиксез, үз хезмәтләре белән яулап алуга ирешә. Аңа ни сөйләсә дә ышаналар иде, ышандыру куәсе бар иде. (Төп һөнәре артист бит!)

Шунысы сагайта иде: әдип үзе сөйләгәннәргә (олы җыелышларда), үзе өндәгәннәргә, шуларның тормышка ашачагына, теләкләргә ирешәчәгенә үзе инана идеме икән? (Паспортта милләтне күрсәтү графасын гына алыйк.) Яшерен-батырын түгел, бу мәсьәләдә Туфаннан көлүчеләр аңа ышанучылардан күбрәк булды. Ярый, паспортка сынар бит өстәп беркетергә рөхсәт иттеләр, итүен... җиңүме соң бу?

Тулы җиңү булмаса да, бу факт җиңеп була икәнне күрсәтте. Ә җиңелгән милләт өчен бу бик тә кирәкле поступок иде.

...Туфан иҗатының бер чорында «сәхнәне кем тота иде, драматургия базары кемнәр кулында иде?» дигәндә, шикләнмичә, театр сәнгатенә түгел, гомумән, сәнгатьтән ерак кешеләр кулында иде дисәк, кемнедер кимсетү булмас. Алар партиягә, хакимияткә ни кирәген яхшы үзләштергәннәр, язганнарын диалогларга бүлү технологиясен беләләр.

Алга барышлар турында хәбәрләр газета-журналларда чыгута, радио-телевидениедә яңгыраугa, актуаль темаларга язылган «писсылар» тут как тут! Куймый кара! Туфан бу юл белән бара алмый. Ул, әлбәттә, илдә бер генә партия хакимлек итүен, аның идеологиясен яхшы белә. Белә торып бөләргәме? «Пионерская правда» газетасында өч сан рәттән генераль секретарь сөйләгән нотыкның тулы варианты басылган заманнар бит! Чак кына читкә тайпылу да кешедән «анти» ясый. Ул чор драматургиясенә бүген күз салган кеше, шундый әсәрләр буенча куелган спектакльләргә неужели тамашачы йөрде икән? дигән сорауны бирми кала алмый. Йөрде! Нишләсен! Карады! Тик ул аннан берни дә ала алмады. «Тирәнлек» дип аталсалар да, алар бушлык иде.

Бүген телевидение каналларының, тапшыруларны бүлеп, реклама күрсәтүләренә күнеккән кебек, шул буш «имезлеккә» күнекте кеше. Рекламаларның мәгънәсез, беркемгә кирәкмәгән «пустышка» икәнен белсә дә, карауга имитация ясавы кебек.

Драматургия ишеген шакыганда, Туфан боларны белә, ситуацияне яхшы аңлый. Ана үз тамашачысын табып, шул тамашачы телендә язу кирәк! Алар күрергә теләгәнне күрсәтергә, тамашачыны үзенә каратырга, тыңлавына, аңлавына һәм хуплавына ирешергә кирәк. Хакимияткә оппозиция постына басып түгел, ә үз позициясендә калып. Туфан социализм «уңышларына» мәдхиядән качып, язганнарында милләткә сыена; милләтебезне яшәтү сагына баса. Милләт эчендә дә бөтен илгә гыйбрәт булырлык проблемалар тулып ята ич! Яхшысын да, яманын да сәхнәдән күрсәтергә лаек булуга инана ул; бары тик, милләтчелектә генә гаепләмәсеннәр дә «тырнак астыннан кер» генә эзләмәсеннәр. Ул тугры сүзле, ачык күңелле, житешсезлекләрне турыдан-туры әйтүдән курыкмаучы әдип исеменә лаек булырга омтыла. «Тырышкан ташка кадак каккан», диләр. Туфан атлы замандашыбыз кадакны күп какты, ташка да, агачка да, хәтта кадак тотмас нәрсәләргә дә каккалады. Кадак тотарлыкка какканнары кубарып алырлык түгел — гомерлек булды. Ничә пьеса язгандыр — санап караганым юк. Әмма төрки дөнья ярты гасырдан артык аның әсәрләре буенча спектакльләрне яратып карый.

Театрның символы — битлек-маска. Туфан театрга керәшеп, урау юллар белән кайтмады. Аның әсәрләрен куяр өчен театрлар үзләре көрәште. Бу феноменны ничек аңларга һәм ничек аңлатырга? Милләт сакчысы булу Туфанның имиджы гына идеме? Битлегеме? Әгәр «битлеге иде» дисәк — андый битлек белән яшәү куркыныч булуны аңламаслык егет түгел иде бит Туфан Миңнуллин.

«Битлегенә кеше күнегә» дип тә сөйлиләр, «битенә битлеге ябышып үскән» диючеләр дә бар...

...Битлекләрне күз өчен һәм авыз өчен тишекләр калдырып ясыйлар. Кайбер бәхәслерәк темаларга чыгышлары вакытында битлек тишегеннән күзлеге чалынып китсә дә, Туфанның күзе белән очрашу мөмкин түгел иде.

Сагыш идеме ул күзләрдә? Ачумы? Өметме? Ышанычмы? Көлүме? Әллә шуларның барысы дамы? Бу — Туфаннан калган сер.

Социаль хәтер дигән төшенчә бар. Аның халык күңелендә, милләт күңелендә булганын, бүлмә жилләткәндәй, тәрәзә ачып кына «жилләтеп» булмый, котылып булмый. Ул — кала, яши. Күпме яшәр? Билгесез.

Бездә халык барысы турында да, һәрчак бөтенесен белеп яши, белгәнен белдерми яши. Тормышлар үзгәрә, чынбарлыклар алышына. Кеше үз белгәнен яши-яши үзеннән дә яшерергә өйрәнә; шулай итмәсә, яшәү мөмкинлеге юклыкны аңлап гамәл кыла. Бу — ике катлы чынбарлыкта яшәү дигән сүз. Кайчан башлангандыр андый яшәү һәм аның ахыры булырмы — беркем дә өзеп кенә әйтә алмый, булдыра алганча, ике катлы чынбарлыкта яшәргә өйрәнә кеше. Бу — битлексез яшәү мөмкин түгел дигән сүз. Аерым шәхесләрнең генә түгел, аерым фиркаләрнең, халыкларның, милләтләрнең дә үз битлекләре бар, дигән сүз. Фажигаме бу? Түгел. Шул битлек астына яшеренеп, төсен, киемен үзгәртеп, тоталитар система гына кире кайтмасын. Ул система шәхесне дә, милләтне дә танымый, үзен генә таный. Сыйныфларга бүлү чалгысыннан котылган халыкны милләтләрне бетерү чалгысы гына кыра башламасын. Ә чалгы чүкегән тавыш һаман колакта...

«Без китәбез, сез каласыз» пьесасы буенча фильмны эфирга чыгарыр алдыннан күрсәткәч, Тукайны станциядән утарларына алып кайту өчен Акчуриннар

жигеп барган фаэтонны Туфан өнәмәде: «Фаэтон шулай буламыни, нигә чынын тапмадыгыз?» — диде.

Каян табарга мөмкин булгандыр, мәсьәләгә тәгәрмәч биеклегеннән каравы мине Туфан әсәрләреннән аерды, әмма араны бозмады, күперләр сүтелмәде. Аның пьесалары буенча куелган спектакльләрдән читләтмәде. Алар минем өчен генә түгел, күпсанлы татар тамашачысы өчен күңелгә баручы рухи азык иде. Әйбәтме бу? Автор өчен унай күренешме? Отышлы спектакльләрдән милләт ни ота? Һәр әсәре сәхнәгә менүдән автор нәрсәгә ирешә? Кафка дигән язучы үз әсәрләрен бастырмыйча яшерүен ничек аңларга?

Кирәкми безгә Кафканың «поступогын» аңларга тырышу! Кафка драматурглар өчен үрнәк түгел. Пьеса язылa икән — ул куелырга да тиеш! Куелмаган пьеса язучыдан драматург тумый. Куелу өчен режиссёр кирәк. Бу әле пьеса язган авторны теләсә кайсы режиссёр ачып, драматург ясый ала дигән сүз түгел.

Автордан драматург ясау өчен үз театры булган режиссёр кирәк. Артистлар штаты һәм бинасы булу мәгънәсендә түгел. (Театр Мейерхольда дигән кебек — үз театры.) Марсель Сәлимжановның Туфанга кадәр үк үз театры бар иде. Ягъни, үз стиле, иҗат методикасы, үз йөзе, тәгълиматы булган театр. «Мәктәп» дисәк, театр белем тарату йорты да, дәвалану урыны да түгел. «Курыкмыйк театрны күңел ачу урыны диюдән, — дигән иде Марсель бер интервьюсында. — Күңел ачарга дип килгән тамашачы пәрдә ачылуга, безнең тылсымда. Аны вәгазь белән куркытмас өчен, вәгазьне нәрсәгә төреп бирү дә безнең кулда. Фаҗигаме, мәзәкме — анысы тамашачы ихтыярында, иҗтимагый хәлләргә карап».

Бу тандем үзе аерым тикшеренүләргә лаек очрак булганлыктан, сүзне кыскартып, алар тудырган спектакльләрне генә карыйк. Марсель хаклы: аларның күбесе — күңел ачу товары, тамашага күбрәк тамашачы җыю коралы. Артистның эше образ тудыруның соавторы булудан үзгәртелеп, рольне башкаручы булуга гына кайтып кала.

Иҗатының башлангыч чорында илһамланган максатлардан читләшеп, үзе кире какканнарны яналык дип тәкъдим итүче авторларның финалы аянычлы. Бу — җинелүне Җинү дип кабул итүгә тиң. Чын иҗатчыга — (миссионерга) «туймадылар микән миннән?» дип, вакыт-вакыт иҗади кардиограммасына карап алу фарыз гамәлдер.

Туфан боларның барысын да белә, аңлый, кушыла. Әмма, аның һәрнәрсәгә үз карашы бар иде.

Туфан иҗади «кардиограммасына» карауны беркайчан да онытмагандыр кебек тоела мина. Ихтимал, шул контроле нәтиҗәсендә, әсәрләрендә үзен кабатламады шикелле. Ләкин, бу Туфан иҗатында бер-берләренә охшаш образлар булмады дигән сүз түгел. Тормышта охшаш характерлар очрамыймы?! Очрый! Безнең милли драматургия ул, әгәр шулай дип әйтергә яраса, характерлар бәрелешенә нигезләнгән драматургия булудан бигрәк, вакыт әмере тудырган шартларныкыдыр; ягъни, теге яки бу ситуацияләргә җавап җимешедер. (Революция, колхозлашу, сугыш, чирәм җирләр, перестройка һ.б.) Шартлар нинди генә булсалар да, алар еш үзгәрүгә дучарлар (бүген колхоз, иртәгә ООО). Шуның өчендер дә, милли әсәрләребезнең читкә таралу радиусы чикле, таләп зурдан түгел, гомерләре дә чамалы.

Туфан — татар драматурглары арасында чит халыклар сәхнәсенә менгәннәрдән, беренчесе булмаса, иң популяры булгандыр.

Минем аңлавымча һәм карашымча, әсәрләрендә Туфан тирәнлеккә карап, аннан кирәген эзләүче түгел иде. Ул тормыш тирәнлегеннән өскә, күккә карап йолдыз эзләүчене хәтерләтә иде. Мәгълүм булганча, чокырдан һәр яктылык чыганагы кояш булып күренә. Тәмәке утын да йолдыз дип алданасын...

Пьесаларында ул кеше ирege турында җир улының, авыл кешесенең гади — тирән фәлсәфәсен җинел үзләштерерлек сәхнә формаларында әйтә белде һәм әйтте.

Тормыш материалы белән сәхнә өчен язылганнары арасында Туфанның үз шәхесе ята. Ул таныла һәм җуелмый.

Хатирәләр — кем язса да, аерым бер кеше хәтере сыйдырган хәтерләүләр генә. Чын хатирәләр, үзгәрмәс хатирәләр һәр авторның әсәрләрендә. Аларның гомере озын-кыска булу шул әсәрләр тәэсирендә тәрбияләнгәннәр кулында. Ягъни, күңелләрдә нинди урын биләп яшәячәген автор үзе яза.

***

Туфан Миннуллин турындагы истәлек-хатирәләремне тагын да тулыландыру максатыннан, без — щепкинчылар театрга җыйналдык. Әңгәмәдәшләрем — Россиянен халык артистлары, Тукай премиясе лауреатлары Ринат Тажетдинов, Әзһәр Шакиров, Равил Шәрәфиев, Россиянен атказанган, Татарстаннын халык артисты Наил Дунаев, халык язучысы, Тукай премиясе лауреаты Рабит Батулла, Татарстаннын һәм Башкортстаннын халык артисты Гөлсем Исәнгулова.

Гөлсем ханым хатирәләрендә Туфаннын щепкинчылар бердәмлеге өчен янып йөрүенә күп мисаллар китерде, ярдәмләшү фактларын санады, ана барыбызнын да рәхмәтле булуыбызны ассызыклады.

— Кылган яхшылыклары өчен Туфан оҗмахка керми калмас. Ул анда булса, безгә дә урын табылыр! — диде уенын-чынын берләштереп, ышаныч белән, Гөлсем Исәнгуловага башка щепкинчылар кушылды.

**Рабит Батулла:**

— Күп эшләр майтарган кешегә, «ат кебек эшли», диләр. Әйтер идем: Туфан Миннуллин трактор кебек эшләде. Байтак кына сәнгать кешеләре, Аллаһ тарафыннан бирелгән сәләтенә атланып, жай гына яши бирәләр, артык ертылмыйча гына, алар шул сәләткә ияреп баралар да, сәләт аты әлсерәгәч, төшеп тә калалар.

Анадан туганда, барлык кешеләр дә сәләт оеткысы белән туа. Шул оеткыга хезмәт килеп кушылса, оеткы сәләткә әверелә. Сәләткә хезмәт кушылса, сәләт талантка әйләнә. Талантка хезмәт кушылса, талант даһи була. Яшерен-батырын түгел, совет мохитендә кем обком тирәсендә күбрәк кайнаша, шуларга була иде бүләкләр дә, олы исемнәр дә, фатир-матирлары да. Андыйлар арасында бар иде чын куәгә ия шәхесләр, уртачалары да аз түгел иде.

Туфан Миннуллин исемле шәхеснен алмаган дәрәҗәсе, яуламаган исеме юк. Шушы дәрәҗәләрнен барысына да Туфан тырышлыгы, иҗади куәсе аркасында иреште. Анын бер генә бүләге турында да «лаексыз алды» дип әйтергә берәүнен дә теле бармас. Без катлаулы, алмашынучан тормышта яшәдек, барыбыз да яхшы идеянен бозылган чорында балигъ булдык. Кемдер шул идеянен халыкка каршы эшләнгәнен анлап, шул идеягә хезмәт итте, кемдер шул идеягә чын күнелдән инанып, халыкка каршы сәясәт алып барды. Кайберләребез сынды, шаукымга бирелде, кайберләребез мәсләгенә — принципларына хыянәт итмәде. Ялган идеяләр шаукымына бирелмичә, шушы шаукымлы мохиттә дә үзләренен максатын, намусын, вөҗданын саф килеш саклап калганнарга һәйкәл куярга кирәк. Хыянәт итмичә калу — бөекләргә генә хас. Алар, ул каһарманнар аста ут янып торганда, өсләрендә Домокл кылычы асылынып торганда, кылдан нечкә, кылычтан үткен күпердән исән-сау чыккан затлар: Һади Такташ, Хәсән Туфан, Тинчуриннар, Борнашлар, Муса Җәлил, Гамил Афзал, Сибгат Хәким, Рәшит Әхмәтҗан, Аяз Гыйләҗев, Нурихан Фәттахлар.

Туфан Миннуллин да шулар нәселеннән!

Миндә Нәҗибә ханымнын кайсыдыр бер газетага биргән интервьюсы саклана, авырып тору сәбәпле, бүген килә алмады, анын белән дә таныштып китик әле.

«Туфан Миннуллин минем өчен күзгә-күз очрашканчы ук «Туфан» иде инде. Болай әйтүемнен сере шунда: безнен халыкта сирәк очраучы Туфан дигән исемгә мин үземчә ниндидер серлелек, тирәнлек, зурлык кебек мәгънәләр салып карадым. Әлбәттә, дөньяны суга батыручы туфан итеп түгел. Хәтта бу образ белән чагыштырганда да хакыйкатьтән артык читләшмәс идек, дип уйлыйм. Чөнки ул үзенен чып-чын тирән һәм зур драматургиясе белән, татар һәм башкорт театры сәхналәренә Туфан булып, давыллап килеп керде...

Анын белән күзгә-күз очрашуыбызга да ярты гасырдан артык вакыт узды. Малеевкадагы иҗат йортында булды бу хәл. Беренче башкорт шагыйрьләре алдына гаҗәп җегәрле һәр хәрәкәте ирләрчә җор булган, кара мыеклы, кара күзле егет килеп басты. Шунда, шул минут эчендә, без бер-беребезне анладык. Өстәлләребез тиз үк кунак өстәленә әйләнде. Әйе, ничек утырырга белә идек без ул чагында.

Кунакнын үз фикерен ярып әйтү сәләтендә, сүзен җөпләп, калын тавышы белән нокта куя белүендә аеруча бер тарту көче барлыгы сизелде. Фикерләү үзенчәлегеннән чыгып та, һәр җөмләсендә ниндидер тәвәккәллек һәм омтылышлы көч барлыгын



*Менә алар — щепкинчылар: Миргалим Харисов (сулдан уңга), Гөлсем Исәнгулова, Рабит Батулла, Ринат Таҗетдинов, Туфан Миңнуллин, Нәҗибә Ихсанова, Наил Дунаев, Фирдәвес Әхтәмова, Әзһәр Шакиров.*

тоеп та мин аның кешелек сыйфатларын бәһаләргә тырыштым. Әйтик, кем булыр икән ул, әгәр дә язмышы аның кулына каләм тоттырмаган булса?.. Имән мичкә ясаучы яки чана табаннары бөгүче булмас иде микән? Һәрхәлдә, сәнгатькә якын торган, сирәк очраучы бер һөнәр кешесе булыр иде, билләһи.

Ләкин зур талант иясе һәм якты шәхес Туфан Миннуллинга язмыш юмарт та, мәрхәмәтле дә булды. Ул ана, илең һәм халкың хакына дип, үзенең акыллы һәм моңлы да, фәлсәфи һәм нәзакәтле дә каләмен тапшырган. Тылсымлы шул каләм иясеннән театр сәнгате зур күләмле кырык пьеса кабул итеп алды. Моннан тыш, әдипнең исәбенә чыкмаслык бер пәрдәлек пьесаларын, хикәяләрен, алтын бәрабәренә торырдай җыр басмаларын тезеп китәргә булыр иде. Ә инде аның җәмәгать эшчәнлеге һәм шуна бәйле чыгышлары, ялкынлы публицистикасы — үзе бер кул тимәгән хәзинә.

Әмма саннарда гынамыни хикмәт? Хикмәт — ул иҗат иткән һәр образның аңы, акылы һәм йөрәге яраткан һәр фикеренең, «Мин — Туфанныкы!» дип кычкырып торуында. Иҗатның чын асылы да шул үзе түгелмени?

Туфан инде укыганда ук үзен бездән ун башка өстен итеп күрсәтә белде. Әгәр Туфан артист булса, үзен драматургиядә шуның кадәр күрсәтә алмас иде. Чөнки сәхнә икенче өлкәгә көчүне гафу итми. Сәхнә аны «үтерер» иде кебек. Театрдан китү аның бәхете булды. Ләкин шул вакытта актёр булса, ул үз теләге белән театрдан китмәс иде. Ана, билгеле, үзенең сәбәпләре булды. Артык туры сүзле, үз фикерен һәрвакытта да ярып әйтә торган кешегә җылы урынга җайлашу, ай-һай, җинел түгел шул.

«Драматург Туфан Миннуллин хатыны булу авырмы?» — дип мина еш кына сорау бирәләр. Чынлап та, Туфансыз мин театрда ничек яшәгән булыр идем икән? Мин очраклы рольләрдә үстем. Үземнең көчем, тырышлыгым аркасында үстем. Дөрес, Туфан драматургиясендә бик күп рольләр башкардым. Бәлки ул минем өстәмә бәхетемдер. Туфан әсәрләрендә уйнау мина икеләтә авыр иде. Чөнки ул әсәр Туфанның башында туганда ук, аның язылу процессы минем аша узган була.

Ике иҗат кешесенә бер түбә астында тормыш итү җинел бирелми. Шулай да, мин язмышыбыздан канәгать. Кызыбыз Әлфия үзен тапты. Ә оныкларыбыз булу Туфанга илһам бирде».

**Ринат Тажетдинов:**

— Бик ихластан әйтелгән сүзләр...

**Әзһәр Шакиров:**

— Туфанның бу дөньядан китеп баруына һаман да ышанасы килми. Ул бер вакытта да мин авырыйм дип сөйләгәне булмады. 2012 елның 26 апрелендә Тукайга чәчәкләр куйганда:

— Туфан, хәлең ничек, больницада ята дигәннәр иде, дип сораган идем. — Үзең күрәсең хәлем ярыйсы, — дип җавап бирде. Өченче майда аны җирләдек. Әлбәттә, кешенең гомере чиксез түгел, ул хәзер безнең буынга килеп терәлде. Кем алдан, кем арттан китәсен белмисен, ләкин инде чират житкән. Шулай да, ул әле эшләргә, яшәргә ашкынып тора иде, шуна күрә аның үлемен яшен суккандай вакытсыз дип

кабул иттек. Шунысы үкенечле түгел: Туфан эшлисе эшләрен эшләде дияргә була. Без бит әйтәбез, үлгәч тә өч көнлек эш кала дип. Безнен театрда 50 ел эшләвебезне, жыелып, зур бәйрәм уздырабыз дип йөрүче, аны оештыручы да ул булды. Барыбызны бергә жыеп, сабакташларын тагы бер мәртәбә халкыбызга, тамашачыларга күрсәтергә теләде. Иптәшләренен талантлы булуы белән чын күңелдән горурлана белә иде ул. Без дә Туфаннын кем икәнен, нинди язучы, драматург икәнен күреп, тоеп яшәдек.

Үзенен әсәрләрендә жаныбызны борчыган сорауларны күтәреп, юк, болай яшәү мөмкин түгел дигән фикерне әйтте. Татар яшәр әле, тиз генә бетмәс дип уйлыйм. Шуна күрә бүген миндә Туфан белән горурлану хисе жанымны жылытып тора.

**Ринат Тажетдинов:**

— Щепкинчылар, студия буларак, театрыбыз тарихында аерым бер урын били. Галәттә, милли студияләрдә укып чыккан артистларнын күбесе биш-ун ел эчендә тарала да бетә, театрда бер-ике актёр торып кала. Татар студиясен тәмамлаганга илле дүрт ел, әмма Камал театрында щепкинчылар әле һаман ижат итә.

Туфан Миннуллин да щепкинчы, ул да һаман театрда. Драматург буларак, анын кендеге мәңгегә театрыбызга бәйләнгән.

Туфан — бәхетле драматург. Чөнки ул үзенен теләктәшен, ижатташын — режиссёр Марсель Сәлимжанны тапты. Марсель дә үз Туфанын тапты. Әнә шул табыш аларнын икесен дә үстерде, олы итте. Шулар өстенә, Туфан — эш аты буларак жигелеп эшли торган адәм иде. Анын армас-талмас эшчән икәнлеге, үжәт холыклы икәнлеге 1956 елда ук, училищеда укыганда ук беленде. Гел бишлегә генә укырга да, кайткач ук кәгазь-каләмгә тотынырга да, тамак туйдырыр өчен төнге эшкә ит комбинатына йөрергә дә үжәт, максатлы кеше генә ирешә ала.

Туфан яза, яза да яза Туфан — ятагы өстендә дә, тумбочкасы эчендә, өстәл өстендә кәгазьләр, ижат жимешләре. Туфан яза, бүлмәне кәгазь туфанына батыра. Язганын шундук сабакташларына укып та чыга. Яза башлаган егеткә анын әсәрен тынлау олы бәһа. Һәм Туфан үзенен беренче тынлаучысы, беренче тамашачысы, сабакташы вә сонра анын пьесаларында унышлы образлар тудырган артистка Фирдәвес ханым Әхтәмгә чиксез рәхмәтле икәнен еш сөйли иде.

Туфаннын икенче бәхете яхшы иптәшләре, сабакташлары булудадыр.

Театр — ул күмәк хезмәт мәйданы. Театрыбыз мәшһүрләре Туфанны күтәрсә, Туфан исә, үз чиратында, театрнын олы терәге булды. «Театр» дигән могжиза илендә ул 50 ел мәйдан тотты, тотачак.

Сәнгать өлкәсендә «Тинчурин театры», «Хәй Вахит театры», «Камал театры» дигән аерым бер чорлар бар. «Туфан театры» дигәч тә, без мәгълүм бер дәверне, үзебез яшәгән заманны күз алдына китерәбез.

**Равил Шәрәфиев:**

— Туфан революционер иде, диярлем мин, тик үзе сайлаган язмышында, үзе сайлаган һөнәре өлкәсендә.

Без Казанга кайтып эшли башлаганда, театрларыбыз бик кызганыч хәлдә иде. Тормыш чынбарлыгын чагылдырган пьесалар юк, сәхнәдә бара торган әсәрләрдәге персонажлар партия рөхсәт иткәнчә ясалган «курчаклар» гына. Туфан тамашачыни көткәнне түгел, ә аны нәрсә кызыксындырганны сиземләп, сәхнәгә заман тамашачысынын үзен чыгарды, үз проблемалары белән, үз телендә сөйләтеп, тормышчан конфликтлардан качмыйча.

Кешегә, ягъни тамашачыга үзен-үзе күрүдән дә кызыклы тамаша юк бит. Бәлки анын драматургиядәге революционерлыгы шушыдыр?

**Әхтәм Зарипов:**

— Әйе, үз вакытында галәмәт кирәкле, зур эше иде бу яна авторнын.

Үз эшенен классик осталары, сәнгатьнен кайсы өлкәсенә күз салсак та, кайчандыр «авангардист» булганнар, «новаторлар» дип аталганнар. Бүген «классик» исеменә ия һәр оста — кичәге авангардист-новатор, үзсүзле сәнгатькәр ул. Үзсүзле иде Туфан?

**Наил Дунаев:**

— «Миләүшәнен туган көне» әсәре белән сәхнәләрне яулавын башлаган Туфан Миннуллинны татар драматургиясе осталары Камал, Тинчурин традицияләренен ышанычлы дәвамчысы дигәнебез нигезле. Үзсүзле булмаса, ул моңа ирешмәс иде.

**Әзһәр Шакиров:**

— Рәсәйдә революцион ситуациянен беткәне дә, бетәчәге дә юк. Тик революционерлары гына сирәк туа.

Туфанның үзе сайлаган иҗат өлкәсендәге революционерлыгын раслаучы фактларның тагын берсе — ул беркайчан да хакимиятнең «агитатор блокноты» булмады. Аның язып, сәхнәгә менгезгән темалары вазгыятьне чагылдырсалар да, көндәге хакимият сәясәтеннән еракларды. Ил-корабльнең тишек булуын, трюмнарга су тулуын белми, күрми язды, дигән сүз түгел бу. Өске палубалардагы, каюталардагы пассажирларга трюмның тишеклеген әйтеп, паника тудырудан ни фәтва? — бу аның таяну ноктасы. Аның иҗади игътибары өске һәм аскы палубалардагы пассажирлар арасындагы мөнәсәбәтләрдә, аларның сәфәре хәвефсезлегендә булды.

Әхтәм Зарипов:

— Моңа ничек ирешә сон ул? Әгәр әсәренең бер персонажы кабахәт кеше икән, ул аның бозыклыгын сурәтләп тамашачыны куркытмый, ә игътибарны аның мәзәк яки мәгънәсез якларына юнәлтә. Көлдерергә тырышмаса да, тамашачыга кызыклы, гыйбрәтле бу. Төп каһарманнарын тасвирлаганда, аларны тиешеннән тыш бизәргә, «әйбәтләргә» тырышмый — ничек күрә, шулай сурәтли. Шулай да, яхшы якларын алгарак чыгарып, начарлыкларын күләгәдә калдыра. Ә инде, кирәк булганда, бунтарь, көйсез холыклыларны тасвирлаганда, киресенчә, каһарманның әхлаксыз, ямьсез якларын күрсәтүдән дә качмый. Сәхнәдә куелган 40 әсәрдән берәр генә персонажга тукталсак та, бу бик озынга китәр иде. Шуңа күрә аның язган төп мәүзугларына, темаларына гына күз салыйк. Аны гражданин һәм иҗатчы буларак борчыган төп мәүзуглар: милләт, хакыйкать, хөррият. Әгәр дә Туфаннан: «Кайсын сайлыйсың: милләтнеме, хакыйкатьнеме? Әллә инде милләт белән хөрриятнеме?» — дип сорасалар, Туфан, икеләнүсез: «Хөррият белән хакыйкатьне», — дияр иде. Кемнәрдер, аны төзәтеп: «Милләт — үзе хөррият тә, хакыйкать тә бит!» — дисә, сабакташыбызның җавабында: «Бу инде чын демагогия!» — диячәгенә шикләнмим. Туры сүзле, ихлас кеше иде.

**Рабит Батулла:**

— Туры сүзлене яклаучыга туры сорау: ник язды Туфан?

**Әхтәм Зарипов:**

— Туфан, профессиональ язучы булганнан, «тик тормыйм, язучы булгач, язарга кирәк»тән чыгып түгел, әйтер сүзе кирәк булганнан чыгып язды. Ул үзенең миссиясе милләт сакчысы икәненә инанган чын әдип иде.

**Наил Дунаев:**

— Ялган әдипләр дә буламыни?

**Рабит Батулла:**

— Язарга өйрәнеп була, иҗатка өйрәнеп булмый. Иҗатка очраклы килеп керсә дә, Туфанның иҗаты очраклылык түгел. Аны заман, чор, милләт, тормыш иҗатка китерде, язарга этәрде. Каләм — аның яшәү, көрәшү, исбатлау, ышандыру коралы булды. Туфан теленнән күккә чөелгән фикер-сүзләр җиргә төшүгә, ягъни сәхнәгә менүгә, аякланып, төбәлгән урыннарына — күңелләргә урнашып, үз булып яшиләр. Бу — чын чичәнлек галәмәте бит!

**Равил Шәрәфиев:**

— Туфан язганнарын сын белән чагыштырганда, кайчак өтергесез — балта белән юнып ясалган кебек тоелсалар да, алар — чын сынчы ясаган сәнгать әсәрләре. Ә сәнгать әсәренә — сынга бәһа биргәндә, аның нәрсә белән, ничек ясавына да, охшаган-охшамаганына да түгел — оригинальлегенә һәм нинди уйлар уйлатуына карыйлар. Кыйммәте шунда.

**Әзһәр Шакиров:**

— Дөрес, бер пьесасында да Туфан ике икең — дүрт җаваплы сорау гына куймас, ә һәркемнең үз җавабы булырлык сорау куяр. Ягъни, уйлы кеше уйланыр сорау.

**Равил Шәрәфиев:**

— Әгәр әсәрдә күтәрелгән проблеманы укучы-тамашачы үзенеке дип таный икән — бу инде авторның уңышы, куйган максатына ирешүе дигән сүз. Һәрхәлдә Туфан, мылтык шартлатуга кызыгып, читәнгә кунган саесканга төбәп атмады, таратуга



*III курстан соң каникул вакытында.*
*Күлле Киме авылы (хәзер Әтнә районына керә), 1959 ел.*

ирешмәсә дә, кояшны каплаган болытка төбәп атты.

**Әхтәм Зарипов:**

— «Атты» дигәнебез «холостой выстрел», ягъни шартлау тавышына кызыгу гына түгелме?

**Равил Шәрәфиев:**

— Хикмәт аткан һәр ядрәнен саесканга тиюендәмени? Бәбкәне «чәллерүне» күзләгән карганың куркып очуы да, мылтык шартлаткан төбәктән бүре качуы да, хуҗасыз этләрнең юашлануы да кешегә файда иң. Туфан әсәрләре буенча куелган спектакльләрдән тамашачының күңеле тынычланып, чистарынып чыгуы, яшәүнең бәхет булуына ышанычы, өметләре артуы шикләндерми мине.

**Әхтәм Зарипов:**

— Ә нәрсә шикләндерә?

**Равил Шәрәфиев:**

— Синең соравыңдагы «холостой выстрел» дигән фикернең «аскормасы». Туфан «һөнәрче түгел, ә оста кәсепче иде» дигән кинаяле фикер түгелме бу?

**Әхтәм Зарипов:**

— Үз соравына үзеннән җавабын да сорала. Чыннан да, һөнәрче югарылыгындагы кәсепчеме, әллә һөнәрен кәсепкә әвереләргән иҗатчымы Туфан Миннуллин атлы драматург — үзен классик дип атаганны ишетеп язган әдип?

**Наил Дунаев:**

— Иң олы сәнгать — иң камил кәсепче тудырган әсәр ул.

**Гөлсем Исәнгулова:**

— Сәнгать кәсеп җимеше була аламыни?

**Равил Шәрәфиев:**

— Сәнгать — баш һәм кул катнашында туган күңел, хыял җимеше. Кәсеп план җимеше булса да, рухсыз эшләнми. Рух — икесенә дә уртак.

**Рабит Батулла:**

— Әгәр җимешнең саны сыйфатка тәэсир итсә?

**Наил Дунаев:**

— Кәсеп белән һөнәр бер-берсен юкка чыгаручы антогоник төшенчәләр түгел. Икесенә дә илһам, стимул, кирәклелек кирәк.

**Әхтәм Зарипов:**

— Ылыслы урман озонлы, саф һавалы булса да, анда озак йөрү арыта, туйдыра. Ә менә катнаш урманда күпме йөрсәң дә, туйдырмый да, арытмый да. Туфан урманы нинди урман?

**Рабит Батулла:**

— Туфан иҗаты — катнаш иҗат урманы ул. Анда һәртөрле үсемлек җимеше.

**Әхтәм Зарипов:**

— Туфан Миннуллин кайсы әсәре белән, төрле милләтләр тарафыннан танылып, мәңгеләшер дип уйлыйсын?

**Равил Шәрәфиев:**

— Мин күрәзәче түгел. Барыбыз күреп, ишетеп белгәннәремнән чыгып кына әйтә

алам: Туфанны төрки халыклар яхшы белә, таный, ышана, ярата. Безнен милләт аннан аласын да житәрлек алды, бирәсен дә мул бирде.

**Әхтәм Зарипов:**

— Бер пәрдәле реалистик пьесалары белән танылган Америка язучысы О'Нил үзе исән чакта бер әсәрен дә чыгармаган, имеш. Ә үзе үлгәч дөнья күргән әсәрләре («Кардифтан көнчыгышта», «Караиб ае», «Карама төбендәге мәхәббәт», «Боз сатучы килгәч» әсәрләре) бүген дә сәхнәдән төшми икән.

**Ринат Тажетдинов:**

— Соравынны әйткәнче үк җавабым: безнең заманда милләт тормышы белән кызыксынучы булса, кайсы әсәре сәхнәгә куелса да, аңа үз тамашачысы табылачак. Чөнки аларда безнең чор тормышы «концентраты». Кирәк булса, «чәй итеп эч», кирәксә, спектакленә барып кара.

**Әхтәм Зарипов:**

— Һәркайсында тамашачы үзе көткәнне табачакмы?

**Рабит Батулла:**

— Тамашачы спектакль карарга билгеле бер әзер фикер белән килә. Көткәнен тапса, спектакль әйбәт булды, — ди, тапмаса — хурлый. Драматургнын максаты тамашачыга ошау түгел, ә аны уяту, уйландыру, будоражить итү, ияртү.

Туфанда тамашачыга ошау кайгысы түгел, тамашачыны үзгәртү, үзенә ияртү уе көчлерәк булгандыр. Шуна да аны яраттылар, хупладылар, ахырда иярделәр.

**Әхтәм Зарипов:**

— Сарык көтүе урамга кергәндә, көтү каршында колга тотып торсаң, алдан кайтучы аны сикереп чыккан икән, колганы тартып алсаң да, шул турыда барлык көтү сикерә. Туфан пьесалары буенча куелган спектакльләрдә юк киртәне сикерүләр очрыймы?

**Равил Шәрәфиев:**

— Тулып ята. Туфан спектакльләрендә генә түгел. Гомумән, безнең тамашачы, элек-электән, театрга көлер өчен килергә өйрәтелгән. Бу — начар. Авторнын үз идеясен уздырырга көрәшүче икәнен тамашачы кабул итми, зәвыклы автор диктовать итүне күтәрми.

**Наил Дунаев:**

— Кушылам.

**Гөлсем Исәнгулова:**

— Зәвыклы тамашачы тәрбияләү өчен, Туфанны алыштырырлык яңа Туфаннар килүе кирәк.

**Әхтәм Зарипов:**

— Спектакльне барлык тамашачыларнын алкышлар белән кабул итүе уңышмы, уңышсызлыкмы?

**Барсы да:**

— Үзең ничек уйлыйсың соң?

**Әхтәм Зарипов:**

— Менә ничә ел инде мин шушы сорауга җавап эзлим: кем соң ул популяр язучы? Популяр актёр кем? Тамашачының ухажёрымы? Докторымы? Бәхәсләшүче партнёрымы? Анысына җавапны башкалар әйтсен. Мин шуны гына өстәп әйтәм: Туфан безнең заман тудырган милләт хадиме, үзенчәлекле иҗатчы, оригиналь шәхес, хыянәтсез иптәш, кешелекле кеше иде. Ул милләте каршында гади кеше күрмәгән, белмәгән бурычлы булуын тоеп яшәде, иҗат итте. Гел бирергә, калдырырга, булдырырга дип яшәгән шәхес даһилыкка дәгъва кыла ала.

Әлеге сөйләшүләребез Туфан рухына бер дога булсын иде. Амин!

**Әхтәм ЗАРИПОВ,**
*режиссёр*

# ТУФАН МИҢНУЛЛИН: «ШӘЙМИЕВ ЧОРЫ ТАТАР ТАРИХЫНА КЕРЕП КАЛАЧАК»

*Татарстан Президенты Матбугат хезмәтенең эшчәнлеге күптәрле, шул исәптән Президент турында җәмәгатьчелек фикереннән хәбәрдар булу. Бу фикерләр Президентның үзенә җиткерелми, алар матбугатта эшләү юнәлешләрен билгеләгәндә исәпкә алыр өчен җыела. 2009 елның 8 апрелендә Туфан ага Миңнуллин белән Дәүләт Советы бинасында булган әлеге сөйләшү дә диктофонга шушы максатта яздырып алынган иде. Бу әңгәмәнең язмасы беренче тапкыр дөньяга чыга.*

**Нурсөя ШӘЙДУЛЛИНА,**
*1999-2014 елларда Татарстан Президенты матбугат хезмәтенең баш киңәшчесе*

**— Туфан абый, Сез, бәлки, Минтимер Шәрипович белән ничек танышуыгызны хәтерлисездер? Аңа кагылышлы нинди вакыйгалар исегездә калган?**

— Мин үзем туры кеше, анарга хәтле — артист кеше. Һәм мин кешеләрне театрга мөнәсәбәтләре буенча бәялим. Әгәр дә кеше театрга килә, спектакльләр карый яки китап укый икән, мин аны кешегә саныйм. Әгәр кеше, бигрәк тә житәкчеләр, болар белән кызыксынмый икән, мин аларны бик өнәп бетермим. Алар, бәлки, унган-булган кешеләрдер, әмма ләкин аларның барыбер бу дөнья турында фәлсәфи уйланулары таррак була. Әгәр экономистлар, физиклар, математиклар, төгәл фәннәр белән шөгыльләнүчеләр әдәбияттан, сәнгатьтән аерылып яшиләр икән, аларның күңеле бик күпкә ярлы була. Мин аларны начар кешеләр дип әйтмим, һәрхәлдә кешеләр турында уйлау, кешеләрнең фаҗигасен, шатлыкларын, аларның күңел тибрәнешләрен аңлаудан алар мәхрүм. Менә шулай ерактан башлавымның сәбәбе шунда: Минтимер Шәрипович ул, кайда гына эшләмәсен, һәрвакыт театрга килә. Мелиорация министры булган вакытында театрга даими рәвештә йөри, хәтта бүләкләр алып килә иде. Башкаларны да үзенә ияртеп килә иде. Икенче бер шундый кешене беләм — ул Рәис Кыямович Беляев. Ул да үзенең иптәшләре, дуслары, яраннары белән бергә, шау-гөр килеп, театрга килә, спектакль карап, үзенең фикерләрен әйтеп китә иде. Мин Минтимер Шәриповичны менә шул вакыттан хөрмәт итә башладым. Бик нык сөенә иде монарга Марсель Хәкимович Сәлимжанов. «Берденбер рәтле министр», — дип йөри иде ул аны. Безгә әле ул вакытта, дөресен әйтергә кирәк, үзләренең вазифалары буенча гына мәдәният министрлары килә иде, калганнары арасыннан даими рәвештә театрга йөрүче министрларны мин белмим. Аннары соң Минтимер Шәриповичның дәрәҗәсе үсә барды. Әмма ләкин ул театрга мөнәсәбәтен үзгәртмәде. Һәм шуның нәтиҗәсе буларак, болай иркенләп сөйләшеп утыру булмаса да, очрашып сүз алышкан вакытта аның белән сөйләшүе рәхәт, чөнки сөйләшергә тема бар. Тема дигәннән, гел театр турында гына түгел, гомумән, кеше, яшәеш, тормыш, киләчәк, хыяллар турында сөйләшәбез. Аның белән бик озак сөйләшеп була. Кайбер кеше белән ун минут сөйләшәсең дә туясың, тема бетә. Әле икенче бер категория кешеләр бар: иң наданнары, алар белән озаграк сөйләшеп була, тик анда инде төп темаң да — анекдот. Мәзәк сөйләшү, аның да ыржаеп көлә торганнары яки мунчаларда гына сөйләнә торганнары. Ягъни, син бу кешеләрдән бер әйбер алмыйсың. Алар үзләре, белмим, үз әңгәмәдәшләреннән нәрсәдер булса алалардырмы...



*Минтимер Шәймиев (уңнан сулга), Фәрит Мөхәммәтшин, Туфан Миңнуллин.*

Минтимер Шәрипович белән сөйләшкәннән соң, үзенә фикер алып китәсең. Бәхәсле булырга мөмкин ул, синең аны кабул итмәвең яки бөтенләй каршы булуың мөмкин. Ләкин — фикер бар. Чөнки Минтимер Шәрипович — фикер йөртә, фикер уята торган кеше. Һәм ул театрга йөрү дигән бик әйбәт гадәтен обком секретаре булып эшләгән вакытында да онытмады һәм минем иң куанычлысы — Президент вакытында да театрга йөрүне, гомумән, әдәбият белән кызыксынуны онытмады. Ул даими рәвештә йөри. Очрашып сөйләшкән вакытта күпләр әйтә: барасы килә театрга, тик вакыт юк, имеш. Мин инде андый кешеләргә өздереп әйтә алмыйм. Әйтерсең лә безнең Президент бер эшсез, гел театрга гына йөреп торып, бүтән бер әйбер белән кызыксынмый. Карап торсаң аның эшләгән эшен, кайберәүләрнеке белән чагыштырып та булмый. Ә менә ул вакыт таба. Беренчедән, ул, илнең башлыгы буларак, сәнгать, әдәбият өлкәсеннән хәбәрдар була, икенчедән, ул менә шушы өлкәдә эшләүчеләргә таяныч та була. Без бүтәннәр белән сөйләшкән чакта һәрвакыт Президентны мисалга китерәбез. Менә берәрсе аз гына, ялгыш кына әйтсә, вакыт юк дип, мин шунда ук әйтеп куям: «Безгә шул эшлексез бер кеше — Президент кына килә инде, аның эше юктыр, күрәсең». Шулай дигәч, шунда ук туктыйлар. Безгә аның театрга йөрүе менә шуның өчен дә бик кирәк.

Һәм нәтиҗәдә бик кызыклы гына килеп чыга: сәнгатьнең кайбер нечкәлекләре турында Минтимер Шәрипович сәнгать өлкәсе, театр белгечләренә караганда өлгергәнрәк фикерләр әйтә. Анардан театр һәм әдәбият дөньясының андый нечкәлекләрне белү бәлки таләп тә ителмидер, әмма ул күрә һәм әйтә.

**— Тәнкыйть буламы ул?**

— Төрле сүз, тәнкыйте дә була. Әйбәт булса, әйбәт, ди ул. Аннары соң шунысы бар: кайбер түрәләр сәнгатьне примитив рәвештә аңлый. Әйтик, элек булса — райком секретаре, хәзер инде берәр министр турында ниндидер спектакльдә кыек сүз әйтелсә, болар аны примитив рәвештә үзләренә кабул итәләр. Ә Минтимер Шәрипович, театрда хәтта дәүләт мәсьәләсендә шундый репликалар яңгыраса да, аны үзенә кабул итеп, «сез безне тәнкыйтьләп утырасызмыни монда» дигән мәгънәсез сүз әйтми. Бу сүз җәмгыятькә әйтелергә тиешме бүгенге көндә? Һәм ничек әйтелергә тиеш? Менә шулар турында кызыклы бер сөйләшү булып ала. Менә бер мисал. Без аның белән бергә Зөлфәт Хәкимнең «Мылтык» дигән спектаклен карадык. Анда берәү, үтеп китешли генә, безнең суверенитет турында бик ямьсез сүз әйтә. Ул җөмләнең спектакльдәге төп вакыйгага катнашы да юк, югыйсә. Мин аны ишетүгә үк әллә нишләп киттем. Мин инде аның төгәл җөмләсен китерә алмыйм, нәрсәгә ирештек, бер чепуха бу суверенитет дигән кебегрәк. Эчемнән уйлап куйдым: бар шундый әйберләр — аларны болай әйтергә ярамый. Әгәр дә без суверенитет белән нәрсәгәдер элек уйлаганча, фикер йөрткәнчә, өмет иткәнчә ирешә алмаганбыз икән, бүген анардан көләргә, мыскыл итәргә ярамый. Ул — халыкның күңел ярасы. Барыбер омтылабыз шушы азатлыкка, киләчәктә өмет итәбез. Һәм теләсә нинди формада сүз әйтеп, моның белән шаярырга, анардан мәзәк ясарга ярамый. Соныннан фикер алышкан вакытта нәкъ шул сүзне Минтимер Шәрипович әйтте. Һәм ул аны ямьсез

итеп әйтмәде. Президент буларак кисәтеп, нигә алай дип әйтәсез, алып ташлагыз дип түгел. «Менә бүген кирәк микән бу әйбер?» — диде ул. Без, бәлки, чыннан да, үзебезнен теләгебезгә ирешеп бетмәгәнбездер, ләкин бу сүзнен асылыннан, мәгънәсеннән алай авыз ерып көләргә кирәк микән дигән мәгънәдә әйтте ул. Күрәсез, анын фикере тирәндә ята. Әлбәттә, ул үзенен бөтен белгәнен-уйлаганын теләсә кайда чишеп, таратып сала алмый. Ул — Президент, анын вазифалары бар, протокол дигән нәрсә бар. Мәскәү белән мөнәсәбәтләре бар. Ул — акыллы кеше. Һәм ул тормыш, кешеләр язмышы турында уйланып фикер йөртә. Ул тормышны бер төсле итеп кенә яки акка һәм карага гына аерып анламый.

Мин дөньяда логика дигән әйберне кабул итәм. Чөнки дөньяда ин тәртипсезлекнен — хаоснын да үз логикасы була. Мин аны анлыйм. Ләкин логика кешене бөтен өлкәдә дә, бөтен яшәешендә дә үзенә буйсындырырга тиеш түгел. Чөнки логика — акыл ул, ә акылнын ялгышуы да мөмкин. Менә тою дигән әйбер бар — интуиция. Кеше тоя, нәрсәнендер куркыныч икәнен яки яхшылык киләчәген сизә. Бу сыйфат хатын-кызларда көчлерәк, чөнки ир-ат — тупас җан иясе. Менә шушы интуиция житәкчеләрнен күбесендә житми. Алар, әйтик, болай фикер йөртә: олы юлдан барсан, ул сине менә шушында алып чыга. Менә юл буенда светофорлар тора, алмашлап утлары яна, син шуларга карап, логика, закон буенча барасын да барасын. Һәм көтмәгәндә бер тыкрыктан хулиган килеп чыга каршына, ә бит логика буенча син һаман алга барырга тиеш. Теге хулиган бөтен законнарны боза. Менә монда инде кешенен интуициясе кирәк. Куркыныч яныймы, юкмы — алдан ук сизенеп барырга. Чокыр булуы, юлнын тайгак булуы мөмкин ләбаса. Моны сәясәт өлкәсенә күчерсәк, Минтимер Шәриповичта интуиция көчле, гаҗәеп интуиция. Мин мона сокланам. Минем үземдә дә тою хисе бар. Мин, мәсәлән, мина кайда нәрсә янаганын, нинди шатлык килерен сизәм. Әмма Минтимер Шәриповичта бу башка дәрәҗәдә — сәясәт өлкәсендә бик көчле.

Әгәр дә тикшереп карасак, анын белеме гуманитар белем түгел. Ул, гадиләштереп әйтсәк, механизатор, механик, техник фәннәр буенча югары белем алган. Ә бит менә шушы вакыт эчендә житәкчелектә эшләп, Президент дәрәҗәсенә житәр өчен бик күп укырга, белем ягыннан әзер булырга кирәк. Ул бит зур, дөньякүләм сәясәтчегә әйләнде. Авыл малаена, ниндидер бер 30-40 ел эчендә дөнья күләмендәге сәясәтчегә әйләнер өчен, тумыштан булган талант кирәк. Мин анын язганнарын укыдым да монын чыганакларын белдем. Ул — бик тәрбияле ата-ананын баласы. Чын мәгънәсендә тормышны белгән, кешеләр тормышын анлаган кешенен баласы ул. Өйдә сабый чактан ук бик көчле тәрбия алган. Ул тәрбия, кирәк икән — кырыс булган, кирәк вакытта аны иркәләү дә, үсендерү дә булгандыр. Бик гаҗәп әйбер бу. Менә анын үзенен сөйләве буенча беләм: ике малаен да тәмәкедән биздерү факты. Кыйнамый, сукмый, вәгазь укымый, әйтә: мә, тартыгыз, ди. Тегеләргә исереп-тончыгып беткәнче тәмәке тарттыра. Әйтә: сезгә шушы кирәкме, сез шулай яшәргә телисезме? Менә нинди тәрбия системасы.

Аннары сон әйтер идем Минтимер Шәриповичнын милләткә мөнәсәбәтен. Без бит инде барыбыз да милләт, милләт дип кычкырырга яратабыз. Ортодоксаль милләтчеләр бар, бер чиктән икенче чиккә ташланучылар бар. Бар анынча даими рәвештә, сабыр гына, акыл белән шушы милләткә хезмәт итү. Президентнын вазифасы «татар! яшәсен татар!» дип яшел байрак күтәреп урамга чыгу белән бәйләнмәгән. Бер генә илдә дә андый президент була алмый, булса да, аны бик тиз алыштыралар. Чөнки илдә төрле халыклар яши, бигрәк тә безнен республикада. Президент — бөтен халыкларнын да гаранты. Ул Төп законга кулын куеп, аны үтәргә ант итә, ул — гарант. Менә шушы ситуациядә безнен Президент үзен үстергән милләте турында уйлый — монын өчен бик зур акыл кирәк. Һәрбер әйткән сүздә бу үлчәнгән булырга тиеш. Президентнын әйткән һәрбер сүзеннән этлек эзләп торучылар бу дөньяда бик күп. Шул ук вакытта ул үзенен татар баласы икәнен онытмый. Аерым привелегияләр мәсьәләсендә кычкырып әйтмәсә дә, безнен милләтнен башка халыклар белән бергә, бер кояш астында яшәргә хокукы барын ул һәрвакыт белеп тора. Милләт мәсьәләсенә бик житди карый. Мәгариф өлкәсендә милли-төбәк



*Киңәш-табыш...*

компонентларын бетерү турында закон чыккач, бездә кинәшмә үткәрелде. Нинди чыгыш ясады ул! Андый чыгыш өчен Мәскәүдә рәхмәт әйтмиләр ана. Менә шундый кискен моментларда ул үз сүзен әйтә. Тукта, Мәскәү ни әйтер, бу минем кәнәфиемә зыян китермәсме дип тормый. Монда нәкъ менә Президентның сүзе кирәк иде. Әгәр дә без генә кычкырып утырсак, мәскәүләр әйтер иде: «Кучка националистов подняли шум», — дип. Кирәкле урында, кирәкле моментта әйтте. Анын төп эше шул. Шушында әйттеме — мина анын калган вакытларда кычкырып йөрүе кирәкми.

Мин ел саен 30 август көнне Кабан күле буена, театр янына барам. Президент килә, бәйрәм унаеннан чыгыш ясый. Мин һәрвакыт игътибар белән тынлыйм: әйтәме, юкмы «суверенитет» сүзен? Нинди формада әйтүе мөһим түгел. Ул әйтә. Ул бит акыллы кеше, суверенитетнын без теләгәнгә ирешмәгәнен ул белә, ләкин барыбер телгә ала. Чөнки ул күнелдә онытылмаска тиеш. Бу нәрсә дигән сүз? Безнең хәтердә, безнең күнелдә ул сүз яшәргә тиеш. Үзләренең дәүләтчелеге булмаган бик күп халыкларның, башка дәүләтнең кул астында буйсынып яшәп, үз-үзен югалтулары бик мөмкин. Ә татар ни өчен үзен саклый? Чөнки анын дәүләтчелеге булган. Гәрчә безнең бүген дәүләтебез юк (хәзерге халәтнең дәүләт дип аталуы бик чагыштырмача), ләкин дәүләт ул һәрбер татарның хәтерендә яши. Шуна күрә Минтимер Шәриповичнын бу кирәкле сүзне кабатлап, башка фикерләргә кушып әйтүе анын ил җитәкчесе икәнен күрсәтә.

Менә күз алдына китерегез, без һәммәбез, кайда гына барсак та, каушап калабыз: нәрсә әйтерләр, ничек сөйләрмен, нәрсә булыр, ничек күренермен... Бик күп җирләрдә чыгыш ясаган кеше булсам да, миндә дә каушау бар. Ә ул кирәк икән — чит илләр кешеләре белән очраша. Кирәк икән — гарәп илләренә бара, алар белән сөйләшә. Кирәк икән — Европа илләре җитәкчеләре белән фикер алыша. Ул дәрәҗәдә сөйләшер өчен рәсми рәвештә торган урынын гына түгел, кешелек сыйфатларын мөһим. Тирә-якта бит күзәтеп торалар. Беренчедән, синен әнгәмәдәшен күзәтә: бу нинди зат икән? Икенчедән, читтән карауча лар, «бу нәрсә ычкындырыр икән?» дип менләгән журналист күзәтеп тора. Ә ул ничек оста итеп алып бара сөйләшүләрне!

Миннән бервакыт сораганнар иде: «Минтимер Шәймиев Россия Президенты була алыр идеме?» «Һәм әйбәтрәк Президент булыр иде», — дип әйттем мин. Ул үзенең интуициясе белән Россиянең нинди ил икәнен анлар иде һәм шушында яшәр өчен бөтен милләтләрне, бөтен халыкларны ничек итеп бергә (ярар, бердәм Россия булсын) тупларга белер иде. Төрле шовинистик законнар чыгарып, башка милләтләрне күрмәскә теләп, Россиянең язмышын фаҗигагә илтмәс иде. Чөнки ул белер иде: бүген Иван Грозный таягы белән дирижёрлык итәргә ярамый. Бу өлкәдә ул бик күпләрдән акыллырак.

Ул сөйләшер өчен гади кеше. Гап-гади генә авыл апасы белән дә сөйләшеп китә ала, чөнки ул анын тормышын белә. Кайбер түрәләр шикелле, болар нигә пылау ашамыйлар микән дип аптырап тормый. Ашарга, яшәргә кирәклеген дә белә, шуна күрә уртак тел таба. Җыеп әйткән вакытта, анда зур мәгънәдәге кешелеклелек сыйфатлары бик күп. Һәм бу анын үзен дә саклый, халыкны да саклый, ана ышаныч та тудыра.

Берәү дә мәңгелеккә килмәгән, булыр бер заман, шушы Шәймиев чоры татар тарихына кереп калган булыр. Безнең тарихта Казан ханнары, аларның төрлесе булган, тарихта исемнәре бар. Кайберсенең бик үк мактаулы түгел, кайберсенеке — данлыклы. Минтимер Шәймиев исеме татар тарихында татар дәүләтенең житәкчесе буларак зур бер урын алачак.

Без бит инде бүген аның урынына кем килер дип шактый борчылабыз, ул сорау тора һәрвакыт. Әлбәттә, андый кеше табылыр, без бит талантлы милләт. Узган инаугурация вакытында әйттем бу сүзне, алыштыргысыз кеше булмый дидем. Әмма ләкин татар тарихының менә шушы кискен борылышлы чорында аның булуы — ул татарның бәхете.

**— Сез шактый вакыт бер-берегез белән аралашып, көрешеп торасыз. Үзгәрдеме ул шушы вакыт эчендә?**

— Үзгәрмәскә мөмкин түгел. Бәлки ул хәзер Мәскәү белән мөнәсәбәттә бераз сабыррактыр. Ә кеше буларак ул үзгәрмәде. Әлбәттә, тәҗрибә туплау мәсьәләсендә дөнья аны һаман өйрәтеп тора, ул үзе дә дөньяны өйрәнү өлкәсендә алга китте — бу да үзгәрү була торгандыр. Әмма Мәскәү мөнәсәбәтендә инде ул бераз гына үзгәрергә мәжбүр, чөнки ана һәрбер уйлаганын уптым илаһи кычкырып әйтергә ярамый. Хәзер ул бераз саграк шикелле. Ул «урталык» дип еш әйтә. Мин үзем холкым буенча урталыкны яратмый торган кеше. Минемчә, йә — болай, йә — тегеләй. Ә Президент булган кешегә урталык бик мөһим. Әгәр дә ул нәкъ менә безнең милләтчеләр, әйтик, кайберәүләр кебек, без Мәскәүне болай итәбез, тегеләй итәбез дип сөйләшсә, аны алып ыргыталар гына. Әгәр дә инде алып ыргыткан вакытта китмим дип әйтә икән, әллә нәрсәләр килеп чыгарга мөмкин. Мин Финляндиядә чечен язучысы белән очраштым. Анарга үземнең чечен халкына соклануымны әйттем. Мин әйтәм: «Сез — батыр халык, үзегезнең азатлык идеясен, үзегезне саклар өчен ничек көрәштегез». Ә ул нәрсә ди? «Ә без аны сездән өйрәндек, — ди. — Сез без ирешкәнгә кан коймыйча ирештегез, ә без нихәтле кан койдык, нәтиҗәбез бер үк дәрәҗәдә, сездә әле әйбәтрәк тә». Чөнки кычкырып, күсәк болгап сөйләшү ярамый, бигрәк тә Мәскәү белән. Мәскәү күсәк белән идарә итә, ул — империя. Ә империядә һәрвакыт күсәк акылдан күбрәк. Күсәккә күсәк белән бармау өчен бик зур акыл кирәк. Менә шушы мәсьәләдә ул инде сабырланды. Әмма, бая әйткәнемчә, кирәкле моментта үзенең сүзен әйтеп куя: сез белеп торыгыз, без барыбыз да бердәм Россия яклы, ләкин нинди Россия? Федерацияле, демократик Россия ягында. Ул моны гел әйтеп тора.

Ә кешелеклелек ягыннан әлләни үзгәрде дип әйтә алмыйм. Гадәттә болай була: гел бер урында утырган түрә бозыла башлый. Бу бик табигый. Чөнки үсә, кайберәүләр исә үзләрен Алланың ярдәмчесе итеп үк тоя башлый. Ә Минтимер Шәрипович түрәлектән киткәч нәрсә буласын белә. Бер сөйләшеп утырганда, миңа әйтте ул: «Ярар, Туфан, бер дә аптырама, китәрбез дә, аксакаллар шурасы ясап, үзебезнең сүзебезне әйтеп йөрербез». Аның очрагында «татар түрә булса, чабатасын түргә элә» дигән гыйбарә эшләми. Ул бит теләсә кем белән, минем кебек, корсакка төртеп, кулын иңгә куеп, йөз илле грамм салып, «әй, агай-эне» дип сөйләшә алмый. Әйткәнемчә, аның үз урыны, дәрәҗәсе, протоколы бар. Әмма ләкин үз-үзен тотышында, кешеләр белән мөнәсәбәтләрдә ул үзгәрмәде. Һәрхәлдә, миңа карата үзгәрмәде.

**— Сезнең якыннан аралашканыгыз да бардыр инде?**

— Бар. Бик кирәкле мизгелләрдә икешәр сәгать сөйләшеп утырганыбыз бар. Мәсәлән, Марсель Сәлимжанов үлгәч, театрны кем җитәкләячәге турында сөйләштек. Аннары соң, бервакыт ул язучылар съездына килмәскә уйлаган иде. Мин аның янына кереп, анда булырга тиешлеген исбатладым. Бүгенге язучылар кемнәр алар, аларның урыны кайда? Ул килеп сүз әйтсә, тагын да яхшы, әйтмәгән очракта да, аның килүе бүтәннәр алдында язучылар оешмасының дәрәҗәсен күрсәтү өчен кирәк иде. Ул моны аңлады.



*Туфан Миңнуллинның 70 яшьлек юбилеена багышланган тантанадан күренеш. Минтимер Шәймиев әдипкә «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены һәм «Татарстан Республикасының халык язучысы» билгесен тапшыра. 21 ноябрь, 2005 ел.*

**— Сезнең белән киңәшкән чаклары буламы?**

— Минем белән киңәшә ул, кайвакытта чакырып та ала, үземне генә дип әйтмим, бер төркем шәхесләрне чакырып алып киңәшә, безнең уйларыбызны белә. Безнең фикерләрне тыңлый, безнеңчә эшлиме, эшләмиме — анысы икенче эш. Менә бу сайлаулар алдыннан да очраштык, күбрәк инициатива минем яктан чыга мондый чакларда. Дәүләт Советы ничек булырга тиеш, бигрәк тә безнең комитет, милләт мәсьәләләрен ничек куярга. Шулар турында сөйләштек.

**— Минтимер Шәриповичка ниндидер тәнкыйть яки искәртү сүзе әйткәнегез бармы?**

— Мин инде аны алай итеп тәнкыйтьләп, Президентка акыл өйрәтеп утыра алмыйм. Әмма үз фикеремне әйтәм. Менә мин болайрак уйлыйм, менә минем фикерем, дим. Әйткәнем бар татар гимназияләре, татар мәктәпләре биналарын төзү турында. Мәсәлән, бездә спорт-шоу белән мавыгу турында, мина моның ошамавы турында әйткәнем бар. Шунарга күрә, ул минем янда безнең «Ак барс» чемпион булды дип әйтми. Туфан янында андый сүз сөйләмәгез, ди. Чөнки минем кычкырачагымны белә. Күрәсең, анда да мин аңлап бетермәгән әйберләр бардыр. Мина калса, безнең дәүләттә, безнең республикада спорт-шоу белән мавыгу кирәгеннән артык. Мин моның белән килешә алмыйм, безнең мәктәпләребез, татар гимназияләре ташландык хәлдә вакытта республикада берничә супер-клуб тоту, миллиардлаган акча туздыру, байларча кылану урынсыз дип саныйм. Мин аны әйтеп торам, югары трибунадан чыгыш ясаганым бар, ул аны белә. Бер тапкыр, Әлмәттә иде ахыры, менә кубок алдык дигәч, әйткән идем: миллиард куйсаң, безнең авыл агае да йөгерә, дип. Бу очракта да барыбер тәнкыйть итәм дип, сүгәргә җыенмыйм. Аның бардыр җайлары, мин аңламаган яклары. Әмма ләкин безнең республика өчен кирәгеннән артык кылану. Карагыз: ике хоккей, бер футбол, баскетбол, волейбол клублары — бар да супер-клублар. Беләсезме, Алексей Морозов йөз миллион акча ала. Йөз миллион! Безнең культурага бирсәң йөз миллион, йөз миллионга ике мәктәп салып була. Бер тапкыр барган идем «Татнефтьпродукт» берләшмәсенә, берәр татар китабы чыгарырга ярдәм итмәсләр микән дип. Үземә түгел. Ә аларга спорт налогы салынган: хоккей на траве. Нәрсәгә кирәк ул шулхәтле? Минемчә, бу әйберләр спортка якынайтмый, спорттан биздерә. Алар — арзанлы тамаша, кешегә аң бирә торган тамаша түгел. Кеше күңеленә байлык бирә торган тамашалар — театр, концертлар. Минтимер Шәрипович аларда да катнаша, аларны да белә. Әмма спорт шаукымының сәбәбен аңламыйм. Ул моны гына аңларга тиеш кеше, аның башы җитәрлек хәл. Мин белми торган сәбәпләр бар, күрәсең.

**— Үз спектакльләрегез турында ничек сөйләшә идегез?**

— Ул килеп карый, карагач фикер алышабыз. Гадәттә Сәкинә ханым белән киләләр алар. Сәкинә ханым, хатын-кыз буларак, эмоциональ кеше, ул хатын-кыз буларак кабул итә, хисләрен ачыграк белдерә. Ә Минтимер Шәрипович ир кеше

буларак фикер йөртә. Һәрхәлдә бик житди сөйләшү була. Примитив сөйләшүне мин анардан ялгыш та ишеткәнем юк. Ул ошаганын да, ошамаганын да әйтә. Менә «Дивана»ны ошатты. Ә «Дивана»да шактый куркыныч әйберләр әйтелә. Бу бит дивана кеше сүзе түгел, ди. Шунысы рәхәт: ул аңлый, аңлап сөйләшә.

**— Фикерен гади тамашачы буларак әйтәме?**

— Ул уртача тамашачыдан бик күпкә югары. Спектакльне тамашачы буларак кына карамый ул. Спектакль карау бит ул ләззәт алу өчен генә түгел, ул — эш. Менә мина, мәсәлән, спектакль карау — эш. Минем баш эшли. Нәрсә бу, ничек бу? Тамашачыга да колак салам, үземнен фикергә дә. Шул рәвешчә төрлечә эшләп утырам мин анда. Ул да эшләп утыра. Рәхәтлек алып кына утыра алмый ул, мона хакы да юк анын. Ул бит ил башы, анын сүзе мөһим. Бездә бит әле шунысы да бар. Ил башы, түрә кеше сүз әйтсә, кирәгеннән артык тырышып куючылар да бар. Берәүләр: бу жире кирәк микән, дисә, икенче берәүләр моны «сызыгыз» дип аңлый башлый. Минтимер Шәрипович моны белә, шунарга күрә сакланып әйтә. Анын белән сөйләшеп утыру бервакытта да авыр тәэсир калдырмый, тәнкыйть сүзен дә бик матур итеп әйтә белә ул. Ышандырып әйтә. Бу — акыллы кеше эше, фикерле, интуицияле житәкче сүзе. Ул дистанция саклый белә. Гади кеше һәм житәкче. Ике арадагы менә шушы әйберне саклый белә ул. Бик үк якын да жибәрми. Ишеткәнен бармы урынбасарнын кем икәнен? Урынбасар — ул кыш көне учак янында утыручы кеше белән бер, якын килсә — учакка пешә, ерак китсә — өши. Шунарга күрә нәкъ урынын белергә кирәк. Минтимер Шәрипович нәкъ урынын белә, бу исә талант инде.


Кыскасы, мин аны бик хөрмәт итәм. Хәтта килешмәгән очракта да. Мин кайда яздым сон әле, кайдадыр басылып та чыкты бугай — анын белән бәхәсләшүе дә рәхәт. Чөнки бәхәсләшер өчен предметнын нәрсә икәнен белергә кирәк. Предметнын нәрсә икәнен аңламаган кеше белән бәхәсләшеп булмый. Яки талашырга, яки ул турыда сөйләшмәскә кирәк.

Мин ана үз фикеремне бик матур гына итеп әйтергә тырышам. Хөрмәт белән. Мин — Президент белән сөйләшкән вакытта кем белән сөйләшкәнемне белеп сөйләшә торган кеше. Менә Дәүләт Советы сессиясе вакытында бервакыт депутат Садыйков тегеләй-болай сүз кычкырганнан сон, мин чыгып әйттем: ул — безнен Президентыбыз, без әдәп тотарга тиеш. Кытайлар, японнар бит әнә бөтенләй килешмәгән очракта да елмаеп тора, үз фикерен сөйләшкән кешесенә хөрмәт белән әйтә. Акыллы кеше дошманы белән дә акыллы итеп сөйләшә.

Һәрхәлдә, мәсәлән, бик әйбәт беләм: ул мина хөрмәт белән карый. Әмма ләкин мин моннан беркайчан да файдаланмыйм. Югыйсә бит начальство бераз кул биреп күрешә башласа, кайберәүләр әйбер сорый башлый. Бернәрсә дә сораганым юк. Сорыйм икән, зур әйберләр, әйтик, мәктәп төзелешләренә кирәкле нәрсәләр сорыйм. Танышлыгынны үз файдана бору — ул акылсызлык галәмәте. Бәлки, мине хөрмәт итүенен дә хикмәте шулдыр. Әйткәнемчә, анын үземә яхшы мөнәсәбәтеннән беркайчан да файдаланмыйм. Кирәге юк анын, мәсьәләләрне хәл итүнен башка юллары бар. Президент хәтта синен гаилә дустын булган очракта да, син анын Президент икәнен беркайчан да онытмаска тиеш. Мин моны бик яхшы беләм.

**2009 елнын 8 апреле**

# ӨМЕТ ХАТЛАРЫ



*Кешене өмет яшәтә, дибез... Киләчәккә, якты көнгә, бәхеткә өмет... Авыр хәлгә калганда хәлеңә кереп, өметләндереп ярдәм кулы сузучы булганда, ул өмет тагын да тулылана, яшәргә көч бирә. Туфан ага Миңнуллин үзенең әсәрләре аша гына түгел, чынбарлыкта да кешеләргә ярдәмчел шәхес иде. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Ярлыкау комиссиясендә башкарган эшләре аша да без моны ачык күрәбез. Әлеге хатларда кешеләр язмышы һәм Туфан аганың аларга кылган игелекле гамәлләре.*

**Редакциядән.**

*Саумысез, Гөлнур ханым!*

*Хатыгызны алдым. Яхшы сүзләрегез өчен рәхмәт.*

*Әйе, Козловкада чакта Сезнең турыда ишеткән идем, үзегез күренмәдегез.*

*Андагы тәэсирләрне көндәлек дәфтәремә теркәп куйдым, бәлки әле матбугатта да бирермен. Билгеле инде, тәэсирләр әйбәттән түгел. Ахыры хәерле булсын. Тормыш бит ул, ничек кенә булмасын, дәвам итә.*

*Безнең анда бару нәтиҗәсез булмады. Ярлыкау комиссиясе берничә кешене азат итте. Акчулпанованы азат итүдә дә анын исеменнән язылган хатнын ярдәме тиде шикелле.*

*Анда чакта Галимова белән (исеме хәтеремнән чыккан) сөйләшеп утырган идек. Мин аңа Ярлыкау комиссиясенә үтенеч яз, ярдәм итәргә тырышырмын дигән идем. Ләкин үтенеч нигәдер килми. Әллә кире уйлады микән? Шул турыда аңа әйтә алмассызмы икән? Һәрхәлдә, миңа хат язып салсын.*

*Үзегез дә, әгәр кирәк тапсагыз, Президент исеменә үтенеч языгыз. Мин инде нинди дер вәгъдә сүзләре әйтә алмыйм, әмма ярлыкау өчен кирәкле таләпләр (характеристика һ.б.) үтәлсә, игътибарлы булырга тырышырбыз.*

*Иң изге теләкләр теләп, Туфан Миннуллин.*

*М.Туфан,*

*6 октябрь, 1998 ел.*

***

*Хөрмәтле Минвәли Галимович һәм Рәхимә Искәндәровна!*

*Бу хатны Сезгә язучы Туфан Миңнуллин яза.*

*Без үткән җәйдә Чувашиянең Козловка шәһәрендәге колониягә барган идек. Без дигәнем, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Ярлыкау (помилование) комиссиясе члennары. Шунда Сезнең кызыгыз Галимова Мөршидәне очраттык. Анын язмышы белән кызыксындык. Шул очрашудан соң шактый вакыт узгач, кызыгыз миңа хат язып салды.*

*Мин анардан әтиегез, әниегез кем, дип сорап хат яздым, һәм ул миңа Сезнең исемнәрегезне, адресыгызны әйтеп хат язды. Хатында ул Ярлыкау комиссиясенә мөрәҗәгать итәсен дә әйткән.*

*Мин Ярлыкау комиссиясенең члены буларак, Сезнең белән сөйләшәсем килгән иде.*

*Әгәр дә Сезнең минем белән очрашып сөйләшү теләге булса, мине табарга тырышыгыз.*

*Миңа түбәндәге телефоннар белән шалтыратырга мөмкин: 38-49-56 — өй, 36-64-70 — эш.*

*Исәнлек-саулык теләп, М.Туфан.*

*23.12.98.*

***

*Мөршидә сеңлем, исәнмесез!*

*Хатыгызны алдым. Менә җавап язам. Язар сүзләрем әллә ни күп түгел инде. Язганнарыгыздан аңлашыла — Сез акыллы кеше. Шуңа күрә үгет-нәсихәт, вәгазьләргә Сез мохтаж түгел.*

*Дөньяның, тормышның ни икәнен миннән ким белмисездер. Аннан соң, дөньяга без икебез ике яктанрак карыйбыз, карашларның, фикерләрнең туры килмәве дә бик ихтимал. Шул сәбәпле Сезнең белән бәхәскә керергә дә теләмим. Бу очракта минем бердәнбер теләгем — Сезнең ирекка чыгуыгызны ишетү. Калганы — Сезнең үз иркегездә.*

*Әтиләрегезгә дә хат яздым. Әгәр очрашып сөйләшергә-киңәшергә теләсәләр, мин кулымнан килгәннең барысын да эшләячәкмен. Әлбәттә инде, кулымнан килмәгәнне эшләргә вәгъдә биреп алдашырга җыенмыйм. Иң зур гөнаһ — булдыра алмаганыңны өстеңә алып кешене ышандыру, алдау.*

*Хатым Яңа елга хәтле барып җитәр дип уйлыйм. Ихлас күңелдән котлыйм Яңа ел белән. Яңа ел яңалык алып килсен. Гадәттә, Яңа ел яңа бәхетләр алып килсен дип телиләр. Мин әйтәм, бәхетнең аның искесе дә яхшы, яңа хәсрәтләр, яңа кайгылар алып килмәсен иде, дим.*

*Түземлек, сабырлык, инсафлылык теләп, Туфан абыегыз.*

*М.Туфан,*
*23.12.98.*

***

*Мөршидә сеңлем, исәнмесез!*

*Менә бер-бер артлы хатлар яза башладым әле үзегезгә. Эш шунда: мин әтиләрегезгә хат язган идем, кичә әтиегез минем янга Дәүләт Советына килде. Озак итеп сөйләшеп утырдык. Ул миңа бик ошады. Чын мәгънәсендә эш кешесе. Сезне искә төшергәндә, ике күзеннән яшьләр атылып чыкты, миңа сиздермәскә тырышып сөртте. Дөньяда иң авыр нәрсә — ир кешенең җан ачысына чыдый алмый җылавы. Сезне бер дә начар итеп сөйләми. Харап иттеләр кызымны, дип кенә әйткәләп куя. Акыллы, уңган иде, ди. Әниегезне кызганып сөйли, аңа бик авыр, ди.*

*Әйе, җинел түгелдер, мин аларны аңлыйм.*

*Аңлаганга күрә дә, кулымнан килгәннең барысын да эшләргә тырышачакмын.*

*Татарның «кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла» дигән әйтеме бар. Мин Сезгә моннан ике ел элек булган хәлне сөйлим.*

*Бервакыт Свердловск өлкәсендәге Нижний Тагил тирәсендә срогын утыручы Әгъзам исемле егет миңа хат язды.*

*Мин инде, әлбәттә, җавап яздым. Китте язышу. Бик мәгълүматлы егет, өстәвенә үзе баянчы да икән. Мин аңа ирекка иртәрәк чыгарга ярдәм иттем. Чыккач, театрга сәхнә эшчесе итеп урнаштырдым.*

*Очрашкалап тордык. Аннан ул бүтән эшкә күчте. Мин аның эзен югалттым.*

*Менә күптән түгел генә үзеннән хат алдым — Башкортстанның Стәрлетамак шәһәреннән. Утыра. Туфан абый, хат язышыйк әле, дигән.*

*Миңа ни өчендер кылган эшләрем өчен оят булып китте. Җавап яздым. «Гафу ит, энекәш, минем инде синең белән сөйләшәсе сүзләрем юктыр», — дидем.*

*Ярый, Мөршидә сеңлем, исән-сау бул. Тагын бер тапкыр Яңа ел белән котлыйм.*

*М.Туфан,*
*29.12.98.*

***

*Исәнмесез, Равия!*

*Козловка кызлары белән хат алыша башладым бит әле картайган көнемдә. Яшь чагымда кайда йөрделәр икән алар?!*

*Шаяртуым өчен гафу үтенәм. Сезнең хәлләрнең шаярта торган түгеллеген аңлыйм. Хатыгызны игътибар белән укыдым. Ләкин һич кенә дә кем икәнлегегезне чамалый алмадым. Әби-бабагызны, әтиегезне белгәч, йә безнең авылдан, йә ике Салтыкның берсеннән, йә Даныштандыр инде.*

*Мина күнелгә ятышлы сүзләр язуыгыз өчен рәхмәт. Сезгә дә шундый сүзләр генә ишетергә язсын.*

*Мин Сезнен барыгыз өчен дә борчылам. Юк вакытымны бар итеп, сезнең хатларга җавап бирергә тырышам. Беләм, сез кем генә дип аталсагыз да кешеләр. Кеше һәрвакытта да җылы сүзгә мохтаҗ. Мин Сезгә адәм рәтле киләчәк телим.*

*Китап мәсьәләсенә килгәндә, мин бит шигырьләр язмыйм, пьесалар гына язам. Сез шигырь җыентыкларымны сорагансыз.*

*Шигырьләр язуыгыз яхшы. Янында күнеленне ачып сөйләшерлек кешең булмаганда, иң яхшы дәва — шигырь, җыр язу, шигырь белән сөйләшү. Кәгазь битенә җаныңда йөргәннәрне язып куясын да җиңеләеп китәсен. Ул юанычыгызны ташлый күрмәгез.*

*Әлбәттә, Сез язган шигырь камил үк түгел, әмма ул ихластан язылган. Иң элек үзегез язган үзегезгә кадерле булырга тиеш.*

*Сезгә иң изге теләкләр теләп, Туфан Миннуллин.*
*М.Туфан,*
*10.01.99.*

***

*Исәнмесез, Мөршидә!*

*Бер конвертка салынган ике хатыгызны алдым.*

*Мин Сезнең бүгенге хәл-халәтегезне аңлыйм. Җанның ашкынып көтүен кичерү җиңел нәрсә түгел. Көтә белү өчен нык сабырлык, көчле ихтыяр кирәк. Без еш кына көтә белмәү аркасында ялгышлыклар эшлибез.*

*Минем «Кульяулык» дигән пьесам бар. Шунда төп персонаж болай дип җырлый:*
*Бәхет гөле чәчәк ата*
*Көтә белгәннәргә генә —*
*Кылдан нечкә сират күперен*
*Үтә белгәннәргә генә.*

*Янә дә тагын халыкта*
*Әс-сабыр — Рахман,*
*Бис-сабыр — Шайтан, — дигән сүзләр бар.*

*Боларны язуым шуның өчен: бәргәләнмәгез, кабаланмагыз.*

*Мин белештем — 26 гыйнварда Ярлыкау комиссиясенең утырышында Сезнең үтенеч карала. Мин тырышачакмын. Нык тырышачакмын. Комиссия утырышы алдыннан эшегез белән танышырмын. Өстән-өстән генә белешкән идем, сөйләшү җиңел булмаячак. Әмма мин шуны беләм: мин ярдәм итәргә тиеш, калганы Сезнең эш.*

*Кызык кына халәттә әле үзем дә — әйтерсең лә 26сында минем язмыш хәл ителә.*

*Хәерлегә булсын, дип хатымны тәмамлыйм.*

*Сабырлык теләп, Туфан абыең.*
*19 гыйнвар, 99 ел.*

***

*Исәнмесез, Равия!*

*Фотокарточкалы хатыгызны алдым. Балаларыгыз шундый да чибәрләр. Карадым да күз тимәсен, тьфү, тьфү, дип куйдым. Бәхетләре булсын иде инде, Ходаем.*

*Хатыгызны укыдым да, шундый төпле фикер йөртә белгән, шигырьләр язарлык күнел байлыгы булган кеше ничек ялгышкан икән, дип уйлап куйдым. Язмыш микән инде ул? Хәерле була күрсен ахыры.*

*Әйе, мин әниегезне дә, бабагыз-әбиегезне дә беләм. Без балачакта әниегез җиткән кыз иде инде. Безнең урамның бала-чагасы бабаларыгызның өендә еш була иде. Бигрәк тә кыш көннәре. Зәйнәп апаның энесе Габделхәйне беләм, тагын бер энесенең исеме хәтердән чыккан. Күп вакыт узган шул.*

*Әниегез белән сөйләштек. Аңа мин нәрсәдер вәгъдә итә алмадым. Эшнең асылын белмәгән килеш нидер вәгъдә итеп булмый. Әгәр дә ярдәм итү минем кулымнан килерлек булса, әлбәттә инде, барысын да эшләргә тырышырмын.*

*Ярый, Равия сеңлем, хатны тәмамлыйм. Сезгә сабырлык, өметегезне җуймавыгызны теләп, Туфан абыегыз.*
*М.Туфан,*
*25 гыйнвар, 1999 ел.*

***

*Мөршидә, сенлем!*

*Мин Сезне котлыйм. Ярлыкау комиссиясе әгъзалары Сезгә ышаныч белдерделәр. Безнен карарга Президентнын гына кул куясы калды. Исән-сау әтиегез, әниегез, балагыз янына кайтып житеп, хәерле гомер кичерергә язсын. Мин дә үз өстемә зур жаваплылык алдым.*

*Тагын бер котлап, иң изге теләкләр теләп, Туфан абыен.*

*М.Туфан,*

*26 гыйнвар, 1999 ел.*

***

*Исәнмесез, Равия!*

*Инде ике хатыгызны алсам да, жавап язмый тордым. Сезнен эшне утырышта караганнан соң ачыклыйсы нәрсәләр бар, диделәр. Киләсе утырышта карарга булдылар.*

*Мина да районга кайтып, Тенештә һәм Рудникта булырга туры киләчәк. Бигрәк тә куркыныч эш эшләнгән шул. Хәерле булсын.*

*Кулымнан килгән ярдәмне күрсәтергә тырышырмын. Булдыра алмаганымны эшләргә алына алмыйм инде, Равия.*

*Сезгә сабырлык, түземлек теләп, Туфан абыегыз.*

*М.Туфан,*

*25.02.99.*

***

*Равия сенлем, исәнмесез!*

*Мин Сезгә шатлыклы хәбәр житкерергә ашыгам: бүген Сезнен эшне карадык һәм Сез азат ителдегез.*

*Алдарак мин авылыгызга һәм Рудникка бардым. Зәйнәп апаны, сеңлегезне, балаларыгызны күрдем. Кызларыгызнын «әнине кайтарыгыз» дип өзгәләнүләре жанымны актарды. Утырышта барысын да сөйләргә һәм үз өстемә зур жаваплылык алырга туры килде. Ходай хәерле кылсын.*

*Кайткач, мина хәбәр итәрсез. Очрашып сөйләшүнен дә зыяны тимәс.*

*Сезгә иң изге теләкләр теләп, Туфан абыен.*

*М.Туфан,*

*25.03.99.*

***

*Румия сенлем, исәнмесез!*

*Хатыгызны алдым. Алуга ук жавап язмавыма ачуланмагыз. Сезгә бит теләсә нинди жавап кирәк түгел, өметле жавап кирәк.*

*Ә Сезгә ни дә булса вәгъдә итәргә минем мөмкинлекләрем Сез уйлаганча ук зур түгел.*

*Хатыгызны кат-кат укып чыктым. Хәлегезне, билгеле инде, аңладым, хәтта язганнарга ышандым да шикелле. «Шикелле» сүзен нигә язганымны төшенәсездер дип уйлыйм — аны шәрехләп тормыйм. Әлбәттә инде, Сезгә һәм Сезнен кебекләргә ярдәм итәсем килә. Сез (хатын-кызлар) — бу шактый ук мәгънәсез тормышнын корбаннары. Сез тәрәксез, яклаучысыз калдыгыз. Еш кына илдә эшләнгән жинаятьләр өчен жәзасын Сез аласыз.*

*Ничек ярдәм итәргә икән Сезгә? Әйдәгез, мин белгән юл белән эш итеп карыйк. Ягъни мәсәлән, Сез үзегез Татарстан Президентына ярлыкауларын (помилование) сорап үтенеч языгыз. Сезгә балаларыгыз һәм туганнарыгыз да кушылса, яхшы булыр.*

*Шуннан Сезнен үтенечне Ярлыкау комиссиясе карар. Мин ул комиссия члены буларак, Сезгә ярдәм итүләрен сорармын, аңлатырга тырышырмын. Әлбәттә, Сезгә ярдәм итү өчен, Сезнен үзегез зиндан дип аталган жирдә тәртибегез яхшы булырга тиеш. Андагы житәкчеләрнен Сезнен турында язган сүзләре гел әйбәт кенә булса, Сезне яклавы жиңелрәк булачак.*

*Менә әлегә шундый жавап. Тагын хат язарга теләсәгез, языгыз. Сезнен белән*

*бергә, Сез күрсәткән адрес буенча кызларыгызга да хат язам, бәлки очрашып сөйләшербез.*

*Изге теләкләр теләп,*
*М.Туфан,*
*8.06.99 ел.*

***

*Исәнмесез, Рания һәм Ләйсән!*

*Бу хатны Сезгә Татарстан халык депутаты, язучы Туфан Миңнуллин яза. Мин әниегездән хат алдым. Ул Сезнең адресыгызны җибәргән. Безгә күрешеп сөйләшергә кирәктер. Әгәр теләсәгез, миңа түбәндәге телефон белән шалтратыгыз — 36-64-70. Ул минем эш урыным — Дәүләт Советы телефоны. 38-49-56 белән өйгә дә шалтырата аласыз.*

*Изге теләкләр теләп,*
*М.Туфан,*
*8.06.99.*

***

*Исәнмесез, Румия!*

*Хатыгызны алдым. Бик кызыклы хат, уйландыра торган хат. Мин шактый тоткыннар белән сөйләшкәнем, хатлар алышканым бар. Аларның барысында да диярлек бер уртак сыйфат күрәм: бөтенесе акыллы, төпле фикер йөртә. Бик күпләре философлар. Ахмак, аңгыра тоткынны очратканым юк.*

*Менә шуннан соң уйландыра — шундый акыллы фикер йөртә алган кеше ничек анда барып эләгә? Төрмәнең нәрсә икәнен белү өчен төрмәгә барып эләгү мәҗбүри түгел ләбаса.*

*Сез дөрес әйтәсез, мин — язучы кешене кешеләр язмышы, бигрәк тә адашканнарның, кызыксындыра. Ләкин ул турыда, ягъни тоткыннар тормышы турында, язарга алыныр өчен, ул тормышның бик күп нечкәлекләрен белергә кирәк. Әгәр теләсәгез, әйдәгез, бергәләп язабыз. Сез миңа үзегез аралашкан, үзегез сөйләшкән, үзегезне уйландырган язмыш ияләре турында язып торыгыз. Материал җыелсын, бәлки шуннан берәр әсәр дә туар. Болай эшләүнең Сезгә дә файдалы тагын бер ягы бар: эш белән мәшгуль булып, вакытның үткәнлеге әлләни сизелмәс. Һәрхәлдә, күңелдә, җанда туган төрле ямьсез уйлардан арынып торырга ярдәм итәр. Хатларыгызга караганда, Сез — уйлый белүче кеше. Русча укыган булсагыз да, телегез килешле.*

*Инде Сезнең турында. Әйе, ярты ел көтәргә кирәктер. Монда характеристикага бик игътибар итәләр. Ялгышмаска тырышыгыз.*

*Кызларыгызга хат язган идем, әниегез шалтыратты. Без тагын бер шалтыратышып очрашырга сөйләшкән идек, ул шалтыратасы көнне мин командировкага киттем. Шуннан бирле хәбәре ишетелми. Ә мин аның телефонын белмим.*

*Менә шундый хәлләр.*

*Сезгә исәнлек-саулык, сабырлык теләп, Туфан абыегыз.*
*М.Туфан,*
*28 июнь. 1999.*

***

*Хөрмәтле Минвәли Галимович!*

*Әлеге хатны язучы кеше — Туфан Миңнуллин, беләсездер андый кешене. Хат язуымның сәбәбе — әлеге дә баягы Сезнең кызыгыз Мөршидәнең язмышы өчен борчылу инде. Нигәдер бер хәбәре дә юк. Эшләгән урынында да берни белмиләр. Китте дә югалды, диләр. Югыйсә, мин үз өстемә зур җаваплылык алып, аны эшкә урнаштырган идем. Мөршидә үзе дә сөенеп туймаган иде. Ни булды икән? Уйга әллә нинди шикләр килә. Ходай саклый күрсен.*

*Бәлки Сез берәр хәбәр бирерсез. Бәлки Мөршидәгә әйтерсез. Ни булганын миңа хәбәр итсен иде.*

*Сезгә исәнлек-саулык, сабырлык теләп, М.Туфан.*
*19 август. 99 ел.*

***

*Исәнмесез, Румия!*

*Бүген Ярлыкау комиссиясенен утырышы булды. Житмештән артык үтенечне карадык. Арада хатын-кызлар да шактый. Ул утырышлардан соң мина бик авыр була. Кешеләргә ышанычым кими. Бу — бик начар нәрсә. Әгәр дә кеше үзе кебек үк кешеләргә ышанмый башлый икән, аның күнеле катылана, миһербансызга әйләнә. Ә каты күнелле, миһербансыз кешеләр жир йөзендә күбәйсә, яшәүнен мәгънәсе калмый. Язучы кешеләргә каты күнелле булырга ярамый, ул кешеләргә ышанырга тиеш. Һәр кешедә иң яхшы сыйфатларны эзләп табарга һәм аны бүтәннәргә сөйләргә тиеш.*

*Менә Сез мина ышанып хат язасыз, һәм ничек инде мин Сезгә ышанмаска тиеш. Мин ышанып, Мөршидә Галимова һәм Жамалиева Равиягә өйләренә кайтырга ярдәм иттем. Хәзер инде алар өчен борчылып яшим, тагын абынмасалар ярар иде инде, дим. Сезнен өчен дә борчылам мин. Шуна күрә дә юк вакытымны бар итеп, Сезгә хат язам. Сез бит адәм баласы. Сезнен дә бәхетле булырга хакыгыз бар. Әгәр дә жир өстендә бер генә кеше бәхетсез икән, димәк, тормыш камил үк түгел. Хатын-кыз өчен бәхет төшенчәсе икенче төрлерәк: алар бәхетнен кадерен ирләргә караганда күбрәк аңлыйлар, бәхетсезлекне авыррак кичерәләр.*

*Вәгазь укый дип ачуланмагыз инде, бәгырькәем, зинһар, өметегезне югалтмагыз. Әнә үзегезгә бик кирәкле һәм файдалы шөгыль тапкансыз. Уйланырга мәжбүр итә торган шөгыль. Унышлар телим үзегезгә.*

*Әгәр хат язарга теләгегез бар икән, кыенсынмагыз, языгыз. Әгәр минем хатларым Сезгә ниндидер жиңеллек китерә икән, жавап язармын.*

*Мин беләм: Сездә тормыш шартлары бик кырыс. Сезнен йортта яшәүнен үз тәртибе, үз кануннары бар. Мондагылар андагыларның хәлен бик аңларга тырышсалар да, аңлап бетерә алмыйлар. Ләкин барыбер анда да, монда да кешеләр яши. Кешелегенне саклау монда да жинел түгел. Ләкин тырышасың, бүтәннәр белән дә, үз-үзен белән дә көрәшәсен.*

*Сезгә мин сабырлык, түземлек, исәнлек-саулык телим.*

*Туфан абыен Миннуллин.*
*М.Туфан,*
*19 август, 1999 ел.*

***

*Румия сенлем!*

*Хатыгызны укып чыгуга ук жавап язам. Чөнки ул мина бик нык тәэсир итте. Һич кенә дә арттырмыйча әйтәм: Сездә язучылык сәләте бар. Әгәр дә электән үк бу эш белән мавыккан булсагыз, инде остарып житкән булыр идегез. Хәзер дә әле соң түгелдер. Ничегрәк язарга дип мин Сезне өйрәтергә алынмыйм, күнелегез ничек куша, шулай языгыз. Сездә күзегез күргәнне язучыларча сурәтләү, колагыгыз ишеткәнне язучыларча эшкәртү сәләте булса, аны язып күрсәтү осталыгы гына житенкерәми. Әмма бу — яза-яза килә торган осталык.*

*Биюченен күлмәге*
*Бии-бии кыскара.*
*Биючегә сүз әйтмәгез,*
*Бии-бии остара, — дигән жыр бар.*

*Язуыгызны дәвам итегез. Әйткәнемчә, ул шөгыль Сезнен бик үк ямьле булмаган тормышыгызда юаныч та булыр, аннан сон, кем белә, бәлки аларны бастырып та булыр.*

*Үзем исән-сау. Тик менә Мөршидәнен эзен югалттым әле. «Дулкын»нан киткән, хәбәр бирми. Хәерле булсын.*

*Иң изге теләкләр теләп, Туфан абыен.*
*М.Туфан.*
*28.09.99.*

***

*Исәнмесез, Румия!*

*Получил Ваше письмо, написанное на русском языке. Я уж буду писать на*

*своём. У меня ни от кого никаких секретов нет. Тем более там у вас переводчики найдутся.*

*Беренчедән, мин Сез биргән телефон аша апагыз белән сөйләштем, кинәшләремне бирдем. Ул Президент исеменә үтенеч язарга булды. Ләкин бер нәрсәне белеп торыгыз: әгәр дә администрациянен Сезнен турыда фикере унай булмаса, Ярлыкау комиссиясе үтенечне карамый. Тәртибе шундый.*

*Аннан сон, Сез минем хатны алмадым, дигәнсез. Мина Сезнен сонгы хатыгыз 27 сентябрьдә килде, мин ана җавап яздым. Бәлки барып җитмәгәндер.*

*Тагын ниләр языйм? Мөршидә югалды. Кайда нишләп йөргәнен әтиләре дә белми. Шуна күрә минем бераз кәефем дә китте. Бушка вакытымны әрәм итәмдер кебек. Югыйсә, укып җыларлык хатлар яза иде. Мин, әлбәттә, кулымнан килгәнчә кешеләргә ярдәм итәчәкмен. Әмма ул ярдәмнен кешеләргә кирәкмәгәнен күрү күнелгә бик авыр тәэсир итә, бүтәннәргә дә ышанмый башлыйсын.*

*Менә шундый хәлләр. Исәнлек-саулык, җиңеллек телим Сезгә.*

*Туфан абыегыз.*
*М.Туфан.*
*9.12.99.*

***

*Исәнмесез, Румия!*

*27 декабрьдә язган хатыгызны алдым. Котлавыгыз өчен рәхмәт. Яна ел яналык алып килсен иде инде — хәерле яналык.*

*Ин беренче сүзем: нинди генә хәлләр булса да, кешеләргә ышанудан бизмәячәкмен. Шул исәптән Сезгә дә ышанам. Чөнки кеше өчен ин зур фаҗига — кешеләргә ышанмый башлау. Шулай булгач, борчылмагыз, Сезне азмы-күпме бәхетле итәр өчен тырышачакмын. Калганы үзегезнен кулыгызда.*

*Әйе, Мөршидә минем ышанычны акламады. Беркөн чыннан да аны телевизордан күрсәттеләр. Милиция бүлегендә. Кулга алганнар. Икенче көнне шул милиция бүлегенен телефонын табып шалтыраттым. Имзасын алып, өенә җибәреп тордык, диләр. Шуннан башкасын белмим. Аны, кызганычка каршы, өйләрендә дә бик көтмиләр иде инде. Әти-әнисенен күнелләре кайткан. Минем аны күрәсем килә. Ана бер генә сорау бирергә телим: бәгырькәем Мөршидә, мина хатлар язганда, ниләр уйлап яздын һәм картлыгынны ничек күз алдына китерәсен?*

*Минем ана да ышанасым килә. Бәлки Ходай Тәгалә күнеленә иман индерер дә упкынга илтә торган юлдан читкә борылыр бу Алла бәндәсе дип уйлыйм. Урамда таушалып беткән, хатын-кыз кыяфәте генә түгел, адәми зат кыяфәте дә калмаган, яшенен ничәдә икәне дә билгесез хатыннарны күрәм дә җаным сыкрана. Алар арасында татар карчыклары да аз түгел.*

*Мин Сезнен кулъязмаларыгызны укып, җыеп барам. Хатларыгызнын да мина килеп җиткәннәре бергә теркәлеп куелган. Язганым да булгандыр, Сез — фикерле кеше, фикерегезне язып та анлата беләсез. Кызганычка каршы, безнен булган, унган кызларыбыз абына. Дөньясы да, күрәсен, унганнар өчен түгелдер. Һәрхәлдә, мин Сезгә изгелек кенә телим. Нинди генә хәлләр булса да, үзегезне саклап калырсыз дип өметләнәм. Кызганычка каршымы, бәхеткә каршымы, кеше гомерен икенче бер кеше яши алмый, үзенә яшәп бетерергә туры килә.*

*Озынрак та яздым бугай. Кешеләрне бәхетле итеп күрәсе килгәннән язылыдыр инде.*

*Хатымны тәмамлап, Сезгә исәнлек-саулык, өметегезне өзмәвегезне телим.*

*Туфан,*
*М.Туфан,*
*12.01.2000.*

# ЭНӘ ТҮГЕЛ, КИТАП!



*Туфан Миңнуллин Фәйрүзә Мөслимова белән Болгарда.*

Арабызда шундый кешеләр була — алар мәңге яшәр кебек, һәрвакыт янәшәбездә булыр кебек тоела. Бу, күрәсең, аларның тормыштагы активлыгы, бик күп мәсьәләләрне хәл итә белүе, дөнья куласасын нәкъ менә алар әйләндергәненә ышануыбыз сәбәпле шулай тоеладыр. Туфан абый әнә шундый кеше иде. «Туфан абый үлгән!» дигән хәбәр бер мизгелгә мингерәйтеп җибәрде: Ничек инде? Ул үләргә тиеш түгел иде бит! Аның үләргә хакы юк иде! Аннан башка безнең дөнья куласасы ничек әйләнер? Тик... фани дөньяда беркем дә мәңгелек түгел, һәм Туфан абый да...

Татар илендә аны һәркем яхшы белә, ул үзе дә һәркемне белә кебек. Дәүләт Советы сессияләре трансляциясен дә кешеләр күбесенчә Туфан абый ни әйтер икән дип, калдырмый карарга тырыша. Театрларга да аның спектакльләренә сөенә-сөенә кат-кат йөри. Базарларда очраганда, үз хәләхвәлләре белән уртаклашып калырга омтыла. (Ә Туфан абый, үзе әйткәнчә, кешеләр белән аралашу өчен базарда йөрергә бик ярата.) Ул һәркемгә ачык, ачык кына да түгел, аның белән аралашу рәхәт, иң якын туганың белән очрашып сөйләшкәндәй буласың.

Туфан абыйның 70 яше уңаеннан бугай, «Ялкын»да аның белән әңгәмә урнаштырырга җыендык. Мин аның янына Дәүләт Советына бардым. «Әңгәмә итеп маташма, үз исемеңнән яз, син мине яхшы беләсең бит», — диде ул. Белүем шул инде — төрле очрашуларда бергә туры килү, әдәби сәяхәтләрдә катнашу, китап-журнал хәлләре турында аягөсте генә фикерләр уртаклашып алу.

Хәтеремдә, Нәҗибә апа турында журналга язма әзерләү өчен, фоторәссамыбыз Рөстәм Мөхәммәтҗанов белән аларның өйләренә бардык. Туфан абый өйдә юк иде. Рөстәмебез исә, фоторәсемнәрен хыялында иҗат итә-итә, күлмәкләрен алыштырта-алыштырта, фонарны үзгәртә-үзгәртә, актриса апабызны өч-дүрт сәгать буе фотога төшерде. Кая ди анда мина үземә тиешле материалны туплау! Ул кайтып киткәч кенә эшкә керештем. Берзаман Туфан абый да кайтты, авылда булган икән — яна суелган ит алып кайткан, мине аш пешкәнче дә калдырдылар. Күчтәнәчкә ит тә биреп җибәрделәр. Мәзәктәгечә килеп чыкты инде бу — бер авыл апасы күрше әбигә мунчага әйтергә кергән дә кунып кайткан, имеш.

Туфан абыйның ахыргача авыл җанлы булып калганын да беләбез. Ул үзенең оныкларын да авылны, авыл хезмәтен яратырга өйрәтә иде. «Оныгым Данияр белән бәрәңге утыртабыз шулай, — дип сөйли Туфан абый. — Күрәм, җирдә казынасы килми, җинел генә яшисе килә. Болай бәрәңге утыртып маташу нигә инде, аны

сатып алып та була, бу бит — экономически невыгодно, ди миңа. Ә миңа сине тәрбияләү, сиңа акча бирү дә экономически выгодно түгел бит, дим. Эндәшми, алай дигәч».

Язучы абый белән Болгар җыенына, Балтач районының Сасна авылына — Тукайның әнисе Бибимәмдүдә каберенә дә бер төркемдә барырга туры килгән иде. 2000 елда Татарстан язучылары һәм журналистларының зур төркемен Пермь өлкәсе татарлары кунакка чакырдылар. Очрашулар Барда районында башланып, аерым төркемнәр белән төрле район, авылларда дәвам итте. Җирле халык янына барып җиткәнче, мондый сәяхәтләр бер-берең белән аралашудан башланып китә бит инде. Без дә шулай поездның плацкарт вагонында әйбәтләп урнаштык. Поезд кузгалып китәргә дә өлгермәде, вагонга чукрак-телсезләр (чыннан да шулайдырмы) килеп кереп, өстәлләребезгә энә җыелмасы, кәтүк-уймак ише вак-төяк таратып үтте, бераздан, ишарәләр белән аңлатып, шулар өчен акча җыярга керештеләр. Аларны кем алды, кем алмады инде. Вагон «сәүдәгәр»ләрдән бушауга, Туфан абый урыныннан кузгалды да өстәл саен үзенең нәни генә «Робагыйлар» китапчыгын таратырга тотынды. Ә үзе, тегеләрнеке төсле ишарәләр белән, акча сорагандай кылана. Без, дәррәү көлешеп, кесәләрдә, акча янчыкларында кармалана башладык. Билгеле инде, бу «сәүдәгәребез» ахырда анысыннан баш тартты. Бүләк булып калды безгә китапчыклар. Аның каравы, һәрберебезгә автографлар язылды. Миңа, мәсәлән, Туфан абый болай дип язган иде: «Фәйрүзә! Мин дә кеше ләбаса, минем дә графоман булырга хакым бар. Сиңа җан тынычлыгы, сүнмәс иҗат ялкыны теләп, М.Туфан. 2.04.2000».

Туфан абый белән соңгы «йолдызлы» очрашуыбыз «Яңа Гасыр» телевидениесенең «Башваткыч» тапшыруында булды. Анда Туфан абый, Луара Шакирҗанова һәм мин көч сынаштык. Җанатарлар итеп университетның тел-әдәбият факультеты студентларын чакырганнар иде. Кроссворд татар әдәбияты, мәдәниятенә нигезләнеп төзелгән, алай да шактый баш ватарлык сораулар килеп чыккалый. Туфан абый алдан ук: «Мин җавап бирә дә алмам, менә кызлар уртасында басып торыр өчен киллем әле», — дип шаярткан булды. Чынлыкта ул күбесенчә безгә юл куйды бугай, югыйсә, бигрәк тә театрга кагылышлыларына ул җавап тапмаслык идеме соң инде! Бик аз гына аерма белән мин — беренче, Луара икенче урын алды. Мәхәлләдәге дини җитәкченең мөхтәсиб, «Кыйссасел-әнбия»не язган төрки язучының Рабгузи икәнлеген безгә студентлар әйтеп бирде. Ахырда, һәркайсыбызга үзебезгә тиешле бүләкләр эләккәч, Туфан абый үз бүләген — өстәл лампасын — Рабгузины белгән студент кызга тапшырды.

Әнә шундый кыска гына очрашуларыбыз турында сагынып сөйләргә генә калды.

**Фәйрүзә МӨСЛИМОВА,**
*шагыйрә*

# «ТӨШ»ТӘГЕ СЕРЛӘР

## Т.МИҢНУЛЛИННЫҢ «ТӨШ» СПЕКТАКЛЕННӘН СОҢ УЙЛАНУЛАР

«Төш» пьесасын Туфан Миңнуллин Оренбург театры, режиссёр Рөстәм Абдуллаев өчен махсус яза. Театр белгече В.Павлова спектакльнең проблематикасын «төрле милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләр, аталар һәм балалар проблемалары, бүгенге иҗтимагый һәм дини вазгыять»[1] дип билгели. Ләкин, безнең карашка, драматургның рухи васыяте буларак яңгыраган әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләр моның белән генә чикләнми.

К.Тинчурин исемендәге театр режиссёры Р.Заһидуллин «Төш» пьесасын сәхнәләштерүгә 2012 елда алына. Безгә спектакльнең премьерасын әдипнең үзе белән бергә карау бәхете насыйп булды. Туфан абый спектакльне, актёрларның уенын дулкынланып, ничектер үзенә хас булмаганча, эндәшмичә тынмый гына тамаша кылды. Спектакль тәмам булгач, көчле алкышлар астында аксакал салмак кына сәхнәгә күтәрелде дә спектакльне гаҗәеп дәрәҗәдә камил сәхнәләштергән режиссёрга, актёрларга ихлас рәхмәтләрен җиткерде. Тамашачыларның фикер-карашлары да истә калган. Пьесаның тәүге куелышын алар төрлечә кабул итте. Сокланып тамаша кылганнары белән бергә, кабул итеп бетермәгәнлекләрен белдерүчеләр дә юк түгел иде. Могҗизага тиң спектакль тамашачының күңел кылларын тибрәтте, йөрәген әрнетте, гомумән, һәркемне уйга салды. Туфан аганы «милләтчелектә» гаепләргә ашыккан тамашачы да табылды анысы. «Төш» пьесасының режиссёр Р.Заһидуллин сәхнәләштергән куелышы вакыт сынавын узды: өч ел дәвамында сәхнәдән, театр белгечләренең теленнән төшми. Т.Миңнуллинның әлеге әсәре тематика җәһәтеннән бигрәк, форма ягыннан үзенчәлекле. Пьесаны «Төш» дип исемләп, драматург әсәрнең стилистикасын алдан билгели. В.Павлова хаклы: «төшнең логикасы үзенчәлекле», «дәлилләр китерү системасы үзгә» — төшләрдә эмоцияләр хакимлек итүе мәгълүм». Мөгаен, режиссёр «драматик хикәяне» мелодрамага шул нигездә күчерә алгандыр да.

Мәгълүм булганча, төш — борынгы әдәбияттан башлап бүгенгәчә киң таралган әдәби алым. Төш «әсәрнең форма ягыннан корылышын, композициясен оештырырга ярдәм итә, катнашучыларга идеологик һәм психологик сыйфатлама бирү, ахыр килеп, автор карашларын белдерү вазифаларын башкара»[2]. Т.Миңнуллин «Төш» пьесасында форма ягыннан М.Кәрим традицияләренә таяна («Салават. Өн аралаш ете төш» трагедиясе (1971), «Ярлыкау» повесте (1984)). «Төш» пьесасында төш (автор белән бәйле тарих) төп сюжет белән кайма хасил итә (Камил һәм Елена мәхәббәте). Драматург иҗат итү тарихын алдан ук теркәп куя: «Мин бу пьесаны спектакль рәвешендә төшемдә күрдем... Язуы җиңел булды. Күчереп язган кебек.

[1] Павлова В. Оренбург. В прозрачных дебрях сна // Страстной бульвар. — 2011. — №4-144 // URL: http://www.strast10.ru/node/2022

[2] Дынник М. Сон, как литературный приём // Литературная энциклопедия: Словарь литературных терминов: В 2-х т. / Под ред. Н. Бродского, А. Лаврецкого, Э. Лунина и др. — М.; Л.: Изд-во Л.Д.Френкель, 1925. — Т. 2. (ФЭБ). // URL: http://feb-web.ru/feb/slt/abc/0.htm?cmd=p&istext=0 (дата обращения: 12.05.2015).

Язганда туктап калдым, чөнки пьеса фикерендә яналык юк шикелле тоелды. Тик барыбер язып бетерергә кирәк дип санадым. Хәерле булсын»[3].

Пьесанын прологында автор-герой тамашачы белән сөйләшү оештыра. Т.Миннуллин, тәнкыйтьчеләрне алдан кисәткәндәй, тәкъдим ителә торган яңа пьесада аның иҗатындагы бөтен темаларның табылачагын искәртә. Әдипнен һәр әсәрен күтәп ала торган даими тамашачы «Төш» әсәрендә «Гөргөри кияүләре», «Илгизәр+Вера» һ.б. пьесаларындагы коллизияләрне танып ала. Т.Миннуллин «кирәк дип санадым»[4] дигән сүзләре белән мөмкин булган бәхәскә алдан ук нокта куя.

Автор, прологта пьесанын язылу тарихы белән таныштырып, тамашачыны әсәрнен үзенчәлекле пафосын — эмоциональ тонын кабул итүгә көйли, әсәр сюжетында уен алымы барлыгына да ишарә итә.

Әдип әсәрнен жанр табигате ягыннан «драматик хикәя» булуын тәгаенләштерә. Билгеле булганча, жанр табигате ике — сыйфат һәм мәгънә өлешләреннән гыйбарәт. Беренче «драматик» дигән өлеш мәгънәви компонент, сәхнәдәге күренешләрне алдан билгели. Хикәя дип атау жанрнын сыйфат ягына карый — спектакльдә актёр уенын бер кысага сала. Драматик хикәя — үзәгендә хикәяләү барышында хәл ителә торган конфликт ята торган жанр ул. Кагыйдә буларак, хикәядә аерым бер кешенен характерын һәм анын җәмгыять белән бәйле конфликтын тасвирлау үзәккә алына.

Әсәрдәге образлар системасы һәм пьеса структурасыннан аңлашылганча, «Төш»не драматург театр традицияләренә тугры калып иҗат итә. Образлар системасындагы хор ярдәмендә («борынгы грек театрында хор дип аталган») Т.Миннуллин тамашачынын игътибарын борынгы юнан трагедиясеннән үк килә торган «мәңгелек проблемага» — язмыш-очрак һәм геройнын иреге проблемасына юнәлтә. Татар драматургынын геройлары да, борынгы юнан трагиклары әсәрләрендәгечә, үз-үзләре белән көрәшкә күтәрелә. Софокл кешенен көче — үз гамәлләренә бәя бирә белүдә, ди.

Персонажлар сан ягыннан күп түгел: гашыйклар Камил (Илфак Хафизов) һәм Елена (Гөлназ Нәүмәтова), аларны тәрбия иткән Фәүзия абыстай (Зөләйха Хәкимжанова) һәм Анна Егоровна (Ләлә Миннуллина). Сәхнә бизәлеше дә персонажларга карап эшләнгән: дүрт тәрәзә / пыяла дүрт күнелгә проекцияләнә. Спектакль барышында сәхнә һәр геройнын күнел тәрәзәләренен ачылуы, фикерләренен тамашачыга җиткерелүенә карап алышына. Әйтергә кирәк, режиссёр Р.Заһидуллин һәм рәссам Р.Моров автор әйтергә теләгәнне бик оста җиткерә алганнар. Камил һәм Еленанын шәхси гаилә тормышы үрнәгендә тамашачы хөкеменә «мәңгелек проблемалар» чыгарыла.

«Төш» пьесасында хор фон тудыру алымы гына түгел, хәрәкәтнен үзен билгеләүче дә. Хор драматизм тудыру алымы буларак дидактик вазифа да башкара. Хор җырлары «эчке тирән мәгънәне» — сызлануларны гәүдәләндерә, конфликт белән шул рәвешле бәйләнә. Пьесадагы мифологик катламда хор ярдәмендә әдип вакытнын турысызыклы һәм циклик модельләрен кисештерә.

Төп героинянын исеменен мәгънәсе борынгы юнан традицияләрендәге Гүзәл Елена турындагы мифка тоташа. Дөрес, автор бер әңгәмәдә героинянын тормыштан алынганлыгын хәбәр итә. Ачкыч символларнын мәгънәсен дә юнан мәдәниятенә бәйле шәрехлибез: чагыштыру өчен: алма (ызгыш-талаш алмасы турындагы миф), йөрәк (йөрәк сурәте хатын-кыз очасы формасынын репродукциясе — борынгы грекларда һәм римлыларда хатын-кызнын матурлыгы турында күзаллау; йөрәк — чормавык яфрагы (шәраб хәзерләү һәм дәрт символы Дионис алла символы)). Т.Миннулин әсәрендә лейтмотивлар техникасы да уңышлы эшләнгән (төш, уен, алма мотивлары).

[3] Миннуллин Т. Төш // Мәйдан. — 2013. — №4. // URL: http://майдан-журнал.рф/tt/yazmalar/item/273-təsh (дата обращения: 15.05.2015).
[4] Шунда ук.

Сәхнәдә хатын-кыз образы һәм пианино Ф.Достоевскийның Неточка Незванова образы белән янәшәлек тудыра. Тормышның төбенә төшә барган хатын-кыз темасы бәҗра булып формалаша. Төп геройның исеме, пьесаның структурасы Һ.Такташның «Камил» һәм «Югалган матурлык» әсәрләрен искә төшерә. Болар барысы да автор фикерен тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

Тәкъдир — Язмыш темасы беренче күренештә үк бирелә. Бу турыда сүзне йөрәгендә тыелгысыз дәрт-дәрман ташып торган Елена башлавы символик укылышлы. Тамашачы НӘСЕЛ традицияләрен бозып, АТА-АНА сүзен атлап үтеп, зина юлына баскан геройлар белән таныша. Елена ярамаган эшме бу, аллә сөюдә иң югары ноктамы, дип үзенең монологында уйлана. Кыз үзен төрлечә аклап карый. Гаепне әбисеннән дә эзли (янәсе, ул оныгын берүзен калдырып, санаторийга киткән), җәмгыятькә дә аудара (Джульетта заманнары артта калды, класста ике генә саф кыз калган ич...), сөйгәненә дә өлеш тия: «Син шундый акыллы, картлар кебек. Ә түзмәдең»[5]. Баксаң, кызның бу адымга баруы дәрт ташыганнан түгел, ә яшүсмерләр өчен хас олылар дөньясына үтеп керергә омтылыш, классташларының көлүеннән унайсызлану аркасында гына икән. Кыз бала бер мизгелдә башка эзгә борылган язмышы өчен җавап бирерлек дәрәҗәдә түгел булып чыга.

Тамашачы Камил яклы. Егет, бөтен җаваплылыкны үз өстенә алып, кызга тәкъдим ясый. Елена сизгеррәк: Камил ничек кенә хәл итсә дә, аның адымы КОСМОС-тәртипнең ХАОС-тәртипсезлеккә әверелүе булачак. Төрки эпосы традицияләреннән үк килә торган халык этикасы буенча нәсел, гаилә кануннарын бозганнарны, һичшиксез, җәза көтә. Чөнки бу гамәл Галәм тәртибен боза. Драматург кайчандыр мөгаллимә булып хезмәт иткән әбидән «үтәмиләр шул Ходай кушканны», дигән яшәешнең гап-гади канунын әйттерә.

Әлеге күренештә уен чаткылары бар. Камил Еленаның кулыннан ала да ир белән хатын булып уйнарга чакыра. Пьесага уен шулай кереп урнаша. Хор җырыннан «Бер матур кыз белән уйнадым», «Он влюблён, я влюблена — / Оба виноватые», — дигән сүзләр күнелгә килә. Әйтергә кирәк, әсәрдә караш ноктасы ике — татар һәм рус мәдәниятләренә нисбәтле. Пьесада милли һәм дини проблемалар күтәрелә. Халык фикере җырның эчтәлегендә генә түгел, ә жанр табигатендә үк чагылыш таба. Хор такмаклар башкара. «Жанр формасы белән такмаклар халык авыз иҗатыннан килгән гомум кабул ителгән кыйммәтләр моделен чагылдыра: формаль рәвештә такмак әхлакый норманы үзгәртүне, башкага әйләндерүне күздә тота». Коллектив күзлегеннән тискәре бәяләнгән күренеш, такмакта норма, уңай дип тәкъдим ителә. Шул рәвешле, такмак жанрында коллектив кыйммәтләр белән диалог җәмгыятьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен, кыйммәтләрне раслауга хезмәт итә. Бу очрак — гомум кабул ителгән нормадан читтән, индивидуаль башлангычның алга чыгуы»[6].

Кыз егетнең мөселман, үзенең христиан динендә булганлыгы өчен борчыла башлый. Чит мәдәниятка караган кыйммәтләрне үзләштергәндә күнелендә туган каршылыкны үтәргә тели:

Е л е н а : Бу кичне мөселманнар ничек дип атыйлар әле?

К а м и л : Зөфаф кичәсе.

Е л е н а : Безнең алай дип аталмыйдыр инде. Без бит...[7]

Әйтелеп бетмәгән сүз түйдагы җырланып бетмәгән рус халык җырында кабатлана. Режиссёр һәм хормейстер мона баянның озын көй уйнавын да өстиләр. Бу исә — Чеховның мәгълүм «өзелгән кыл чыны» деталенең инварианты. Корьәндә, яна туган

[5] Шунда ук.

[6] Эммер Ю.А. Миромоделирующая функция частушки в праздничном дискурсе // Вопросы когнитивной лингвистики. — 2013. — №1. // URL: vital.lib.tsu.ru›vital/access/services/Download/

[7] Миңнуллин Т. Төш // Мәйдан. — 2013. — №4. // URL: http://майдан-журнал.рф/tt/yazmalar/item/273-tesh (дата обращения: 15.05.2015).

балалар мөселман булган очракта, милләтара никахлар катгый тыелмый. Пьесаның башында ук Еленаның чит мәдәниятка кереп китүеннән эчке унайсызлык тоюы сизелә. Гөлназ Нәүматова Еленаның сызлануларын бик тирән житкерә алды. Елена үзенең Камил белән икесе ике төрле кеше икәнлекләрен таный. Берсе — романтик, дәртле, хискә бирелүчән, икенчесе — прагматик, төпле, гыйлемгә омтылышлы. Гыйлемлелек темасы да беренче күренештән үк тоемлана башлый.

Өйләнешү шатлыгыннан гашыйклар ижтимагый вазифаларын да җинел генә атлап үтәләр: Елена ана һәм хатын булу турында күп уйланса, сөйләсә дә, өйдә хатын вазифаларын үз өстенә алырга ашыкмый: урын-жир жыйнаксыз, аш-суны ире үзе хәзерли. Кыз исә тулаем өйләнешү уены белән мавыккан. Камил исә 7 ул үстерергә хыяллана: «Жирне күтәреп торырга ир-егетләр ине кирәк. Явызлар башлаган сугышта үләр өчен дә ирләр кирәк». Мәгълүм булганча, исламда 7 — камиллек саны, Кәгъбәне 7 тапкыр әйләнәләр. Димәк, Камил Галәм тәртибе — КОСМОС алдында җаваплылыкны бөтен йөрәге белән тоя булып чыга.

Еленаның каршылыклы хисләре «Мин сине шундый сагындым...» җырындагы: «Ак бураннар урап алса, / Табарсың микән юлны?» дигән сүзләрдә чагыла. Гүзәл Елена турындагы миф Андромеда йолдызлыгы турындагы мифка тоташа. Төш темасы үз чиратында вакытның циклик булуы турындагы билге — спираль галактика формасындагы йолдызлыктагы томан белән бәйле.

Камил беренче күренештә пыяла артында жинаятьче сыман тамашачыга ян белән тора. Аның беренче хәрәкәте кулын сөлге белән сөртү була. Режиссёрның бу табышы — ирнең тормыш стратегиясенә ишарә. Сюжет үстерелешендә ир проблемалардан кача (русларда «умывать руки» дигән гыйбарә бар). Тәпкәләр һәм карават парлы образы ярдәмендә режиссёр «обломовщина» инвариантын — обломов диванын — героиняның рефлексиясен ассызыклый. Геройларның төш халәтендә икәнлекләрен дә истән чыгармыйк, чөнки төштә предметлар үзгә мәгънә алалар. Әйтик, өйдәге тынычлык, иминлек символы тәпкәләр төшлектә бәхетсез никахны, интригаларга эләгү куркынычын белдерә, дип шәрехләнә.

2 пәрдәле спектакль үз эченә 9 күренешне ала. «Төш»тә 9 санының килеп керүе дә очраклы түгел. Пифагор 9 саны — чик сан, башка бөтен саннар аның эчендә әйләнә, ди. Нумерологиядә 9 таркалмый торган материяне символлаштырып килә. Димәк, Т.Миннуллин әсәрендә пространство үз эченә аерым кешеләр тормышыннан гыйбарәт бербөтен яшәешне ала. Шул сәбәпле режиссёр актриса Гөлназ Нәүмәтовадан 7 төрле хатын-кыз образын уйната. Чыннан да, дәртле Еленаның тормыш юлы төрлечә була ала.

Т.Миннуллин пьесада шәрык һәм гареб фикерләү рәвешен очраштыруга ирешә (чагыштыру өчен: М.Ю.Лермонтовның «Безнең заман герое»ннан «Фаталист»). Шәркый фикерләү рәвеше өчен «язмыштан узмыш юк» дип яшәү — тәкъдиргә ышану хас, көнбатышча фикерләгән кеше, киресенчә, тормышны үзгәртә алачагына ышана. Икенче пәрдәдә тәкъдир һәм хөрлек темасы язмышны үзгәртеп булмау мотивына тоташа. Менә ишарә буларак татар халык җырлары — дүртьюллыклар кертелә.

Тамашачы балаларының язмышы өчен кайгыра торган аналарның сөйләшүен ишетә. В.Павлова фикеренчә, «Анна һәм Фәүзия дуэты спектакльгә кешеләрнең, халыкларның үзара мөнәсәбәтләре өчен гаять тә әһәмиятле якны — үз дәрәжәңне саклау, ихтирамлылык нотасын кертеп җибәрә»[8]. Анна Егоровна монологы Елена үскән гаилә тормышына үзәктән карау мөмкинлеге бирә. Язмыш әбине татар мохитенә китерә, ул, яшәргә җайлы-унайлы булсын дип, телне, гадәтләрне үзләштерә. Анна Егоровна татар гаиләсендә бала тәрбияләү тәртибенә игътибар итә. Бу күренештә «чит»-«үз» оппозициясе автор тарафыннан тирән үткәрелә, татарның милли яшәеш тәртибе үзәктән ачыла. Чыннан да, ислам — татар

[8] Павлова В. Оренбург. В прозрачных дебрях сна // Страстной бульвар. — 2011. — №4-144 // URL: http://www.strast10.ru/node/2022

кешесе өчен дин генә түгел, яшәү рәвеше ул. Гореф-гадәтләрне үзгәртмичә саклау темасы ике әби сөйләшүендә дә чагылып китә: «әтисенә карап улына бар, әнисенә карап кызын ал»[9]. Анна Егоровна да кызы кебек, гореф-гадәтләргә саграк карый, кызым үземә охшамаган, ди. Ләкин тамашачы әби белән кыз арасындагы уртаклыкны тоеп ала. Алар икесе дә баш югалтырлык дәрәҗәдә дәртле. Анна Егоровна укытучылык гамәле белән мавыгып китеп, ирен дә, кызын да югалта.

Т.Миннуллин ата-аналарны газиз балаларының киләчәк язмышы, бигрәк тә гаилә корулары өчен җаваплы булырга чакыра. «Без нишли алырбыз икән?»[10], — дип әрни Фәүзия апа, Аллага тапшырып, Анна Егоровна исә күршеләренә, аларның гамьле булуларына ышана. Камилнең әнисе моны сынау дип кабул итә. Гыйлемле хатын-кыз буларак, рус әбисе бәхетле булыр өчен, һичшиксез, телне һәм гореф-гадәтләрне үзләштерергә кирәклеген таный. Күршесен ихтирам иткәнгә, Камилнең әнисе эчен тырнап торган сиземләүгә игътибар итми. Ләлә Миннуллина (Анна Егоровна) һәм Зөләйха Хисмәтуллина (Фәүзия) бу күренештәге драматизмны тамашачыга гаҗәеп осталык белән җиткерә алдылар.

Балалар турында җитди сөйләшүне русның кыю такмакларын башкарган хор туктата. Хорның дидактик вазифасы шул рәвешле чынга аша. Тамашачы беренче күренештә үк билгеләнгән тема — кабул ителгән нормалардан китү дулкынына көйләнә. Хореографның (Ләйсән Хәмәтова) профессиональлеген билгеләп үтик: милли биюләрнең элементлары геройларның кайсы мәдәни мохиттә икәнлекләрен сөйләп бирә. Бию техникасында милли характер, фикерләү рәвеше, кыйммәтләр, әхлак нормалары чагылыш таба.

Татарча сөйләм русча сөйләм белән алышына: шул рәвешле, сөйләшү барышында геройларның әдәбендәге үзгәрешләр ассызыклана. Әби Еленаның гөнаһы өчен гафу үтенә, кызына хакыйкатьне төшендерә: «Чтоб ты это знала и запомнила на всю жизнь. Все люди на земле как люди, одинаковые. Нет ни плохих, ни хороших. Но так сложилось: все народы разные. Тоже нет плохих, ни хороших — все равные. Но у каждого народа есть свои нормы поведения, своя вера. Как говорит отец Камиля — религии разные, Бог один. Такова жизнь — вот эти нормы поведения частенько сталкиваются»[11]. Шул рәвешле, Анна Егоровна Еленаны милләтара никахларның шактый каршылыклы булуы, ә хискә бирелүчән кешеләрнең мондый кыенлыклар алдында югалып калырга мөмкинлеге турында кисәтә. Беренче тапкыр әби кызы белән милли характер хакында сүз кузгата: «Ты, доченька моя, страстная как твоя мама. Страсть погубила твою маму. Страсть, излишняя доверчивость, доступность губит русскую женщину. Коня на скаку остановит, в горящую избу войдёт, говорят о нас. Но часто мы остаёмся под копытом скачущего коня и сгораем в горящей избе»[12]. Бу юллар — Некрасовның «Мороз, красный нос» поэмасыннан мәһабәт славян кызы тибы турындагы юлларның үзгәртелгән варианты. Шул рәвешле, эчке мәгънә мөмкинлекләрен файдаланып, драматург тамашачыны милли эстетик идеал, милли характер турында уйлануларга алып килә.

4 нче күренеш рус халкының туй такмаклары белән башлана. Автор хатын-кыз такмакларын сайлап ала. Шулай Еленаның лидерлык сыйфатларына басым ясала. Рус халкының туй йоласы — кәләш җыры әнисенең яраткан җыры «Уральская рябинушка» булу очраклы түгел. Җыр — күңел көзгесе, шул рәвешле, драматург «кан тарту» мотивын кертеп җибәрә. Бүләккә дип җырланган җырда миләш образы ачы язмышка ишарә итә.

Камилнең туйны ясин белән чагыштыруы урынлы түгел, чөнки ясин — исламда

[9] Миннуллин Т. Төш // Мәйдан. — 2013. — №4. // URL: http://майдан-журнал.рф/tt/yazmalar/item/273-tosh (дата обращения: 15.05.2015).
[10] Шунда ук.
[11] Шунда ук.
[12] Шунда ук.

күмү йоласы белән бәйле дога. Мәет янында ясин чыгу кеше үлгәннән соңгы юлны җинел үтсен өчен кирәк. Камил, бу йолалардан аз-маз хәбәрдар булса да, әлегә рус әдәбиятыннан Тургеневның Базаровы кебек, кешене табигатьтән өстен, хаким зат дип саный. Яшьләрнең туйдан соңгы сөйләшүе фәлсәфи мәгънәгә ия: хөрлек һәм кеше темасы шулай үстерелә. Камил хатынына тулы ирек бүләк итә. Илфак Хафизов уйнаган образны караганда, бер фикер урнаша: эмоциональ яктан үзен шулай тыйнак-җыйнак тотар өчен, актёрдан никадәр эчке сабырлык, көч таләп ителә. И.Хафизов героеның гел югалтулардан торган тормыш драмасын бөтен тулылыгы белән ачып бирүгә ирешә. Гөнаһка тарткан богдай җимешен татыганнан соң (тагын бер деталь игътибарга лаек: Камил сәхнәдә кетердәтеп алма ашый), герой җан тынычлыгын җуя. Камил табигатьтән бик талантлы булса да, ни кызганыч, ата буларак та, табиб буларак та үзен таба алмый.

Бу күренештә пьесага Шүрәле турындагы миф кертелә. Т.Миннуллин матурлык /гариплек категорияләренең шартлы икәнлеген раслый. Камил тамашачы алдында гарип Шүрәлене терелтү мифын уйлап таба. Бу — Б.Шоуның мәгълүм пьесасыннан Пигмалеон һәм Элиза Дулиттл турында легендар тарихның ироник варианты. Сизгер Елена «акыллы» Камилгә хакыйкатьне ачып сала: «Соң Шүрәленең Шүрәлелеге беткәч, әйбәт буламы? Кешегә охшаган Шүрәле котсыз бит ул, Камил. Шүрәле бит ул урман бизәге. Ул кагылып китсә, агачлар яшәрә, яфраклар лепердәшә, ул көлеп үтсә, урман ямьләнә, йоклаган табигать уяна. Аның көлгәнен хәтта йолдызлар да ишетә — яктырак җемелди башлыйлар, ай елмая».[13] Шүрәле турындагы миф гаҗәеп кызыклы уйларга этәрә. Милләтара никахта кайсыдыр як үзенең милли сыйфатларын җуя, бу — котылгысыз күренеш. Ләкин үз асылыннан баш тарткан җан нишли? Кан тартуын ничек җиңә?

5 нче күренеш уйга чумган татар кызы җыры белән башлана. Ирен ярата торган Елена эчке сызлануларының сәбәбен эзли: болар — эшеннән канәгать булмау (ул — укытучы), баласызлык. Пьесада, төрки әдәби традицияләргә хас булганча, баласызлык Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән сынау кебек анлана. Бала — Аллаһы Тәгаләнең бүләге ул. Яшь хатын баласызлыкны Аллаһы Тәгалә алдында кылган гөнаһлары өчен җавап тоту дип исәпли: «Ходай алдында гаебебез бар безнең, Камил. Шуның җәзасын алабыз. Түзмәдек»[14]. Ир үз чиратында хатынына, диннең нигезләрен үзләштермичә торып, артык мавыкмаска кинәш итә, югыйсә, фанатикларча бирелгәнлек бәлагә китерер, дип кисәтә. Камилнең бу турыдагы сүзләре тамашачыны уйга сала: «Мин Алласызлык турында әйтмәдем, дин турында әйтәм. Аңла, дин ул идеология генә, Алла — рух. Аңла, бәгырькәем, Ватан бар һәм шул Ватанга хезмәт итәбез диюче партияләр бар. Ватан төшенчәсе — изге төшенчә, партияләр изге була алмый. Дин дә шулай»[15]. Елена Камилне алласызлыкта гаепләве белән хаклы түгел, ир иманлы булуын үзе үк белдерә. Сөйгәне белән ачыктан-ачык сөйләшкәндә, ир Язмышны сайлаган вакытта һәркемнең Аллаһы алдында бурычлы булуын әйтә. Һәр кешедә Аллаһының бер өлеше-кисәге яши, яшәешнең илаһи тәртибен бозган кешене исә җәза көтә. Әсәрдә тәкъдир һәм хөрлек темасы «ирек — җаваплылык ул», дигән мәгънәдә үзенчәлекле ачыла.

Уен мотивы Еленаның Шекспирның «Отелло»сын уйнарга чакыруында да кертелә. Кыз үзендәге инфантильлекне җиңә алмый, чынбарлык белән күзгә-күз яшәүдән кача, һаман уйный. Ул гүя гаилә уенын алып бара, ир ихтыяры белән яшәүнең тәмен эзли.

6 нчы күренеш иргә хәсрәт китерүче хатын турындагы татар җыры белән башлана: «Яр булыр өчен яралмаган, / Җан көйдерер өчен яралган». Бу күренештә барлык катнашучылар бергә җыйнала. Сүз гаилә башлыгы — ирнең үз гаиләсе

[13] Шунда ук.
[14] Шунда ук.
[15] Шунда ук.

өчен җаваплы булырга тиешлеге турында. Анна Егоровна Камилне: «Ал син аны кулга»[16], — дип үгетли. Фәүзия апаны да яшь гаиләдәге хәлләр борчый. Камилнең туганнарын килешнәренен сектага керүе турындагы кешe сүзе сискәндерә. Камил, өлкәннәр йогынтысына бирелеп, хатынына кул күтәрә: «Ялгышканмын. Бүгеннән соң мин теләгәнчә яшибез»[17], — дип яный.

7 нче күренеш гаилә, язмышына тигән өлеш турындагы татар һәм рус җырлары белән ачыла. Камил хатынын дүрт стенага бикләп куюдан ары китә алмый, аның рух канатларын тулысынча сындыра. Нәкъ менә шушы күренештә С.Садыйкованың Ә.Ерикәй сүзләренә 1942 елны язылган «Көтәм сине» атаклы тангосы яңгыравы — символик. Танго темасын спектакльгә хор алып керә. Билгеле булганча, тангоның ватаны — Буэнос-Айрес һәм Монтевидео. Бу җирләрдә Африка, Испания, Көньяк Америка мәдәниятләре кисешә. Әлеге биюнең хореографиясе үз эченә милонка, хабанера, полька, мазурка һәм вальс элементларын туплый. Партнёрларның артык якын торып биюләре тангоны югары сәхнәгә чыгару өчен шик уята. Аны уйлап табучылар дәртле, сексуаль характердагы бию икәнлегенә басым ясыйлар. Урам музыкантлары тангоны башкарган вакытта скрипка, гитара, арфа, флейта һәм аккордеон кебек музыка коралларында уйныйлар. Танго-җыр артык эмоциональ. Танго-җырның эчтәлеге ярсу хисләр белән бәйле. Төп темасы — фаҗигале мәхәббәт. Танго — хәрлекне сагыну турындагы бию, аның максаты — ир-ат һәм хатын-кызны якынайту[18]. Танго темасы костюмнарда да чагылыш таба. Режиссёр тапкан деталь игътибарга лаек: героиня дискларны кулыннан төшереп җибәрә, С.Садыйкованың тангосын тиз генә таба алмыйча аптырый. Бу күренеш табигый, чөнки Ә.Ерикәйнең әсәре фронтка киткән сөйгән ярга тугрылык турында. Төшнең сихри законнары буенча геройларның яшәеше үлеләр дөньясы белән кисешә. Күренеш әбинең үлеме турындагы шомлы хәбәр белән ябыла, аның шәүләсе пыяла артында пәйда була.

8 нче күренеш татар җыры белән ачыла. Ихтыярсыздан Экклизиастның: «Һәр гыйлемдә — хәсрәт бар, белемен арттырган кеше хәсрәтен арттыра», — дигән сүзләре искә төшә. Җыр тамашачыны Еленаның фаҗигасенә әзерли. Камилнең өй җыештыруы гаиләдә рольләр алышыну турында сөйли. Елена үләргә тели, Камил исә тагын кача, дөресрәге, җаваплылыкны монастырьга аудара.

9 нчы күренеш гөлбакчага сикереп, ташка тарыганнар турындагы татар халык җыры белән ачыла. Бу җыр беренче күренештәге гашыйклар очрашкан гөлбакча турындагы җыр белән кайма хасил итә. Ир муенындагы дәртле ташкүнел метафорасы — драматургның табышы. Теләсә кем мондый йөкне күтәрә алмый шул. Соңгы күренештә гаилә драмасы фаҗига белән тәгалләнә. Камил алкоголизм чире белән авырый торган Еленага мәрхәмәтлелек күрсәтә. Ихтыярсыздан Горькийның «На дне» әсәреннән Актёр образы искә төшә. Елена Камилгә тормышның төбен дә, төмен дә татыганлыгын әйтә. Хатын бөтен бәлаләрендә ата-аналарын гаепли: «Я — творение человеческого греха». Аллаһы Тәгаләне битәрли: «Мин дә, син дә гаепле түгел, безне очраштырган Ходай гаепле»[19]. Шулай итеп, тыелгысыз дәрт бөҗрасы ябыла, бу да, берсүзсез, — драматургның табышы. Әйткәнебезчә, Елена-Нәүмәтова күңел каршылыкларын гаҗәеп дәрәҗәдә оста җиткерде. Зал бу образның кичерешләрен күз яшьләрен тыя алмыйча күзәтте.

Эпилогта язучы-герой төштәге вакыйгаларның хатынның үзенә кул салуы белән тәмамлануын хәбәр итә. Ләкин пьесада герой-драматург Еленаны үлем алды сүзеннән мәхрүм итә, чөнки ул — болай да «үле җан». Кеше илаһи башлангычына ирешү өчен, гомер буена үз өстендә эшләргә бурычлы. Хорның

[16]Шунда ук.
[17]Шунда ук.
[18] Иванов С.Л. Танго как жанр музыки и танца // URL: repository.buk.by:8080
[19] Миннуллин Т. Төш // Мәйдан. — 2013. — №4. // URL: http://майдан-журнал.рф/tt/yazmalar/item/273-tosh (дата обращения: 15.05.2015).

соңгы җырлары да үле җаннарга кырыс хөкем сүзе булып яңгырый: «Самовар куйдым күмерсез», «Эх, яблочко / Сбоку верчена; / Я жила с милым, / Да не венчена»[20].

Тормыш фаҗигасенең сәбәбе — хатындагы ирек-хөрлеккә омтылышның чиксезлеге һәм ирнең ихтыярсызлыгы. Камил һәм Елена, үз «мин»нәреннән артык беркемне дә күрмиләр, шуңа күрә нәсел алдындагы бурычны, ата-ана сүзен җиңел генә атлап үтәләр. Бу Галәмдәге тәртип — Космос җимерелүгә, Хаос барлыкка килүгә китерә. Пыялага иннек белән язылган кушу мисалы — Елена+Камил = ♥ — килеп чыкмый. Режиссёр героиняны берничә тапкыр пыялага китерә, кушылучы якларны боздыра. Арифметик мисалның кыскаруы геройлар арасындагы хисләрнең юкка чыгуы турында хәбәр итә (юкка гына «хисләр арифметикасы» димиләр бит). Пыялага иннек белән язу әхлак нормасына да сыешмый.

Сәхнә бизәлеше аерым игътибарга лаек. Караватг, урын-җир детале — әсәрнең структурасын барлыкка китерүче образ. Бу — авторның төш пространствосына күпер. Бу — гөнаһ урыны, биредә ике гашыйк зина кыла. Бу — хыянәт урыны. Караватг, урын-җир — хатынның ялгызлык пространствосы да.

Урын-җирнең пөхтә итеп җыелган яисә, киресенчә, җыелмаган икәнлегенә басым ясала. Елена урын-җирен тәртиптә тотмый. Аны йә Камил, йә Фәүзия апа җыештыра. Хатынның тыелгысыз дәрте аның тормышын тәртипсез итә. Туй төнендә хатын караватка туфлиен салмыйча менеп бии. Символик укылышта бу — хатынның гаилә тормышын туфлие белән таптавы. Ак мендәр тышы чәчәкле тыш белән алышына. Шулай кайчандыр бер-берсен өзелеп сөйгәннәр арасында сафлык, тугрылык юкка чыга.

Сәхнәдә — кечкенә өстәл. Савыт-саба алышыну да эчке мәгънәгә ия. Чәйнек / чынаяк / чәй эчү дә Еленаның тыелгысыз дәртен символлаштыра. Пар чынаяк (яшь парларга ишарә) ялгыз чынаяк белән алышына. Чынаяк пары — язмыш тәлинкәсе. Пар чынаякны бәхетсез гаилә символы — ялгыз чынаяк алыштыра. Сызгыра торган чәйнек — уңышсыз, тәртипсез өй билгесе. Борынгылар өйдә сызгыруны йорт бушап калуга юраганнар. Технократик заман вәкилләре сызгыра торган чәйнекне йортка хәтерсезлекләрен кисәтер өчен махсус кертәләр.

Тәрәзә/көзге сәхнә пространствосын оештыра. Тәрәзә — күңел символы. Тәрәзәләр — геройлар һәм тамашачы позициясен билгереп килүче пыяла. Аерым гаиләнең тормышы пыяла аша бирелә (чагыштыру өчен: «За стеклом»), шул рәвешле, иҗтимагый проблемалар калкуландырыла. Еленаның хисләре киеренкеләнгән мизгелләрдә тәрәзә көзге белән алышына.

Хор (Лилия Вильданова, Резидә Сәләхова, Артём Пискунов, Булат Зиннәтуллин, Тимур Баһаветдинов) спектакльгә җанлы кереп урнаша. Ир-ат костюмнары һәм уен кораллары танго атмосферасын тудыра. Хатын-кыз костюмнары миллилекне ассызыклый. Актёрлар сәхнәдә кеше күп булуы турында иллюзия тудыралар. Музыка кораллары миллилеккә басым ясый. Мандолина, курай — татар күңеле символлары.

«Төш» пьесасы, һичшиксез, татар әдәбиятының алтын фондына керәчәк. Атаклы рус галиме Ю.Лотман: «Төш ул — «үзеннән эчке дөньяны аңлауга юл», — дип билгерә. Т.Миңнуллинның «Төш»е яшәеш кыйммәтләрен яңадан барларга, тормышны яңа күзлектән бәяләргә этәрә. Спектакль, берсүзсез, Тинчурин театры коллективының уңышы да. Тамашачы драматург тудырган серле-сихри чынбарлыктан яңа мәгънәләр эзләр, гыйбрәтләр алыр. Бу гаҗәеп камил куелыш әле озак еллар күңелләрне әсәрләндерер, дип ышанабыз.

**Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

[20] Шунда ук.

# ТУФАН МИҢНУЛЛИН ДРАМАТУРГИЯСЕ

2016 елда оешуына 110 ел тулачак татар театры үсешенең һәр этабында аны репертуар белән тәэмин итүче, үсеш юналешен билгеләүче бер яки берничә әйдәп баручы драматург булганлыгы мәгълүм. Әйтик, баштагы чорда андыйлар рәтендә Г.Камал, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан булса, 20-30 нчы елларда — К.Тинчурин, Т.Гыйззәт, 40-50 нче елларда исә Н.Исәнбәт, М.Әмирләр алгы планга чыга. Ә инде алтмышынчы елларның икенче яртысыннан соң бу җаваплы вазифаның төп авырлыгын Т.Миңнуллин үз җилкәсенә ала. Болай дип әйтү башка драматурглар булмаган, яки алар бернәрсә дә язмаган дигән сүз түгел. Әлбәттә, башка драматурглар да бар, алар да шактый актив иҗат итәләр. Ләкин күрсәтелгән алтмышынчы еллар уртасыннан алып яңа XXI гасырның беренче дистә еллары ахырларына кадәр вакыт аралыгында сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да үзәк позицияләрне алып торган драма әсәрләренең зур күпчелеге Т.Миңнуллин иҗатына карый. Әйтергә генә ансат, әлеге вакыт-чорда барлыгы кырыктан артык, төрле жанрдагы, төрле проблема күтәргән, йөзләрчә эреле-ваклы образлар, күрелмәгән өр-яңа характерлы геройларны сәхнәгә чыгарган пьесалар яза Т.Миңнуллин. Аның бу фидакарь хезмәте татар халкының театр сәнгатен үстерүгә керткән бәһаләп бетермәслек зур өлеше булып саналырга хаклы.

Драматургия әдәбиятның иң авыр һәм үтә катлаулы төрләреннән санала. Һәм юкка түгел. Пьеса язу өчен әдәбият кануннарын, сүз сәнгатен камил белү генә җитми. Бирелә бөтенләй башка закончалыкларга таянган сәнгать булган театр дөньясын да тулысынча аңларга, аның өчен аеруча мөһим булган шартлылык һәм тормыш дөреслегенең сыйфатлы синтезын тудыра белергә кирәк. Шуңа күрә дә драматургиягә иҗатчылар сирәк килә. Килгәннәренең зур күпчелеге уңышка авыр ирешә. Т.Миңнуллинга да Мәскәүдәге Щепкин исемендәге югары театр училищесы тулай торагы почмагындагы такта белән бүлеп алынган «иҗат лабораториясендә» башланган тәҗрибәләре тиз генә уңыш китерми. Минзәлә театрында куелган «Авылым кешеләре», Әлмәттә яшь артистлар тарафыннан уйналган «Очканда-кагынганда» пьесаларын әле берничек тә камил драма әсәрләре дип әйтеп булмый. Г.Камал исемендәге театрда Р.Бикчәнтәев тарафыннан балалар өчен куелган «Азат» әкият-спектакле дә, шактый отышлы куелуына карамастан, Т.Миңнуллинны халыкка таныта алмый. Беренче зур уңышны аңа М.Сәлимҗанов сәхнәләштергән «Миләүшәнең туган көне» драмасы алып килә. «Хрущёв җепшеклеге» елларының дымлы яз һавасын үзенә сеңдергән әлеге әсәр менә кадәр татар театрында сәхнәгә күтәрелмәгән өр-яңа проблемасын, шул елларда иҗат мәйданына килгән җырчы, художник, шагыйрьләр, музыкантларның тормыш-көнкүреше, яшәеше, уй-фикерләре, яшәү рәвешен тамашачы алдына чыгара. Һәркайсының үз характеры, дөньяга карашы, тормыш фәлсәфәсе бар яшь кешеләрнең. Һәм алар үзләренең төрлелеге, җәмгыятьтә үз урынын табу өчен аңа гына хас юллар эзләве белән кызыклы. Чор һәм шәхес, җәмгыять һәм иҗат кешесе, заман һәм иҗатчы кадере, дәүләт һәм кыйммәтләр шкаласы үзгәреше проблемаларын күтәргән әлеге әсәрдән алга таба, «Дуслар җыелган җирдә», «Хушыгыз!» драмалары да өстәлеп, бөтен иҗат буыны вәкилләренең язмышын (иҗатка килү, уңышка ирешкән еллар һәм хушлашу чорларын эченә ала) чагылдырган трилогия туа.

«Миләүшәнең туган көне» спектакле язылган чорда формалашкан режиссёр М.Сәлимҗанов һәм драматург Т.Миңнуллин тандемы алга таба дистәләрчә уңышлы спектакльләр барлыкка китерә. Шуларның «Ир-егетләр», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Моңлы бер җыр», «Канкай углы Бәхтияр», «Илгизәр+Вера», «Дивана», «Мулла» кебекләре арадан иң уңышлылары рәтендә саналырга хаклы.

Гомумиләштереп караганда, Т.Миңнуллин язган пьесаларны ике төркемгә бүлеп анализларга мөмкин: 1) заман темасына багышланган, авторның чордаш геройларын сәхнәгә чыгарган, пьеса язылган вакытта җәмгыятьнең, халык тормышының актуаль проблемаларын чагылдырган һәм 2) татар халкының менталитетын тәрбияләү, милли үзаның үстерүгә юнәлдерелгән тарихи һәм тарихи-биографик әсәрләр. Әлбәттә, бу бүленеш шартлы. Чөнки, аерым алып караганда һәр пьесада үзенә

генә хас жанр төсмерләре, фикер яңалыклары, стиль үзенчәлекләрен табарга мөмкин. Әйтик, «Диләфрүзгә дүрт кияү» спектаклендә төп сурәтләү чараларының берсе буларак музыка компоненты алына һәм ул вакыйгалар барышында шактый күптөрле вазифалар башкара. Ә менә музыкаль сурәтләү чаралары ягыннан аңа шактый якын торган «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәре автор тарафыннан фәлсәфи яссылыкта чишелгән, Кеше һәм Әҗәл, Яшәү һәм Үлем арасында барган аяусыз көрәшкә, ситуациянең котылгысызлыгына карамастан, оптимистик рухта хәл ителә. Җәлил һәм аның көрәштәшләре батырлыгына багышланган «Моңлы бер җыр» драмасы исә хәзерге заман шагыйренең җәлилчеләр каһарманлыгы чыганаклары турында уйлану формасында язылса, вакыт һәм вакыйгалар урыны, пространство категорияләре белән ирекле эш ителсә, Тукай тормышының билгеле бер этабын тасвирлаган «Без китәбез, сез каласыз!» әсәрендә тормыш вакыйгаларының табигый эзлеклелеге сакланган.

Т.Миңнуллин әсәрләренең үзенә куелган конфликтлар да гаять күптөрле. «Нигез ташлары», «Монда тудык, монда үстек», «Ир-егетләр», «Төш», «Сөяркә» кебек пьесаларда төп каршылык якын кешеләр, бер гаилә әһелләре, ата-ана һәм балалар, җан дуслар, хезмәттәшләр арасында булып, шулар аша җәмгыятьнең актуаль проблемаларында чагылса, «Ай булмаса, йолдыз бар», «Моңлы бер җыр» һ.б. әсәрләрендә конфликт, гомумән, сурәтләнгән вакыйгалардан читкә чыгарылып, автор һәм персонаж яссылыгына күчерелгән. Драматургның күп кенә пьесалары драматик хикәя, драматик повесть формасында язылганнар. Боларда персонажларны капма-каршыга бүлү, вакыйгаларны каршылык аша үстерү юк дәрәҗәсендә! Күбрәк проза жанрында очрый торган эпик хикәяләү манерасы өстенлек ала. Драматургның бу язу манерасы кайбер драматургия, театр белгечләренә аны конфликтсызлыкта гаепләү өчен дә сәбәп булды (П.Руднов, Мәскәү). Аларны тыңлаганнан соң Т.Миңнуллин шактый гына вакыт кәефсезләнеп, уйланыбрак та йөрде. Безнең карашка, бу авторның кимчелеге түгел, бәлки иҗат үзенчәлеге. Язучыны ни өчен мин уйлаганча язмыйсың дип битәрләү, гомумән, дөрес түгел. Һәркем тормышта булган вакыйгаларны үзенчә кабул итә һәм үзенчә әсәр буларак формалаштыра.

Т.Миңнуллин язучы-драматург, публицист буларак та, җәмәгать эшлеклесе, халык хадиме – дәүләт депутаты буларак та соңгы елларда илкүләм җәмгыяви үзгәрешләрне җентекләп күзәтеп, анализлап барды. Аның бу беркадәр шик, саклык, икеләнү аша кабул ителгән күзәтүләре драма әсәрләрендә дә чагылмый калмады. Чагыштырмача соңгы елларда язылган һәм 2006 ел «Яңа татар пьесасы» конкурсында беренче-икенче урыннарны яулаган «Дивана», «Мулла» драмалары нәкъ шундыйлардан. Сурәтләнгән вакыйгалар, катнашкан персонажлар төрле булсалар да, бу ике пьеса, минем фикеремчә, бер-берсенә нык бәйләнгән. Ни өчен дигәндә, алар җәмгыятебездә барган бер үк глобаль яңалык, үзгәрешләрнең ике ягын сурәтлиләр. Чорлар алмашу, идеологик ориентирлар үзгәрү тарихи вакыйгасы ул. «Дивана»да житмеш ел дәвамында ил белән идарә иткән марксизм-ленинизм идеологиясе, социализм, коммунизм утопиясе чигенү, юкка чыгу турында сөйләнсә, «Мулла» драмасында исә җәмгыятькә дин-иман кайту, халкыбызның меңьеллык ислам мәдәнияте кыйммәтләренең бүгенге кучәрләреннән ычкынган тормышыбызга күп авырлыклар, каршылыклар аша кайтуы тасвирлана. Әлеге әсәрләрнең бик күп театрларда куелуы һәм тамашачыларның спектакльләрне зур кызыксыну белән кабул итүе аларның нәкъ әнә шул көннең кадагына суга торган актуальлеге чорны, заманны янача чагылдыруы белән аңлатыла.

«Кеше китә, җыры кала» гыйбарәсен кулланcам, яңалык булмас. Ләкин бу контекстта ул Т.Миңнуллин эшчәнлегенә гаять тәңгәл килә. Туфан Габдулла улыннан соң гаҗәеп зур иҗат мирасы калды. Һәм ул күпкырлы бай иҗат дөньясы үзенең тикшерүчеләрен көтә. Алда драматургның хезмәтенә өр-яңача якын килеп, тирәннән эзләнеп язылган том-том монографияләр туар дигән өметтә калам.

**Мөхәммәтгали АРСЛАНОВ,**
*сәнгать фәннәре докторы*

# ТУФАН ДӘВАМ ИТӘ...

Туфан дигәч тә, Америка ярларында ду килеп котырынган цунами, җил-давыллар турында сүз бара дип уйлый күрмәгез. Андый бәла-казалардан Ходай сакласын! Сүзем — олпат милләттәшебез, данлы драматург, утлы публицист, оратор һәм җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллин турында. Аның бакыйлыкка күчүенә дә инде байтак вакыт үтеп бара икән...

Туфан — халкыбызның күтәреп алынган һәм яраткан улы иде, бу — бәхәссез. Аның эшчәнлеген, иҗатын һәм исемен мәңгеләштерү гамәлләре дә үзен озак көттермәде: туган ягы Кама Тамагы районында ана багышланган музей ачылды, Казандагы үзәк урамнарның берсенә аның исемен бирү турында карар чыгарылды һ.б. Камал, Тинчурин, Кариев исемен йөрткән мәдәният сарайлары булган кебек, Түбән Кама театры инде Туфан Миңнуллин исемен йөртә.

Кайчак уйлап куясың: бар иде бит әдәбиятыбызның гөрләп торган чаклары! Бу хакта Бауман урамына урнашкан Матбугат йортына һәм Язучылар союзы идарәсенең ул чактагы рәисе Гариф Ахунов исеменә бәйләп әле дә булса еш сөйлибез, сагынып искә алабыз. Юкка түгел, чөнки очрашулар вакытында бишенче каттагы Тукай клубы һәрвакыт шыгрым булыр иде. Ай саен партҗыелышлар да, төрле жанрдагы секцияләр дә даими эшләп тора. Ә инде Фәрваз Миңнуллинның (аннары инде Мөсәгыйт Хәбибуллинның) рәсми эш бүлмәсенә якын торган бер мәйданчыкта бильярд сугып мәйханә килүләр дисенме... Анда Илдар Юзеев, бер як җилкәсен сикертеп һәм йомры сүзләр уйнатып, яшь мәйдаманнарга көч биреп тора. Анда — партоешма секретаре Туфан Миңнуллинның гөрелдәп торган тавышы, тапкыр сүзләрдән баш чөеп гаярь көлүләре!.. Татарстан китап нәшрияты директоры Гарәф Шәрәфетдинов, баш редакторы Шәүкәт Галиев пәйда булдымы, берара тынлык та урнашып куя. (Аның өчен, чөнки һәркемнең китап чыгарасы бар!)

Туфанның иҗатта шулай ук гөрләп торган чагы. Кай арада язып өлгерәләр ул — пьесаларының театр сәхнәләреннән төшкәне юк. Кыска гына ошбу язмада аның зур шәхес, иҗатының микъдары һәм үзенчәлекләре турында сүз озайтып тормыйм, иҗатына мәдхия укудан да баш тартам. Чөнки бу — мона кадәр әйтелгән сүзләрне һәм аның хакында язылган мәкаләләрне кабатлауга кайтып калыр иде.

Ә шулай да... аны «мактау», дөресрәге — мактатуның кулай ысулын оста уйлап таптым мин! Озак еллар бергә гомер иткән халал җефетенә, аны якыннан белгән каләмдәш дусларына: «Туфан исән чагында үзенең бөек икәнен белеп яшәдеме, юкмы?» — дигән сорау белән мөрәҗәгать иттем. Әйдәгез, аларның җавапларын тыңлап карыйк булмаса.

**Нәҗибә Ихсанова:**

— Белгәнлер. Ул үзенең фикерле кеше икәнен тоеп-аңлап яшәде. Һәр нәрсәгә карата үзенең ачык фикере бар иде. Җәмгыятьтә, татар әдәбиятында үз урыны барлыгын беркайчан да онытмады. Аның белән кинәшүчеләр күп иде.

**Разил Вәлиев:**

— Шунысын яхшы беләм: «бөек» дигән сүздән тартына иде ул. Бөеклек — Тукайчарак дәрәҗәдә булырга тиеш, дип әйткәне хәтердә. Әчтән генә белеп яшәде шикелле. Ләкин беркайчан да бу хакта кычкырып әйтеп, үзенә урын дәгъвалап йөрмәде.

**Рабит Батулла:**

— Әлбәттә! Ул үзенең кем икәнен белеп яшәде дип икеләнмичә әйтә алам. Инсаннар үзе турында бөтен кешедән дә яхшырак белергә, тормышта үз урынын төгәл чамаларга тиеш. Туфан кайда гына һәм нинди генә кәнәфигә утырмасын, милләткә файда китерде.

**Гәрәй Рәхим:**

— Исән вакытында ук үз дәрәҗәсен саклап, татар халкына лаек кеше икәнен белеп яшәде. Бу аның эчке горурлыгы иде. «Әгәр мин татар халкына лаек булмасам, бөтенләй читкә — икенче бер өлкәгә киткән булыр идем», — дигән сүзләре истә калган.

**Марсель Галиев:**

— Белгәндер, ләкин чәпчемәде, тыйнаклык саклады. Татар халкына сүзе кирәклеген тойды һәм бөтен көчен шуна таба юнәлтте. Аның белән күп очрашуларга йөрдем. Ул чыгып баскач, залдагы халык алга тартылгандай була иде. Йөзләре нурлана, анардан ниндидер хикмәт көтеп, һәркем тынып кала. Туфан сөйли башлауга, зал буйлап рәхәт дулкын йөгерер иде.

... Әйе, Туфанның иҗаты гына түгел, милләтпәрвәр образы да безнең көнелләрдә әнә шулай дәвам итә.

Тагын бер сыйфатын үземнән дә ассызыклап әйтәсем килә: ул яшьләр белән дус иде, әдәбиятка килүче яшь көчләргә һәрвакыт хәерхаһлы булды. Шүрлегемдә автографлы берничә китабы саклана. Менә аның «Кырларым-тугайларым» дигән пьесалар җыентыгына язган култамгасы:

«Рашат дуска! Бергә-бергә яшәп иҗат итсәк кенә, бәлки, кайбер уңышларга ирешербез, әйеме? 30 ноябрь, 1982 ел.»

Никадәрле ихлас һәм тыйнак әйтелгән сүзләр!

Инде, ниһаять, бер «хикмәт» пәрдәсен күтәрергә дә вакыт җитте бугай.

Илдә үзгәртеп кору җилләре исә башлагач, хәтта газета-журналларның баш редакторларын сайлап куюлар да модага кереп китте. Фәиз Зөлкарнәйнең юл-транспорт һәлакәтендә вафатыннан соң (1996 ел) «Идел» журналы коллективы да шушы демократик уенга кушылып китте. Җыелыш шактый давыллы башланды, аның кайнарлыгы уенның ахырына кадәр барды. Кандидатлар — Туфан Миннуллин һәм Рашат Низами. Туфанның «погон»нары болай да җитәрлек, яшьләр журналы дилбегәсен яшьләр кулына тапшырырга кирәк, дигән фикер алга сөрелде. Уен шартлары, минем аңлавымча, Туфанга каршы корылган булып чыкты. Һәм... Язучылар союзы идарәсенең ул чактагы рәисе Ринат Мөхәммәдиев, матбугат министры Ислам Әхмәтҗановның тәкъдиме һәм «тырышлыгы» белән мин фәкыйрегезгә баш мөхәррир урынын тәгаенләделәр. Эш урыным яхшы — «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары сыйфатында тыныч кына эшләп ята идем югыйсә.

Туфан абый утырган урынынннан җәһәт кенә торды һәм ишекне дөбердәтеп (холкын беләсез!) япты да җыелышны ташлап китеп барды. Менә шуннан соң, ярты ел чамасы микән, безнең аралар суынып алды. Аннары инде Туфан Миннуллин үзенең язганнарын китерә торды, без аларны кичекмәстән номерга җибәрә тордык. Берсендә ана сугышчы-композитор Фәрит Яруллин турындагы роман-хрониканы (ЖЗЛ сериясеннән) култамга белән бүләк иттем. Укып чыккан. «Чынлыкта аны үлемгә җибәргәннәр икән», — дип көрсенде.

Вафатына бер атна кала микән, композитор Рөстәм Яхин турындагы поэма китабымны бүләк иттем. Укып чыккач, котлап, телефоннан шалтыратты.

Тагын бер деталь. Айдар улым белән аның машинасында Киндерледәге дача бакчасына барышыбыз иде. «Әти, беләсеңме, кичә 18 нче больницада Туфан абыйны күрдем. Пижамадан иде, исәнләшеп уздым», — диде ул кинәт кенә. Мин уйга калдым. Күп тә үтмәде... Туфан Миннуллинның вафаты турында кайгылы хәбәр!

Арабыздан каядыр китеп барды, ләкин ул безнең арабызда һәм хәтер күгендә мәңгелеккә калды. Туфан дәвам итә.

**Рашат НИЗАМИ**

# ТУФАН КЫЗЫ ЯЗМАЛАРЫ

Еш кына мина: «Туфан абыйны төштә күрдем әле», — дип әйтәләр, ни күргәннәрен дә сөйлиләр. Шулвакыт күнелдә сәер хис туа. Нигә ул шул кешеләрнен төшенә кергән дә минекенә кермәгән?

Минем тормышымда бар нәрсә дә әти белән бәйләнгән.

Әти вафат булгач, Фәүзия апа Бәйрәмованын бер кеше алдан да, соныннан да әйтмәгән сүзләре тетрәндерде: «Татар халкы сөекле улын югалтты, син — газиз әтиенне». Әйе, газиз әтиемне... Әтигә үзе исән чакта «газиз әтием» дип эндәшкәнем булмады. Гомумән, безнен гаиләдә назлы сүзләр кушып сөйләшү төчеләнү дип саналды. Әти мина кырык яшем тулганда гына «кызым» дип дәште, хәтерлим, ул чакта ничектер сәер булып киткән иде, чөнки мина — «Әлфия», оныгы Диләрәгә генә «кызым» дип эндәшә иде.

Әти турында ин беренче хатирәләрем үземнеке түгел, ә әти, әни һәм аларнын дуслары сөйләгәннәрдән. Мин 1 гыйнварда туганмын. Әни: «Яна ел кичендә Равил Шәрәфиев белән вальс биедек тә, иртән билем авырта башлады, эчем авырайды», — дип сөйли. Равил абыйнын әнисе: «Бала табар вакытын житкән, роддомга барырга кирәк», — дип өйрәткән. Инде мин туганны белгәч, әти үзенен ин якын туганнан туган энесе Мөнир абый белән урамнан баралар икән. Бераз кабып алганнар. Шунда әти: «Эх, шатлыгым эчемә сыймый, хәтта берсен тотып кыйныйсым килә», — дип әйтеп ташлаган. Мөнир абый, озак уйлап тормыйча, каршыга килүче бер агайны сугып еккан. Әти: «Шундук айныдым», — дип сөйләгәне хәтердә. Теге кеше бәйләнеп тормаган, аякларына басып, өстеннән карны каккалаган да: «Что вы, ребята, делаете?!» — дип, китеп бару ягын караган.

Баланы өйгә алып кайткач, коендырасы, биләвен алыштырасы, юасы — мәшәкате житәрлек. Әти әнигә кырт кискән: «Бер яшь тулгач кына кулга алам — куркам», — диган. Әни Равил абый Шәрәфиев белән бергаләп мине коендыра торган булган. Равил абый әле дә: «Әлфияне шәп-шәрә күргән беренче кеше — мин», — дип сөйләп йөри.

...Тагын туктап калдым. Әти турында сөйләгәндә дә, язганда да, ул каршылыклардан тора, дип еш әйтәм. Искә алган менә шушы ике вакыйгада да бер кеше турында сүз бара: ярата, тик кулына алырга курка...

Мин мәктәпкә укырга кергәнче, без хәзер Салих Сәйдәшев музее урнашкан йортта, ул вакыттагы театр коммуналкасында яшәдек. Бервакыт әти өйгә телевизор күтәреп кайтты. Мона кадәр күрмәгән гажәп нәрсә. Безнен йортта гына түгел, күрше-тирәдә дә андый юк, шуна күрә таныш-белеш, күршеләр безгә телевизор карарга жыела. Мина ике яшь тирәсе. Идәнгә тезелеп утырган кешеләрнен аяклары янында үрмәләп йөргәнемне бераз чамалыйм. Шулвакыт күршебез Халимә апа Искәндәрованын бик катгый рәвештә урысчалатып: «Не мешай!» — дип шелтәләгәне хәтердә. Калганы истә түгел, анысын мәрхүм Фирдәвес апа Әхтәмова сөйләргә ярата иде. Әни мине кулына алган да: «Әйдә, кызым, булмаса, без коридорга чыгып торыйк...» — диган.

Шулай кисәк-кисәк хатирәләр янара. Әти эш өстәле артында утыра, нидер яза, кичке як, чөнки лампа яна. Мин урындык астыннан үрмәләп, өстәл астына кереп утырам, әтинен тезләренә менәм, ул нидер әйтеп, мине кире төшереп жибәрә. Мин анын өстәлендә яткан әйберләр белән уйнарга ярата идем, каләм-карандаш, блокнот, скрепка, кнопка... Коенганда ин яраткан уенчыкларым — әтинен кырыну әйберләре: алюминий тәлинкәдә кечкенә таз, стакан, пумала. Әти кырынганда, яныкларын сабынлый да: «Кил әле, Әлфия, сине «пәп» итәм», — ди, ә мин сабын күзгә тиюдән куркып качам.

Менә ул мине балалар бакчасына илтә. Сирәк кенә андый чаклар да булгалый иде. Еш булмаганга хәтергә уелып калгандыр. Толстой урамындагы бакчадан үткәндә, әти тезе белән күрсәтмичә генә аркага төртеп ала. Мин: «Әти, нигә алай эшлисен?» — дигәнгә, ул берәр үтеп баручыга төртеп күрсәтә дә: «Әнә, теге кеше сина төртте», — ди. Мин: «Юк, ул син иден!» — дип кызып-кызып исбатлый башлыйм...



*Әдитнең кызы Әлфия, хатыны Нәҗибә, оныгы Диләрә.*

Әти китапханәсендә китаплар бихисап. Мин ин калыннарын киштәдән тартып алып, идәнгә тезәм — басма ясыйм. Әти күргәч, болай ярамый дип, минем белән бергә китапларны кире урыннарына куя да, янына утыртып, китап — ул изге нәрсә, дип сөйли. Китапны сакларга кирәклеге турында тагын бер сүзе исемдә. Ялгышмасам, Хәкимҗан Халиковның шигырьләр китабын пумала белән төрле төсләргә буяп чыктым. Аклы-каралы рәсемнәрне төсле иткәнмендер инде. Әти ачуланмады, китапка ничә кешенен хезмәте кергәнен аңлатты.

Бер генә ачуланган вакытын хәтерлим. Гаебем ни — белмим, шук балада төрлесе булгандыр. Әни минем «этлегемне» сөйли, әти каеш күрсәтә, сүз тыңламаганнарга менә шушы янәсе. Эш каеш күрсәтүдән узмады...

Бала чакта әтидән чынлап курыкмый идем. Әнидән күбрәк эләгә иде. Әти йә өйдә юк, йә эшли, йоклый, ашый — кыскасы, аны борчырга ярамый. Үсә төшкәч, мин әти сүзеннән курка башладым. Кайчан, нигә алай булды — белмим. Ләкин бу ниндидер дәрәҗәдә безне бер-беребездән ерагайтты. Читләшүнең башка сәбәпләре дә бар иде.

Үсеп буйга җиткән ике бала әнисе буларак шуны әйтә алам: балага ни кирәген дөрес аңлау шактый авыр эш, сина яхшы булып тоелган балаңа да ярар дип ышанып булмый. Әти дә, әни дә, үз эшләре белән нык мавыккан кешеләр буларак, үз стереотипларын, тормышка ашмаган хыялларын миңа сеңдерергә тырыштылар. Әни һәрвакыт театр тирәсенә барма, галим бул, укытучы бул дип тукып торды, мине профессор, академик итәргә хыялланды. Әти, күрәсең, татар әдәбиятына, сәнгатенә якын һөнәр сайлавымны көткән. Мин, тыңлаучан бала булганга, аларның хуплавын яуларга тырышмадым түгел, тырыштым. Тик алар теләгәннәр берсе дә минеке түгел иде. Инде үз юлымны табып, шул юлдан барганда, әти: «Синең эшең эшмени», — диде, әни, кешеләргә сөйләгәндә: «Кызыбыз шундый башлы иде, беркем була алмады», — дип уфтанды (әле дә уфтана). Ата-ана һәм бала каршылыгы безнең гаилә мисалында ачык күренә.

Ярый, янадан хатирәләремне барлыйм. Без өченче сыйныфта укыйбыз, аңа кушылган булгандыр инде, әти безгә герой-пионерлар турында сөйләргә килде. Безнең пионерга кереп йөргән вакытлар. Ни сөйләгәне истә калмаган, дәрес ахырында: «Сез герой пионерлардан кемнәрне беләсез?» — дип сорады. Балалар исемнәр атый, әти аларны кабатлый. Шунда Марат Казей исеме аталды. Әти андый герой пионерны белми икән, исемен дә ачык ишетеп бетермәгән. Әйе, әйе, Марат Кащей, ди бит. Әтине кайтканда оялтканым исемдә, шуны да белмисең, имеш. Әти миннән сорый, син Фатих Кәримне беләсеңме, Муса Җәлилне беләсеңме, Фәрит Яруллинны беләсеңме дип, бәхәсне үз файдасына бормакчы. Ул атаган кайбер кешеләрне белмәгәч, менә син дә барысын да белеп бетермисең дип, балаларча куанган иде.

Минем үсмер чак. Әти Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый. Казан кибетләрендә нидер бар барын, тик ул ачлы-туклы тормыш итәргә дә җитәрлек түгел. Әти «ит ташучы» поезд булып саналган «Татарстан» проводниклары артыннан Мәскәү күчтәнәчләре җибәреп тора, без шул ук ысул белән кыстыбый камыры пешереп, юылган кием-салым, башка ул сораган әйберләрне озатабыз. Һәм язгы каникулда әти мине Мәскәүгә, үзе яшәгән тулай торакка «кунакка» чакырды. Могҗизалы урын иде ул. Кайсыдыр төньяк халыкларыннан бер язучы (исемнәре онытылган инде) бозланган балыкны юнып-юнып сыйлый, берәү коридорда думбра чиертә, бүлмәгә шагыйрь Зөлфәт кереп, әти белән бер-берсенә төртмәле сүзләр

әйтешәләр, әти спиртовкада кофе кайната, «капчыклы» аш пешерә. Барысы да кызык! Әти мине Мәскәү буйлап экскурсиягә йөртте, ВДНХ күргәзмәсенә бардык, театрларга кердек, студент чакта яшәгән тулай торакларын, Щепкин училищесы бинасын күрсәтте. Кыз бала ин истә калдыра торган вакыйга да шул сәяхәт белән бәйле. Зур бер кибеткә кереп, мина ике пальто алдык. Бала-чага киеме түгел — зур кызлар кия торган. Кышкысы — ачык кызыл, капюшонлы иде. «Кызларга кызыл килешә», — дия иде әти. Оныгы Диләрәгә машина алып бирәм дигәндә дә, ул бары тик кызылны сайлады.

Әдәби курсларда әти ике ел укыды. Әле ул заманда почталан хат язышу гадәте бар иде. Шул вакыттагы берничә хаты саклана. Аларда әти мина олы кешегә мөрәҗәгать иткәндәй язган. Хәзер аларны мин еламыйча укый алмыйм.

Шул ук яшүсмер вакытларда әтинен ике тәрбия дәресе хәтергә кереп калган. Подъезд ишек төбендә бармакка ачкыч божрасын эләктереп, ачкычны әйләндереп торам. Әти мина алай беркайчан да эшләмә, ул — жилбәзәк урам хатыннарынын ир-ат игътибарын жәлеп итү ысулы, диде. Икенчесе (әти тәмәке тарта иде әле ул вакытта), мин әтине тәмәкесе кулында чакта житәкләп алдым. Анда да ул «беркайчан» сүзен кулланды. Беркайчан да тәмәке тарткан ир-атны култыклама, диде. Тәмәкесен йә тартып бетерсен, йә ташласын, аннан сон гына култыкла, үз кадеренне бел, диде.

Әти мине ачыктан-ачык ике мәртәбә яклап чыкты. Беренчесе — мәктәптә. Класс дәресендә сыйныф житәкчебез ул вакытта мәш килеп төзелеп яткан БАМ төзелешенә баруны батырлык дип сөйләде. Миннән сорадымы, үзем әйттемме — онытылган. Нидән тимер юл төзелешенә бару батырлык булсын, дидем. Бу бик тә дөрес түгел сүз булып чыкты. Класс житәкчебез әтине мәктәпкә чакыртып, укытучылар бүлмәсендә анын каршында мине «прорабатывать» итте. Мине чыгарып жибәреп, күпмедер вакыт сөйләшеп тордылар. Әти чыкты да, бернидән дә курыкма, шулай да андый фикерләренне бик кычкырып сөйләп йөрмә, диде.

Мәктәп елларында әти минем белән әдәбият дәресләре турында сөйләшергә ярата иде. Дәреслекләрдә язылганнарны кабатламыйча, үз фикерем булуын хуплады. Чацкийны — бездельник, Сатинны демагог дип атавымнан рәхәтләнеп көлә иде.

Мин сонгы, унынчы сыйныфнын 1 сентябренә барганда да, әти мәктәпкә озата килде. Бик горурланып басып торганы хәзер дә күз алдында...

Мәктәптән сон КДУнын мехматына керәм дигәнгә әти каршы төшмәде, минем мәсьәләдә әни белән бик бәхәскә керми иде ул, тик «үзегез сайладыгыз, теләсәгез нишләгез» позициясенә басты. Анын шундый гадәте бар иде. Әнинен хыялы — мине профессор-математик итү. Укый башлауга ук, андый әйбер барып чыкмаячагын анлап алсам да, тырышып укыдым, шундый белем алуыма бер дә үкенмим, чөнки математика мантыйк белән фикер йөртергә өйрәтә, гомумән, фикерләү системасын төгәл жайга сала. Шулай да мехматтан китәргә талпыну булып карады. Өченче курста мине режиссура ныклап кызыксындыра башлады. Марсель абый Салимжанов белән озаклап сөйләшүләр башланды, хатын-кызга авыррак дип кисәтсә дә, ул минем бу теләгемне хуплады, кинәшләр бирде. Әнинен коты очты, ничек инде, профессор буласы кеше, укуын ташлый, өстәвенә Мәскәүгә китеп бара... Ничек итәсен-итте, башта монда укып бетер, аннан сон барырсын, дип күндерде. Әти дәшмичә генә бу көрәшне күзәтте. Ләкин укып бетергәнче үк мәхәббәт, кияүгә чыгу, бала табу — ул планнар барысы да жилгә очты.

Әти балаларымны бик яратты: «Безнен Нәжибә белән өч балабыз бар», — дип әйтә иде. Кызым Диләрәне иркәли иде, ана бөтен нәрсә дә диярлек рөхсәт ителде, төрле командировкалар-сәяхәтләрдән кайткан күчтәнәчләрне тарату Диләрәгә бүләк тапшырудан башланып китә иде. Ул да бабасына нык тартылды, булачак ирем бабама охшасын иде, дип хыяллана иде.

Улым Даниярны бабасы чын ир итеп тәрбияләргә тырышты. Безне ачулана, гел үбеп, малайны бозып бетерәсез, дия иде. Авылга, бакчага үзе белән иртәп йөртте, Данияр балта, пычкы, чүкеч тота белә икән, бакчадагы эшләрнен нечкәлеген андый икән — боларны барысын да ана бабасы өйрәтте. Мин Даниярга карата артык таләпчән, гел ачуланып торганына борчылдым. Әти ир балага нык тәртип кирәк, юкса дөньяны хатын-кыз тәрбияләгән, ир кеше була белмәгән ирләр басты, дия иде.

Әти, үзе әйтмешли, «төчеләнмәде», ләкин авыр моментларда миңа иң ышанычлы терәк булды. Башта үземне орышып ата, мин еларга тотынгач, елама, көрәш дип ачулана иде. Ләкин нәтиҗәдә ярдәмсез калдырмады. Ике бала белән ялгыз калганда да, хезмәт хакы эшкә барып житәргә трамвай билетына житмәгәндә дә булышты. Үземә генә түгел, балаларыма да әти иде.

Төчеләнмәү минем үземдә дә бар. Хәзер уйланып утырам да, әтигә минем тарафтан иркәләү, жылылык житеп бетмәгәндер. Ул, бигрәк тә олыгая башлагач, шуңа мохтаж булды. Ах-ух килеп, Туфан абый, сез тегенди, сез мондый, дип бөтерелгән хатын-кызларга һушы китә иде инде. Әти, аларның күбесе моны ихластан әйтми бит дисәң, булсын, миңа шуннан рәхәт, диде. Миннән дә шуны көткәндер... Нишләтәсең... Үткән елларны кире кайтарып булмый.

Әти минем белән үзе дә бик житди сөйләшә иде. Көнкүреш темалар конкрет һәм тиз сөйләшенә дә, милләт, тел, әдәбият, сәнгать турында сәгатьләр буена гәпләшеп утыра идек.

Яңа әсәр язылып бетүгә, миңа укытасы килә, тик үзе биреп түгел, мин сорап алганны көтә. Әни шыпырт кына, әтиең яңа әсәр язып бетерде, сораш әле, дия иде. Әти куанганын күрсәтмәскә тырышып бирә, тиз генә укы да шундук фикереңне әйт, ди. Укып бетергәч, тукта, бераз уйлыйм, дисәң, юк, шундук әйтелгән фикер иң дөресе була дип үзенекен итә. Ниндидер минем карашка житешмәгән ягын әйтсәң, бәхәсләшә, исбатлауны таләп итә. Башта килешмәгән кебек булса да, соңыннан теге яки бу формада әйтелгән фикерне исәпкә ала. Гомумән, безнең белән мөнәсәбәтләрдә әти «ялгышын танымады». Күпмедер вакыт узгач, чыннан ялгышканын аңлагач, тәнкыйтьләнгән әйберне әкрен генә төзәтә иде. Без сүз әйтмәсен дип, күп кенә эшен бездән яшертен эшләде. Нагорный бистәсендә, авылында йорт салганын без бер-ике елдан гына белдек. Эшен тәмамламыйча, гаиләдән беркемгә дә күрсәтмәде, тәнкыйтьләп «әппәтитемне» бозасыз, дия иде. Вафатыннан соң гына Кече Битаман авылындагы Данил Салихов ихатасында нәни генә йорт салып куйганын белдек...

Гомумән, төзү эше, язу белән беррәттән, әтинең сүрелмәс бер гыйшкы иде. Жәй житүгә, быел ни төзер икән дип фаразлар кора идек. Казандагы кызлар гимназиясе директоры Илһамия Тимеркәева аңа ярдәм сорап барганда, нәкъ кешесенә барып эләккәнен белдеме икән? Бердән — татар мәктәбе, икенчедән — кызлар, өченчедән — төзелеш. Берничә ел артыннан туктамыйча йөрде, төзелә башлагач, көн саен диярлек эш барышын карап-тикшереп кайта иде. Инде төзелеп беткәч, ничек куанганы — әйтеп бетермәслек. Кызлар яңа бинада укый башлагач та, бу гимназия аның шефлык итә торган бер урынына әверелде. Иң яхшы укучы балага ай саен нәни генә премия тапшыра, чыгарылыш сыйныфтагы алдынгылыкны яулаган кызга көмеш беләзек бүләк итә... Аның башлаган эшен без, гаиләсе, дәвам итәргә тырышабыз. Бу гимназия безгә дә бик якын.

Ни калды дисәм... Ике мәртәбә турыдан-туры яклады, дидем дә берсен яздым, икенчесен юк икән. «Интертат» газетасы мөстәкыйль басма булудан туктап таратылгач, без, анда эшләгәннәр, кыен хәлдә калдык, үзебезчә көрәшеп карадык, һәм безгә бер мизгелдә сытып бетерәчәкләрен бик яхшы итеп аңлатып бирделәр. Шулвакыт әтигә безне нишләтерләр инде, дигәч, ул: «Курыкма, синең артыңда мин бар», — диде.

Әти минем дә төшләремә керә. Гадәттә, ул миңа эш куша. Көлсәң көл, еласаң ела — шуларны үтим. Казан читендәге бакчасына берни утыртмам, үскән агач-куак үссен, үләннәрен генә чабып торырмын, дигән идем, төшкә керде, үзем кишерсуган утырта алмыйм, син утырт, диде. Утырттым. Хәзер кызыксынып китеп, ирем белән бергәләп ныклап бакча эшенә өйрәнеп барабыз. Быел яз яңа төшкә керде, яшелчәләр утыртасың, әйбәт, сарымсакны оныттың бит, диде...

**Әлфия МИҢНУЛЛИНА-ЮНЫСОВА**



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Күршеләр

Татар язучыларына да икешәр катлы коттеджлар төзелә икән, дигәч, күпләр ышанмаган иде. Менә бит! Күп вакыт үтмәде — төзеп тә куйдылар. Унике жыелыш жыеп, үзара канга-кан килеп бәхәсләшкәннән соң бүлешеп тә алдылар.

Ин матурын, ин зурысын Туфан Миннуллинга бирергә дигән карар чыгардылар. Арыды... Ничә ел буе Мәскәү парламентында эшләде...

Жирәбә салганда, анын күршесенә шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов чыкты. Кичтән Хужа Насретдин булып йокыга китә, иртән Тукай булып уяна торган Мөдәррис Әгъләм:

— Яшибез болай булгач! — дип сөенеп куйды.

Күченү башланды. Туфанның мәхәббәт йорты каршына өч «КамАЗ», кранлы бер япон машинасы, ике «Волга» килеп туктады. Өлгергән Әстерхан карбызы сыман кызыл чырайлы шагыйрь егетләр унике суыткычны (эчендәге утыз алты казылык, жиде каклаган каз, Сергач мишәрләреннән алган ат ите белән бергә), тагын сервант һәм шуныңише бинихая авыр кирәк-яракларны мамык урынына очыртып кына керттеләр. Егетләрне сыйлап, жайлап, көч-хәл белән машиналарга төяп жибәргәннән сон, Туфан, самолёт трабына чыккан президент кыяфәтендә, коттеджнын икенче катына күтәрелде. Ике канатлы ишекләрне жырлатып кына ачып, балконга чыкты. Ерак түгел авыл өйләре күренә иде. Бакчаларда, иелеп, арт белән күкне терәп чүп утаган хатын-кызларга карап торды. Башы әйләнеп китте. Биеклекне өнәми иде Туфан, шуна күрә самолётка да утырмый иде. Аскы катта гына яшәрмен, ахры, дип уйлап куйды.

Ул арада, тәрәзәләрне зыңгылдатып, дөбер-шатыр иткән тавыш ишетелде. Караса... Күрше капка төбенә сабын савыты чаклы гына «Запорожец» килеп туктады. Тәрәзәсендә Мөдәррис Әгъләмовнын пеләш башы чагылып алды. «Запарай»нын тутыккан, калжайган калаен корт ашаган ишеген ача алмыйча азаплангач, Мөдәррис Әгъләм жыйнак гәүдәсен, йомарлап, тәрәзәдән тышка ыргытты. Аксак шофёр белән икәүләп, ике минут эчендә Мөдәррисне байлыгын ташып та бетерделәр: тутыккан пружина эзе төшкән бер матрац та тарихка керәсе өч капчык кульязма-китаплар.

Бераздан калтырча «Запорожец» төтен торбасын жирдән шалтыр-шолтыр өстерәтеп китеп барды. Мөдәррис өске катка менде, чишенеп ташлады да ялгызак матрацка сузылып ятты:

— Шәп!

Бераздан ул, аскы катка төшеп, болдырга чыкты. Карга канаты сыман кара трусигынын Брежнев чорында тегелгән мул балакларын жилфердәтеп, сажинлы адымнар белән жирне үлчәргә кереште. Ике арадагы ызанга Туфан, тимер чөй кагып, чәнечкеле чыбык сузып өлгергән дә икән. Мөдәррис чөйләрне суыра башлауга, биек баскычтан Туфаннын бөдрә, көр тавышы ишетелде:

— Нишлисен, дәһи?!

— Мине шигырь яздырмаскамы исәбен?! Мин үлчәп карадым, нәкъ житмеш ике сантиметрга аерма чыга.

— Синен якка кергәнмeмe?

— Киресенчә, үзеннен ялгыз кергәнсең!
— Ничек үземнен ялгыз?
— Шулай! Миңа житмеш ике сантиметр киңлектә жирне күбрәк калдыргансын, казып чиләнсен, шигырь язарга вакыты калмасын, дип.
— Ә минем пьесалар язасы юкмыни?!
— Пьесаларнын әдәбиятка ни катнашы бар! Драматургия бит ул сбербанкнын бер филиалы гына! — диде Мөдәррис.
Бу низаг атна буена барды. Мөдәррис, ике араны үлчәп, ызанны үз ягына күчереп куя, Туфан — үз ягына. Аптырагач, ике арадагы ызанга Туфан Сафуан Муллагалиевтән житмеш ике сантиметр киңлектәге тротуар жәйдерде. Шуннан соң тынычландылар.
Шундый борчулы көннәрнен берсендә Туфан «Волга» машинасынын, капка баганасына бәрдереп, ике ишеген умыртып чыгарды. Ул арада, кувалда тотып, Мөдәррис килеп житте:
— Хәзер төзәтәбез аны, Туфан әкә, кайгырмагыз...
— Кайгырмыйм да. Миңа нәрсә тора ул ике ишек! — диде Туфан.
Ул арада Мөдәррис капканын инен үлчәп алды:
— Ине алты метр капкаңнын. Машинанны аркылы чыгарсаң да бәрелми бит югыйсә...
— Тизлек зур иде. Арт белән чигендем мин, туксан белән, — диде Туфан.
Кол Галидән алып Эдита Пьехага кадәр укып барган Мөдәррис Әгъләмов техникадан хәбәрдар иде. Туксан чакрым тизлек белән чигенә алырдай машинанын безнен илдә генә түгел, байлыгы череп ятучы капиталистларда да юклыгын уйлап, бик аптырап башын чайкады. «Арттыра бу... Кичә Аяз Гыйләжев белән утырганнар, ахрысы», — дип уйлады. Сынган «Астра» сигаретын төкереклэп ябыштырды да фикерле иреннәре арасына кыстырып куйды.
Икенче көнне Туфан утыз ике бройлер чеби алып кайтты. «Волга»ны сарай кырыена этеп китерделәр.
— Чебиләргә менә дигән кетәклек була бу, — диде Туфан.
— «Мерседес» булмаганда, ярый инде, — диде Мөдәррис.
Туфаннын уң як күршесе Гәрәй Рәхим иде. Йортны үз проекты белән төзетеп куйган шул чукынчык Григорий Рәхим — Гәрәй Радионов. Анын мөселман һәм христиан архитектурасынын гүзәл үрнәгендә төзелгән йорты алгы ягыннан карасаң, арткы ягына чыккан кебек, арткы ягыннан карасаң, алгы ягы кебек тоелмый иде.
Гәрәй Рәхим туган авылы Федотовкадан керәшен сарыклары алып кайтты (Батулла-Турай энциклопедиясендә «керәшен сарыгы» дип дуңгыз атала). Тоз күзле чучка малайларынын жыбылжык исе әрсезләнеп тирә-юньгә таралды. Аларнын үтенне сытарлык итеп чинауларын Туфан каш жыерып тынлап торды да: «Мөдәррисtән күрәсе казалар пүчтәк кенә булыр, ахрысы», — дип уйлап куйды.
Туфан магнитофонга кадак кагу, балта-пычкы тавышларын яздырган иде. Магнитофонын бар көченә борып, тахтага сузылып ятты. Берзаман торып караса, Мөдәррис тә, Гәрәй дә үз ихаталарында үкертеп эшләп яталар. Бер сәгатьтән сон Туфан арыган кыяфәт белән баскычка чыкты.
Шабыр тиргә баткан, еш-еш сулу алган Гәрәй Рәхим чиләгеннән генә күтәреп су эчте дә:
— Ну эшлисен дә икән, Туфан! — диде.
— Ә как же, мин бит крәстиян малае!
«Шигырь-мигырь маташтырганчы, балта тотып эшләсеннәр, файда булыр, ичмасам», — дип, үзалдына сөйләнде.
Шулай итеп, бер атна буе магнитофоннан балта-пычкы тавышларын уйнатып, «Диләфрүзнен кияүдән аерылуы» дигән яна пьеса язып бетергәннән сон, Туфан дөньяга чыкты. Караса... Гәрәй Рәхимне танырлык та түгел, Хиросима бомбасыннан исән калган кеше кебек. Яңагы суырылып калган, Югары Совет ашханәсендә тукланып, матур гына түгәрәкләнеп килгән корсагы кадакка эләккән футбол тубы сыман шиңгән. Кулында балта. Сикәлтәле борынын биетеп, нәселле тешләрен күрсәтеп көлгән була тагын үзе.

Мөдәррис исә бер атна эчендә, шигырь сөйләр өчен, сәхнәле итеп, иркен сарай корып куйган. Кыяфәт тә элеккечә. Кулы коралга ябышып тора каһәрнен. Ярлы язучыларга юкка гына ун ел буе дача төзешеп йөрмәгән икән...

— Синен, Туфан әкә, пычкын тешәлмәгән, балтан да үтмәсләнгән. Китер, үткенләп бирим, аннары плёнкана янадан яздырырсын.

Туфан бер мәлгә өнсез калды. «Менә йөр син моны шагыйрь генә дип, бөтенесен белеп тора, шайтан алгыры...»

Шагыйрьнен ничек булса да жаена төшәргә дип, Туфан кесәсеннән затлы сигарет кабы чыгарды:

— Мә, жүнлене тарт!

— Үземдәге жүнсезеннән дә туйган.

«Тукай булса да булыр икән, киребеткән», — дип уйлады Туфан.

— Миндә суыткычлар күбәйгән, берәрсен алып чык үзенә.

— Мин телевизор карамыйм бит, — диде Мөдәррис.

Күршеләр әнә шулай чөкердәшеп яши башладылар.

***Искәрмә.***

*Үзгәртеп кору дәвере килгәч, матбугатта сүз иреге башланды, дип, Язучылар берлегендә стена газетасын чыгармый башлаган идек. Рәисебез Туфан ага беркөнне әйтә:*

*— Егетләр, стена газетасы эленеп тормагач, күңелсез бит, әйдә, чыгарыгыз әле яңабаштан. Нәрсә турында языйк, дип тормагыз, әнә язучыларның коттедж төзүе турында юморескалар языгыз! — ди.*

*Язучыларга йорт төзер өчен җир бирәләр икән, дигән сүз таралган иде. Мин инде хыялны чынга әвештерел, юмореска язып ташладым. Стена газетасы чыкты, элеп куйдык. Бу язманы Туфан ага үзе дә ошаткан кебек булган иде. Берничә ел узгач, мин аны "Социалистик Татарстан" газетасында бастырып чыгардым.*

*Беркөнне Туфан ага чылтырата, тавышы тәшвишле:*

*— Син нәрсә бастырып ятасың анда?! Депутатны халык каршында рисвай итеп... Сайлаучылар күзне дә ачырмыйлар, үзең гаделлек, намус хакында трибуналардан шар ярып сөйләгән буласың, үзең әнә катлы-катлы йорт җиткереп кергәнсең, оятын кая куярсың, диләр.*

*— Юморесканы ошаткан идегез бит, Туфан абый, — дим.*

*— Пәри — башка, җен — башка. Стенада эленеп тору бер хәл, бу очракта бит газета бөтен республикага тарала.*

*Минем тәмам борчуга калуымны сизенеп, ул:*

*— Чын күңелдән ачулана дип уйлама тагын. Болай... гына әйтүем. Газетта басылган, телевизордан әйтелгән һәр сүзгә тулаем ышана шул безнең халык. Бу беркатлылыгы белән кая барып чыгар мескенем..*

## Җәяүле Туфан

Гәрәй Рәхим белән Марсель Галиев Кукмарага барырга хыялланып йөриләр. Тик менә машина табу мәсьәләсе генә...

— Туфан Миннуллинның машинасы бар да бит, шофёры да тынлаучан. Иртән эшкә тугыз белән уннарда гына килә шул Туфан. Ә безгә таң белән китәргә кирәк. Биреп тормас шул, син сорап кара әле, сине тынлый ул. Халык язучысы дигән исемнән дә баш тартты бит ул, син әйткәч, — ди Гәрәй Рәхим. Кичтән Марсель Галиев телефоннан Туфан Миннуллин номерын жыя.

— Исәнмесез, Туфан әкә!

— Ярыйсы әлегә. Живой, — ди Туфан.

— Саламәтлекләр ничек, Туфан әкә? Нәжибә ханым еш елмаямы? Сез бит Нәжибә ханымга гына түгел, безгә дә бик кирәкле шәхес, Туфан әкә.

— Йә... йә... — дип куя Туфан Миннуллин, рәхәт изрәгән тавыш белән.

— Безгә генә түгел, бөтен халыкка кадерле шәхес бит сез, Туфан әкә. Шуна күрә сәламәтлегегез турында халык кына түгел, үзегез дә бераз кайгыртырга тиеш. Хәтерлисездер, элек машинага гына утырып йөргән түрәләрдән көлә идегез, аяклары бетә бит бу бичараларның, дистрофикка әйләнә баралар бит болар, дип... Менә хәзер, депутат булгач, сез дә гел машинада... Әзрәк җәяү дә йөрергә иде, Туфан әкә. Бигрәк тә иртәнге якта... Сез бит Казансу буенда торасыз хәзер. Менә шуннан, саф һава сулап, иртән эшкә җәяүләп барулары үзе бер шифа ич... Әйтүемчә, сез бит халыкка кирәк язучы, Туфан әкә... Шекспирдан кала икенче зур драматург.

— Йә, йә, — дип куя Туфан Миннуллин, иркә мырылдауга күчеп. Марсель Галиевтән болай ук кайгыртучан, җылы мактау сүзләрен еш ишетүгә күнекмәгән Туфан Миннуллинның зиһене таралып китә, каш арасындагы өч ермачлы җыерчыгы языла, күнеле тула.

— Рәхмәт инде җылы сүзенә, хак әйтәсен, иртәләрен җәяү йөрергә бик кирәк тә сон... Тукта әле! Син нишләп болай... аек баштан үзен... Хискә бирелеп киттең әле... Берәр йомышың бар мәллә?

— Йомышым дип, Туфан әкә, әллә ни йомыш юк инде анысы. Шул... машинанны биреп торсаң дигән идем, иртәгә, иртәнге якта...

— Гомер булмаганны, нигә бик җәелеп сөйли дисәм... Баштан ук йомышынны әйтергә иде аны.

— Ул хакта бит Ризван Хәмиднең беренче һәм соңгы язган хикәясе бар, Туфан әкә, — дип, сикәлтәле көлә Марсель Галиев. Пауза бирмәскә, Туфан әкәне мактау иләслегеннән айнытмаска кирәк дип, тизрәк сөйли башлый.

— Күршесе Гайҗан бабайга Мансур исемле малай йөгереп керә дә: «Бабай, Рәмиснен велосипедын алып торыйм әле?!» — ди. Шулчак Гайҗан бабай: «И-и, улым, улым, йомышынны алай ордым-бәрдем хәбәр итмә син, — ди. — Башта хәлне белеш, сихәтлеген ничек, бабай, башың авыртмыймы, аякларың сызламыймы, диген. Сыерыгыз сөт бирәме, Хөсни әби коймак пешерәме үзенә, дип сора. Минем күнелне тәмам йомшарткач инде оныкның биләсәпитен үзем китереп куярмын алдына», — дигән. Берничә көннән сон, теге — Мансур исемле малай тагын шулай йөгереп кергән дә: «Исәнме, Гайҗан бабай, исән-сау гына торасыңмы, аякларың сызламыймы, Хөсни әби тәмле итеп коймаклар пешерәме үзенә...» — дип тезеп киткән. Мона бик күнеле булган Гайҗан бабай, малайның башыннан сыйпап: «Хәзер инде төп сүзгә күчсәк тә була. Йомышың ни иде, олан?» — дип сорап куйган.

— Гайҗан бабай, бакча башында мунчагыз яна! — дип кычкырып җибәргән малай.

Бу кыйссаны тынлый-тынлый Туфан Миннуллин бик рәхәтләнеп көлеп куя да:

— Хикәяң шәп! Ризван Хәмид язгандырмы-юкмы, әмма хикәяң әйбәт! — ди. Бераз уйланып тора да, саранлыкка юмартлыгын, юмартлыкка саранлыгын бизмәнгә куеп карый да: — Болай булгач, иртәгә иртән эшкә җәяү барырга туры килә инде... — ди.

## Пыт–пыт

Бөтен депутатлар да юри генә уйный, ә Туфан Миннуллин чынлап уйный... Шулай итеп, ул, СССР Югары Советы сессиясендә законнар кабул итеп утыра торгач, 17 кило 658 граммга кимеп, тәмам ябыгып кайтып төште. Бөтен дөньясына кул селтәде дә туган авылына юл тотты. Трактор сатып алды. Үзенекен дә, күршетирә карчыкларның да бакчаларын сөреп-тырмалап чыккан быел. Бәрәнге, чөгендер, кишер, суган, помидор, кыяр утырткан. Кориандр, әнис, борыч, тәмәке, тмин һәм тагын әллә ниләр чәчеп бетергән.

— Тракторынның маркасы нинди? — дип кызыксына язучылар.

— Дүрт тәгәрмәчле инде, — ди ул, сорауны бик өнәмичә.

— Ә маркасы нинди?

— Арткы тәгәрмәчләре зуррак, алгылары бәләкәйрәк.

— Юк, маркасы нинди дим?

— Маркасы дип... Пыт-пыт итеп эшли инде!..

## Васыять

Шигъριяттә жыйнак булыгыз,
Көнкүрештә тыйнак булыгыз!

**Туфан МИҢНУЛЛИН,**
*СССР Язучылар берлеге әгъзасы, СССР халык депутаты,*
*СССР Югары Советы әгъзасы, ТАССР Югары Советы депутаты,*
*КПСС члены, СССР һәм РСФСР Язучылар берлеге идарәсе секретаре,*
*КПСС өлкә комитеты әгъзасы, Азия һәм Африка илләре комитеты әгъзасы,*
*Иделне саклау җәмгыяте әгъзасы, «Современник» һәм Татарстан*
*китап нәшриятларының редсовет әгъзасы, «Казан утлары» журналының*
*редколлегия әгъзасы, «Идел» журналына фатиха бирүче,*
*Татар Дәүләт академия театрының худсовет әгъзасы,*
*ТАССРның Культура фонды әгъзасы, Почёт Билгесе ордены кавалеры,*
*РСФСРның К.Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты,*
*ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты,*
*Республика комсомолының М.Җәлил исемендәге премия лауреаты,*
*РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның атказанган*
*сәнгать эшлеклесе, ТАССР Министрлар советының Почёт*
*грамотасы белән бүләкләнгән, элекке ДОСААФ члены,*
*элекке пионер, хәзерге персональ пенсионер...*

***Искәрмә.***

*Бу ике юллык шигырь, чынлап та, Туфан аганыкы. Ә инде автор исеме астына ул башкарырга тиешле җәмәгать эшләрен санап төшү — мәзәк табасы килүдән. Монда бар да дөрес. Буталып, хаталанып бетмәс өчен, аны Туфан аганың үзеннән язд ыртып китерттем. Илле яшьлегенә багышлап чыккан нәни генә китапта басылганнан соң ул аны, беренче кат күргәндәй, көлә-көлә укып чыкты да:*

*— Бер кешегә шушы кадәр җәмәгать эшен тапшыралар димени! Җүләр илдә яшибез бит, әй! — дип куйды.*

## Безнең хакта

Беркөн килеп, каһкаһәләп көләр Вакыт:
Боларнынмы бөек булу исәпләре?!.
Туфан, уйнап, робагыйлар язган чорда
Йөргән күпме шагыйрь кисәкләре.

## Матурлыкка караш

— Хатын, тынла әле! Туфан агабыз Миннуллин чибәр хатын-кызга карата менә ничек оста килештереп әйткән:

*Язмыш сине көнче ирдән саклый күрсен –*
*Матурлыгың көн дә тотып кыйный торган, –*

дигән. Шәп бит! Карап-карап торам да... Сине дә бит, хатын, айга бер тәпәләп торырга була, ә!

— И-ии, картым, хет атнага — бер, дисәң, кулын корыр идеме?!.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

### ТР ПРЕЗИДЕНТЫН САЙЛАУ

Рөстәм Миңнеханов Татарстан Президенты вазифасына кандидатлар арасыннан беренче булып республиканың Үзәк сайлау комиссиясенә муниципаль депутатларның имзаларын тапшырды һәм Федерация Советына кандидатлар исемлеген тәкъдим итте.

Муниципаль берәмлекләрнең 400дән артык депутаты республика лидеры Рөстәм Миңнеханов өчен тавыш биргән. Булачак сайлауда республика Президенты вазифасына аның кандидатурасын күтәреп алучылар арасында Татарстанның барлык 43 район һәм ике шәһәр җирлекләре вәкилләре бар. Депутатлар Татарстан Президенты вазифасына дәгъва кылучы кандидатларның берсе өчен генә тавыш бирә алды. «Муниципаль фильтр» аша узмаган кандидатлар сайлау алды «узыш»ыннан төшеп кала.

Рөстәм Миңнеханов Татарстаннан Федерация Советына өч кандидаттан торган исемлек тәкъдим итте: Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык төлек министры Марат Әхмәтов, хәзерге сенатор Сергей Батин һәм РФ Президенты каршында эчке сәясәт идарәсе экс-начальнигы Олег Морозов.

### ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫ

Казанда спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты булды. Анда 190 илдән 2500гә якын спортчы катнашты. Чемпионатны ачу тантанасында РФ Президенты Владимир Путин чыгыш ясады. Ул бу вакыйгага әзерлекнең югары дәрәҗәдә булуын билгеләп үтте һәм ТР Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнехановка рәхмәт белдерде.

### ФЕСТИВАЛЬ

Мәскәүдә «Россия китаплары» фестивале булды. Анда республикабыз нәшриятлары, шул исәптән Татарстан китап нәшрияты да катнашты. ТР нәшриятлары стендында барлыгы 1150 китап тәкъдим ителде. Узган ел республикабызда 1,5 мең төрле китап басылган.

Фестивальдә РФ Президенты Владимир Путин да катнашты. Ул Татарстан китап нәшрияты эшчәнлеге белән дә кызыксынды. Нәшрият директоры Илдар Сәгъдәтшин аны үзләрендә соңгы вакытта басылып чыккан китаплар белән таныштырды. Олуг кунакка Габдулла Тукайның 2014 елда 15 телдә басылып чыккан, Россиянең иң яхшы 100 китабы исемлегенә кертелгән «Шүрәле» китабын бүләк итте.

### XV ФЕДЕРАЛЬ САБАНТУЙ

Красноярск шәһәрендә XV федераль Сабантуй булып узды. Бәйрәмгә Россиянең 36 төбәгеннән татар диаспорасы вәкилләре, Татарстаннан 500 кешелек иҗади делегация килде. Тамашачылар милли көрәш, ат чабышлары, спорт ярышлары, уеннар, Татарстан сәнгать осталары концертын карап хозурланды. Көрәш финалында Марий Элдан Муса Галләмов, Новосибирск егете Мансур Галиевне җиңеп, Сабантуйның абсолют батыры булды. Аңа «Фольксваген» автомобиле бирелде.

Федераль Сабантуйда ТР Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов катнашты. «Бу бәйрәмнең монда кебек гаять киң колач белән үткәрелгәне юк иде әле», – диде ул һәм Красноярск крае губернаторы Виктор Толоконскийга рәхмәт әйтте.

XVI федераль Сабантуй Түбән Новгородта булачак.

### «ФӘНСАР» ҮЗӘГЕ

Татарстанның ел саен «Сәләт» балалар, яшүсмерләр хәрәкәтендә катнашучылар ял итә торган Биләр шәһәрчегендә «Фәнсар» дип исемләнгән фәнни-белем үзәге ачылды. Бу үзәк мәктәп укучылары, студентлар өчен гуманитар, табигый фәннәрне, математика, информатика һәм IT-технологияләрне өйрәнү урыны булачак. Әлеге кече академияне ачу тантанасында Татарстан Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Ул лагерь территориясенең «Уңайлы мохит» программасы нигезендә инвалид балалар өчен дә көйләнгән булуын югары бәяләде, «Фәнсар» үзәгенең квалификацияле педагоглар, балалар бакчалары тәрбиячеләре, укытучылар хәзерләү урыны була алуын да искәртте. «Сәләт»тә кечкенә балаларны татар теленә өйрәтү проекты да эшли.

Лагерьны ачу тантанасында Биләр

шәһәренең «Фәнсар» үзәгенең татарстанлылар өчен генә түгел, ә барлык Россия һәм чит ил вәкилләренә дә хезмәт күрсәтүгә исәп тотып ачылуы искәртелде.

### ИФТАР МӘҖЛЕСЕ

Рамазан аенда мөселманнар өчен изге җомга көнне «Казан-Арена» стадионында республикакүләм ифтар мәҗлесе узды. Бу кичтә стадионда Коръән аятьләре яңгырады, Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин ураза хикмәтләре, ифтар йолалары турында бәян кылды, Кол Шәриф җәмигъ мәчете имамы Илфар хәзрәт Хәсәнов эчтәлекле вәгазь сөйләде.

Стадионның икенче катында ачык һавада ахшам намазы укыдылар. Намазга баскан ир-егетләрнең алдагы рәтендә Татарстан Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миннеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Россия мөселманнары Үзәк диния нәзарәте рәисе, югары мөфти, Шәйхелислам Тәлгать хәзрәт Таҗетдин. Дагыстан, Чечен республикаларыннан, Мәскәү һәм Россиянең кайбер башка төбәкләреннән дини даирә вәкилләре, җәмәгать эшлеклеләре бар иде. Рамазанның ураза тоту гына түгел, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек ае да булуын хәтердә тотып, балалар йортында тәрбияләнүчеләр, физик мөмкинлеге чикле кешеләр, күп балалы гаиләләр ифтар мәҗлесенә махсус чакырылды.

ТР Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миннеханов Кол Шәриф мәчетендә Гает намазында да булды.

### ФОРУМ

Казанда «Милли тормыш һәм дин» VI Бөтенроссия дин әһелләре форумы булды. Ана Россиянең 63 төбәгеннән 900дән артык делегат чакырылган иде. Форумда ТР Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миннеханов катнашты. Әлеге чарада дин әһелләре алдында ислам динен тарату белән бергә татар милләтен саклау, үстерү бурычы куелды.

### МӨСЕЛМАН КИНОФЕСТИВАЛЕ

XI Казан халыкара мөселман кинофестивалендә катнашу теләген белдергән 52 илдән 700 гариза килгән. Бу — узган ел белән чагыштырганда, 200 кинофильмга күбрәк. Конкурска төрле номинацияләрдә көч сынашыр өчен 50 кинофильм сайлап алыначак. Татарстан быел барлык номинацияләрдә дә иҗат җимешен тәкъдим итәчәк. Фестиваль 5-11 сентябрьдә узар дип көтелә.

### АЗНАКАЙДА ТУКАЙГАҺӘЙКӘЛ

Азнакайда Габдулла Тукайга һәйкәл ачылды. Бөек шагыйребез олуг мирасын яд итүнең матур үрнәге булып бу төбәктә дә үз урынын алды. Ул көнне «Татмедиа» филиалы бинасында 85 еллык тарихы булган «Маяк» газетасының (баш мөхәррире Гөлгенә Кәримова) музеен ачу тантанасы да булды. Бу чараларда ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, Азнакай муниципаль районы башлыгы Марсель Шәйдуллин, «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Фәрит Шаһиахмәтов, аның урынбасары Сөмбел Таишева, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Вахит Имамов, дистәдән артык район газеталары мөхәррирләре, шушы төбәктә туып үскән каләм ияләре катнашты. Кунаклар Уразай авылы янәшәсендәге Чатыртау (киләчәктә бу тауны республикабызның табигый һәйкаленә әверелдерү күздә тотыла) түбәсенә сәяхәт кылды.

### ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы **Хәсәнов Әнәс Хәсән улына** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге, татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен профессиональ язучы **Нуруллин Вакыйф Нурулла улына** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республикада массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте генераль директорының басма массакүләм мәгълүмат чаралары буенча урынбасары **Әдиятова Әлфия Нәби кызына** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

***

Сынлы сәнгатьне үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен «Россия рәссамнар берлеге» Бөтенроссия иҗат иҗтимагый оешмасының Чаллы оешмасы, Татарстан Рәссамнар һәм Язучылар берлекләре әгъзасы **Латыйпов Хәмит Нәҗип улына** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«25 лет новой государственности Республики Татарстан»: «За судьбу Республики отвечаем мы — это и есть самостоятельность» (интервью И.ИБРАГИМОВА с Председателем Государственного Совета РТ Ф.МУХАМЕТШИНЫМ); И.ТАГИРОВ. «От автономии к суверенитету»;
«80 лет со дня рождения Туфана Миннуллина»: М.ШАЙМИЕВ. «Всё более горжусь и восхищаюсь им».
«Проза и поэзия»: стихотворения, посвящённые Т.Миннуллину Г.МУРАТА, Ш.ГАЛИЕВА, М.АГЛЯМОВА, Г.РАХИМА, Р.МИННУЛЛИНА, А.ЮНУСОВОЙ, Ф.ТАРХАНОВОЙ, Л.ЛЕРОНА, Р.РАХМАН, Л.ШАЕХА, Ф.ГИЛЯЗОВА; Р.ХАННАНОВ. «Из архива Т.Миннуллина»; повесть Т.МИННУЛЛИНА «Зимой и летом письмо с приветом».
«100-я страница»: Т.МИННУЛЛИН. Этический кодекс татарского народа.
«Драматургия»: комедии Т.МИННУЛЛИНА «Долой мужчин, да здравствуют женщины!», «Го-о-о-ол!», «Нужник».
«Воспоминания»: статьи П.ЛОХАНОВА, Ф.БИКЧАНТАЕВА, Р.АЮПОВА, Ф.ИБРАГИМОВА, Р.ГАЛИЕВА, О.ХАНОВА, Л.МИНАЕВОЙ, А.ЗАРИПОВА, Р.НИЗАМИ, А.МИННУЛЛИНОЙ-ЮНУСОВОЙ, Ф.МУСЛИМОВОЙ;
письма Т.МИННУЛЛИНА заключённым.
«Публицистика»: статьи Р.ВАЛИЕВА, И.ИБРАГИМОВА, Р.САГДИ; интервью Н.ШАЙДУЛЛИНОЙ с Т.МИННУЛЛИНЫМ.
«Литературная критика»: статьи М.ХАБУТДИНОВОЙ «Секреты «Сна»; М.АРСЛАНОВА «Драматургия Туфана Миннуллина».
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Государственный герб Республики Татарстан. Авторы: учёный Назим Ханзафаров (идея) и художник-монументалист Риф Фахрутдинов; народный писатель РТ Туфан Миннуллин.

# IN THIS ISSUE:

«25 years of the new statehood of the Republic of Tatarstan»: «We are responsible for the fate of the Republic, that is independence» (interview by I.IBRAGIMOV with the Chairman of the State Council of the Republic of Tatarstan F.MUKHAMETSHIN); I.TAGIROV. From autonomy to sovereignty;
«Prose and poetry»: poems dedicated to T.Minnullin by G.MURAT, S.GALIEV, M.AGLYAMOV, G.RAHIM, R.MINNULLIN, A.YUNYSOVA, F.TARHANOVA, L.LERON, R.RAHMAN, L.SHAEH, F.GILYAZOV; R.KHANNANOV. «From archives of T.Minnullin»; story by T.MINNULLIN «Letter with greetings in winter and summer».
«100th page»: T.MINNULLIN. Code of ethics of the Tatar people.
«Drama»: comedies by T.MINNULLIN «Down with men, long live women!», «G-o-a-l!», «Outhouse».
«Memories»: articles by P.LOHANOV, F.BIKCHENTAEV, R.AYUPOV, F.IBRAGIMOV, R.GALIEV, O.KHANOV, L.MINAEVA, A.ZARIPOV, R.NIZAMI, A.MINNULLINA-YUNUSOVA, F.MUSLIMOVA;
letters by T.MINNULLIN to prisoners.
«Publicism»: M.SHAYMIEV. Increasingly proud of and admire them; articles by R.VALIEV, I.IBRAGIMOV, R.SAGDI; interview by N.SHAYDULLINA with T.MINNULLIN.
«Literary criticism»: articles by M.HABUTDINOVA «Secrets of «Sleep»; M.ARSLANOV «Playwright by Tufan Minnullin».
«Pages of humor»: rubric is led by M.GALIEV.
«From photo archives of magazine: rubric is led by R.FAYZULLIN.
Diary of social-cultural life.
On our covers: State emblem of the Republic of Tatarstan. Authors: scientist Nazim Khanzafarov (idea) and muralist Rif Fakhrutdinov; national writer of the Republic of Tatarstan Tufan Minnullin.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Татарстан Республикасының Дәүләт Гербы.
*Авторлары: Назыйм Ханзафаров (идея) һәм рәссам-монументалист Риф Фәхретдинов.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Татарстан Республикасының халык язучысы Туфан Миңнуллин.

# ӘДИПНЕҢ ГАИЛӘ АЛЬБОМЫННАН






КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)